ISSN 0206-4189
Индекс 73210
12+

# Казан утлары

2.2015



№2 (1108) 2015

# БУ САНДА:



**Гәрәй РӘХИМ**
**«Халкыбыз горурлыгы»**

«Үзенең бөтен иҗаты, табигать биргән гаять үзенчәлекле, моңлы, бик тә милли, үтемле, җанга якын тавышы белән бергә Илһам Шакиров халкыбызның бөек һәм катлаулы тарихы, бу өлкәдәге фәнни эзләнүләр белән кызыксынучы, сәнгатебезнең һәр тармагы — әдәбияты, театры, сынлы сәнгате, архитектурасы, классик музыкасы белән һәрдаим кызыксынучы, ул гына да түгел, шушы өлкәләрне һәм гамәли, һәм фәнни яктан яхшы белүче иҗтимагый шәхес тә».

124

**Әзһәр ШАКИРОВ**
**«Әти»**



«Әти әйтә:
— Мин шахтада сукыр атлар белән эшли идем, — ди.
— Әти, ул сукыр атлар җир астына ничек төшәләр соң? — дип сорыйм.
— Улым, алар башта сукыр булмыйлар, бер-ике ел җир астында эшләгәч кенә сукыраялар.
— Әти, сукырайгач та эшлиләрме?
— Без аларның арбаларына күмер төйибез дә әкрен генә алларыннан җитәкләп барабыз, алар безгә иярә.
Мин исә әлеге сукыр атларны күз алдына китерәм дә, мөлдерәп күз яшьләре килә, еларга ук тотынам».

145

КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Айдар ХӘЛИМ. Паравыз кычкыртты. *Хикәя.* ....3
Рим ИДИЯТУЛЛИН. Җир-туфрагым – җан бизәгем. *Шигырьләр.* ....9
Камил КӘРИМОВ. Тургайлы болытлар. *Роман-элегия.* ....14
Рәниф ШӘРИПОВ. Үз бәясен алсын вакыйга. *Шигырьләр.* ....78
Рәдиф СӘГЪДИ. Мин дә бер татарыңдыр... *Документаль бәян.* ....83
*100нче бит:* Хәнәфи БӘДИГЫЙ. Җәлил энциклопедиясен төзик! ....100

ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘЛӘРДӘ

Ринат БАТТАЛОВ. Иҗау – иҗат мәйданы. ....112
Ибраһим БИЕКТАУЛЫ, Гыймран САФИН, Ринат БАТТАЛ, Әлфирә НИЗАМОВА, Гөлфия ИСХАКОВА шигырьләре. ....114

ИЛЬҺАМ ШАКИРОВКА — 80 ЯШЬ

Гәрәй РӘХИМ. Халкыбыз горурлыгы. ....124
Флюра НИЗАМОВА. Табыну. ....129
Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Алпар. ....135
Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Моң тажы. ....137

ӘЗҺӘР ШАКИРОВКА — 75 ЯШЬ

Әхтәм ЗАРИПОВ. Милләт җанлы артист. ....140
Әзһәр ШАКИРОВ. Әти. ....145

ИГЕЛЕК

Фәнзаман БАТТАЛ. Яхшы гамәл заманы уздымы? ....149

ХӘТЕР

Әлфия ШАМОВА. Сезнең язмыш сугыш уты белән үрелгән. ....162
*Шаян сәхифә.* Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде.* ....174
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. *Сәхифәне Рәйсә МУСАБӘКОВА әзерләде.* ....178

АК ҖИЛКӘН

Раил ГАТАУЛЛИН. Килмә якын. *Шигырьләр.* ....180
Хикәя яза аласызмы? *(Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ, Надия ВӘЛИЕВА хикәяләре).* ....181
«Танымыш» дәресе. ....187

Мәкаль әмәсе. *Сәхифәне Рәфикъ ЮНЫС әзерләде.* ....188
Яңа китаплар. ....189
«Казан утлары» архивыннан. *Сәхифәне Равил ФӘЙЗУЛЛИН әзерләде.* ....122
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

тм
татмедиа

Гамәлгә куючы —
«Татмедиа»
ачык акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*

**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Нурия Беломоина**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир — 222-05-50 (өст. 1618).*
*Җаваплы сәркатип, компьютер үзәге — 222-09-83 (өст. 1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст. 1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст. 1267).*
✆: **Факс** — (843) *222-09-83 (өст. 1612).*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмахананең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.01.2015, график буенча 29.01.2015.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^1/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-214. Тираж 4004.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс: 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2015 ел



Айдар
Хәлим

# ПАРАВЫЗ КЫЧКЫРТТЫ

ХИКӘЯ

*Баласы туган таңда ирен фронтка озаткан Рәфыйга түти Зиннурова истәлегенә*

Башланганына бер ай үткән иде микән әле, сугышның сайрар кошы булган «повесткасы», озын-озак көттермичә, авылда беренчеләрдән булып анын Газинурын эзләп тапты. Син аның туры килүен кара: җомга көнне никах укытып, язылышып, туйлары нәкъ сугыш башланган 22 июнь көнендә булырга тиеш иде бит. Шулай ниятләп куелган диярсең. Фаҗигале хәбәр ике йөрәк бәйрәме өстенә шомлы күләгәсен төшерде, әмма, күптән көтелгән вакыйга булганга, курәсең, үзенең кара паласы белән туй кояшын тулаем каплый алмады. Күпне кичергән халык кайгысын йөзенә чыгармыйча эченә йотарга тырышты. Дөрес, туй алып килә торган гадәти шау-шу бу хәбәрдән шактый сүрәнәя, басыла төшкән, әмма, ничек кенә булмасын, мич башында гөҗләп утырган ачы балның зәһәрен тыяр дәрәҗәдә баса алмаган иде. Үтәсе мәҗлесләр барыбер үткәндәй, теләкләр барыбер әйтелгәндәй, биреләсе бирнә-мәһәре барыбер бирелгәндәй булган иде. Бер-ике көрәгә балдан соң ук кызып алган кода-кодачалар, бер мизгелгә булса да шик-шөбһәләрен оныткандай итеп җырлаштылар, тыпыр-тыпыр биешеп, аяк асларындагы яшь бәбкә үләнен таптый-таптый аны буйга үстергәндәй иттеләр.

Башкалар ничегрәк кичергәндер, кияү кочагына керү шатлыгыннан исергән, моңа кадәр зур юллардан, ил-дөньякүләм тарихи вакыйгалардан читтә, тыныч табигать култыгында үсеп чәчкә аткан гөлниса, өйләнешкәннәренә әле бер ай чамасы гына тулган, кичә генә үсмерлектән чыккан кыз-бала, туй кырандасыннан турыдан-туры тупсадагы биана меңдәренә сикереп төшкән килен-киленчәк, зиһене белән бүген үк, бүген булмаса, иртәгә, шушы тупсадагы мендәрнең табанына нинди энәләр белән кадалачагын да, сугышның нәрсә, нинди икәнлеген дә, киявенең аңа беренчеләрдән булып китүенең шәхсән үзенә нинди дәһшәт, нинди куркыныч белән янаганын да уйлап та, мәгълүм

Айдар ХӘЛИМ (1942) — *шагыйрь, публицист, прозаик; «Гомеремнең ун көне», «Өч аяклы ат», «Татар моңы», «Хунвейбин» һ.б. китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Чаллыда яши.*

жырда жырланганча, йөрәк башкаеннан кан саудырып кичереп тә өлгермәгән яшь йөрәк иде ул безнең Тәнзилә бәгырькәебез.

Авылдан беренче булып сугышка китүчеләр, Газинурны да кертеп, барысы дүртәү иде. Салих. Сабирҗан. Иҗтиһат. Һәм Газинур үзе. Аның Газинуры. Араларыннан Салих белән Газинур гына өйләнеп өлгергән. Салихның өйләнгәненә ике ел. Менә кем бәхетле!.. Бер яшьлек улы бар. Ул-бу була калса, улы бар. Тәнзиләнең биатасы военкоматтан килгән кәгазьне, ялгыш түгелме дигәндәй, өчаякта иген иләгән иләк кебек, кат-кат кояшка кыегайтып, алдын артка, астын-өскә әйләндереп карады да:

— Яшьләрдән башладылар, яшьләрдә тәмамлана, димәк. Алар германны бәрәчәк... — диде. — Безгә килеп җитмәс, Ходай кушса...

Авылдан бишәүләп юлга чыктылар. Әле баласы юклыгын, яңа гына башлы-күзле булуларын хәтердә тотып, авылдан үзләрен бердәнбер озата баручы итеп киленчәк Тәнзиләне алдылар. Тәнзилә моңа шатланып бетә алмады. Әмма авылда хушлашу минутлары аның өчен шулкадәр газаплы булыр дип уйламаган иде. Дүрт гаиләнең дүрт ихатасыннан чыкканда — дүрт елаш. Авыл очыннан чыкканда — бишенче елаш. Кемдер туган тупсасы каршында бер генә үксесә, Тәнзилә башкалар өчен биш тапкыр үкседе. Гүя болар барысы да бер озын төш иде. Нинди сугыш? Нигә китәләр? Ышанып елыймы, ышанмыйчамы? Шунысы сәер: тоюынча, нәрсә булганын һәм булачагын аешып та өлгермәгән, әлегә чыркылдык кызлар шикелле, хыял белән чынбарлык, әкият белән хаклык, гөман белән томан арасында яшәгән Тәнзиләнең гүя бу кайгыга катнашы юк кебек иде. Катнашы булган хәлдә дә, алар әлегә алда, киләчәктә генә булачаклар кебек тоела иде. Гүя бу елашлар эченә әлегә ул үзе дә һәм Газинуры да керми тора, болар барысы да башкаларны кызганып кына өзлегүләре иде. Нинди кайгы ди?! Газинуры янында бит. Тагын ни кирәк? Җитмәсә, әнә ул, аның тегермән ташы кебек киң күкрәкле кияве, арба үрәчәсенә аякларын чалыштырып утырган да, тальянының күрекләрен тартып өзәрдәй булып, җыр сузып маташа. Аның җырларының сүзләре гел яңа, гел кеше ишетмәгәнчә була. Бу юлы да шулай килеп чыкты:

Безнең дә ихата арты озын кура,
Канат очы талган кош куна.
Беребез генә ләй анда, лай, беребез монда, лай,
Җәйгән җылы урыннар буш куна...
Аһ, җанашым, сары ла сандугач!
Сагынып кайта алсам, ишегең ач!..

И-и-и, нигә болай сөйли, нигә болай җырлый бу Газинур? Әйтерсең лә мәңгегә китә!.. Җәйгән җылы урыннар сине көтәр, синнән башка аңа беркем дә үрли алмас, җаным!.. Кайт кына!.. Хәер, кайтмый кая барсын ди ул? Озак тормас, урап та кайтыр һәм алар Газинур белән башланып өлгермәстән өзелгән тормышларын үкчәгә-үкчә янадан башлап, туган йорт тупсасына бер-бер артлы тупылдатып бәбиләр төшерерләр. Юк, беркем беркая китми бүген. Мөмкинме? Әнә, бодай башаклары инде өченче буынга сикергән, әнә, күктән якты кояшнын бар дөньяга алтын балавыздай нурлары эреп ага. Әнә, янәшәдән Мендәрле Кул чишмәсенең бормалы агымы, кызлар толымы кебек кояшта ялтырап, аларны озата килә... Ничек кенәләр ташлап китәрсең? Тәнзилә күзләренең сулмас нуры белән Газинурына сокланып карый, кешеләр бар дип тормыйча, аны шашып кочаклыйсы, үбәсе килә башлый. Шуны гына сизгәндәй, Газинур:

— Жырла, Тәнзилә! — ди.

— Мин жырлый белмим! — ди Тәнзилә. — Тавык та миннән матуррак жырлый...

— Жырлый белмәсәң дә жырла, тавыгым. Боерам!.. Беләсен, мин бит китәм!..

— Беләм, китмисең! — ди елмаеп Тәнзилә. — Без бергәбез!..

«Боерам!..» Нинди гайрәтле сүз. Газинуры «Мин боерам», дип «минләп» вакланмый. «Боерам» гына, ди. Аны ул ярата, димәк. Ир-атның шулай гайрәтле сөйләшүен Тәнзилә дә үз күрә... Хәер, ир-атның күз карашы да боеру инде ул. Әгәр син үзең яратсаң. Яратмасаң, боерыкны үтәү газап...

Ә менә кучерләре Нәгыйм абзыйның улы Төхфәт чабып салган хуш исле үлән өстендә Миякәгә бару сабантуйга бару кебек гади бер сәяхәт түгел, ә чынлап та авылдаш егетләрнең ниндидер жан өшеткеч, котсыз военкоматлар аша каядыр китүләре икән шул. Әмма ул үзе Газинурының каядыр китеп барачагына һич кенә дә ышанмый. Ышанасы килмәүдән түгел, чынлап ышанмый. Кавышып та өлгермәгән ике яшь йөрәкне ничек аерырга мөмкин? Мәгънәсезлек бит бу. Сугыш дигәч тә. Шулкадәр дә мәгънәсез түгелдер бит бу военкомат дигәннәре?

Ә военкоматта бернинди дә мәгънә эзләп маташмадылар. Жегетләрне анадан-тума чишендереп тикшерделәр. Барысы да сау-сәламәт булып чыкты. Тулышкан бодай бөртеге кебек эркелешеп торалар. Хәрефеннән хәрефенәчә жентекләп, хәрби билет, юллык документларын тутырдылар. Нигә бу? Әйтерсең, югала торган кешеләр. Бар, югалтырсың мондый дастуен ир-жегетне. Үзләре белән алган атналык ризыкны — кипкән сохари, кем белә, бәлки, соңгы хөрмәтебездер дип, аерылу хакына куначадан тотып алынган тавыкның арык билдәмәсе, чүпрәккә төрелгән савытта сары май, былтыргы как, табада пешкән төче күмәч кебек, шуларына өстәп, кем нәрсә хәстәрли алган, шундый азык-төлекне, хат язарлык кәгазен, энәсеннән жебенә кадәр тикшереп, яңадан юл капчыкларына салдырдылар.Тәнзилә алма кебек кызарынды: ул, әле хатын булып өлгермәгән килендәк, тәжрибәсезлеге аркасында, киявенең юл капчыгына бирнә кульяулыкларын азрак салган иде. Нигә күбрәк итмәгән? Ah!.. Әгәр Газинуры боерган булса, Тәнзилә сөйгәне хакына үзе чиккән кульяулыкларын гына түгел, саф йөрәген ак киледә төеп тә салган булыр иде ул капчыкка...

Һәм иң көтелмәгәне — аларга үз атларында Әкчин стансасына юлга чыгарга һәм мотлак көндезге сәгать дүрткә барып житәргә куштылар. Районнан барлык никрутлар шунда жыела, имеш. Тәнзилә ике ут арасында калды: Әкчингә үк озата бару уенда булмаса да, Газинурын, үзе килгән ат-арбасын ташлап, авылына берьялгызы ничек кайтып күренсен ди? Район үзәгеннән кайтканда, егерме чакрымлык урман-тау арасын берүзе ничек үтсен ди? Әнә, аңа Газинуры да кайт диярга ашыкмый. Димәк, баруын тели. Бәлки, бергәләп кире дә кайтырлар әле. Сугыш кадәр сугышның аның бер Газинуры, шушы дүрт авыл егетенә генә калган көне юктыр. Һәм ул ире хакына башкалар турында уйлап, башкалар хакына үзе хакында уйламыйча, арба урәчәсендә, кем әйтмешли, иренең тезләре өстендә диярлек ирәеп-иркәләнеп, Әкчин тарафына — утыз биш чакрымлык сәфәргә чыкты. Юл да, сәфәр дә, сәяхәт тә!.. Киявең янәшәсендә, рәхәттә!..

Таш юл тузаныннан туналып, шактый арып һәм таушалып, алар нәкъ кушылган көндезге дүрткә Әкчин вокзалына килеп життеләр. Сандык кебек кискен туры почмаклы, төрмә кебек килбәтсез-тәрәзәсез, ике яктан керешле-чыгышлы соры вокзал бинасының алды һәм арты сипкән борчактай

борчулы сибелгән халык, йөзләре кайгылы чалшайган, чәчләре-башлары тузгыган хатын-кыз, киерелгән кәефле, ярымкызмача ир-ат, атлы-колынлы арбалар, тегендә-монда чабышкан малай-шалайлар, зәңгәр түбәле, кызыл йөзле милитсия, йозак шикелле үзләренә бикләнгән хәрбиләр белән кайный иде. Егетләргә ерак юлдан оеган аякларын яздырып алырга да бирмәделәр. Көттермичә яңгыраган катгый команда аларны перронга тезелә башлаган никрутлар ташкынына китереп кертте. Тәнзилә киявенең үзеннән аерылып шушы ташкынга өерелеп кушылганын сизми дә калды. Ул Газинурын барыбер дә күзеннән язлыктырмаска тырышты. Аның башына кигән жинел кәпәче астыннан ургып чыккан дулкын чәч бөжраларын, туры текә борынын, хәтта каш өстендәге кара төрткедәй миненә кадәр якын, сөйкемле һәм кабатланмас чырае бәрәкәтен ул бу ташкыннан югалтты дигәндә эзләп таба иде. Йөзләгән кеше кайнашында ул бары тик шул бөдрә чәчне, шул текә борынны, каш өстендәге кара төрткене күзәтте һәм күзеннән ычкындырмады. Алар барысы да гамьсез яшьлегенең бары тик «шул егетне генә» үз итүенең сөйдергеч сәбәпләре иде. «Бу кадәр байлыкны ялгызым күтәрә алырмынмы?» — дип борчыла иде киленчәк.

Һәм ул шушы сөйдергеч сәбәпләрне вокзал перронында янадан кичерде. Минут чиксез озак, сәгать чиктән тыш кыска иде. Бу мизгелнең шатлыгын, бергәлек рәхәтен кая куярга белмичә, ул гүя беренче тапкыр күккә карады. Июль күге зәңгәр һәм ач томшыклы зур кошлар белән мыжгып торгандай күренде. Ул, куркып һәм каушап, карашын жиргә төшерде. Анда таш перронга таяк булып каткан никрутларның телсез һәм тынсыз рәтләреннән башка бер нәрсә дә юк иде. Алар картайган, карайган, хәтта яктылардан якты Газинурының сөлектәй буе да ничектер имгәнгән һәм кара көйгән булып шәйләнде. Кинәт Тәнзиләнең янәшәсеннән тавыш-тынсыз, пышылдап һәм похылдап ниндидер ялтыр кабыргалы гыйфрит алга таба шуышты. Бу шундый биек, шундый дәү, шундый да пәһлеван нәрсә, гүя ниндидер өреп кабартылган кара конгыз, аның турына житкәч кенә йөрәк ярып кычкыртты. Тәнзилә куркуыннан чүгеп куйды. Гүя аны, шушы камил куркыныч уенчыкны, аның алга-артка йөргәләгән терсәк-пешкәкләрен, кемдер күргәзмә өчен дип еллар буе ясаган, игәгән, бөккән, шомарткан, кара буяу белән буяган, аннан киптереп, шундый ук кара май белән майлаган һәм тагын да күн каеш белән ялтыраткан. Һәм ул кара конгыз Газинурын аңардан аерыр өчен бирегә, Әкчин стансасына сугышның үзеннән чаптырып килеп тә житкән. Ул гыйфритнең үзеннән биек тәгәрмәчләрен, озын куласаларын, тагын да әллә нәрсәләрен юньле-рәтле күреп тә өлгермәде, бу гыйфрит, авыр тын алып, тагын да куркыныч сызгыртты, корсагына бар һаваны суырып алып, күперткәндәй итте дә, гүя кабыргалары белән аның зифа буй-сынын сыдырып узгач кына, авыр көрсенеп, бар тирәне, шул исәптән Тәнзиләне дә, ак томан эченә батырып пышкылдады. Хатын башта айнымый торды. Гүя ул актин-ак кәфенлек эчендә төренеп калды. Паравыз дигәннәре шушы түгелме? Чуен юлыннан илле биш чакрымда туганыннан бүгенгесенә кадәр авылыннан чыкмыйча яшәп, актин-ак сөт, ит-май, табигый үлән тәрбиясендә буй житкереп, үзе дә ак каймакка әйләнгән бу татар-мөселман кызының, унсигез яшенә житеп, паравыз да күргәне юк иде. «Паравыз... паравыз... Сугыш чыкмаган булса... — дигән уйлар узды аның башыннан. — Шушындый тимер юл... шушындый паравызларны кайчан күрер идем әле, рәхмәт төшкере...» Гүя аның тормышыннан сугыш куркынычы киткән, аны кара ялтыр паравыз алыштырган иде. «Газинурыма ... — дип пышылдады ул, — алып килгәне, күрсәткәне өчен рәхмәт, илаһым...» Шушы көтелмәгән кечтеки генә шатлыктан күзенә

яшь бөртеге саркыган иде. Көтмәгәндә янәшәсеннән шакылдау-ухылдау, коргаксыган буш мичкә авазлары чыгарып, авызлары шәрран-яра ачык мал вагоннары тәгәри башлады. Алар гүя Газинур кебек корбаннарны көтә-көтә тутыккан, сугыш кырыннан яныл чыккандай, кызгылт төстә иделәр. Шулчак Тәнзиләнең гәүдәсен кайнар тир басты. Әйтерсең, бүгенге кансыз чынбарлыгы күнелендәге ярымхыялый, балачактай саф тормышын куып житте һәм өстенә басып, сары чебештәй сытып ташлады. Гөман томаннан аерылды. Тукта, син нәрсә сөйлисең? Паравызны күрсәткән өчен кемгә рәхмәт әйтәсең? Газинурын алып киткән сугышкамы?! Сугышны чыгаручыларгамы? Шул сугыш чыгу аркасында аны Әкчингә алып килергә мәжбүр булган кияве Газинургамы? Әле кайда соң ул?! Үзен чорнап алган парнын ак кәфенлеген ертып, күз нурлары белән никрутлар ташкынын капшады. Газинурлары күренми, алар ак томан эчендә оеган иде.

Кинәт боерык яңгырады:

—По ва-го-на-а-ам!..

Ул баласын югалткан болан сыман, инде сыегайган парнын юеш тукымалары аша алга ыргылды. Томан ертыклары эченнән манзара ачылды: никрутларны вагоннарга утырталар икән!.. Газинуры кайда? Анын Газинуры? Әллә ул чынлап та китәме, Ходаем? Аны хәзер салкын тир басты. Мона кадәр ниндидер сугыш аркасында бер парның икегә аерылуына ышанмаган, мондый хәлгә кеше ышанмаслык әкият кенә итеп караган унсигез яшьлек киленчәкнен йөрәгеннән үткән бу уктай очлы сораудан кап-кара чәчләре ак көмеш булып агарды. Ул тәмам айныды. Башыннан яулыгы шуып төште. Аһ!.. Ул, тезләренең хәле бетеп, вагоннан вагонга йөгерде. Кинәт алдагы кызылдан көйгән вагон каршында — гүя туган авылы шәйләнде. Таныш йөзләр!.. Исемлек буенча... алып китәләр түгелме? Кайтарганда да исемлек буенча алып кайтырлармы? Үз исем-атын ишеткән һәр никрут вагонның мал абзары кебек ыржайган авызына ыргып керә дә карангылыкка чума, ыргып керә дә карангылыкка чума.

— Хәмәтнуров!..

— Мин!

Әйе, аныкылар! Әнә, Салих карангыга сикерде! Хуш, Салих! Ул авылнын иң яхшы чалгычысы иде.

— Зөлкарнәев!

— Мин!

Инде мал абзарынын карангы карынына Сабиржан чумды. Ул авылнын иң көчле көрәшчесе иде. Аннан жирдән югарыдагы чокырга Ижтиһат сикерде. Ул авылнын иң унган тракторчысы иде.

— Сибгатуллин!..

— Мин!..

Бу анын — аныкы, аныкы гына булган Газинуры иде. Авылнын атаклы гармунчысы, анын сөйгәне иде.

— Газину-у-ур!.. Минле-гази-ну-у-ур!..

— Ху-уш, ...Зилә-ә-ә!

Ишетте! Күрде!.. Ул шундый да очлы күз. Аеруча сагынган чакларында, ана, кыскартып, Зилә генә, ди.

Якты күбәләк кебек каш өстендәге миннәреннән күлмәк жиннәренә кадәр яктырып, кин, яссы маңгаеннан очкынлы нурлар чәчрәтеп, вагон эчендәге кара базга инде анын нурлы Газинуры томырылды...

Ишекләр шартлап ябылды. Состав башыннан йөрәкләрне өзеп, сузып һәм адәм акылын аяк табаннарына кадәр тетрәндереп, аерылуларның беркайчан да кавышуы булмаячагын раслагандай итеп, теге паравыз кычкыртты.

Тәгәрмәчләр сызлана-сызлана хәрәкәткә килде. Әүвәлдә алар авырлык белән пыш-пыш сөйрәлеп, Тәнзиләнең колак төбендә тукылдарга да тотындылар. Тукта, Газинуры әллә чынлап та киттеме? Китү дигән нәрсә шушындый була микәнни? Әллә чынлап та берьялгызы калды инде?! Хатынкайның янәшәсеннән азагы-чиге булмаган кызыл тукыма булып тоташып, вагоннар тәгәрәде. Тәнзилә унга карады. Анда бары тик өзлеккән паравыз тавышлары гына тирбәлә иде. Алардан да үзәк өзгеч, сагышлы, үкенечле тавыш юк икән дөньяда. Тәнзилә сулга карады. Анда да инде кырылган калай сыман паравыз тавышлары гына сулкылдый иде. Кешелекнең, мәңге язылып та, язылып бетә алмаячак китабы икән ул паравыз кычкыртулары.

Янында Газинуры да, теге кара конгызга охшаган гыйфрит тә юк иде. Ул, җәясеннән ычкынган ук кебек, янәшәсендә чапкан состав белән ярышырга теләгәндәй, алга ташланды. Тәнзилә инде баласын гына түгел, баласының атасын — парын югалткан боланга әверелгән иде. Аны тотып тыю мөмкин түгел иде. Ул чаба — эшелон йөгерә, ул йөгерә — эшелон чаба иде. Менә-менә ул паравызны куып җитәчәк!.. Әнә, ул аны күрде. Ул аны хәзер кочагына суырып алачак һәм сугышка җибәрмәячәк! Паравыз аңа хәзер кара башлы тирес корты булып күренде. Кинәт озын торбасыннан юлына көлтә-көлтә очкыннар коелды. Бу мизгелдә елгалар агудан, җил исүдән туктаган иде. Әмма дәүләт көче белән көчәйтелгән пар машинасының көче авылның җәяүле кызыннан көчлерәк иде. Тук-тук-тук!.. Тик-тик-тик!.. Так-так-так!.. Соңгы вагоннар!.. Һәм — иң соңгы вагон! Тапшырылмаган кульяулык!.. Тәнзилә бу авызы ачык мал вагонына тагылырга һәм үзе дә сөйгәне белән фронтка китәргә теләгәндәй, ачык кочагы белән алга томырылды...

Әмма ул буферларга чытырдатып ябешә дә, вагоннарны эләктерә дә алмады. Куллары буш һавада эленеп калды.

Һәм хатын, йөрәк ярсуын тыя алмыйча, киләчәккә мәңге дә барып җитмәячәк авазын салды:

— Га-зи... ну-у-ур... лы-ы-ым!..

Паравыз, Әкчин белән хушлашып, соңгы тапкыр кычкыртты.

Тәнзилә йөрәген тотып перронга ауды...

* * *

...Алар беркайчан да күрешмәячәк.

Балага узарга да өлгермичә, унсигез яшендә тол калган Тәнзилә, Газинурын каршыларга дип, гомере буе шушы кызыл состав артыннан йөгерәчәк. Киявенә тугрылык саклап, килен булып төшкән тупсасында картаячак һәм туксан ике яшендә дөнья куячак.

***Хөрмәтле укучыларыбыз!***

*1 февральдән элемтә бүлекләре 2015 елның икенче яртыеллыгы өчен язылу кампаниясен башлап җибәрде. Яраткан журналыбыз «Казан утлары»на элекке бәядән язылып калырга ашыгыгыз!*

***Редакция.***



Рим
Идиятуллин

# ҖИР–ТУФРАГЫМ — ҖАН БИЗӘГЕМ

## Нух көймәсе

...Таң туганда көймә ярда иде.
Бишек сыман иркә тирбәлә;
Нух тир сыга, йөзе көйгән балта
Бил яздыра чинар түмәрдә.

Житез жилләр, дүрт тарафка исеп,
Хәйран калгыч хәбәр таратты:
«Гарәфәт тау кадәресе көймә
Туфан кичәрләргә яраклы!»

Тын алгачтын чак-чак, Нух пәйгамбәр,
Чүгеп тезен бәби үләнгә,
Чөйде башын Күккә: «Ий, Илаһым,
Ярлыкачы азгын кавемемне,
Дучар итмә хурлы үлемгә.

Житсен догам: тайпылса да читкә,
Туры юлга кайтыр өммәтем;
Газап өстәп сына, соң кат сына
Син яралткан адәм куәтен».

Калыкканда жирдән, сыйпый-сыйпый
Янчетелгән үлән сабагын,
Ишетте ул көчле күкрәү булып
Янгыраган Илаһ авазын:

«Манмадым Мин сезне ак, карага,
Бүлмәдем Мин байга, ярлыга;
Кин дөньяга сыймый башласагыз,
Батырырмын жирне дәрьяга, —
Дип әйттемме?! Әйттем, кисәттем!

---

Рим ИДИЯТУЛЛИН (1940) – *Башкортстанда яшәп иҗат итүче татар шагыйре; татар һәм башкорт телләрендә дөнья күргән берничә китап авторы. Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Һ.Такташ исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Башкортстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре.*

Санламыйсыз керсез җан сихәтен,
Өстен күреп көр тән ләззәтен;
Хәрәм аштан тамагыгыз туймас,
Су эчендә сусыныгыз канмас, —
Димәдемме?! Дидем, кисәттем!

Газап юлы озак. Һәр теректән
Ал да бер пар, ике җенестән,
Кузгал! Котылсагыз аман, соңра
Җәннәттәге татлы җимештән
Авыз иттерермен. Эчтем антым
Җилкәненә тулар җил белән!..»

...Ялт тутырды ярны киек-җанвар,
Хайван-ерткыч, сансыз кош-кортлар,
Килгән мискин төстә кичәгенәк
Нухтан көлгән карагруһлар.

Көймә авызында Хак илчесе,
Җилфердәтеп яшькелт күлмәген,
Салды аваз: «Яшәү — Күккә тансык,
Кабул кылдык Раббы бүләген!»

Фәрештәләр шаһит: парлы терек
Узды таптап, тешләп бер-берсен,
Хәтерләтеп гүя титаннарның
Олимп тавындагы көрәшен.

И-һи,
Нинди гыйбрәт булмас, моңа тиклем
Күрелмәгән мәхшәр мәлендә:
Чат ябышып ишәк коерыгына,
Керде посып иблис мәлгунь дә.

...Таулар купты капылт, ярылды җир,
Ай ватылды, кояш йомылды,
Дәрьяга соң көймә — бер йомычка,
Шашкын давыл ярдан йолкып аны
Ажгыр дулкыннарга томырды.

Сүнде вакыт, үлде, ак дөньяның
Калмагандыр бөртек бер коты;
Кайда көймә, әллә күккә ашты,
Әллә микән төпсез су йотты?..

...Кем ышанмас, инсез-тинсез күктә
Туфаннарны җиңәр көч барга:
Таң туганда, тетек җилкән болгап,
Баш терәде көймә буш ярга.

Сагынычлы җирдә һәммә терек
Тәмләп капты ләмен, көлен дә;
Җәберсенде ишәк, төртеп аны,
Ыргып төшкән иблис мәлгуньгә...

*P.S.*
Тәмам сукыр гавәм, күзалламый
Жирне янә туфан басасын;
Тик кемнәр соң төзер Нух көймәсен?!
Йа, Илаһым!
Атайларның гыйбад оныклары
Сатып эчте соңгы балтасын.

Тотып Коръән, нигә фал ачарга?
Алдагысы безнең ап-анык:
Шашып чаба халык, туш уйнатып,
Көтә ярда тишек «Титаник»...

## Кайту

Жен-пәриләрдән шүрләдек,
Шүрәле килеп чыгарлык
Карурман юк килеш тә;
Су кердек сулыш капканчы,
Чапай бер кул белән йөзеп
Ярга житәр инештә.

Малай чакның коргаксыган
Эзләрен хәтергә эләм,
Кай тарафка баксам да;
Тик кошлар мине танымас,
Жаннарны өзеп сайрамас,
Тугандашлар булсак та.

Зәңгәр күк чүт-чүт карайган,
Ак болыт шактый картайган, —
Битләре шау жыерчык;
Толымына тасма үреп,
Мине ябык малай күреп
Йөргән кызый — шыр карчык.

Уянырмы икән авыл,
Күтәрелер микән давыл,
Ачы итеп сызгырсам?
Кояш баештан чыгармы,
Теге чибәр сүз кушармы
Йөз елдан кабат кайтсам?

Бер урамны биш урадым,
Һаулады эт, ишетмәдем
Сабый бала тавышын;
Әлләме соң иблис ләгыйнь
Авылымның баш өстендә
Селтәп ята чалгысын?

...Жир-туфрагым — жан бизәгем! —
Тереклекнең, кешелекнең
Башлыгы вә башламы;
Чыксан юкка, зиратында
Ятим калып, зар елашыр
Бабамнарның ташлары...

***

Утыралар гөрләп күгәрченнәр,
Бозлы кәрнизләрдә сыенышып;
Әйтәләр күк: «Яшәмисез никләр
Дөнья хозурында сөенешеп? —
Жилпенегез, жиргә жимнәр сибеп!»

...Украина! —
Әнә Бәхет каласында кардәш —
Ыру, низаглашып, үтерешәләр;
И бәхетсез башлар, алар кошлар
Сыман жан жылысын өләшсәләр
Бер-берсенә, бу кадәр дә нурсыз
Булмас иде бу быелгы көзләр...

## Кем үтерде Пушкинны?!

Житкәннәр шагыйрь башына:
Буып өзелмәс жепкә,
Йа, Ходам,
Үлемсез А.С.Пушкинны да
Томырганнар чүплеккә.

Телгәләнгән бәгыремдә
Кубып нәфрәт ташкыны,
Бар галәмгә салдым оран:
Кем үтерде Пушкинны?!

Бәлкем Ходам ул залимне,
Әвәләп туңган таштан,
Күрегез адәм хурын, дип,
Жибәргәндер Марстан?

Даһилар да беркатлы шул:
Жанны корым капласа,
Аны акка буятыр, ди,
Хет бер шагыйрь калса да,

Аһ,
Заманның зәһәр жилендә
Сүнде лә сүз очкыны;
Юк, килмешәк Дантес түгел,
Без үтердек Пушкинны.

...Алыштырыр нәрсә бармы
Көн аллаһысы Кояшны,
Төн алиһәсе Айны?!
Ясин чыгар татар булмас,
Үтерсәгез Тукайны.

***

Патшалар килә, патшалар китә...
Галимжан абзый абзарын сүтә.

Калмагач жегәр, калмады малы,
Калды жәмгысе чыкмаган жаны.

Патшалар килер, патшалар китәр;
Галимжан абзый дөньядан үтәр.

Кителмәс дөнья, патша үлсә дә,
Тузган тәхеткә төшмәс тилчә дә.

Их,
Каплар күнелне салкын күләгә
Ил-йортта пыскак бер ут сүнсә дә...

***

...Ә кабере текә үрдә иде;
Кара көздә, күк сыктаган жомга
Көндә, апам кара гүргә керде.

...Жиңү таны аткан майда, мине
Детдомнарга алып китәр көндә,
Чат ябышып ертык итәгенә,
Үксегәчтен, «алып калдык сине»,
Дип сөйләдең жылы жәйдә генә.

...Бер аягым, пар таягым белән
Менәлмәдем тайгак яр битеннән,
Салалмадым туфрак каберенә,
Син юксың шул, апам, яннарымда,
Тотыныйм соң кемнен итәгенә?!
Апам, апам,
гафу үтенәм!

## Урынлы сорауларга урынсыз җаваплар

— Йә, гөманла, киләчәктә адәм
Нинди кыяфәттә буласын?
— Күр, шәрә маймыл шәрә агачта
Тәмләп ялый акча букчасын.

— «Житте мина», дип әйтерме берсе,
Ике гасыр гомер яшәсә?
— Юк, әйтмәс, мыжык карчыгы сонгы
Йөзьеллыкта ләм-мим дәшмәсә.

— «Үлеп кайтты», дигән сүз ишеттем,
Анлыйсынмы шунын мәгънәсен?
— И газиз жир! — сыендыра хәтта
Читтә кангырганнын жәсәден.

— Сабый — ул мәхәббәт жимеше ич,
Ә кемнәрдән туа яман зат?
— Гажәеп: ата-ана имансыз
Баласын да йөрмәс яманлап.

— Нигә килә икән бәндә жиргә,
Иртә-сонмы китәр булгачтын?
— Кара, ел да шәрә кала, мәгәр
Сыктаганы бармы агачнын?!

— Гоголь киткәч, буладыр бит язып,
«Үле жаннар»ны да янартып?
— Лафа хәзер, күрсәтәләр әнә
«Кара йөзләр»не дә агартып.

— Кем кулында бизмән? Бармы хаклык? —
Биек күктә оча түбәннәр.
— Без багучы түгел, язмышларны
Ходай язар, әжәл төгәлләр.

— Мөслим гөнаһ койгач, Гарәфәт тау
Үсә икән ничә карышка?
— Йә, хуш! Күрешергә насыйп итсен
Ожмах капкалары каршында...

**Редакциядән:**
*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Камил
Кәримов

# ТУРГАЙЛЫ БОЛЫТЛАР

РОМАН-ЭЛЕГИЯ

***

— Иртәгә машинаны утильгә тапшырам дигән идең. Тор инде, тор! Йоклап калма!

Шушы яшемә җитеп мин күрмәгән төшләр калмагандыр инде.

Бар икән әле. Төннәрдән бер төнне...

...Чыбылдык эчендә иркәләнеп ятам, имеш. Җиде кыз, мин үскәнне көтеп, алмаш-тилмәш бишегемне тибрәтә. Араларында берсе, күпертмә чәчен шомырт карага буяганы, аеруча ыктыматсыз кыйлана — мине тизрәк үстерергә теләпме, дуамалланып селкетә. Пружина түзмәде — сузылып төште, тал бишегем идәнгә бәрелде...

— Тор диләр сиңа, тор! Тагын ялын үтеп китә. Яз көне аю да өненнән чыга. Җәй житкәнче машинаны алыштырабыз дип ничә сөйләштек. Тагын бәяләре арта башлаган инде әнә...

Тавык төшенә тары кергән, чыпчык чүпләп бетергән... Кызларны тиз генә югалтасым килмичә, уянгач та күзне ачарга куркып ятам.

Безнең өйдә «Төшлек» китабы икәү. Өйдәгеләр, йокы аралаш, тизрәк шул китапка ябышабыз. Әгәр татарча китап төнге саташуларны яхшыга юраса, русчасын карап та тормыйбыз. Ә инде күңелсез вакыйгалар хакында алдан ук кисәтеп, өркетә башласа, русча төшлеккә күчәбез, юрамышларын жеген-жеккә китереп, барыбер сөендерерлеген эзләп табабыз һәм киләсе саташуларга чаклы яшәрлек куанычлы юаныч алабыз.

Мин бүгенгесен юрап маташмам. Урыс «төшлеге» актарганымны күрсәләр — җиде кыз хакында әйтеп кара инде син аларга! Китапсыз гына юрап; балаларыңның санын, оныкларыңның яшен искә төшереп; өнең белән буталган төшенне гамәл дәфтәреңә теркәп; оялтмыйча һич туктамаслар. Соңгы җөмләләре дә алдан ук мәгълүм: «Атаңа охшасаң, өч хатынга житәрсең әле, дип әнкәң мәрхүм тикмәгә генә әйтмәгәндер...»

Тавышсыз-тынсыз гына утыра белсә, шыр тиле дә акыллы булып күренә, дип әйтте минем тәхәллүсем. Каршы дәшмәгән кешене эштә генә түгел, өйдә дә рятталар, Нуриәхмәт кызының нәсыйхәтен рәхәтләнеп тыңлыйм.

---

Камил КӘРИМОВ (1950) — *прозаик, «Ком сәгате», «Сакау куке», «Уен», «Игезәкләр йолдызлыгы» романнары һәм күп санлы повесть-хикәяләр авторы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

— Сина бит искереп беткән машинаң өчен илле мең сум бирәбез дип торалар. Хөкүмәтнең тагын утыз мең кешегә ярдәм итәрлек кенә субсидиясе калган ди, рекламаларны тыңла бераз!

— Әйе шул. Бүген тәвәккәллим. Дөрес әйтәсең. Ярар!

Әйе, ярар, дигәнеңне ишеткәч, хатын-кызның бәхәс гайрәте шундук сүрелә, әрләгәндә югалып торган иман нуры янә гөлт итеп кабына.

Без социализмның соңгы малайлары...

Дүрт кешелек гаиләмне өлгергән анар җимеше төсендәге «Жигули»га төяп, иске гасырдан яңа гасырга килеп кердем. Инде ике гасыр арасында йөреп тузган иске машинамны автосалон миннән илле меңгә сатып алачак икән. Шәхси эшмәкәрләр генә уйлап чыгарган уен булса ышанмас идем: икегә түлә — өчне алырсың; SMS җибәр — «Мерседес» отарсың; ун мең белән китереп салсаң, йөз мең булып әйләнеп кайта, кебек алдау уеннарын күп күрдек инде. Ә монда, Федераль президент үзе үгетләп тора, нинди хәлдә булуына карамастан — илле мең! Әйтсәм әйтим, узган гасыр азагында өр-яңа килеш егерме дүрткә сатып алган идем мин аны. Тузган саен бәһасе арта барган, бахырның. Утильгә тапшырам да кредитка алам... Баштагы мәлләрдә икеләнебрәк тә йөрдем. Санаклары ямаулы, мангае җыерчыклы, ишек яңаклары ярыклы, черек бусагасы түбә калае белән ямалган. Утильгә кабул иткәндә, минәйтәм, экспертлар төпченеп һәр кимчелеген беркетмәгә теркәп барсалар — оятыннан кереп качар урын тапмассың, дип таныш-белешләрнең машина яңартканын көтеп йөрдем. Инде үзем дә тәвәккәллим... дигән булам да күңел түренә кереп оялаган Тәхәллүс гел кирегә сукалап тора: «Югалтуга түзәрсеңме? Малыңмы, җаныңмы, дигәндә хатыныңны үртәп: малым, дия идең! Ничәмә-ничә Сабантуйга алып кайтты. Дачага җәяү йөртмәде. Күпме такта, кирпеч, цемент ташыдың?! Иске күлмәкне дә чыгарып ташламыйсың — машина сөртергә ярый, ә бу йөреп торган мал, гаилән сулышы сеңгән куыш...»

— Документларыңны тагын бер карап чык, — дип икеле-микеле уйларымны бүлдерә Нуриәхмәт кызы. — Кабаланып онытып калый торган гадәтең бар. Берсендә Әгерҗегә тиклем правасыз чыгып киткән идең. Ярый ла поезд белән китереп җиткерделәр.

— Әйе шул.

— Карале, багажникны яхшылап чистарттыңмы? «Бардачок»ны? Синең кесә телефоның гел шунда йөри, онытыла күрмәсен, калдыр өйдә генә, арзан нәрсә түгел, ярты машинаң бәясе. «Жигули»еңны пресс белән сытып, коймак итсәләр, эзләрсең аннары.

— Ярар, мә, телефонны алып куй. Ә машина сүнә калса, юлда ватылса?!

— Мин дә иярим микәнни? — ди Нуриәхмәт кызы, шаяртуымны фәкать чынга алып.

— Онытып торам икән...

— Нәрсәне тагын?

— Май бәйрәменә авылга кайта калсак, дип бакны тутырып заправить иткәнием.

— Бер бак бензин да өстәп бирергә... бакча җимеше түгел лә ул — акча җимеше! Бушатып ал да стоянкадагы берәрсенә сат!

— Әйе. Сөт чиләге белән чүмеч алып чыгам да литрлап сатам. Безнең «Жигули»ның аккумуляторын, генераторын, тромблёрын да яңарткан идем, аларның да кире искеләрен куясы түгелме?

— Теләсәң нишләт!

— Ярар. Бензины беткәнче йөрим әле бүген. Ике йөз чакрым туда, ике йөзе — сюда... Аерылышу сәяхәте булыр.

— Батырларча аерылышырга оста инде син. Кичкә кайтып житмәсәң, каян эзләргә соң үзеңне?

— Оргсинтез ягындагы «Болгар-авто»ның иске машиналар өеменнән табарсың...

— Пресска кертКәндә, кабинадан төшәргә онытма тагы!

— Йокы чүлмәге дигәч тә... «Мөстәкыйм карт йокысы» белән чирләмим лә.

— Синнән әллә ниләр көтәргә була... Чистый, сугышка киткән кебек иттең. Бар инде, кояш авыша башлады, әнә... Артыгын кума! Юк машинаң өчен соңыннан штраф түлисең булыр. Урлата күрмә — илле меңне саклаган кебек саклап йөре.

***

Вакыт машинасына юл күрсәтәсе юк. Кая барасын үзе белә ул. Күңелем сизә: бүген мине кайдадыр бер мажара көтә...

Тагын ике елдан мәркәзебездә Универсиада үткәреләчәк, имеш: шәһәрнең астын өскә чыгарып актаралар, аркылы-торкылы күперләр коралар, урамнарны ябып, юллар җәяләр, сазлыкларны киптереп, спорт сарайлары салалар. Фатирыңнан чыгуга транспорт агымына кысыласың да машинаң «автопилотка күчә». Шикле самолёт ягулыгын бетерер өчен аэродром тирәли әйләнгән кебек, шушы «бөкегә» ияреп, көне буе йөрергә дә була. Ләкин эш бензин бетерүгә генә терәлеп калса — әнә «Жигулиең»ны юл читенә чыгар да эшләтеп калдыр. Алай кызыгы юк шул. Саубуллашу сәяхәтенең романтикасы булырга тиеш.

Ниһаять, тыгынлыктан котылып, олы юл бөҗрасына чыктым. Монда — дүрт ягың кыйбла! Үзем, кайсы кыйбланы сайларга белмичә, хәтерем навигаторыннан тукталышлар эзлим, ә үзем гүя машина сайлаган юнәлешкә буйсынам. Олы юл — туры юл, төтен моржасының песи мырлавыдай тигез гөрелтесенә кәефләнеп, «Жигули»ны иркәлисе килә. Күр инде бу тәртипне: йөрәк жылысы — 90, тизлеге — 90, тахометры алдашмый, ризыгы-мае мулдан, салон миче ал тәрәзәгә кызлар сулышын өреп бара... Ирексездән сөярсең — приборлар өстендәге күн панельне шап-шоп итеп яратып алдым. Ничекләр итеп шушы сылукаеңны үз кулларың белән илтеп сатарга кирәк?! Һай! Артык хисләнеп китеп, «сатарга» дигәнне кычкырып әйтеп ташламадым микән? Машина галиҗәнапләре андый сүзне ишетсәме — шундук тәне кыза, суы кайный, йөрәк тибешендә тахикардия башлана, юл һавасын өнәмәгәндәй төчкерергә тотына, руле майшыклана...

Асфальтның кайрагы кипкән, чит-читләрендә кар дегете генә өелеп калган, яшеллек уянмаган әле.

Көрт астыннан чыккан «подснежник» (умырзая түгел) дип белдеме, әллә яшьлеген югалткан машинамны кызгануданмы — пост янында власть бүлешеп торган инспекторларның берсе мине ясалма мәрхәмәтле көлү белән озатып калды. Үтеп киткәч, мин дә кайтарып көлдем, маңгай тәрәзәсенә эленгән көзгедә сурәте югалгач кына үзем белән бергә-бер калдым. Ләкин бу халәтне бөтенләй үк япа-ялгызлык дип әйтү дөрес түгелдер, арткы утыргычта, мина ышыкланып, ниндидер шайтан бара шикелле. Ул шайтанның уйларыма үтеп керерлек, гамәлемне үзгәртерлек коткысын тоеп барам... Уңышы җыеп алынган күңел кырымны гел кирегә сукалавына һич ачуым кабармый кебек...

«Житмешенче чакрымны үтеп китә күрмә... Шадкедән Әби патша юлына туп-туры чыгып була... Анда Нырты кызы Начтук яши... Белмәгәнгә сабышма... Сезнең бригада килгәндә, ул совхоз пекарнясында эшли иде... Күкрәк астына яшереп көн саен ике күмәч алып кайта иде... Куеныннан яңа пешкән ипи исе килә иде, ә?!. Зәмзәмиядән аерып алалсаң, сиңа гына өйләнер идем, дип ай буе сөелдең. Бригадагыз Казанга күчкәч, фатирыңа кайтып керсәң — Начтук түткән

белән Зәмзәмия жингән икәүләшеп чөкер-чөкер самавыр сыгалар. Акча күп эшли ул, икебезгә дә житәр, дигәндәй парлашып сине күтәләр иде... Зәңгәр күзле, күмер-кара чәчле Начтугың кайтып китте. Тагын Зәмзәмиян белән калдың...»

«Үсәлигә сугылмыйсыңмы соң? Казан циркында «каз өмәләре» үткәргәндә, Эльвира апаң Һидиятовна сиңа ел саен бер тере каз бүләк итә иде. Олы башын кече итеп, синең ижатына баш ия иде... Бәлкем Үсәли мәчетенә садака кертеп чыгарсың. Атказанган сәүдә хезмәткәре рухына дога кылырлар иде... Ояласыңмы?!. Чын күңелдән кылынган матурлыкны оныткач, кальбеңдә йорт казлары каңгылдашамы?.. Ярар, үтеп кит инде...»

«Ыслушай, әнә теге мактанчык «Лексус» сине бер уза, каршыңа басып уйнаклый, аркылы төшә, юри артта калган була да, узып, тагын юлыңны кисеп чыга... Манчы әле шуны! Хет канатына булса да ышкылып уз! Барыбер полисың әрәм кала. Синең уенчык машинаң өчен иминият компанияң түләгән акчага үзенең «Лексус»ын янартып карасын әле (!). Юк, юк! Бәрә күрмә, караңгы пыяласы аша күреп бетермәгәнмен — руле кыз бала кулында икән... Кызларга кызыл машина гына түгел, зәңгәре дә килешә».

«Рәхмәт» аланында туктасаң озакка китәр, әле кире кайтасың да бар. Бик кысталсаң, әнә, Катмыш урманы иркен».

«Уразбахтыга тарта инде сине. Теге вакыйганың азагы күңеленне кытыклый... «Яшь ленинчы» газетасына эшкә урнашкач, иң беренче һәм уңышсыз командировкага чыккан авылың... 1980 елның июне. Казаннан килгән журналистны беркем көтмәгән. Киресенчә, авылдагы афәтне тикшерер өчен кайсыдыр ки әләкчесе хат белән чакырткандыр дип уйладылар. Чыгарылыш кичәсе узгач, мәктәп директоры, ике балалы хатынын ташлап, өлгергәнлегенә аттестат алган бер кыз белән Казанга китеп бара. Әлеге мәхәббәт бәетенең азагы фажигале... Бу турыда балалар гәҗитенә язарга ярамый иде...

Элгәре син шушы авыл исемен күрүгә «директор мәхәббәтен» фаш итеп искә ала идең... Тора-бара, үзең ир уртасы яшенә житкәч, киресенчә, кыска гомерле бәхет хакына партбилетын, карьерасын, киләчәген югалтырга ризалашкан агайга сокландың гына, хәтта үзеңнән дә директор батырлыгын кабатларга әзер чакларың булмады түгел — булды... Сине бары тик үзең китергән беренче ачы тәжрибәң генә коткарып калды... Юлыңда бул, бәхет эзләүче кеше!»

«Мамадыш тыкрыгында тукта. Кафега кереп тамак ялга. Анда тәмле ашаталар. Янына кызлар килеп утырыр. «Чырык-чырык», «чирик-чирик» сайрарлар, Чаллыга хәтлек кенә алып бар, кыйммәт сорамыйбыз, диярләр. Мин Чаллыга бармыйм шул, дисәң... Алар Казан ягына китәргә дә риза... Рәхәт өчен акча кызгана торган яшьтә түгел инде син хәзер. Барыбер яңа машинаңны кредитка сорарга жыенасың. Алып кит кызларны, утыргычыңа иннек буялыр, чәчләре сыланыр, хуш исле салфеткалары төшеп калыр дип тә куркасы юк. Кайту белән «Жигули»ең туп-туры егәрле чүкеч астына керәчәк һәм солдат чемоданы чаклы тимер кирпечкә әвереләчәк...»

Вәт шайтан коткысы!

Мамадышка житәрәк Казан ягына карап, ялтырап торган ямь-яшел бер «Matiz» юл читенә чыгып туктаган. Яңа гына чабылган печән чүмәләсе кебек ымсындырып тора. Шофёр дип аталырга тиешле кешесе — ирләрне кызыктырырлык яшьләрдәге чая ханым. Машина туктатасы килеп күтәрелгән кулында шифалы судан бушаган пластик шешә селкенә. Аягындагы яшел туфлие, муенындагы үтә күренмәле бакыр-яшел шарфы — машинасына заводтан ук ияреп килгән аксессуардыр кебек. Татар илен шулкадәр дә әфсенләп торган мондый федераль елмаюны гамьсез генә үтеп китеп буламы соң?!

— Бензин кирәкме? — дидем мин, уң як тәрәзәмне төшереп кенә. Яшермим, рус кызларын авызга каратырлык кына беләбез әле ул телне.



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ
НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кабина ишеген ачып керергә исәбе юк, сөйләшер өчен тәрәзәне ахырынача төшереп бетерергә туры килде. Рамага тотынып, башы белән тыгылгач кына күреп алдым — кызның ун тырнагы ун төрле төскә буялган. Блондинканың чәч төбеннән дә үзенең зәңгәрсу төсе чыгып килә иде.

— Бензины җитәрлек. Радиаторга өстисе бар иде.

— Минем запас антифризым юк. Хәзер инде җәйгә чыктык дисәк тә була, аңа су өстәсән дә ярый. Тукта, ә син кимегәнен каян белдең? — дидем мин, күпчелек автоледиларның тәҗрибәсе сүнгән машина мәсьәләсендә көпчәккә тибеп карарлык кына икәнлеген искә төшереп. — Приборлар күрсәтми бит аны, — дип үземнең бу өлкәдә шактый ук һөнәрле икәнемне дә сиздерергә теләдем.

— Радиаторы кайнап чыккач шикләндем, — диде кыз, әле һаман елмаюын югалтмаска тырышып.

— Алайса булган инде... Сервиска кермичә, пока кабызырга ярамый моны.

Көзгегә карагач та үземнең белдеклелегемне күреп шаклар катам мин... Сары чәчле кызны артык үгетләргә туры килмәде, җинел ышандырдым, хәзер инде ул миннән тәгаен кинәш көтә.

— Син Казан кызымы? — дидем мин, юл уңаендагы автосервисларны сайларга теләгәндәй, җавап көтеп. — Карамай тукталышында әйбәт осталар бар.

— Юк, юк, анда чаклы бик ерак, кире юл бит ул. Без Берсутта торабыз. Катмыш борылышыннан ерак түгел. Өйгә кайтып җитсәм, анда әтинең дуслары күп, машинамны сүтеп җыярлар иде әле. Ә сезнең Чаллыга барышыгыз идеме, бөтенләй икенче яккамы?!

— Я еду в Никуда!

— Еракмы инде ул — Никуда?

— Килеп җиттем. Хәзер кире борылам да сине, бауга тагып, Бөрсет дигән ял бистәсенә илтеп куям.

— Кайда икәнен беләсезме?

— Белмәскә. Рәсим Низамов концерты белән килгәнебез бар. Кызык халык яши анда — урыслары русча белми, татарларының татарчасы чамалы.

— Сез артист мәллә?

— Юк. Артистлар чибәр була... Мин Бөрсеттән мунча буралары ташыдым.

— Сез бизнесменмы әллә?

— Каян килсен! Нәселебездә сыңар сатучы юк. Тәк, сеңлем, Катмыш борылышына чаклы тартып алып барам, «Matiz»ыңны тыеп кына иярерсең. Курортыгыз Чулман буенда, бик аста ята. Озын таудан төшкәндә, бу яшелкәенне миңа китереп бәрәсең инде син. Борылышта күчеп утырырсың. «Жигули» йөрткәнең бармы?

— Ник булмасын?! Башта шуның белән йөрергә өйрәндем инде. Ә сез «Matiz»дан курыкмыйсызмы?

— Кабинасына сыйсам, курыкмам. Слушай, сеңлем, ә синең праваң бармы соң?

— Әллә сез «ГАИ»шникмы?

— Аллам сакласын!

— Ә... нәселегездә сыңар инспектор да юк, әйеме?!

— Әйе. Правасыз кешегә руль бирсәң, үзеңнең праваңны алалар...

Чәче көнбагыш чәчәге төсенә буялган кыз, сыланып торган джинсы чалбарының тыгыз кесәсенә ике бармагы белән генә тыгылып, таныклыгын күрсәтте.

— Леонтьева Надежда... Исемең бик өметле, үзенә килешеп тора, — дидем мин. Белмим, никтер елмаюымны яшерә алмадым... Әле дә ярый туган елын кычкырып укымадым. — Минем документлар бардачокта, кирәксенсәң алып кара.

«Әти, шигыреңне язып бетердеңме әле, бик кирәгие», — дип әйтеп әйткән

ди шагыйрь Зөлфәтнең төпчек кызы Калрия, горшокта утырган чагында. Ие, утыз яшьлек Надеждага бик кирәк иде ди минем исем...

— Өенә кайтып житкәч сөйләшеп торырга вакыт та булмас, сорап калыйм әле, өметкәй, каян кайтып килешең иде, машинаңны сулышына ут капканчы каулагансың?

— Чаллыда «Зәңгәр күз» конкурсында катнаштым.

— «Зәңгәр күз»? «Нечкә бил» түгелме?

— «Нечкә бил»дә диплом алдым инде мин.

— Анысына ышанам! — дидем мин, үземне бер мәлгә жюри кешеседәй хис итеп. Ә синең кебек зәңгәр күзләр күп идеме?

— Күбен бик күп... барыбер икенче турга үттем.

— Син әле «Мөлаем йөз», «Нәфис муен», «Ягымлы тавыш» дигән конкурсларда да жиңәчәксең, әгәр бүген минем үртәүләргә үпкәләмәсәң.

— Ярдәм итәргә ашкынып торган кешегә үпкәлиләрме соң?!. Житмәсә әле сөйләшүне акчадан башламадыгыз.

— Их, Надюша! Мин профессионал шофёр, илле еллык стажым бар. Ярдәмгә мохтаж кеше янынннан гамьсез генә үтеп китә алмыйм шул...

Бөрсет пристане Чулманның сөзәк ярында. Язгы сулар үзәнлектә җәй уртасына чаклы кипшеми, шуңа күрә дә бу авылда өйләрнең, кем әйтмешли, күз-колагы өстә — нигезе кеше биеклеге. Машина өй янына килеп туктауга урта тәрәзәнең пәрдәсе селкенеп куйды. Мин ике машинаны бергә бәйләгән ефәк арканның төенен чишкән арада капка төбенә бер ханым чыгып басты. Надяның әнисе булса кирәк, артык төпченмәдем, кыз сорарга килгән буйдак түгел лә мин. Шәүләсенә баш кагып кына исәнләштем. Ә шулай да ирләргә хас кызыксыну маңгайдагы бер җыерчыкны кытыклап тора: Надя кемгә охшап бәйгеләргә ыргылырдай сөйкемле булып үсте икән — әнисенәме, әтисенәме?

— Төене бик нык чияләнгән, кисеп алсаң җәлке инде, кызыгыз юлда йөрергә ярата бугай, кирәге чыгып куюы бар, — дидем мин, хуҗабикә каршында тураеп басып.

— Надя, калай тартмалы инструментларны алып чык әле.

— Юк, юк, монда инструмент ярдәм итә алмас, — дип каршы төштем мин, ашыгыбрак акланып. Тимер сандык күтәреп әтиләренең дә чыгып басуын теләмәдем. Үземне кызыксындырган сорауга җавап күз алдымда: буе-сыны, күзе-йөзе белән Надя әнисенең үрнәгеннән коелган иде. — Бер зур калак тапсагыз, шул җитә.

— Нинди калак кирәк — йөзле, йөз иллеле, ике йөзлеме?

Әни кешенең төзүчеләр телендә сөйләшүенә сокланып куйдым.

— Белмәгәнегез юк ахры.

— Әтиебез балта остасы безнең. Гомер буе пилорамда. Хәзер төшке ашка кайтырга тиеш. Бергәләп чәй эчәрбез.

— Вакыт ягы кысанрак шул. «Бөрсет» курортында йөрүләр бүгенге сәяхәт планына кермәгән иде. Бер зур калак алып чыксагыз...

— Надя, яңа келәттән ике йөзле калак алып чыгып бир әле.

Ике машина уртасында басып калдык шулай. Ишегаллары зур күренә, Надя ике йөзле калак эзли. Вакыт беразга тукталып торды кебек. Мин ирексездән пүчтәк уйлар белән юанып алдым: кызык, калакларның да ике йөзлесе була бит әй! Син аңа ышанып, жепсә тезәсең, бер-ике сугу белән ул кәкрәя, бөгеләсыгыла, келәшчә белән турайтып һаман кагасың, эшләпәсе күмелә дигәндә сынып чыга. Балта осталары гына белә торган сүгенү сүзләре белән тозлапборычлап кире суырып аласың да аның эзенә янасын кагасың... Калакның кыска торыклысы, хәнҗәрдәй очлысы, чыныккан корычлысы ышанычлырак...

И, мужик, янында һәйкәлгә тиң сабырлык белән сөйкемле ханым өнсез басып тора. Ә син, нindидер черек кадак фәлсәфәсенә кереп чумдың. Танышу йоласы да бар бит әле.

— Минем исемем...

— Беләм... — дип кинәт бүлдерде ул мине. Исемем авыз эчендә калды.

— Ә, концерт белән килгән идек бит. Хәтерләп калгансыздыр, — дидем мин, тапкыр җавап әйткәндәй сөенеп.

— Әйе, концертыгызны да карадым. Сәхнәгә язу кисәге ыргытучы да мин: «Здравствуй, Коля, с приветом к тебе Люба!..»

— Сәхнәгә коелган сорауларны җыеп барам мин. Кайткач актарып карармын әле. Минем тормышта Люба исемле бер генә кыз булды. Анненково авылыннан... Син?!.

Оятымнан кая кереп качарга белмичә... Юк, киресенчә, йөрәгем урын эзләп бәргәләнә башлады. Бу газаптан Люба мине үзе коткарды.

— Шулай танымаслык булып үзгәрдем микән?

— Мин үзем дә алдынгылар слётына килгән VII класс укучысы түгел шул. Шактый ук күптән андый түгел инде. Танадың бит әле минә...

— Казан тапшыруларында бик еш күрәм. Син бит гел адресыңны әйтеп сөйлисең. Онытырга ирек бирмисең.

Озын тәнәфестә онытылып калган ике пионер кебек басып торабыз. Беләм, бу очрашуның минутлары бик тә санаулы, вакыт машинасы мине кабат Яңа гасырга алып китәргә дип ашыктырып тора. Хыял дәрьясыннан ишелеп төшкән сорауларның һич югы бер-икесенә генә булса да җавап табып өлгерәсе иде.

— Безнең район халкы төпләнергә дигәндә, Казанны үтеп китми торган иде. «Бөрсет»нең табигатенә кызыккансыздыр инде.

— Сигезне бетергәч, мин Иске Шаһгалигә йөреп укырга тиеш идем. Туган-тумача белән киңәшләштек тә Алабугадагы апам янына килеп урнаштым. Культура-агарту училищесын бетердем. Аннан шушы ял йортына эшкә җибәрделәр. Кияүгә чыгып калдым. Унҗиде генә иде әле. Яшем тулсын дип яши торгач... бүгенге көнгә чаклы язылышмаган әле без.

— Әйтәм җирле, Надя синең фамилиядә. Төпчек кызыңмы?

— Юк. Бердәнберебез! Ун ел балабыз тумады. Өметебез өзелде дигәндә, Ходай Надяны бирде. Иркәләп үстердек. Мәктәптә үк төрле олимпиадаларда җиңеп барды. Медальгә бетерде... Кайда нинди конкурс ишетсә — шунда килеп керә. Җиңү яуларга бик ярата...

Ул арада Надя — Надежда чыгып житте. Кулында — кәгазь салфеткага төреп токкан ике йөзле кадак. Люба белән безнең озын тәнәфес бетте. Яшьлек хатирәләреннән тиз генә бүгенгегә кайтып, кыз янында чит-ят кешеләрдәй кыланып торабыз.

— Кызым, син өйгә кереп чәй куя тор. Табада барын җылытырсың. Кунакны ач килеш кайтарып җибәрү килешмәс.

— Әни, ул абый буксир өчен акча алмыйм, ди. Бәлки машинасын заправить итәрбез? Теге 200 литрлы мичкәдә күп әле ул безнең запас бензин.

Заправка дигән сүздән котым алынды.

— Кирәкми, кирәкми! Бензин өстәсәгез, тагын әллә кая китәм мин.

— Никудамы?

— Әйе! — дидем. Ә үзем акланырдай сүзен таба алмадым.

— Барыбер сәер кеше Сез! Әллә романтик, әллә качкын, әллә бәхет эзләүче — аңламассың!

— Кызым, дорфаланма! Кушканны эшлә. Мин кунакка йорт-кураны күрсәтәм.

— Өйне сатарга ниятләмисездер ич, әнием?

Кызның төртмә теле бик тирәнгә кермәсен өчен, мина да сүзгә катышырга туры килде.

— Авылда өй салып ятам. Бәлки кайбер киңәшләрегез ярап куяр. Әтиегез һөнәрле кешегә охшаган, йортыгыз патша сараеннан ким түгел.

— Безнен Берсутта бөтен кеше патша хәзер, — диде дә, Надя ашыгып кереп китте.

Өйләренең капка баганасы гына тимер торбадан, калган өлеше — гел бура. Баз өсте, утын келәте, тавык өе, дуңгыз сарае — эре бүрәнәләрдән өелгән. Ак мунчалары өч бурадан сипләнгән.

Соңгы елларда Бөрсеттә йөк машиналары паркы, пристань, пилорама, борыс-такта сату өчен базар мәйданы корылган. Күрәсең, авыл эче яр буендагы урманны кисү хисабына зурайгандыр.

Люба хәзинәдәге бар мирасын берьюлы күрсәтеп өлгерер өчен, мактанчык экскурсовод кебек ишегалды буйлап йөртә.

— Мунчагызны газ белән җылытасызмы?

— Юк. Утын ягабыз, газ миченең пары тәмле түгел. — диде Люба һәм, баядан бирле шушы соравымны көткән кебек, җәһәт кенә ялган йозакны салдырды. Минем салкын мунча эченә ияреп керәсемә һич шикләнмичә түргә узды.

— Менә бу бүлмәдә тышкы киемнәрне калдырабыз, — диде ул, өстендәге бәрхет жакетын чөйгә элеп... Ә монысында юынабыз, казанында җәен-кышын җылы су өзелми, ышанмасаң тотып кара.

— Ышанам! — дидем мин, Любаның тар-тар такталар белән шакмаклап тышланган түрдәге ишекне ачканын түземсезлек белән көтеп.

Кызыну өлешендә пешкән ылыс, каен бөресе, мәтрүшкә төнәтмәсе, яңа гына аертылган сосла исе — бөтенесе бергә кушылып, исерткеч сулышка әверелә. Өч яруслы ләүкәнең кыздырылган көмәч төсендәге такталары коп-коры. Люба өстәге катны сыпырып, мине иләсләндерде...

— Менә, мин шушында кызынып ятам инде.

Һәм Люба, шушы ләүкәдә үткән минутларының тәрҗемәи хәлен иркенләбрәк күз алдыма китерер өченме, беркавым уйга житәрлек итеп тирән сулыш алды да тынып торды.

Минем өчен артык зур сынау иде бу.

— Люба, хәзер ирен кайтып керә. Оятка калабыз, салкын булса да мунчага кердек түгелме?

— Ярты сәгатьсез кайтмый әле ул. Эш вакыты бик төгәл аның.

Ярты сәгать, имеш... Пионер учагы тирәсендә энже чәчәк бәйләме тотып күз алдымда калган Люба белән өч сәндерәле ләүкәгә менеп утырыр өчен нәрсә соң ул утыз минут?!.

Үз сулышым үземне өтә башлады, әйтерсең лә безгә сиздерми-нитми генә кемдер мичкә ягып җибәрде. Мин урамга ашыктым. Ире кайтып җиткәнче китәргә кирәк. Бүгенге вакыйгада артык кешеләр катнашуын теләмим. Монарчы хәтерем көндәлегендә ире дә, кызы да теркәлмәгән иде. Барысы да искечә калсын.

— Тукта! — диде ул миңа, сугыш кырыннан чигенеп авылына качарга җыенган дезертирга кычкыргандай итеп.

Туктадым.

— Яшәү мәгънәсен үзгәртердәй очрашудан соң шушылай хушлашмыйлар бит инде. Мин Казанга еш йөрим. Күрешербез, шалтыратырмын. Әйт телефоныңны.

— Лутчы үзеңнекен әйт, алай ышанычлырак булыр. Хәбәр бирермен.

Үч иткәндәй, авторучкам машина шүрлегендә калган. Ул минем ни

эзләгәнемне анлап, мунча миченнән күмер кисәге алып килде. Һәм уч төбемә телефон номерын язды... Язды да, күмерне тиз генә мичкә ыргытып, корымлы бармагын өреп суытты.

Күмере утлы иде анын...

Люба... Любовь... Любовница...

Любаны үсмерчак үзәнендә калдырып, мин янадан бүгенге көнгә кайту юлына чыктым. Юл дип әйтү, мөгаен, чамасыз купайту булып янрар, Бөрсет тавын менгәндә, машинамнын тыны кысылды, кабинага лампа сөременен керосинлы исе кебек әче һава тыгылды, ян тәрәзәне төшереп кенә дә котылырлык түгел, язгы хушлыктан исергән жилнен төтенле читлеккә керәсе килми. Тау битендә сүнеп калса — оятын кая куярсын! Бәлкем Өмет белән Мәхәббәт икесе бер булып, мин күздән югалганчы карап озатып калырга теләгәннәрдер. Бөтен хәрәкәтем күз алдында.

Шөкер, самавыры кайнап чыга дигәндә генә тәки тау башына менеп житте. Яфрак ярып өлгермәгән каеннарнын тар урманында килеп туктарлык кына коры аланнар бар иде инде. Капотны күтәреп куйдым, дүрт ишекне дә төбенә чаклы ачтым, рәхәтләнеп суынсын. Гайбәте түгел, гадәте — өр-яңа чагында ук жәй көне кыза торган кимчелеге бар иде бу «Жигули»нын. Нуриәхмәт кызын Әгерже Сабан туена алып кайтам дип сәяхәткә чыксан, туган ягына барып житкәнче, биш-алты жирдә туктап, моторын суытырга туры килә иде. Кызу канлылык — бу машинанын нәселеннән килә торган чир.

Иркенләп суынсын, картлач...

Любаларнын түбәсе күренерлек кенә биеклектән үткәнемә карап торам. Кояш баешынарак авышкан саен, нурлары отыры ерагая барды, көн яктысы әкренләп офык тирәсендә куера башлады. Сәер, багана башындагы утларнын гына түгел, хәтта көн яктысынын да чиге бар. Ә галәм каранғылыгынын чиге юк.

Кешенен уй-хыяллары чиксез, дибез... Ә бит хәтернен чиге бар. Өч-дүрт яшеннән языла башлаган хәтер сонгы көненәчә тулылана гына. Зиһен мөмкинлеген «ай кью»лар белән үлчәп буладырмы, юкмы — анысына ышануы кыен, ә менә хәтер сыешлыгынын гигабайтлар белән үлчәнәсенә ышанам...

Ундүрт яшьлек рус кызынын шушы көнгәчә хатирәләрем өемендә күмелеп калуы — ул бөтенләйгә оныту булмаган. Үз очрагын көтеп, дулкынландыргыч минутлар, шул ук вакытта хәвефле үзгәрешләр һәм дә язмышларны манғайга-манғай чәкәләштерердәй бәрелешләр хәлендә сагалап торган. Яшьлектән ераккарак киткән саен исенә төшкән вакыйгалар жетеләнә, жирсүләр кискенләшә. Сагыну дигән лирик сүз каты бәгырьле хөкемдарга әверелә. Яшьлектәге хисләрне янарту безгә яшәргә комачаулый...

Юкны бар итәргә оста инде син — хәтер!..

Анненково кызы Люба белән хат алышканда, мин консерватория дигән катлаулы сүзне кулланмаска тырыша идем. Ул минем кечкенәдән жырчы булырга хыялланганымны белә, ә үзенен хыялын сорасан, «не знаю» дип кенә жавап бирә.

Ике ел буе хат алыштык. Хәреф хаталары китмәсен өчен, жөмләләрне ике-өч сүз белән генә язам. 650 укучылы мәктәбебездә миннән башка бүтәннәрнен рус кызы белән хат алышканын хәтерләмим. Телгә керерлек грамотныйланып барам. Рус теленнән язма эшләрдә «5»ләләр ала башлагач, партадашым Мөдәрриската шик төште, имеш, аннан күчермим микән... Гафу итегез, үзем эшләрдәйне гомерем буе үзем эшләдем. Плагиатларны женем сөйми! Үзем, үзем, үзем... Я сам!

Колхоз базарыннан кырык чакрымда гына яшәгән авыл өчен русча гәпләшүнен әллә ни кыенлыгы юк инде анысы. Яшерен-батырын түгел,

әле тагын бер «мәктәбем» бар... Әтине жирләргә дип алып киткәндә мине, ярты яшьлек баланы, күршедәге көтүче Гатаулла абыйларга кертеп торалар. Гатаулла абыйның гаиләсе ишле, хатыны Нәфисә апаның жиде бала алып кайтканы өчен ордены да бар. Мина күз-колак булып торырга кеше житәрлек дигәннәрдер инде... Зираттан әйләнеп кайткач, мине алып чыгалар, тик ике күземне ача алмыйм икән... Шул көннән ике күземә дә ак төшкән — нәкъ Габдулла Тукайныкы кебек! Инде кызлар сөясем юк, яшереп тормыйм, шушы көнгә чаклы ике күземдә дә ак тап йөртәм. Күпне күргән кызлар мина: «Күзен уйнашчыларныкы шикелле, гел мут ялтырый!» — ди торганнар иде. Әйтәм ич, аннан түгел ул...

Күз авыртуым яшәреп, ел саен бер тапкыр Питрәч больницасында дәваланып чыга идем. Менә кайда өйрәндем мин русча сөйләшергә!

Люба белән без уку алдынгыларының район слётында таныштык. Жиденче классны (кичерегез, сыйныф дия алмыйм, без укыган дәреслекләрдәге «сыйнфый дошманнар»ны хәтерләтә) тәмамлаган чак. Иртәдән кичкә кадәр Мишә буенда бәйрәм иттек. Районның Пионерлар йортыннан китерелгән быргы-барабаннар тантанасында өчпочмаклы әләм күтәрелде. Рапортлар бирелде, докладлар ясалды. Брест крепосте каһарманы, Советлар Союзы герое Пётр Гавриловның чыгышы вакытында без сугышчан киноларда күргән, зур һөжүм алдыннан гына була торган дәһшәтле тынлык урнашты. Батыр якташыбызның Краснодар ягыннан кунакка кайткан чагы иде. Слётның тантаналы өлеше үзенчә кызык тәмамлана: Мишә буендагы тугайда чирәмле кәсне кисеп, зур йолдыз казыла; йолдыз өстенә ялкыны якын-тирә авылларга күренерлек учак ягыла; соныннан утлы күмерләрне тигезләп җәяләр дә Жир күкрәгендәге йолдыз жем-жем итеп безне үз тирәсенә жыя...

Күмер төшкәнче, йолдыз учагы дөрләгән арада, аланга корылган ачык сәхнәдә концерт башлана. Минем мактана торган урыным инде ул сәхнә! Шигырь сөйләүчеләр — муеннан, ә без жырчылар алай ук күп түгел...

Май ахырында Питрәчнен нарат урманы кырпак кар яуган кебек тоташ ландыш чәчәгенә күмелә. Бүгенгегә аны шактый жыйганнар, жырчыларның һәммәсенә дә бирәр бәйләм бүләк итеп торалар.

«Әниемә хат»ны жырлап бетерүем булды, сусыл яфракларына төренгән энже чәчәкләр бәйләмен сузып, бер кызның яныма килеп басуы булды. Халык лепердәшеп кул чаба, ә мин инде каушавымнан әлеге кызга ияреп чыгып барам. Чәчәк бүләк итүчеләргә: «Рәхим ит! Котлыйм! Маладис!» — дип хөрмәтләү сүзе әйтергә кушылмаган ахрысы — кыз ләм-мим. Мин аның рус кызы икәнен белми идем әле.

Сәхнә читендәге төркемгә кереп, кыз янында басып калдым, ул миннән качарга жыенмый, ә минем китәсем килми. Күңел тутырып бер иснәдем дә энже чәчәкләрне кызның үзенә кайтардым. Ялындырмый гына алды, кушучлап тотты да сокланып карап тора, әйтерсең лә әлеге бәйләмне үз гомерендә беренче тапкыр күрүе! Чынлап та, жем-жем итеп энже нурлар бөркелә, яна яуган кар бөртекләре кебек... Эремиләр генә.

— Салют! — дигән булам. Үзем шул арада исемемне әйтеп өлгерәм.

— Люба! — дигән була ул да, кулындагы чәчәкләр белән сөйләшкән шие генә.

Ахрысы ландыш иснәп туйды, кызый борынын жыерып куйды. Аннан, буш кулы белән толым төбенә үрелеп, «маржа тарагы»н төзәткәләп алды.

Районда кемнен кемлеген исеменә карап кына әйтер хәл юк, ярты керәшен урыс булып йөри бездә. Ләкин Люба Анненково дигән чеп-чи урыс авылы кызы иде.

— Красиво поёшь!..

Шушы сүзне Любадан кабат ишетер өчен генә дә яратырсың бу рус телен...

Шуның белән шул булды инде — хат алышырга сәбәп.

Безнең авылның почта аты Мәскәү поезды кебек төгәл йөри. Якшәмбе көнне кичтән кибет янындагы зәңгәр әрҗәгә хат төшерәм икән — атна кичкә, көн уртасына, җавап килеп җитә. Бер сәгатькә дә соңармыйча...

Киләсе елга мәктәпне тәмамлап, бергәләшеп Казан урамнарыннан бәхет эзләрбез әле, дигән хыяллар хат саен телгә алына башлагач кына, Любаның җаваплары сирәгәйде. Беләм, почта атын да алыштырмадылар, хат ташучы Мәһикамал апабыз да өй түреннән көн саен сәгать уникеләрдә үтеп китә. Анненково авылыннан көткән өмет атнадан-атнага, айдан-айга отыры сирәгәйде. Һәм ахыр чиктә юкалыгы белән буш конверттан әллә ни аерылып тормаган соңгы хаты килеп төште. Куен дәфтәреннән ертып алынган сыңар биттә «хуш» дигән кәлимәсе бар иде.

«...Бүтән язма. Казанга күчеп ятабыз. Минем фамилиям үзгәрде. Аңлыйсыңдыр дип ышанам...»

Любага хат язарга ярамаганны аңлыйм, ләкин фамилиясен ашыгып алыштыруы гына бигүк аңлашылып бетми — үзе ашыкканмы, әллә ашыктырганнармы?

Атна буе тешем сызлады. Берара тынычлангандай итә дә өй түребездән, почта ящигы чаклы сумкасын күтәреп, Мәһикамал апаның үтеп киткәне күземә чалынуга, тагын сызлый башлый. Мамыкка сеңдереп ландыш төнәтмәсе тидерергә күнеккән идем, энҗе чәчәк дигәнебез, кызыл тәлгәшле орлыкка өлгергәч, чат агуга әверелә икән, бөтнек суты тамызырга куштылар...

«Хат алышмыйча түзә алмыйм мин хәзер...» — шулай дип ялгыш әйтүем булды, клуб юлында кызлар күзләр өчен капка төбендәге бүрәнә өеменә менеп кунаклаган Мырый Минлевәлие очып та төште, өенә кереп өлгердеме-юкмы, бөгәрләнеп беткән конверт кисәге тотып та чыкты. Мырый Мусасының бер энекәше армиядә хезмәт иткән җирдә казакъ кызына өйләнеп, шунда яшәп калганын ишетеп беләм, тик аның минем белән хат алышырлык Нәзифәсе барлыгын каян белим. Аларга авылдагы яңалыкларны хәбәр итеп торырга кирәк икән, Нәзифәләре бик чибәр, имеш, әле җиенга кайтып төшүләре дә бик ихтимал, ди. Озакка сузмыйча Көнчыгыш Казакъстанның Шемонайха районына «авиа» конвертка салып бер хат очырдым. Монысы да кияүгә чыгып качты бугай дигәндә генә, ниһаять, җавап алдым. Тел мәсьәләсе искечә хәл ителде, Нәзифә татарча яза белми, мин казакъчаны каян белим?.. Русчалатып сөйләшәбез. Любаның фоторәсемен каршыма куям да сорыйм: «Нәзифә, бездә алмагачлар чәчәк койды, сездә җәй җиттеме әле?» — дим... Бер айдан соң ул миңа әйтә: «Без инде кавын ашыйбыз, сездә алма өлгердеме әле?» — ди. Икенче соравына җавап биргәндә, бездә инде кар ява, ә алар Уба елгасында су коеналар икән... Хәер, ашыгасы юк, алдыбызда әле зур киләчәккә юл ачылырга гына тора. Иң мөһиме — Люба әкренләп онытыла. «Хорошо поёшь» дигән авазы да ерагайганнан ерагая бара. Районнан Мишә яры буйлап җәяү кайтырга туры килсә генә, шыксыз күмерләрен сарут каплаган пионер учагының кыршылган йолдызы янында гүя мине кемдер туктата.

Күпне күргән Мишә елгасы да бу тугайга җиткәч, үзенең тымызыклыгын онытып, бераз уйнаклап ала, бала чагына кайткандай бормалана, төбе күренерлек итеп саега, агымы көчәя, вак дулкыннары сөзәк ярдагы чуерташларга бәрелеп су төбендә чөкердәшеп куя.

1975 елда Анненково авылы бөтенләй таралды, «...халкы башка җирләргә

күчеп киту сәбәпле...» дигән катгый Указ белән, ТАССР Верховный Советы аны исемлектән бөтенләй сызып ташлады... Кызлары фамилияләрен алыштырып бетерде бугай.

***

Алга таба, һаман-һаман өзгәләнеп укучыны артык ялыктырмас өчен, бала чагымның кайбер күренешләрен язмамның шушы бүлегендә үк тасвирлап калдырыйм.

Сугышка хәтле әти гупчым минем әти булмаган әле ул. Әни белән алар 1946 елны кавышканнар. Авыл советында язылышып кайткач төшкән бердәнбер фотолары саклана: әни кин канатлы алъяпкычтан, бәби итәкле күлмәктән, чәчен шома итеп тарап мәктәп баласыныкыдай ике толымга үргән; әти гимнастёркадан, галифе чалбардан (зурайткач, тез өстендә ямаулыгы барын күрдек), күкрәгендә «Сугышчан Дан ордены» белән «Сугыштагы батырлыклары өчен» дигән медале дә бар. Фронттан алып кайткан яралары аны жинә. Мина ярты яшь тулган көнне зур газаплар кичереп, әти: «Үзенә генә үсәргә туры килер инде, улым», — дигән дә әни кулында вафат булган. Өч бала белән ялгызы калгач, әни пенсия артыннан йөреп карый. Ләкин райсобес документларны кире бора. Больницада үлмәгәч, сугыш инвалиды буларак, дигән диагноз куелмаган икән...

Әни шуннан соң әтинең орден-медальләрен безгә уйнарга бирде. Ул «уенчыкларның» бер файдасы тиде тиюен... Әш шунда ки, минем муенымда кечкенәдән бер җөй саклана. Бу шрам үзем белән бергә үсте. Кызлар алдында оялып, гел күлмәк якамны күтәребрәк, муенны кырын салып йөри идем. Бала чакта мин аны, салкын тиеп, тамак шешүдән калган дип аңлатырга тырыша идем. Үсә торгач, янгырдан соң көпчәк эзендә калган буксир арканы йолкыганда кәкре чыбык очы ертып алды, дип акландым... Ә инде кунак кызлар күрә башлагач, әти мине «Ура!» кычкырып бүрек урынына чөйгән дә орден белән ялгыш сыдырып алган дип горурлана башладым. Ярты яшьтән әтисез калганымны кунак кызлар каян белсен соң?!. Ә авылыбыз кызларының күзендә мин үземне мескенәйтә торган кызганулы караш тойган кебек була идем. Шушы кимсенү бөтен язмышымны үз кулына алыр дип кем уйлаган?!

***

«Жигули»ем суынгандыр инде шәт. Мал иясенә охшамаса, хәрәм була, диләр: тиз кыза — бик тиз суына ул!.. Карангы төшкәнче кайтып өлгерәсе иде.

Бөрсетле Өметен Мәхәббәте белән еракта калдырып киткән идем инде. Шулчак приборлар тәрәзәсендә бензин күрсәткечнең кызыл уты янып-сүнеп уйный башлады. Завод авторлары чыгарган китапка ышансаң, тагын 40 чакрымга тикле юл үтеп, бензин эзләп йөрергә була. Приборың дөрес күрсәтсә... һәм дә машинаң яңа чакта.

Шөкер, Чаллы юлында ягулык тукталышлары, кем әйтмешли, адым саен, берсеннән үрелеп карасаң, икенчесенең түбәсе күренеп тора. Шөкер, килеп җиттем. Яңа калыккан ай ярыгы сыман тәрәзәдә түткәйнең кершәне кипмәгән маңгае да сөрмәгә тонган боек күзләре генә.

— Ничәнче колонка? Нинди? Ничә литр? — Бензин ханәкәсенең житәкчел тавышы тәрәзәне тишеп чыкты. Әгәр шушы минутта ул ишетергә күнеккән саннарны әйтә белмәсәң — берәр үткен сүзе белән атып ега хәзер. Ничә литр, имеш...

— Берүземә генә ярты литры да житеп ашкан инде аның... Йөз чакрымга бер чиләк дип исәпләсәк, бу арбаны утильгә илтеп тапшырганчы биш литры да артык...

Нуриәхмәт кызы белән читтән торып кына киңәшеп сөйләнгәнемне ишетеп ошатмадымы, түткәйнең күз тирәсендәге сөрмәсе өрелде.

— Юк, юк, әйдәгез, тутырып салыгыз! — дидем мин, сәүдә низагын тизрәк туктатыр өчен. Һәм әлеге «броневик» авызыннан шуып чыккан чуен табага менлекне сыладым.

Тагын тулы бак белән кайтып кердем...

Житмеш биш ат көчле машинамны үз аранына ябып, «Кайда йөрден?!» дигән сорауга җавап эзләп торам менә... Кавышканыбызга утыз ел узды, гел дә гел хәйлә корырлык фантазиям дә коргаксыды бугай инде. Ярар, кичке уенга дип кенә чыккан уңайдан ялгыш таң аттырып кайткан егет-малай кебек, мыштым гына тугарылырмын...

Ләкин бу кичне мине өйдә көткән хәбәр «Жигули» мәрәкәсен атна-ун көнгә чигереп куйды...

***

Эленке-салынкы гына йөргән ирләр турында безнең авылда бер әйтем яши: ул кушканны кулының очы белән генә эшли, диләр. Мин хәзер рульгә ике куллап ябышам. Сәбәбе бар.

1999 елны «Татарстан» журналының май санында Фаил Шәфигуллин фаҗигасе турында мәкаләм басылып чыкты. Талантлы язучыбызның үлемендә Бауман районы эчке эшләр бүлегенә буйсынган айныткыч хезмәткәрләрен, тикшерүчеләрен һәм эшне йомып калган шул ук район Прокуратурасын гаепләп язылган иде ул. Минем жалобалар, СССР хөкемдарларын айкап, яңадан үзебезнең Бауман районы милициясе кулына әйләнеп кайта торды. Ләкин үзем уяулыгымны югалтканмын...

«Жигули»ем күп еллар буе газета һәм журналлар нәшриятының түләүле «стоянка»сында торды. Ә аны тәүлек буе милиция хезмәткәрләре саклый торган иде. Мәкаләм басылып, бер ай үтмәде, җәйге каникулга чыккан улымны классташлары белән төяп, «Крутушка» базасына байдаркада йөзү ярышларына алып киттем. Мин техниканы белмим түгел, яратам да хәтта. Су скважиналары бораулаган елларда үзем дизелист, үзем мастер, бораулау агрегаты җиһазланган «МАЗ-500» машинасын да үзем йөртә идем... Сак астында атналап яткан «Жигули»емны кабызганчы бер кат маен-суын тикшереп, көпчәкләрен тарттырып кына юлга чыга идем. Ә бу юлысы, гөнаһ шомлыгы, ярышка соңарырга ярамый, дип улым ашыктырды...

Дәрвишләр бистәсен чыгып, «бөкеләр»дән котылдык, инде «Крутушка» юлына борылабыз дигәндә генә машинам сулга каера башлады, әгәр рульне ике куллап тотмаган булсам, барган көйгә дүрт баланы текә дамба астына очырта идем... Туктап өлгердем. Карасам... уң яктагы алгы көпчәкнең өч болты яртылаш сүтелгән, берсендә генә эленеп калган. Үз башына төшкән кеше белә — бу этлек эше! Сул яктагысы булса — машинага утырганда ул шундук шофёр күзенә чалына. Исән-сау кайтып туктаган җирдә өч болт үзеннән-үзе сүтелә алмый... Шушы хәлдән соң мин машинамны милиция сакламый торган башка җиргә күчерергә мәҗбүр булдым.

Юлга нык ышанып, кесә телефоны белән сул колагын кашып барган сынар куллы йөртүчеләргә үч итеп, мин рульне ике куллап тотам. Ә кесә телефонын бөтенләй сүндереп куям. Өйдәгеләр моны белә. Юлда югалды бугай, дип өзгәләнмәскә өйрәнделәр.

Кайткач, телефонымны кабызсам, ни күрим — концертлар оештыручы администратор егет мине эзләп өч тапкыр шалтыраткан. Ул, Төмән-Свердлау-Чиләбе-Өфе-Чаллы маршрутына билетлар таратып, афишалар ябыштырып кайтканнан бирле хәбәрсез югалган иде. Зур төркем белән ерак гастрольләр

оештыруның чыгымнары күп. Залларны тутырырлык тамашачы жыя алмасаң, ике атна буе акча туздырып, үз-үзеңә зыян китереп йөрисе дә юк. Билетларны кире жыеп кайту очраклары бик еш була. Шуна күрә мин дә инде Себер-Урал концертларыннан өметемне өзгән идем...

«Уфа-Чиләбе, пешә кура жиләге...»

Жырларга ышансаңмы?!

Чиләбе алкышлы шәһәр түгел инде хәзер. Тамашачыларның кимегәнен, «Афәрин!»ле кычкыруларның сүрелгәнен, юмор сөючән күзләрнең сүнеп барганын килгән саен ныграк тоясың. Элеккечә олы юлга чаклы хөрмәтләп озатып куюлары да бетте...

Трактор заводының Мәдәният йортында: «Киләсе очрашуларга чаклы бер кая да таралышмыйча, кризисларга бирешмичә, исән-имин яшәп торыгыз. Сау булыгыз!» — дип микрофонны сүндергәндә, яз аеның кичке уны иде инде. Арысланнар асрый торган читлеккә охшатып арматурадан корылган гардеробта аягөсте генә капкалап тамак ялгадык. Күмәч алырга онытканбыз, симез колбасаны печенье өстенә салып, бутерброд иттек. Жимле чәйне карындык стаканнарда чайкый-чайкый карынны чылаттык. Шуннан арысына юмартлары да юк, мәрхәмәт көтеп утырыр өчен вакыт ягы да кысанрак. Төн уртасы житкәнче Чиләбе тирәсеннән ерагаерга кирәк. Ни өчен дигәндә, шәһәр капкасын чыгу белән адашуың ихтимал. Кеше сүзенә генә ышанмас та идек, бу якларда күп йөрдек, беләбез, үзебезнең дә адашкалаган бар.

Еракка барасы булса, шофёрлар, уч иткәндәй, күбрәк төнлә йөрергә ярата: беренчедән, каршы яктан килүче машиналар азая; икенчедән, фуражкалы «өрәкләр» югала.

Чиләбедән биш якка чыгып качарга була.

Без барасы якта Магнитогорски белән Сатка арасы бар. Кагыйдә буларак, юл төене бөжра ясап кисешә. Ә монда ул, никтер, һәр ягы бишәр чакрымнан торган өчпочмак рәвешендә. Чиләбе татарлары төзүчеләр салган мондый геометрик фигураны күз бәйләп тә китә ала. Ә безнең ише сәяхәтчеләр өчен ул «Бермуд өчпочмагы»... Үз белдегебез белән борылгалый торгач, әлеге өчпочмак тирәли ике әйләнеш ясадык. Болай булмый, берәр юлдашка ияреп китсәк кенә. Тик, туктамыйлар, яшь-жилкенчәк белән тулы «Газел»ебезне, киресенчә, читләтеп узалар. «Кафе» дип язылган вагонны дөбердәтеп, ит пешерүче Каф тавы агайларын уяттык. Алар ваучер хәтлек кенә тәрәзәдән шөшле белән төртеп күрсәткән якка тәвәккәлләдек. Барабыз да барабыз... «Магнитогорски-120» дип язылган зәңгәр тактаны күргәч, шофёрыбыз безне сүгә башлады... Житмеш чакрым кирегә киткәнбез...

Янадан «Бермуд өчпочмагы»на кайтып утырдык.

Жырчыларыбыз арасында Назлыгөл атлысы бар, кулында дисбе йөртмәсә дә, табын артыннан «Амин» әйтеп куба торган бердәнберебез. Шул әйтә куйды:

— Кабаланмыйча көтик, Ходай берәр фәрештәсен насыйп итәр әле, — ди.

Аның бу нәсыйхәте ачуны китермәде, чөнки башка чарабыз юк.

«Фәрештә» дигәне «Беларусь» тракторына утырган иде. Мангаена да фара куйган — дөньяны ут белән айкап килә. Кул күтәрергә уйламадык та, ул үзе туктады.

— 16нчы регион! Татарларым, ни булды, машинагыз ватылдымы? Әйдәгез, буксир белән Чибәркүлгә алып кайтам! — дип безне күрүенә бик куанды бугай ул.

— Уфа юлын күрсәтсәң, бик рәхмәт, кунакка йөрергә вакыт юк, — дибез.

Ул безнең хәлне аңлаптыр, артык үгетләмәде. Үнике кеше икәнлегебезне күргәч, төн уртасында өенә алып кайтырга бигүк атлыгып тормагандыр.

— Иярегез, әйдә, Чибәркүлгә житкәч, мине узып китәрсез, Уфа юлы шул булыр. 60 тан артыгын куа алмам, түзәрсез...

Трактор тизлегенә ияргәч, билгесезлек, чарасызлык халәте чигенде, мәгәр, язгы төн эзәрлекләвеннән күнелне битарафлык, гамьсезлек биләп алды. Сөйләшергә дә иренеп изрәү, өстән-өстән генә уйланулар йокы карамагында иде.

Гадәттә мин, холкын — синең язмышың, диярга яратам. Алай гына түгел икән. Үз-үземә каршы төшеп барам әле... Кайчандыр шушы Чиләбе — Магнитогорски якларында бер ханым Борис исемле ир белән җитәкләшеп чуен юлларга шпал салган. ПМС[1] вагоннарында күәс камырыннан Зәмзәмия исемле кыз әвәләгән. Минем тормыш юлымның «стрелкасын» читкә борып, язмышымны пыран-заран китерер өчен... Бүген мин нәкъ менә шул якларда адашып йөрим. Кеше язмышы — чит кеше кулында түгелме?..

Яшьлегем хатасының көмәне шушы яктан.

Көпчәкле трактор Чибәркүл борылышына кереп югалгач, Чиләбе белән Өфе арасында гүя берүзебез генә бүленеп калгандай булдык. Дәверләр буе тапталган, гасырлар буе тузган, дистә еллар буе яңартылмаган таш җәймәдә без. Чакрымнарның күп өлеше мул суы ташлап качкан иске идел төбе кебек. Текә яр итәгенә ышкылып дигәндәй барабыз. Уң якта — яссы, чытырманлыгын югалткан куе кара чиксезлек. Әйе, әйе, кара чиксезлек... Бик беләсегез килсә — җиһандагы яктылыкның да чиге бар, ә караңгылыкның чиге юк, караңгылык — ул галәм белән тоташа...

Табигатьнең инде яшелгә манылган чагы. Ә бу текә ярга кышын кар да кунмый, ул елның дүрт фасылында да чем-кара — Урал тавының безгә мәгълүм булмаган файдалы казылмасыдыр. Шул кыяларга үрмәләп, ярыкларга колак салып, курай моңнарын тыңлыйсы, кантарларыннан асылташлар эзлисе килә.

Ләкин, бу юлның аулак урыннарында туктарга кушмыйлар, каршыңа таш тумраны тәгәрәп төшсә дә игътибар итмәскә, әйләнеп үтәргә, диләр. Болар барысы да — юлчыларның иминлеге өчен телдән-телгә күчеп йөри торган кагыйдәләр. Тау башында яңа гасырның аяусыз афәте сагалап тора. Электрон җиһазлар төялгән фургоннарны бушатып, Мәскәү базарына арзан мануфактура жыярга чыккан алыпсатарларны талап, чит ил автомобильләре урлап җәзасыз кала килгән тау юлбасарлары, ни кызганыч, пиратлар хакында уйлап чыгарылган борынгы әкиятләр түгел монда.

Безнең шофёр да рульгә ике куллап ябышкан, монысы төнге сәяхәттән күшеккән жанны жылыта бераз... Алай да Төмән белән Чиләбедә тамашачының аз булуы, «Бермуд өчпочмагы»нда адашып йөрүләр, кара, таулы юл шомлыгы — бөтенесе бергә кушылып, артистлар төркемендә отыры тынгысызлыкны көчәйтте; шәп маршрут дигән гастрольнең романтик рухын сындырды, администратор егетнең Казаннан чыкканчы ук солистларга өләшкән күтәренке вәгъдәсе, энәгә төртелгән шар кебек, күзгә күренеп шинә башлады.

— Уфага шалтыратып карарга кирәк. Билетлар авыр тарала, монда көн саен казаннар концерты, диярга ярата ул. Тагын шулай дип башласа, кереп тормыйбыз, «объездной»дан туп-туры Чаллыга китәбез.

Мин шундук администраторга каршы төштем:

— Башкорт вакыты бездән ике сәгатькә алданрак йөри. Төнге икедә кассиршаны йокысыннан уятып, нинди жавап ишетермен дисең?!.

— Без йокламыйбыз ич әле... Акча эшләү берәүгә дә жинел түгел...

Һәм ул, кирегә үгетләмәсеннәр тагы дигәндәй, ашыгып номер жыя башлады.

[1] Юл салу машиналары станциясе.

Сөйләшүдән анлашылган кадәресе шул булды: билетлар сатылып беткән, Өфегә күкрәк киереп керәбез, Ходайның рәхмәте... Минем өчен генә дә сәер яналык бар иде, конферансьегызны бер хатын-кыз эзләп килде дигәннәр. Түзмәдем, егеттән кабатлап әйттердем.

— Нинди хатын?! Нинди кыз?!

— Ике ботлы, ике беләкле, ди... Барыбер түгелмени?.. Яшьлек дустын дип әйткән бугай.

— Шаяртасыңдыр инде.

— Ие, төнге сәгать икедә 1нче апрель оештырдым ди сина...

Барыбер түгел шул... Күнелнең нәүмиз чагы. Чит шәһәрләрдә йөргәндә, кунак егет булып, кызлар белән күнел ачып, телефоннар алышып, фотолар яшереп сөяркәләр үрчеткәнем юк. Монысына кеше ышанмаса да, үз-үземне алдалый алмыйм. Иярләнгән концерт заллары санаулы гына, ике-өч сезон эчендә шул ук маршрут буенча кабат әйләнеп кайтасын, кынгыр эшләренне тамашачылар гайбәтеннән яшереп кара(!) Син килүгә махсус, афишаларга фломастер белән сызгалап, барлы-юклы авторитетынны кушаматларга таркатырлар... Өфе белгәнне төгәл ике сәгатьтән сон Казан сөйли.

Афиша димәктән, сонгы елларда минем исемне эре-эре кызыл хәрефләр белән яза башладылар. Ана карап әле монарчы берәүнең дә мине эзләп килгәне булмады... Төнге йокымны башваткычка алыштырган яшьлек дустым... Өфе кызы... Лена Фаткуллинамы?

Бик мөмкин... 1972 елда КПСС Үзәк Комитетының «Иҗат яшьләре белән эшләү турында» карары чыккан иде. Шул унайдан комсомолның Өлкә комитеты «Идел» яшьләр лагеренда атналык иҗат семинары үткәрә башлады. Май аенын җәйгә тоташкан көннәрендә, ике ел рәттән, мин дә шул грандиоз вакыйгада катнашу бәхетенә ирештем. Мин инде ул вакытта артезиан коелар бораулауга «Аллаhу-әкбәр!» әйтеп, Культура институтында «энә белән кое казу»га керешкән идем. Семинарга «Тәнәфес» дигән хикәямне сайлап алдылар. Проза секциясендә Иддар Юзеев, Аяз Гыйләжев, Әхсән Баяновлар аны әйбәт кенә мактап журналга тәкъдим итәргә дигән нәтиҗә ясадылар. Мин бу хөкемне уенга санап йөрдем. Ләкин, 1978 елның апрелендә, 80 мең тиражлы «Казан утлары»нда, исеме дә үзгәртелмәгән килеш, хикәям басылып чыккач, мин үзем-үзем сокландым! Нишләп сон син, шундый төшемле эшенне ташлап, егерме алты яшендә көндезге укуга килеп кердең, дип тинтерәтүчеләргә менә дигән җавап иде бу.

Журнал чыгып, атна-ун көн үтмәгәндер, Уфадан хат килеп төште. Лена Фәткуллина дигән кыз хикәямне бик яратып укыган, фотомны күреп, мине башкорт егетенә охшаткан...

Лена белән без бер-ике тапкыр хат алышып өлгердек. Ул, никтер, фотосын җибәрергә ашыкмады, студент кешенең Өфегә свиданиегә барырлык вакыты юк та: көнозын укуда, кичен эшкә йөгерәм, җәйге каникулда студентларның төзелеш отряды белән китәм. Ике арада әкренләп хат йөрүдән туктады. Соныннан шунысы ачыкланды: Казан университетын тәмамлап: «Азатлык» радиосында эшләгән талантлы журналист Фәнис Фәткуллин Лененың бертуган энекәше булган икән.

Шул елны хикәям «Замандаш» конкурсында III урынны алды... Шактый ук алга таба китеп әйтсәм дә ярый, «Тәнәфес»тән сон дистәләрчә китабым дөнья күреп, дүрт роман, җиде повесть һәм күпме хикәя бастырып, мина Лена кебек сөендереп хат язучы кызлар бүтән булмады... Кем син, Лена?..

Администраторга ачуым кабара бара, Уфадан аншлаг дигән хәбәр алгач, баһадир йокысы белән гырлап бара. Мин киерелгән булып, утыргычка ябышкан гәүдәмне турайттым, егетне уятыр өчен. Чыннан да, ул кисәк уянып як-ягына

каранды, ул-бу юклыкны сизгәч, кабат йокыга чумарга ниятләп башын кыңгыр салды. Ачуы чыкса да түзәрмен, сорашмыйча хәлем юк.

— Мине эзләгән кешене Лена димәдеме?

Җавап озак көттергәч, ишетмәмешкә сабышты бугай дигән идем, ә ул фикерен җыеп интегә икән:

— Исемен әйтте әйтүен, рус кызы түгел.

— Лена — татар кызы. Башкортстанда руслар исеме кушу модада ул. Бәлки Ритадыр? Люба түгелме?

— Юк инде, юк! Әйтәм ич, саф татарча, сирәк очрый торган исем.

— Илсөяр... Сәвия... Тәнзилә...

— Юк.

— Назлыгөл түгелме? — диде Назлыгөл, мине үртәп. Тәки, йоклаган ише кыланып, безне тынлап бара икән.

— Юк. Назлыгөл дә түгел. Рәхиләме, Сәрияме?.. Шундыйрак исем.

— Рәфинә түгел инде, анысын юри уйлап чыгарасың. Слушай, бәлки Сәвиядер? Сәвия!

— Вәт, нәкъ өстенә бастың, яшьлек дусты Сәвия, дигән. Инде тынычлап йокла, калганын иртәгә сөйләрсең.

Йокы... Болай да ярты гомеребез диярлек йоклап үтә. Чынга ашырасы хыяллар хакына яшисе иде әле, йокыны җиңәрлек исемнәр барында...

Илсөяр, Сәрия, Наилә, Назлыгөл, Сәвия...

Бу исемнәр минем хәтер лабиринтында чатыр корып яшәп ята: искә төшергәнне көтеп, онытыбрак торсам, вак-төяк истәлекне дә зур сәбәп итеп, күз алдыма килеп баса; тымызык ым кагып, өемдәге көйне боза; төшләремә үтеп керә; минем белән утыз ел буе ингә-ин, күзгә-күз, мендәргә-мендәр ышанып яшәгән Нуриәхмәт кызының түгәрәк көзгесеннән яшь китерә...

Бу исемнәр белән минем күңелем шыгрым тулы.

Мине Сәвия эзли... Исемен ишеткәч тә сагынуым көчәя башлады. Нинди тыелгысыз ашкыну соң бу?! Гамәлдән чыккан сөюдән нәрсә көтәм? Бу көрешү икебез ике якта корган гаилә бәхетен чагыштырып карар өчен кирәкме? Әллә үкенүләр өченме? Гомерем буе Сәвия белән көрешүләрдән куркып яшәдем. Авылыбыз Сабантуйларына кайтмас булдым. Көрешә калсак, сер бирмичә тыелып калырга, күрмәмешкә сабышып кына үтеп китәргә көчем җитмәс, яшьлектәгеге кабатлар өчен ялынырмын, үгетләрмен кебек идем... Ә хәзер шушы ук көрешүгә үзем ашкынып керәм. Аның өчен генә саклап йөрткән сорауларым бар. Безнең буын инде хисап көненә керде. Бер-беребезне эзләп табып, җавап тотар чагыбыз җитте. Шуңа күрә дә безнең яшьтә очраклы дип әйтердәй көрешүләр була алмый... Яшьтәшләрем дә минемчә җирсү, минемчә юксыну белән олгаядыр лабаса?! Кемнәрдер мине дә эзләргә тиештер бит... Без инде һәммәбез дә кичәге көннәр күләгәсендә яшибез. Хәтер җебе ялгау-ялгау, вакыйгалары төен-төен...

Сәвия...

Сәвияләрнең өен мин бура вакытыннан хәтерлим. Рәшәткә читендәге чирәмлектә шаңгырдап торган нарат бура. Ундүрт эргәле. Монысын төгәл хәтерлим, чөнки июль башында, миңа ундүрт тулган көннәрдә күтәрделәр. Мишә буеннан су коенып кайтышлый, буралары янында туктап, ял итеп ала идек. Сәвиянең бөтен нәселе Тукай урамында. Өч чакрымлы авылыбызның тагын алты урамыннан пүнәтәйләр белән эзләсәң дә, бүтән туган-тумачасы юк.

Тукай урамы бозлык чорыннан өелеп калган ак ташлы тау битендә. Анда тургайлары сайрап торган болытлар да бик якын иде. Сәвияләрнең бурасы,

кояш нурын үзенә сендергәнме — әллә кайдан — ерактан, Казан юлыннан ук балкып тора иде.

Бураларының чаеры кипкән арада миңа унбиш тә тулып алды. Иске өйләрен сүтәргә бик ашыкмадылар.

Ул җәйне без су коеныргa ешрак йөри башладык. Ник дисәң, җәйге каникулга чыкканчы ук чиллә башланды. Күпне күргән агайлар моны үзләренчә аңлатты: кыш җылы килде, җир туңмады, эрегән кар сеңә барды, ташулар хәлсез булды; икмәкне көл өстенә чәчеп кайттык, дип сөйләделәр. Күптәннән сыналган — корылык ел билгесе бу, диделәр.

Авыл кызды. Көн уртасында капка келәсен тотар хәл юк — кулны пешерә, бар яшеллек төсен салды, юлларда тузан күперде, бәрәңге сабаклары ябыкты.

«Карга боткасы» уйнарга куштылар.

Борын-борын заманнан калган уеннар, йола бәйрәмнәренең кайсысын гына телгә алма — алар барысы да яшь парларны табыштыру-кавыштыру өчен уйлап чыгарылган. «Кич утыру», «Каз өмәсе», «Әрәпә җыю», «Авыл артына чыгу», «Сабан туе», хәтта... «Карга боткасы» да. Без ул йолаларның соңгы егетләре...

«Карга боткасы» дигәч, безгә бала-чагалар гына түгел, кыз-кыркын, егет-җилкенчәк тә иярде. Тезеп санасаң, егермеләп булырбыз, шәт. Өйдән-өйгә йөреп, әүвәл йомырка җыйдык. Уен бетәргә, Сәвиянең әнисе боламыгын пешереп куярмын, диде.

Тукай урамы сулы ярда, адым саен улак, авылның буеннан-буена чишмәләр челтерәп тора. «Карга боткасы» уйнаганда, кеше өстенә инеш суы сибү дигән нәрсә юк бездә, халык хәзер матур киенә, суга чыланса да, өс-башы чиста калсын, уенчыларга сүзе булмасын.

Кемне эләктерәбез — шуны коендырабыз, кем кача — икешәр-өчәр чиләк су күтәреп куа китәбез, мотоцикл килсә — сүндергәнче манчыйбыз... Авылга чыр-чу таралды, юеш тузан исе күтәрелде... Сары Кәрим кызы кибеттән кайтышлый Сәвияләр бурасына ышыкланып котылмакчы булган да аны Мөхәммәт эзләп тапкан. Чиллә күзендә бер чиләк чишмә суыннан сазамык түткәйнең тәне тартышкандыр, күрәсең: «Ах паразит, ах заразы!» — диепләр кычкырып, сумкасындагы сургучлы чәкүшкәсен Мөхәммәтнең баш түбәсенә бәреп ватты... Мөхәммәт йомычкалар өстенә ауды. Кемдер ачудан Сары Кәрим кызына чәрелдәтеп тагын бер чиләк су тондырды. Тиз генә пожарныйга барып, авылда «ашыгыч ярдәм» машинасы урынына йөри торган җигүле атны алып килдек. Мөхәммәтне солы саламы түшәлгән кабык арбага сузып салып, медпунктка илттек. Ни хикмәттер, Сәвия белән без аны озата барып, җәрәхәтендәге пыяла ваклары чүпләп, башын бәйләп чыгарганнарын көтеп тордык. Мөхәммәт өенә үз аягы белән кайтты.

Уен өзелде...

Без медпункттан әйләнеп килгәнче «карга боткасы»н ашап бетереп, чуенын корытканнар иде инде. Ходайның рәхмәте, шул кичне үк яңгыр килде, таң атканчы яуды...

Сәвия белән без туганлашып калдык. Мәктәп бәйрәмнәрендә биюле кичәләр булса, икәүләшеп катнаша идек. Вальска чыксак, ул минем иңбашыма кулын куяр, ә мин аның биленнән тоткан булам... Ләкин, икебез дә башны ике якка борып, ул үзенә кемнедер эзли, мин үземә һаман кемнедер эзли идем...

Уен өзелгән иде...

Уен гына өзелмәде. Сәвия белән ике арага тургайларыбыз түгел, хәтта тимер кошлар да үтеп чыга алмаслык тирән упкын уелган иде...

***

Уфа—Чиләбе юлының чама белән яртысын үтеп, Аша дигән ризыклы тукталышында артистлар берәм-берәм жиргә коела башлады. Урынымнан кузгалмадым, кафе-ашханәләргә иң беренче булып барып керә торган гурман бит мин, югыйсә... Баянчы Ринат Вәлиев тә моны сизеп алды.

— Кәрим абый, авырыйсыз мәллә? — диде ул, догалары белән ярдәм итәргә теләгәндәй, нурлы йөзенә гамь чыгарып.

Ерак сәфәрләргә йөрсә дә, Ринат биш вакыт намазын калдырмый, Сергач мишәрләренә хас төгәллек белән Ходай каршындагы бурычын үти. Соңгы рәттәге урыннарны аңа мөнбәр итеп калдырырга тырышабыз.

...Хәвефле сәфәрләр бик күп артистларны дин юлына алып керде...

Алгы рәткә авышкан администратор Маратның ныклы тавышы ишетелде:

— Автобусны үзем саклыйм!

Саклар да шул. Казанның «УНИКС» залыннан арендага алынган радиожиһазлар анын өстендә. Ак калай белән тышланган әржәләрнең берсен генә урлатсаң да, түләр өчен бригадан ай буе бушка эшләячәк.

Икәүләшеп саклыйбыз. Сәвия турындагы уйларым ачлыкны жиңде... Юк, жиңмәде, Сәвиянең минем арттан Магаданга килмәвенә үч итеп, утыз елдан соң ачлык игълан итәм!..

Бераз жилләнсен дип алгы ишек ачык калган иде. Салонда хужа юк дип уйладылармы, үз өйләренә кайткан кебек, һичбер тарсынусыз-нисез, яшь кенә ике «шомабаш» килеп керде. Марат белән икебезне күргәч тә бик исләре китмәде, сумкаларны этә-төртә урын ипләделәр.

— Куда?!! — дип кычкырды Марат. Бу сорау түгел, бу — приказ иде.

— Моннан унбиш чакрымда машинабыз сүнеп калды, сезгә утырып барабыз, — диде шомабашның берсе, вәкарь белән генә.

— А ну встали!!!

Марат чакырылмаган кунакларны каршы алырга әзер булган икән, тегеләрнең әрсезлегенә ышанып, автобус шүрлегеннән, тастымалга төрелгән ике көпшәле «обрез» чыгарып, гәүдәләрәгенең аягына төбәлде. Ике тәтене дә киереп куйгач кузгалдылар, анда да кабаланмыйча, тыныч кына...

Кесә телефоны шундый чакларда кирәк тә инде ул. Кафедагыларны ашыктырдык, «разборка» булуы да бик ихтимал иде.

Артыбыздан куа килүчеләр юкмы, дип ярты сәгать чамасы сагаеп баргач, әкренләп тынычландык, безнең төркемдә ирләрнең күп булуы өркетте ахрысы үзләрен, бәлки мондый бәрелешләр бу тирәдә гап-гади күренешкә әверелгәндер...

Юл озын, вакыт иркен — бөтен язмышыңны уйдан кичерергә житә.

***

Бүген төн уртасында, Милади елның мең дә тугыз йөз алтмыш тугызынчысы дөньяга туа! Тулгагы башланды инде... Башка көннәрдә кичке тугызда ук ут сүндереп куя торган нужакуар авыл, жиң сызганып, йокысыз төнгә әзерләнә: балачакта калам дисәң — мәктәптә бал-маскарад көтә; ирләр арасына кереп «үсәсең» килсә — клубта чыршы бәйрәме. Өлгергәнлегеңә аттестат алгач, егет кеше укытучылар арасына бәйрәм эзләп керерме?!. Кире кайту юк! Үсәргә тек үсәргә! Тизрәк ир кеше буласы килә.

Халык әйтә: ир кеше әүвәл агач утыртырга, өй салырга, аннан бала үстерергә тиеш, ди. Әйе, китап кушканча бәхетле тормыш турында хыяллансаң, кыласы күркәм гамәлләрең шушы тәртиптә үтәлергә тиештер. Ә мин, оят булса ни әйтим, язмышымны «бала ясаудан» башладым... Аннан соң гына, алты кубометр

утын алыр өчен, Богомол Мөхәммәт абый бригадасына ияреп, «Сыер күле» тирәсенә ун гектар нарат үсентесе утырттым. Шушы Яңа ел төненнән соң кырык ел үткәч кенә, ата-бабаларыбыз үстереп биргән «Коры Елга» делянкасыннан бер бурага җитәрлек деловой нарат төяп алып кайттым...

1968 елның 31нче декабре.

Калын карлы йомшак кыш. Бураннарның тынганына атнадан арткандыр инде: тыкрыкларга такыр юл, өй түрләренә керле сукмак төшкән. Тавык-казлар ябылуда. Көрпә тагаракларын ишегалдына чыгармагач, чыпчыклар кавеме абзар кыегында үчегеп чыркылдаша. Салкын моржага кунган ике чәүкәне очкылык тота. Мич ягарга вакыт инде.

Әни бүген силос базы тирәсендә кар көрәүдә. Нәрәтне кая бирсәләр дә, кышкы кыска көннәрдә төшке ялсыз гына эшлиләр. Караңгы төшкәнче кайтып җитәргә тиеш.

Безнең әни өч ятим үстерде. Шулай да, Яңа ел каршылыйбыз дип, өебездә чыршы бизәлгәнне хәтерләмим. Һәрхәлдә безнең ише гади колхозчы гаиләсе өчен ул чын мәгънәсендә мәктәп бәйрәме. Сынар әфлисун, ике алма, дүрт прәннек, сигез карамель салынган рәсемле пакет бирерлек Кыш бабайдан гайре тагын нинди туганым бар соң минем?!. Аһ, ул елга бер генә тапкыр эләгә торган әфлисунның уч төбендә чыршы урманы исен бөркеп торуы, хәлвә эчле карамельнең тел очында озак итеп эрүләре... Кыш бабайның Себердән килмәгәнен, физика укытучысы икәнен бик яхшы беләбез. Кар кызы да сатучы Сәгадәт апаның уртанчы баласы... Беләбез! Шулай да сөенәбез, алар бит башка көннәрдә бушлай бүләк өләшми. 31нче декабрь төнендә олысы-кечесе әкият көтә, ырым-юрамышларга, вәгъдә-котлауларга ышана, Яңа елның иртәгесе яңа көнен ашыктыра. Иртәгә без барыбыз да тигез, сөекле (һәм хәтта мин дә) бәхетле булачакбыз!

Үзең турында язганда, шунысы кыен: күзгә яшь тыгыла...

Культура йорты дип әйтү авылыбызга бигүк килешеп бетми сыман. Крупская заманыннан калганча, клуб инде ул бездә...

Җәй көне танцы-мансылар уздыра торган тәрәзә астындагы мәйданчыкны кар чүмәләсе каплаган, алай күп ямады ич әле, фойе белән зал кушылган сынык түбәдән ишелеп төшкәндер ахрысы. Караңгы төшкәнгә инде ярты сәгатьләп бардыр. Юктан кызык табып көлешкән мәктәп малайларыннан гайре иптәшкә ярардай кеше күренми. Әллә Күн урманыннан чыршы таба алмаганнармы, Яңа ел киче гыйнварның беренә күчте микән дигән шигем бар. Чүмәлә төбәсенә басып, тәрәзә аркылы гына фойены күзәтәм. Әнә ул... унсигез яшьлек чыршы... Киң итәкле яшел күлмәк кигән кунак кыз кебек киенеп-ясанып, төзәнеп-бизәнеп кыл уртада басып тора!.. Зурлар әкияте, мажаралар, танышулар өчен урын буш әле анда... Башта кино карыйбыз...

Җимгә төшкән күгәрченнәр ише — бик тиз җыелды халык. Халык дип яшь җилкенчәкне әйтәм, баласы-чагасы булган абыйлар, апайлар гына түгел, яңа өйләнешкән егетләр, кызлар да клубка чыкмый бездә. Тол хатыннарга, кияүдән кайткан кызларга, буйдак иргә — пожалысты. Ара-тирә тәрҗемәсез генә сүз кыстырсам кичерегез, юкса, Люба белән тагын күрешә калсак, урыс телен бөтенләй онытып бетерүем бар.

Кинодан соң, уеннар тамаша күрсәтә торган якта башлана. Завклуб авылда кемнең нәрсәгә һәвәслеген белә. «Ачык сәхнә!» дип игълан итте дә чыгыш ясаучыларның исемнәрен үзләреннән сорамыйча да алдан ук исемлеккә теркәргә кереште. Катнашучыларны колхоз идарәсе сатып алган бүләкләр көтә... Иң соңыннан лотерея уены үткәрелә, иң зур отыш — көмеш муенлы шампан шәрабы...

Түземсезлек белән залда ут сүнгәнне көттем. Пәрдә яктысы алгы рәттән ары китми, эңгер-меңгер эчендә, кыюланып, уртаданрак буш урын эзлим. Мин генә түгел, тагын бер-икебез тыз да быз килеп рәт арасына сыенды. Ниһаять, кыл уртада тик бер генә буш урын барын шәйләп алдым. Артык уйлап торырга вакыт юк, озын буйлы егетләрчә баш иеп, ике кыз янындагы бушлыкка кереп киттем. Шушы рәт башында стенага сөялеп калган Фәтхулланың «Ялгышасың!» дигән пышылдавы да туктата алмады.

«Утырсам ярыймы?» — дип икесеннән берьюлы сораган идем, үзара колактан колакка нидер пышылдашып өлгерделәр.

«Ярый, ярый» дигән җавабыннан Балдамай Габделхәенең төпчек кызы Рәзифәне танып алдым. Аның күршесе, ягъни минем янга туры килгәне кунак кыз булып чыкты.

Берара тын гына иялләшкәч, урыныма лаек түрә кебек гәүдәне турайттым, башны горур чөйдем. Сер бирмәгәнгә сабышсам да, кунак кыз белән танышасым килеп, көчкә түзеп утырам. «Әзрәк вакыт үтсен әле, күрше-тирә минем хәлне күзәтүдән туктасын, теге Фәтхулланың «ялгышасың» дигәнен шәрехләргә кирәк. Тәк, Фәтхулла...» Сигезне бетергәнче бергә укыдык, дөресрәге мин аның өчен дә укыдым. Отряд советы кушуы буенча, өйләренә барып дәрес әзерләшәм. Өйгә бирелгән эшләргә тотынганчы, ишегалдына чыгып утын ярышам, тирес түгәм, сыер абзарын җыештырам, малларына су эчертәм, печән салышам... Аннан соң гына: «Уф, Алла...» — дип дәреслеккә тотынабыз. Фәтхулла мин ятимнән бәхетсезрәк — ул үги әтиле ятим. Яңарган гаиләдә инде ике сенелкәше дә бар, тик алар кечкенә, әлегә кул арасына кереп булышырлык түгел. Үги әтисе — колхозда ат җигүче. Йорт тирәсендәге бөтен ирләр эше җиденче класс малае Фәтхулла өстендә. Гаилә хәлләрен аңлаптыр, укытучылар күчми калуын теләмәделәр, мине шефлыкка беркетүләре дә ярдәм йөзеннән. Сигез классны тәмамлап, Казанга китүенә иң сөенгән кеше мин булдым! Борисково бистәсендә Теплоконтроль заводы бар икән, Фәтхулла курслар бетереп, шунда слесарь-сантехник булып урнашкан. Тәк... Балдамай кызы Рәзифә дә «теплоконтроль» ашханәсендә эшли... Димәк, «икеле-берле» Фәтхулла әлеге кунак кызга үзе кызыгып йөри... Аны якын китермәгәннәр, ә саклап тоткан буш урын миңа эләкте!

Шарф ярыгыннан күренеп торсын дип, чыгарылыш кичәсеннән калган атлас галстукны таккан идем, дулкынланудан муенымдагы җөй кызыша башлады. Күлмәк якамның өске сәдәфен ычкындырган арада кунак кыз ягына борылып алдым... Баш түбәсенә такыясыман үреп салган чәчен Төркиядән посылка белән генә кайтартыла торган купшы ак кәҗә мамыгыннан эрләнгән эре шакмаклы шәлгә төргән; шәлнең бер почмагы түгәрәк якалы сары пәлтәсенең ачык изүеннән күпереп чыккан; кулында бармакларына сыланып торган юка күн перчатка. Йөзенә туп-туры карап өлгермәдем, ну беләм — безнең авылда моның кебек чибәр кыз юк. Ни сөенергә, ни көенергә белмим. Ачык сәхнә ябылыр, залда кинәт ут кабыныр... Минем өс-баш яктыга чыгып хан курчагыдай күркәм кызга иярердәйме? Кыш буе кияргә тиешле көзге яшел пәлтәм... Солдат пилоткасына охшатып тегелгән колакчынсыз сарык «папаха»... Йон бияләйне кесәдән чыгармам пожалый... Муенымдагы җөйне юка зәңгәр шарфым белән каплармын... Аллага тапшырып, тәвәккәлләргә кирәк.

Авыл артистларының кызыгы беткән арада залдагы халык «базар» ясап ала, тавышыңны тыймыйча сөйләшсәң дә исләре китми.

— Минем исемем...

— Беләм! — диде кунак кыз. Үзе Рәзифәгә карап көлемсерәгән була.

— Ә синеке? — минәйтәм, иске танышлар кебек, «сез»ләмичә генә...

— Зәмзәмия, — ди бу.

— Фәтхулла ник утырмаган булды?

— Чакырмаганга күрә... Заводта да гарык аннан.

***

Әйткәнем бар инде: мин кечкенәдән рәсем ясарга ярата идем. Кыш бабайның колагына укытучылар пышылдаганмыдыр, чыршы бәйрәмнәрендә сабакташларыма исле сабын, уенчык, пенал ише нәрсәләр эләксә, мина гел диярлек буяу карандашлары бирәләр иде. 1963 елның җәендә, безнең авылга Харис Якупов килеп төшкәндә, буяунын буяудан аермасын күрә башлаган идем инде мин. Җае чыкканда, зур рәссамга ияреп, колхозның көчле кешеләрен эзләштек. Кыр батырларының өйләрен күрсәтәбез, савымчыларны җәйләүдән табып бирәбез, маллар утлаган җирдә мактаулы көтүчеләр барын да беләбез... Шунысы сәер: үзебез туып үскән авыл кешеләре рәсем өлгеләрендә монарчы без күрмәгәнчә соклангыч, горур, көчле һәм изге затларга әверелә. Чокыр-чакырлы юллар тигезләнә, челләнең тузанлы кояшы яктыра, күгәргән урман жетеләнә, чәчәкләр канатлана... Бөтен хикмәт бизәүдә! Харис абый алып килгән буяулар серле димәк! Әгәр шул буяуларны чәлдерсәк... Юк, чәлдерсәм... Мондый изге серне башкалар белән бүлешеп, туачак сихри матурлыкны уртак сөенеч итәргә ярамый... Ул минеке генә булырга тиеш!

Тәки чәлдердем!

Шомырт куагына кунып сайраган былбылга кул сузымы ара калганчы якынайганым бар... Җыр туганда кошлар да һавәсләнеп, бар дөньясын онытып тора икән. Харис Якупов та Мишә куенындагы атауны кысалы киндергә күчергәндә, тормыш гамен онытттырырлык мавыгуга чумган иде. Яшел фанер белән тышланган тоткалы тар сандыгы гел ачык. Анда буяуларның нинди генә юк: зур төймә кебек тезелгәннәре, хәлвәле конфет кебекләре, бармак юанлыгы карандашлар... Мин шудырганы сыгып чыгара торган теш пастасы кебек иде. Өйгә кайткач, ишек келәсен элдем дә чәлдермеш малны күреп «аһ!» иттем: салават күперенең сары төсе эләккән — Кояштан коелганы!

Илле ел үткәч, мин бу вакыйганы «Казан утлары»ның ел азагында җыйнала торган редколлегиясе белән чәй эчкәндә искә төшерермен. Табын артында тиз арада күңелләре нечкәргән иҗатташларым, мина ияреп, үзләре кылган шуклыклары белән мактаныша башлар. Ләкин аларның күрше әби кетәклегеннән урланган йомыркалары, мәчеттән — дисбе, китапханәдән — сүзлек, иҗат йортыннан — штопор, хәтта Мәскәүнең Съездлар сараендагы банкет залыннан чәлдерелгән көмеш кашыклары да Харис Якуповның сары буявы янында төсен вә кыйммәтен югалтып, вагаеп калды...

Рәссамның авылдан киткәнен көтәргә түземлегем җитмәде, бикләнеп буяуга чумдым. Тәрәзә төбендәге гөл чүлмәкләренә тузганак чәчәге, көзге рамы, почмактагы шкаф янагы, сәке аяклары һәм, әлбәттә, рәсем дәфтәрендәге өйләр, агачлар, балаларга — хәтта этләр, песиләр, куяннарга да сары төс керде... Буяу бетте, төсләр сүнде, серле пумала гап-гади бер коры таякка әверелеп калды. Рәсем ясауга гыйшкым сүрелде... Ә шулай да төннәр буе төсле төшләр күреп саташам. Һәр күргән манзара, үтелгән көн, чынга ашырга тиешле хыялларым рәсем-рәсем булып хәтеремә сенеп бара. Күңел чиксез бит ул — анда җанын теләгәнчә бихисап рәсем, күргәзмә заллары сыя... Мин үзем гашыйк булырдай кызның сурәтен дә күрәм... Һинд киноларын карасам, мәхәббәт турында җырлар тыңласам, шомырт чәчәкләре иснәсәм — чем-кара толымлы, коңгырт карашлы, аяк чокырына имән бармагын куеп авыз ермыйча гына елмая торган, тыгыз тәнле, буйга миннән бераз гына кыскарак булган идеалым күз алдыма килә дә

баса. Ул кызны очратыр өчен миңа әле сикәлтәле юллар аша бик күп илләр-җирләр кичеп, билгесез сәфәрләр кылырга, эзләп тапканчы туктамаска кирәк булыр. Мин бит әле бу дөньяны рәсемнәрдән генә күреп беләм.

Харис абый Якупов рәсемнәрен кайда гына күрсәм дә, иң әүвәл алардан сары төсне эзлим хәзер...

Шул елны мин шигырь яза башладым... Олы юл өстендә яшәгәч, Казаннан безгә атна саен диярлек концерт килә. Яңа җыр ишетсәм, көен отып алам да сүзләре урынына үзем чыгарган шигырьне өстәп куям. Нарат урманы тирәлеп тора, эчкәрәк керәм, кеше күрмәслек итеп сыенам да җырлап җибәрәм!

Мин бу язга тагын сине эзләп кердем,
Төшләремдә бүген тагын сине күрдем...

Җыр, нарат делянкаларын айкап, беразэзләнә дә: «Монда юк әле синең идеалың», — дигәндәй янә үземә әйләнеп кайта...

***

Ут янгач, өйрәтелгән халык тоташ агым булып фойедагы чыршы янына юнәлде. Мин Зәмзәмия белән янәшә барам. Әйдә, дип әйтүче юк, хуш дигәнен дә ишетмәдем. Кунак кызга башкалар күз салмасын өчен бераз сөйләштерәсе булыр, арага кермәсләр.

— Зәмзәмия, син безнең районнанмы?
— Ә син үзең кайсы районнарны беләсең соң?
— Ну, Актанышны. Абый шуннан өйләнде.
— Тагын.
— Мамадышны:

Акты, дисвительни факты!
Мамадыштан кайткан чакта,
Бер шешә аракыбызны
Ат типте дә ватты!

— Тагын нинди мәзәкләрең бар?
— Абзекай гынам, Чистопольга каян кайтасы?
— Почти минем як инде. Каманың теге ярында.
— Булганым юк шул. Ну, Татарстан картасын яттан беләм.
— Бүген шигырь яздыңмы соң?
— Ә син аны каян беләсең?
— Мин әйттем! — диде Рәзифә. — Әти бүген синең шигыреңне «Җиңү байрагы»ннан кычкырып укыды.
— Көлепме?!
— Жук, ник көлсен. Мактады. Менә, тумышыннан ятим бала, авырлык белән үстерде Мәдинә, күрерсез, шагыйрь булып китәр әле бу малай, диде.

Алай икән... Димәк, Рәзифә инде Зәмзәмиягә минем турыда пышылдап өлгергән. Караңгы чырай күрсәтүче юк. Кыюрак булсак та ярый.

— Зәмзәмия, чыршы янында икәү танцевать итәрбез ич инде.
— Үзең җавап бирмәдең, әле миңа шигырь яздыңмы бүген?
— Көне ул түгел. Ёлкага багышлап миллион шигырь язганнар инде, — дигән булдым. Мин үзем миллионны бигүк күз алдыма китерә алмыйм әле, шулай да матур сүзләр кыстырып сөйләшкәндә, кунак кызлар алдында культурныйрак килеп чыга.

— Миңа багышлап язмадыңмы, ләхер? — диде Зәмзәмия, уенын-чынын бергә кушып.

— Бер дә белмәгән килешме?

— Белгән кешеләрнең кызыгы юк та. Шигырьне мин серле булырга тиеш дип беләм.

— Ә танцевать итә алмыйсың бүген, — дип сүзне алдырып китте Рәзифә. — Безне өйдә көтәләр.

— Сездән башка чыршы янына керәсем килми инде хәзер... Озатып куйсам ярыймы суң кунак кызыңны?

— Озатып куй, озатып куй, — диде Рәзифә. Ул никтер Зәмзәмиянең ризалыгын сорап та тормады.

Кунак кыз янында утырып тамаша карауны бигүк очраклы күренеш дип әйтмәс идем мин. Ике сәгать буе бер-беренә түзеп, житмәсә колактан-колакка пышылдашып та утыра алгач — димәк, бу киноның азагы әле урамга чыккач та дәвам итәчәк. Яшьләргә бик таныш фал инде бу... Әнә, Сәвия дә күреп алды, эзләгәнең шушымы инде дигәндәй үртәүле карашын яшерер өчен башын аска иде. Кунак кызлар барында авыл кызлары ял итә...

Клубтан кайтышлый еш борылып карыйсың инде ул, кемнәр ияргәнен, озатып куясы кызыңның капка төбенә тагын нинди егет килеп басасын белеп, кирәге чыкса, көтелмәгән аңлашуларга алдан ук әзерләнеп, йодрыгыңны йомарлап торасың.

Кунак кызларга чи чаер кебек сылана торган карт буйдаклар, кыюлык өчен генә әче бал йотып чыккан әрсез шалапайлар чыршы тирәсендә мажара көтә бугай, безнең артта җигүле чана табаны сыярлык такыр юл тынып — ял итеп калды. Клуб тирәсендәге яктылык куышыннан ерагайган саен, Яна ел күгенең йолдызлары ныграк яктырды. Көн саен шушылай әкияти матурмы авылыбыз, әллә бүген генә серле күренәме?

Заманында безнең авыл дүрт колхозга бүленгән булган. Балдамай Рәзифәсе яши торган як — элеккеге «Йолдыз» колхозы, хәзер аны өченче бригада дип кенә йөртәләр. Минем ул якка төнлә түгел, көндез дә бик барганым юк. Машина йә трактор белән булса бер хәер: олы урамнан туп-турыга да ике тыкрык унга... Ә монда тар чана эзеннән... Өчәүләшеп янәшә атлау мөмкин хәл түгел, сыймыйбыз, физкультура дәресендәгечә тезелешеп барабыз, Рәзифәгә ияреп. Сөйләшергә дә җайсыз, җавап ишетер өчен кар ерып янәшәгә чыгарга кирәк, урам буйлап кычкырып йөрмәссең ич!..

Рәзифәләрнең өе авыл читендә үк, ун минут чамасы йолдыз санап барабыз инде. Клубтан ерагаеп, төн түренә тирәнрәк кергән саен, мине билгесезлек үзенә ныграк йолып ала торды. Урамдагы суыктанмы — күңелдәге романтик дәрт сүрелә төште. Өчебез арасындагы тынлык гап-гади, көндәлек өметсезлек белән тулды. Колакчынсыз көймә бүрегемне әле бер, әле икенче якка авыштырып, колакларымны җылыткан булам. Көзге пәлтәм тәндәге җылымны үзенә алып бетерде. Әле кайтасы да бар... Казандагы адресын әйттерә алсам, кире борылыр идем, билләһи!

Шөкер, фанер көрәк белән тап-такыр итеп көрәлгән капка төбенә килеп бастык. Ботинка табанындагы карларны каккан булып тыпырдап алдым — үземчә аяк бармакларымның исәнлеген тикшерәм. Рәзифә: «Хәзер, торып торыгыз әле!» — диде дә шул уңайдан җылы өйгә кереп тә китте. Зәмзәмия белән ике ялгызлык боегып калдык. Ул капкага сөялде. Йолдызларның нуры бергә кушылып, Балдамайның нарат капкасын яктыртыпмы яктырта. Зәмзәмия кино экранындагы мәхәббәт кебек ымсындырып тора. Таңнар аттыра торган чак түгел, вакыт бик аз, сөйләштереп калырга, өйрәнчек гөсләче кебек үҗәтләнеп,

Зәмзәмиянең кылларын чиртеп карарга кирәк. Мин гөсләгә якынайдым. Алмагач кабыгы кебек шакыраеп каткан күн перчаткамны салып аңа үреләм.

— Кулың тунмадымы? — дигән булам.

— Юк! — ди ул, куян мамыгыннан эрләнгән бияләен миңа сузып. Мә, киеп кара!

— Зурайтам ич! — дигән булам.

— Югач утыра ул. Ки!

Кидем шул. Кими ни?!. Бияләйнең җылылыгын белсәгез — май ае инде миңа! Ул минем муенымда тузгыган шарфымны төзәтте, көзге пәлтәмнең тар якасын күтәреп куйды. Кунак кызлар миһербанлы шул.

— Синең күзләрең яшел икән...

— Йолдыз яктысында гына шулай ул, өйгә кергәч көрәнләнә, — дигән булам.

— Бар, кайт. Туңгансың син.

— Иртәгә клубка чыкканда каршы алырга килимме?

— Иртәгә...

Зәмзәмия теләгән сүзен әйтеп өлгермәде, кечкенә капка ачылып китте. Рәзифә икән.

— Әйдәгез, әти өйгә керергә кушты.

— Миңа дамы?

— Әйдәгез, дигәч, әйдәгез! Яңа елны каршы алабыз! — дип, Рәзифә икеләнерлек итмичә, этә-төртә дигәндәй мине капкадан кертте.

Унсигез яшемә җитеп, минем әле мең хуҗалыклы авылыбызның нибарысы җиде-сигез, арттырып санасаң, унлап өенә кергәнем бардыр. Әгәр Зәмзәмия кунак кыз булып кайтмаса, Балдамайның өй эчен гомердә килеп күрәсем юк иде.

Һәр өйнең үзенә генә хас исе барын беләм... Балдамайларның өй эченә юкә сәкедә киптерелгән балан кагы исе сеңгән. Ике тәрәзә арасындагы стенага терәп корылган өстәлдә табак-табак бөккән, өчпочмак, паштет кисәкләре. Бу ниг-ъмәтнең көндез үк пешкәнлеген сизеп торам... Таба ашы пешерү дигәндә, минем әни авылда бер оста, мичтән яңа чыккан ризыкны гына аера беләм.

Сорап та тормаенча, пәлтәмне салдырып чөйгә элделәр. Ботинкамны бусага төбендә калдырып түргә үткәч, юка оегым белән җылы суга кереп баскандай булдым — идәннәре җылы иде.

Зәмзәмия инде әллә ни арада сары пәлтәсен салып чөйгә элгән, җәйгечә калган. Маңгай чәчен уңъяк каш өстенә авыштырып тараган, өлгергән чикләвек төсендәге толымын баш чүмеченә әрдәнәләп өйгән. Иренәнә ягылган иннек төсендәге чия кызыл кофтасының юкалыгы гәүдә нәфислеген сурәтләп тора... Җәй килешер иде аңа...

Урындыкларыбыз Зәмзәмия белән янәшә туры килде, анысы әйбәт әле, кара-каршы утырсак, мин ашарга оялыр идем. Өч литрлы банканы авыштырып кына биш стаканга да әче бал салдылар. Минекенә шартларга җитешеп бүрткән кара җимеш төште. Моны Рәзифә күреп алды:

— Бәхет җимеше эләкте, — диде ул. Һәм бераздан өй эчендә тавыш югалып алды, герле сәгатьнең тел уйнатуын исәпкә алмаганда, бу минутны тынлык дип атарга ярый торгандыр.

— Әти, әни, Зәмзәмия, сине дә Корыч, бәйрәм белән котлыйм. Яңа елны кем белән, ничегрәк каршы аласың, алга таба гел шулай барыр, ди. Бергә булыйк, саулык, муллык, бәхет телим барчабызга!

Сәгатькә караган кеше юк...

Стаканнарны чәкештергән арада мин стенадан сәгать эзләгән булып кырын

күз белән генә Зәмзәмиягә карап алдым. Саулык, муллык, бәхет теләүгә куаныр, хуплар гына анысы. Ләкин ул бит әле «бергә булыйк» дигәнне дә каршы әйтмичә үткәреп җибәрде.

Аннан соң әтисе рәттән ике стаканны бушатты. Әнисе ана: «Күнелең булдымы? Әйдә, йокларга вакыт!» — дигәндәй сөелеп карап куйды... Алар, алдан ук сүз куешкандай, икесе бер булып табын артыннан купты. ЗАГСка чакырылган яна парлар кебек җитәкләшеп, алгы өйгә уздылар.

Әллә ни күп вакыт үтмәгәндер, бер өчпочмак кына ашап өлгердем — Рәзифә дә торып басты.

— Йокым килә. Яңа елны үзегез генә каршылагыз. Зәмзәмия, сиңа урын бу якта, — диде Рәзифә, юан аяклы агач караватка күрсәтеп. — Утны сүндерергә онытма. Юкса, урта ишекнең пыяласыннан безнең якка яктылык төшә. Пока!

Ул, үз артыннан ике канатлы урта ишекне шәпләп ябып куйгач, мин алдагы өйнең сизгерлеген тикшерер өчен генә әйтә куйдым:

— Яңа елга хәтлек ике сәгать бар ич әле.

Тегеләрдән ул-бу ишетелмәде.

Сәгать теленең текелдәвенә ияләштек. Инде матчага беркетелгән уклаусыман люминесцент лампаның черелдәве тынгы бирми. Урамдагы суыкның көчәюен күр — багана башындагы электр чыбыклары гөслә кылыдай зыңлый.

— Ут эчендә утырабызмы?

— Сүндерсәк, сәгать теле күренмәс инде, — дигән булам.

— Аларның бу сәгать фосфорлы. Саннары төнлә дә янып тора.

— Стаканнардагы балны кире бушатырга кирәк, — дигән булам, ут сүндерүнең хәл ителүенә сөенеп.

— Эчмисеңмени?

— Эчкәнем юк... Тартканым да юк, — дигән булам, сорамаса да, үземне әйбәт егет итеп күрсәтәсем килә.

Ул утны кайдан сүндерәсен белә иде, үзе китте.

Караңгыда калгач, мин кунак кыз белән әллә кайчангы танышлар кебек батыраеп, кила-килешенә үк биленнән кочып алып алдыма утырттым. Егылмас өчендер, ул кырынаеп, ике куллап иңемә таянды. Кызлар исләмәен бу кадәр якыннан иснәгәнем юк иде әле — исертә икән бит ул! Зәмзәмияне берьюлы: кысып кочаклыйсым, кулга күтәрәсем, куенына сыенасым, муенын тешлисем килә... Ичмасам, бөтен тынлыкның көен бозып, урындык шыгырдый башлады.

— Әйдә, тегендә күчеп утырыйк. — Әллә Зәмзәмия, әллә караңгылык үзе колагыма пышылдады бу сүзне?!.

Тегендә дигәнебез — юан аяклы агач карават инде.

Табыннан ерагайдык, ашау кайгысы юк. Яңа елның да соңгысы түгелдер әле — башка елларда каршыларбыз. Ерак араларны якынайтып, кемнәрнедер сөелүдән мәхрүм итеп, кунакка наз кайткан, минем бүгенге кичемә өлеш булып, нарат күркәсе ачылырдай җылыда, агач карават кырында, серле билгесезлектән күңел юанычы көтеп утыра.

Кыш көне алып кайтып мич башына җәйсәң — нарат күркәсе ачылып орлык коя... Минем әле унсигез яшемә җитеп, ятлар кызыгырдай кызлар белән карават җылысында утырып караганым юк. Клубта вальска чакырсаң, кызны биленнән кочып әйләнергә була; чишмә буенда таң аттырсаң, туңасыңдыр дип пинҗәгеңне иңенә саласың. Зәмһәрир суыкта капка төбенә чаклы озатып куйсаң, ашык-пошык саубуллашасың да җылыныр өчен тизрәк өеңә йөгерәсең... Ә монда, бүгенгәчә бөтенләй белмәгән-күрмәгән-ишетмәгән кыз белән яңа гына танышкан килеш,

икәүдән-икәү генә калгач,ниләр эшләргә мөмкин булса, инде шөкер, артыгы белән эшләнде... Кайтып та китәсе килми. Тәнемдәге һәр күзәнәк сусау белән тулды — тик су эчәсем килми. Шушы көнгә кадәр җанга тынгы бирмичә җыелып килгән иясез мәхәббәт хисе эчтән бәреп чыгардай булып үрсәләнә: тагын, тагын, тагын нindидер ачыш бар әле дип чамасыз ашыктыра, уяулыкны йоклата.

Менә кайчан кирәк син — Илаһи Сүз!

— Зәмзәмия, иртәгә клубка чыкканыгызны көтеп торырга түземлегем җитмәс, өегезгә килеп алырмын. Рәзифәгә әйтерсең, яме...

— Бая ук җавап бирә башлаган идем, бүлдерделәр. Иртәгә китәбез.

— Ничек инде?!. Озын ял бит әле! Үз авылыңа кайтасың бармы? Егетләреңне сөендерергәме?

— Әллә син көнче кешеме? Көнче егетләрдән бик куркам мин...

— Белмим. Бардыр инде бераз. Күрешеп җитмәгән, китәм дисең ич.

— Безнең авылга кыш көне кайтулары җинел түгел. Самолёт очса, Чистай аша, очмаса — Норлат аша, буран чыкса, җәйгә шае юл юк.

— Шулай булгач, кунакта ят рәхәтләнеп.

— Завод планны үтәмәгән. Иске ел өчен тагын ун көн эшлисе бар, диделәр. Ялны кыскарттылар.

— Алайса Рәзифә дә... Фәтхулла да китә инде сезнең белән.

— Фәтхуллагыз теләсә нишләсен. Аңа минем керешем юк... Ә менә бераз ятып ял итеп алсам ярар иде. Иртәгә икенче сменага чыгасы.

— Өлгерерсең. Казаннан безгә көн саен өч тапкыр автобус килеп тора. Минутына чаклы төгәл йөри.

— Рәхәттә яшисез. Ә без кышын билет ала алмыйча интегәбез. Җәй җитте исә, Мурзиха кичүендә паром белән чиләнәбез.

— Син чынлап та ятып тор, Зәмзәмия. Мин уникс тулгач уятырмын. Йокыңны саклап утырыйм, фәрештәң булып.

Үземнең кыюлыгыма үзем шаккатам! Әле ярый әйттем. Зәмзәмия җәймә өстенә менеп ипләнде, чалкан түгел, миңа таба борылып ятты. Стенага чигенебрәк миңа урын иркенәйтте.

Караңгыда күз ияләшә дисәләр дә, кызның йөзе аерымачык күренми, гәүдә бөгелешләре, бил нечкәлеге сүрән рәсем кебе генә. Өстенә карап, көтелмәгән бәхеттән сөенеп утырам.

— Сөйлә берәр нәрсә, вакыт тизрәк үтәр, — ди бу.

— Әкият кирәкме?

— Юк. Әкияттән туйган инде мин. Хыялларыңны сөйлә.

— Мин барыбер шагыйрь булам.

— Анысын ишеттем. Тагын?

— Хыял күп булмый инде ул.

— Авылыгызда сөйгән кызың бармы?

— Булса, синең караватың кырыенда утырмас идем әле.

— Яратып караганың да юкмы?

— Кызыгып йөрүләр булды инде. Мин күбрәк хат алышырга яратам. Көнгә җиде хат алганым бар. Ышанмасаң, Маһикамалападан сорап карарсың.

— Кем ул Маһикамал апа?

— Хат ташучы.

— Сөйлә. Нинди кызлар ошый сиңа?

— Өздереп кенә әйтә алмыйм. Ну, «Кавказская пленница» киносындагы Нина кебек булсын иде.

— Наталья Варлей ул... Кап-кара чәчле, җырлап-биеп кенә... Иренә «господин» дип дәшә торган һинд кызлары да бар әле...

— Белмим. Ну, минем өчен генә үскән бер саф кызны табып, ЗАГСка чаклы үпмичә, кагылмыйча... туйдан соң... бөтен кунаклар таралышып беткәч, мин аны күтәреп алам да тупыл мамыгы кебек кабарып торган урын өстенә салам. Ул риза, ул минеке генә... Люба исемле кызым бар иде минем, Анненково авылыннан. Районда уку алдынгылары слётында танышкан идек. Ике ел буе чүкер-чүкер хат алыштык үзе белән... Ә ул, сигезенче классны бетерүгә кияүгә чыгып, Казанга качты...

— Житте, тукта! — Зәмзәмия үзалдына сискәнеп-тартышып куйды. Кисәк хәрәкәт белән стенага таба борылып тынсыз калды. Мин аны аргандыр бүген, йокыга китәргә телидер дип уйлаган идем. Ә ул бүрәнә эргәсендәге сүсне кыштырдатып, нәрсәдер эзләнә, әйтер сүзен югалткан мосафир сыман чуалган зиһененең төпләнгәнен көтә бугай.

— Утырма. Ял ит син дә. Сәгатьнең унике туласы юк бүген.

Артык үгетләрлек гозер түгел, әйткәнендә үтәмәсән кабатлап тормаслар, ике уйларлык мәл калдырмыйча мендәренә баш салдым... Жилкәгә жилкә терәгән килеш як-якка карап калдык. Әйтер сүзләр, кирәкле сорауларны авыр тынлык йотты. Рәхәттән изрәп, бер-беребезнең йөрәк тибешен тыңлап ятабыз. Сәгатьнең текелдәве сирәгәйгәндәй булды, вакыт шултиклем әкрен уза ки, әллә инде безне йокыга җибәрә алмыйча тәүлекләр узды шунда. Зәмзәмияне курку катыш сагаю тотып торадыр, ә мин унсигез еллык йокыдан яна уяндым гына әле... Кыз баланы — куркаклык, ә егетләрне тыйнаклык саклар дигән минутлар шушыдыр инде ул...

Кунак кызларны кочаклап йоклау йоласы элек-электән булган ди ул. Әнинең дә сөйләгәне бар. Сугышка хәтле, Казанның «Микоян» прәннек заводында эшләгән чакта, Сикертән авылына Гөлчирә исемле иптәш кызларына кунакка кайтканнар болар. Шәһәрдә сөйгән егетләребез калды дип, авылныкыларны кич утырырга кертмәгәннәр. Таң алдыннан, сандугач йокысы вакытында, тәрәзәне алып кергәннәр. Гөлчирә белән икебезнең уртада әзмәвердәй егет ята. Билемнән кысып кочаклаган! Ну кул уйнатмыйлар, тимиләр икән үзләре. Егетләр шулай үсә, имеш...

Әнинең яшьлегеннән соң утыз ел үткән. Сикертәннекеләр кебек тәүфыйклы егетләр беткәч, кунак кызлар белән кочаклашып йоклау йоласы да әкренләп югалган.

Ятам Сикертән егете кебек. Иртәгә, Зәмзәмия белән Рәзифә Казан автобусында юл буе миннән көлеп барырлар инде, кочакларга да курка торган бер җебегән нәмәрсә икән дип.

— Стена кырыена ятыйм әле, минем ибем бу түгел, — дигән булам.

Зәмзәмия, артык сүзләр әйтеп тормаенча гына ризалашып, мина урын бирде. Жәймәне алып аткан уңайдан мин аның, ул минем кочагымда калдык... Жәймә астында мамык юрган бар иде...

Тән җылысы утыз алты, дибез... Егет белән кыз кушылса, житмеш ике була икән ул!.. Юрган астында бәлеше пешеп чыккан мич кайнарлыгы. Галстугыние белән костюм-чалбарымны салып атмасам,, йә тизрәк юрганны ачмасам — билләһи, пешеп үләм... Суынасым да килми... Кунак кыз янында тирләп-пешеп яту да килешми... Юрган астында яткан килеш кенә өс-киемнәремне идәнгә шудырдым. Кыен да, рәхәт тә үзе. Аяклар буталды, куллар ябышты, мин үптем, ул иренен турсайтып кына торды... Бәхет күгенең жиденче катына менеп життем...

— Кинонны боздың инде, — диде Зәмзәмия.

— Көндезге кагыйдәләр төнгелеккә ярамый икән ул, — дигән булам. Ә үзем тыела алмыйча үбәм дә үбәм!

Кинәт ул йөзен читкә борды, тирән итеп сулыш алды да сулкылдарга кереште. Янагы буйлап кайнар, бик кайнар күз яше тәгәрәп төште. Аптырап калдым, күз яше койдырырлык бернәрсә дә эшләмәдем ләбаса!.. Ул сулкылдаган чакта гәүдәсе дерелдәп ала. Йокы күлмәге дым гына. Гүя кызның тәне дә елый, тирләми, җаны авыртуданмы эре-эре күз яшьләре бөтен күзәнәкләреннән саркып чыга.

— Сындырдылар мине...

Әлеге сүз ярадан әрнү булып ишетелде. Авыл җирендә була инде ул андый хәлләр: аяк сына, кул сына, бил кайшыла... Зәмзәмиянең аксаганы сизелми, кочагы нык, биленнән кочаклаганда ыңгырашмады. Озак уйланып, артык баш ватарга ирек бирмәде Зәмзәмия, үзе җавап тотты.

— Көчләделәр мине...

— Көчләделәр?!! Кинодагыча, бандитларчамы?!.

— Нинди кино инде ул һаман, бала-чага шикелле... Ышанып йөргән — сөйгән егетем Хәтим... Аттестат алган көнне... выпускной вечердан соң... мотоцикл белән каршы алырга килде дә... урман эченә алып керәп... Безнең авылда сигезьеллык мәктәп кенә. Унынчыны Тимофеевкага йөреп укыдык.

— Ә ул үзе өйләнергә теләмәдеме? Или син риза түгел идеңме?

— Түгел ди! Мәктәпне тәмамлаганда, унҗиде генә иде әле миңа. ЗАГСка яшең җиткәнне тагын бер ел көтик диде. Бер ел буе көттек.

Зәмзәмия көттем, димәде, «көттек», диде. Яратышканнар инде, күрәсең.

— Кыен булса сөйләмә, Зәмзәмия...

— Сөйләп бетердем инде. Миңа унсигез тулганның икенче көнендә үк Яңа Жизнинең бер кәнтәе белән Урал ягына чыгып качты... Район суды гаризамны алмады.

Ул моны елый-елый сөйләде. Зәмзәмиянең күз яшьләре өчен мин инде үземне гаепле саный башладым. Ник соң без бер авылда туып үсмәдек икән? Ник Хәтимнән алданрак күреп өлгермәдем.

— Елавыңнан тукта... Алдагы өйдән Рәзифә чыгып җитә хәзер. Мине гаепләрләр...

— Чыкмый. Елаганымны күп күргән инде ул. Син әйт менә: мин нишләргә тиеш? Миңа да бит әле унсигез генә яшь! Минем дә башкалар кебек бәхет эзлисем килә.

— Эзләмә.

— Алга таба яшәп маташудан ни мәгънә дисеңме?

— Юк, мин сине үзем бәхетле итәм...

— Чынлапмы? Кабатла, тагын кабатла!

— Дошманнарга үч итеп, бәхетең булам. Елама гына берүк. Тукта. Күз яше мине каушата, аяк-кулымны бәйли, мескенәйтә. Минем синең алда көчле ир буласым килә.

— Бул! Бул... Еламам. Яратырмын.

Яратылганнан калганны яратып була микән? Белмим. Беләсем дә килми... «Яратам» сүзен шундый да җиңел әйттерә икән бу кавышу! Каты бәгырьле, күз яшьле, мавыктыргыч, туйгысыз ләззәтле һәм минем өчен өр-яңа халәт иде әле бу... Менә хәзер икебезнең дә язмыш хаталы. Бер яралыны коткару өчен икенчебез яраланды.

Җылы сүз хисне көчәйтә.

— Рәхмәт сиңа, Зәмзәмия!

— Анысы нәрсә өчен тагын?

— Яшермичә сөйләп биргәнең өчен. Теләсәң алдалый ала идең бит. Кагылырга хәлемнән килми иде.

— Ялганым тотылгач, сине югалтуы авыррак булыр, дидем. Беренче төнне үк барысын да белеп торуың лутчы. Алга таба үзең уйлап бетер. Мина синең самимилегең ошый. Йомшак күңелле син. Кызлар хыялы.

— Инде кайчан күрешәбез?

— Атна саен Рәзифәләргә кайта алмам. Яхшы түгел. Әгәр сагынсаң, Казанга кил. Сигезенче трамвайның соңгы тукталышында, Промысловая урамы. Карун Хәсән кайда яши дип сорасаң, фатир хуҗасын бала-чага да әйтеп бирер...

Ярар, дип әйткәнемне хәтерләмим. Өнсез калган ише генә йокыга киткәнмен. Зәмзәмия черем итеп алгандырмы, юкмы, белмим, мин уянганда аның күзе ачык иде инде, яшьләре кипкән, тын алганы сизелми.

Өй эчендәге яктылыктан сискәнеп киттем, ут кабынмаган гыйнварның беренче таңы аткан... Хәзер Рәзифәнең әтисе малларга печән салырга дип торачак, аның мал-туар янында кияүдәй сырмасы өйнең бу ягында эленеп тора. Кунак кыз куенында ирле-хатынлы кебек әүмәкләшеп төн чыкканны күрсә — контор ачылышына, икебезне дә бер арканга бәйләп, ЗАГСка алып керә. Авылыбыз шыксыз зур булгач, метрикә бирүне дә, парлыларны кавыштыруны да үзебезнең сәвит хәл итә. Мөһер сугучысы да минем әти ягыннан якын туган апам. Секретарь Разыя... Аның кулына эләксәң — шалт пичәтне! Мин бүген үк нитәргә... ниерәк бит әле... нитим бераз. Зәмзәмиянең дә бүген Казанга кайтып китәсе бар, аны көтеп торып, «Теплоконтроль» заводы эшеннән тукташа, зыяның кем каплар.

Юрган астында килеш кенә киендем дә, пәлтәм белән бүрекне култык астыма кыстырып, иртәнге суыкка чумдым, ботинкамның бауларын да атлый-атлый бәйләдем. Кичтән сизмәгәнмен генә, Рәзифәләрнең этләре дә бар икән, салам чүмәләсе төбеннән салкын ишегалдына чыккач, йөткерә-йөткерә өреп калды.

Авыл кешесе көн ачылганда өеннән чыгарга тиеш, ә мин астыртын сөенеч белән кайтып киләм. Яңа ел төнен биләмдә үткәрүчеләр бер мин генә булдым ахрысы, башка урамнарда эт өргән тавыш ишетелми.

Әни иртүк торып мичкә яккан, казан астына утлы күмер тарткан чагы, өйгә каз шулпасы исе таралган.

Безнең өйдә «хәерле иртә», «хәерле кич», «тыныч йокы» дип көн саен кабатлана торган төче сүзләр юк.

— Мин кайттым, — дигән булам.

— Бөтен хатаны да үзеңә ясарга димәгән, башкаларның ялгышыннан гыйбрәт алырыең ичмасам... Кешене күр, өйрән аннан сун...

— Кемнән өйрәним, әни?! Әтидәнме?

— Хәерченең теле әче! — Әни үз язмышына киная дип кабул иттеме, тавышын көчәйтте. — Атаң мәрхүмгә охшасаң, өч хатынга житәрсең әле син дә... Болай бикәчкә кереп, төн кунып йөри башласаң...

— Яңа ел каршыладык ич, әни... Соң утырдык.

— Әбизәтелни кунып калырга дигәнме? Балдамайлар очыннан кайтырга трамвай көтәсе юктыр ич.

Әни минем кайда кунып кайтканны белә булып чыкты... Төн уртасына чаклы җыелып, күрше Фатыйма әбиләрдә урамның карчык-корысы кич утыра: кем шәл бәйли, кем йон эрли, оек ямый... берәрсенең оныгы ияреп киткәнемне күреп калгандыр инде. Әни белән бәхәскә керүнең һич файдасы юк, акланам дип аллә нинди ялганга кереп чумарсың... Яңа хәбәрнең болай да ялганы күп була...

— Әни, мин әз генә ятып торам әле, яме...

— Ашатып та кайтардыларму? Аш пешкәние...

— Төне буе табын артында утырдык, — дигән булам. Ә үзем туп-туры диванга.

— Рәхәт булган жирдә хәсрәт бар шул, улым...

Абый минем өчен махсус алды бу диванны. Нальчик шәһәрендә су бораулаганда, әйбәт кенә акча эшләп кайткан чагы иде. Питрәч универмагында күреп калган да «автолавка» дигән машинага төяп җибәргәннәр. Менә, энекәш, шагыйрь булырга хыялланган кеше шушындый диванда айлы тәрәзәгә карап йокларга тиеш, ди абый... Арка терәвече биек, калын мамык белән сырылган; тыгыз матрасы пружиналар өстендә биеп тора; баш-башындагы озын бүкән сыман таянычлары шарнирлы — төшереп куйсаң, ятагы озынаеп кала. Ишек катында торгач, кергән бер күрше аны сынап, утырып-утырып мактый. Диванга яткач, безнең өйнең бөтен эчке матурлыгы күренә.

Армиядәге Үзбәк егете белән хат алыша башлагач, апам киергесен кулыннан төшермәде. Кичләрен клубка йөрмичә чикте дә чикте. Колхозның нәни бозауларын карап эшләгән илле тәңкә акчасы мулине жепләр алырга житмәгәндер, билләһи! Тәрәзә пәрдәләре, көзге өслеге, әнинең караватитәге, буеннан-буена тартылган кашагалар — барысына да безнең авыл жирлегендә үсми торган чәчәк бизәкләре, сайраган килеш туктап калган кошлар сурәте, монарчы мин күрмәгән күбәләк канатлары чигелгән. Үзбәк армиядән туп-туры безгә кайтты. Секретарь Разыя апабыз пичәт сугып жибәрде. Апам чиккән чигүләрен өеп калдырды. Зинһар, алып китә күр, бәләкәй генә бирнәң булыр шунда, дип әни күпме ялынды. Тыңламады, Үзбәгең үзе дә мине сатып алмый әле, диде.

Апамны искә төшерергә иренәм, Зәмзәмия күз алдымда тора.

Бигрәк озын төн булды бу... Ниндидер ун сәгать эчендә таныштык, сөештек, кавыштык... Инде язып аңлата алмаслык сусау белән сагынам да. Өйләнү шушылай башлана микән?..

— Гел юлдан бирәр нәрсә табып алып кайта торган гадәтең бар синең. Кемдер югалтканны... Кечкенәдән, иске ачкычлар таптың, ватык сәгатьләр, радио кисәкләре, сынык эш коралларын өйгә ташыдың... Беренче күрешүдә үк янында кундырган кунак кызың да берәрсе югалткан нәмәрсә булмаса гына ярар иде, Ходаем!

... Әни, мин сиңа төшемдә генә җавап бирермен. Йокым килә, аягымда чак басып торам.

Минем мендәрне бу тиклем кочаклап ятканым юк иде әле... Кояш баеганчы йоклаганмын.

Кышкы озын кич...

Егет кешенең уяна торган, хыяллана һәм моңлана, ашкына һәм уфтана, дәртләнә һәм әзләнә торган чагы. Авыл тулы кеше, өй саен якты тәрәзә, өендә әниең бар — ә син никтер үзеңне ялгыз хис итәсең... Хатларны кич яздым, мәхәббәт турындагы китапларны кичтән укый башлыйсың, шигырьләрне дә карангы төшкәч кенә яза ала идем... Өйнең жылы якка карый торган бер тәрәзәсе менеке, анда — жиһан тарафыннан гүя бары тик минем язмышны күзәтер өчен генә яратылган сагышлы тулган Ай.

Авыл жирендә прицепщик, ягъни тракторчының ярдәмчесе дигән бер эш бар иде. Жәйге каникулларда бераз акча эшләп алыр өчен ярап тора үзе. Туңга сөрүләр башлангач, сабанчылар бер үк тракторда атналап алмаш-тилмәш эшли. Безнең инде һәр кичне клубка йөри торган чак. Эш көне дә, эш төне дә ике алты арасында. Төнге смена кичке алтыдан иртәнгә чаклы... атна буе клубка чыгып булмый. Ә көндезгесе...

Унике сәгать буе сабан рамасындагы калай утыргычта тузан суырып хәлдән тайган кебек буласың да, өйгә кайтып бит-кулыңны югач, янадан туасың — тәнгә көч тула, күрлек арта, ару-талулар юкка чыга. Тамакка капкаладым

микән, юк микән — анысын хәтерләмим, клубка очам! Берәр көн клубка чыкмый калсаң, дөнья бозылыр, аккан чишмәләр туктап калыр, сине онытырлар да кызлардан өлешсез калырсың кебек...

Клубтан кайтып, ае сүнгән тәрәзәң кырына авасың да, йокыга китеп өлгермисең — инде әниең уята башлый:

«Тор, улым, тор, соңга калсаң, урыныңа башка прицепщик алырлар... Тор, улым, тор, акча эшлисең ич. Йокының поты бер тиен аның... Тор инде, тор дим, ялкау егетләрне кызлар да сөйми...»

Аһ, бу таң йокысының тәмлелеге! Һай бу мендәрнең тирәнлеге! Абау шушы кайнар юрганны алҗыган тәннән куптарып алулары! Вәт мин җүләр, шушындый рәхәтне әрәм итеп, клубка чыккан булып, кырыкмаса-кырык егеттән калган кызларны куып йөреп... Житте! Бүген кич клубка чыкты юк. Кырдан кайтам да мендәргә чумам... имеш. Ләкин кич житүгә. иртәнге «тукран тәүбәсе» тагын онытыла... Ял ит, йөрмә, дип бәйләп куйсалар. җиледән үрелгән арканны өзеп качарсың...

Зәмзәмия киткәннән соң төннәр тагын да озынайды: клубка да чыгасы килми, йоклыйсы да килми. Сөйгән ярыңны эзләү — тәнгә тән тисен өчен генәме? Күкрәгемдә аның тән җылысы сеңеп калган кебек, колагымда төнге пышылдавы, күлмәк якамда аның ислемай исе.

Ике атнадан бирле кайтканы юк. «Ник?» дигән сорауга үз-үземне юатырдай җавап эзлим: раштуа суыкларыннан курыктымы? Рәзифә сменалы эштә бугай, ял көнен туры китерә алмыйдыр. Башка авылларга кунакка кайтып, егетләр сөеп йөри микән, әллә минем эзләп килгәнне көтеп Казаннан чыкмый ятамы?..

Ләкин мин артык көтә алмыйм инде...

***

1968 елның 31 декабреннән соң авылда миңа бик күп нәрсәләр тыелды, ярамады, каршы төште, баш имәде, аңламады, тыңларга теләмәде. Пыяла койма эчендә яшим сыман: күрәм, матур сүзләр сөйлим, сокланам, аңлашмакчы булам — ишетмиләр; үреләм, ялынам — кулым житми; тамгалы кош кебек бәрелеп-сугылып очынам, пыяла койманы үтә алмыйм. Өйгә кайтам да төне буе ай нурында коендырып шигырь язам... Саф хисләр өермәсендә шашынып, татлы сөю газапларыннан иләсләнеп язылган, һәм, әлбәттә, азагы һичшиксез кавышу белән тәмамланырга тиешле саф әкиятем бер төн эчендә челпәрәмә килде. Ишек яңагына ел саен сызык өстәп ашыктырган буй үлчәмемә карап, ай үсәсен көн үсәм, инде менә яшьлегемә килеп житәм дигәндә генә...

Капка төбендә мотоцикл тырылдады, шундук «Пип-пип!» иттереп саңгырау аваз салды. Максимовтыр, безнең урамда бүтән матай юк.

Авызы колагына житкән — сөенечтән түгел, үртисе килүдән.

— Сөенчегә нәрсә бирәсең?

— Әйтеп кара башта...

— Хатының кайтып килә. Урман авызында машина көтеп калды. Ничава гына чибәр икән.

— Ә син аны каян белдең?

— Район универмагына барып килгәнием. Казан автобусыннан бик күп кеше төште анда. Туктап сөйләшеп тордым. Алып кайтадырыем Зәмзәмияне — чемоданы сандык хәтлек, арба кирәк.

— Мин монда причём? Балдамай кызына ияреп кайтышыдыр, — дигән булам, ә үземнең... тавышымның коты очты.

— Туп-туры сиңа! Хатын-кызлар бик шәплап сораштырды инде үзең. Ә мин тизрәк сөенче алыйм дип ашыктым.

— Нинди сөенче булсын инде бу?!

— Сөенче, сөенче! Маскарад көнне алданрак күреп өлгергән булсам, сиңа эләкми иде инде ул... Абзаңа рәхмәт әйт!

Һәм Максимов, дөя чаклы бүләк откандай сөенеп, китеп барды. Каеш көегедәй әче майлы төтен эчендә басып калдым, зәһәрлеге елатырдай итеп күзне әчеттерә... Ул миннән бер яшькә олы... Абзый, имеш. Сигезне бетерде дә укуын ташлап, матай белән кызлар куып йөри.

...Юк... юк... юк! Капкадан кертмим Зәмзәмияне! Нишләргә?! Капканы эчтән бикләп калыйммы?.. Бәлкем Зәмзәмия, болар өйдә юк икән, дип кире китеп барыр. Әллә, капкага йозак элеп, карурманга чыгып качыйм да яшьлегемне шунда адаштырыйммы?!. Әни өйдә шул, капкага ул хуҗа. Мин төпчек малай гына...

Өйләнүе бик тиз икән ул... «Хатының кайтып килә!» — дигән Максимовның, билләһидер менә, матай төтене дә таралып бетмәгән иде әле, өй түребездә «Ветеринарная служба» машинасы туктады. Колхоз фермасына «ашыгыч ярдәм» килгән булгандыр инде. Тиз йөрүен күр син аның, кирәк чакта урман авызында икешәр сәгать көтә торган идек, биш чакрым араны җәяү кайтмас өчен.

Мин, йөгереп килеп, Зәмзәмияле машинаны кочаклап алыр дип уйладылармы — берара тын калдылар, ашкынучылар күренмәгәч, йөртүче янынннан төймәләре өзелеп беткән әзмәвер агай төшеп, «УАЗ»ик автобусының арткы ишеген ачты... И Ходаем, әллә Зәмзәмияне носилка белән төшерәләрме?! Күзе буылган тамашачы сыман, сыным катып карап торам. Теге әзмәвер, әүвәл чемодан чыгарды, аннан, сикереп төшәргә ирек бирмичә, Зәмзәмияне ике куллап биленнән кысып, кояшка таба күтәрде. Күр әле син аны, тыпырчынмый да, безнең чирәмлеккә басарга теләми диярсең — аякларын тездән чүгеп, кер бавына эленгән курчак ише, күндәм генә җилфердәп тора.

Минеке лә ул! Түзмәдем, очынып килдем дә әзмәверне куркытырлык итеп:

— Җибәр, агай, синең курчак белән уйнар чагың үткән инде! — дидем.

Ә ул Зәмзәмияне минем кочагыма ыргытты, егылмадым, тотып калдым.

— Мә, рәхәтен күр! — дигән була, халат төймәсен бозау чәйнәгән нәмәрсә. — Сезнең белән үртәшеп торырга вакыт юк.

«Ашыгыч ярдәм» ферма тыкрыгына борылды.

— Җүнлерәк машина килгәнне көтмәгәнсең. Корычларның буаз кәҗәсе чирләгәнме, районнан ветврач чакыртканнар дип көләрләр әле.

— Нәрсәсе бар инде аның?

— Әти мал врачы булган, шуңа бәйләп сөйләрләр.

— Алайса әтиең алып кайтты дип исәплә.

— Исәпләрсең... Әти мин туган елны ук үлгән инде ул.

— Димәк, рухы каршы алган, изге юлда йөрим икән.

— Безнең авылда егет өенә кунакка кайтып йөргән кызларны дөрес аңламыйлар.

— Ник әле кунакка гына, бөтенләйгә диген.

— Бөтенләйгә?!!

— Йә инде, йә, урам уртасында әрләшеп торган ише итмә, мужик була бел.

— Мужик түгел мин. Әле егет кеше!

— Мужик! Мужик! Алып кер өеңә.

Күн авылыннан аерылып кайткан Рәшидә сандыгы чаклы чемоданны урам уртасыннан капкабыз төбенә күчереп куйдым.

— Болай өйләнмиләр бит инде, Зәмзәмия?!

— Ә ничек өйләнәләр соң?..

— Хыялымдагыча! Шашып сөелеп, язылышасы көннәрне саный-саный... Туйдан соң кияү чоланында калып... Мин синең чәчкәдәй саф матурлыгына хуҗа булып... Син, курка-курка, әкрен генә туй күлмәгенне саласың... Ә мин сине ашыктыра алмаудан гаҗиз калган хәлдә, түземсезлекнең чигенә җитеп көтеп торам. Ниһаять, үсеп буйга җиткән, төрле хәвефтән, мәкерле кызыгулардан, мут малайларның ымсынуыннан минем хакка исән-имин саклана алган кыз бала үз теләге белән куеныма керә. Шушы татлы минутларны бүлдерергә һичкемнең дә хокукы юк!

Бәлки әле җөмләне дәвам итәр өчен тагын да матуррак сүзләр тезә алган булыр идем... Тик Зәмзәмия, янакка суккандай җилле селтәнү белән, өметемне өзде. Кояш яктысында өрелгән сабын куыгыдай аллы-гөлле хыялым чәчрәп шартлады.

— Әй!!! Шагыйрьләр шикелле төчеләнеп, кыланчык җөмләләр белән сөйләшеп торма, зинһар! Әллә кем диярсең... Әнә, Солтания апам, бездән күбрәк күргән — чәчәкнең сафлыгы серкәләнгән чакта бал кортларын кызыктырыр өчен генә кирәк, ди... Ә мин инде синнән өч айлык җимешкә бөреләндем.

— Синең районыңның кайсы якта икәнен дә белмим бит хәтта.

— Татарстан картасында бар: Сөлчә районы Яңа Җизни авылы.

— Географиядән үтмәдек. Белмим. Әти-әниеңне дә күргән юк. Бәлки алар каршы төшәр.

— Әти юк. Паспортка сызык куймас өчен генә Борисовна дип язганнар. Әни йөкле килеш синнән тартып алмый инде мине.

— Барыбер... Өйләнү... Җиде тапкыр үлчәнергә тиешле.

— Син җиде тапкыр үлчәгән арада берәү килә дә кисеп китә. Беләбез ул мәкальне...

Кычкырыбрак сөйләштекме — әни йөгереп чыкты. Зәмзәмияне танырга теләгәндәй, чекрәеп карап торды-торды да соравын бик катгый куйды:

— Яңа ел төнендә кунып кайткан кызың шушымы инде?

— Әйе! — дип ашыгып җавап бирде Зәмзәмия. — Каян белдегез?

— Чемоданыңнан!

— Менә ничегрәк килеп чыкты бит әле... Улыгыз йоклавын йоклады да, хәзер өч айлык корсагым белән куып җибәрәсезме?

— Авылда ике гомер яшәп сынар аягыбызны басмаган Балдамайларга сөйрәп алып кереп көчләмәгәндер ич улым? — Өч айлык?! Йөгең беленми бер дә.

— Солтания апам әйтә, беренче бала ыспай күперә, ди.

— Белмим, ягы-ягы белән шулайдыр бәлки... Рәхмәт, куандырдың, улым. Атаңа охшасаң, өч хатынга җитәрсең әле... Авыр туфрагы җиңел булсын. Әрләвем савап булып барып ирешсен. — Һәм әни Зәмзәмиянең сәяхәт сандыгын җирдән йолкып алгандай кисәк күтәрде дә, җил-җил атлап, капкага ашыкты. — Үзем дә өч ятим үстердем, бер дә кеше баласын елатырлыгыбыз юк.

Безнең авылда бәләкәй капкага, бусага рәвешенә китереп, аркылыга киң такта куялар — биегрәк булсын, кар күммәсен диптер инде. Зәмзәмия әниемчә генә атлап кереп китә алмады — кара юбкасының тар итәге аягын тышаулаган иде.

Капка баганасына сөялеп мина текәлде. Күтәреп алып кереп, мендәргә бастырыр дип уйлады ахрысы... Үртәүле күз карашына бирешмәскә тырышып гамьсез генә көтәм, беләм, хәзер аның тизрәк өйгә кереп, минем яшьлегемә хуҗа буласы килә... Менә ул, маңгай чәчен сыпыргандай итеп, көрсенергә җаен тапты да велосипедка атланган ише аягын кырын күтәреп, ишегалдыбызга сикерде. Мин дә аңа ияреп, капканы ябып кердем... Яшьлегемнең кирәге калмады инде.

Тәүбәннән яздырырлык гыйшыклы көннәре, фәрештәңне азындырырлык дәртле төннәре белән тәүге атнабыз күңелле генә узды. Бер буралы өйдә үзенә посып ятарга урын табалмагач, әни күрше Хаҗәр апаларга кунарга йөрде.

Никахсыз шаяруларның икенче атнасында мин тагын сагышка чумдым. 1968 елның 31 декабрь төне кылт итеп исемә төште... Әгәр мин, Зәмзәмия белән картайганчы бергә яшәп калсам, яшьлегемнең сагынып сөйләрдәй гүзәл минутлары булмас кебек. Ул көн саен бер-ике тапкыр үксеп ала, тик шунысы бар — елаганда никтер күзе кызармый... Солтания апасының акыллы киңәшләре теленнән төшми... «Яңа Жизни сукмаклары»на Илдар Юзеевтан килгән җавап хатын ертып маташа иде, ничек сизеп калдым... Безнең әле ширбәт ае, дип берәр рюмка шәраб эчмичә юрган астына кермәдек... Ә үзе минем өч айлык йөгем бар, ди. Безнең авылда малаем өйләнде дип шаран ярмыйлар, ә малаем башлы-күзле булды, дип сүз уңаеннан гына әйтеп куялар.

Минем дә бер атна эчендә күзем үткенәйде, башым эшли башлады, колагым Зәмзәмиянең әйтеләсе сүзләрен алдан ук ишетеп өлгерә... Кызый бәлкем миңа кияүгә чыккандыр да, ләкин мин аңарга өйләнмәдем әле... Сусавым басам дип чамадан тыш су чөмергән печән чабучы кебек, инде бу чишмә яныннан тизрәк китәсем килә.

«Мин синең белән яшәргә җыенмыйм, Зәмзәмия!»

«Бар, хет теләсәң кая олак! Баланы шушы нигездә табам! Урамга куып чыгарырга хакыгыз юк!»

Ашык-пошык киендем дә, әнине эзләп, Хаҗәр апаларга йөгердем.

— Әни, гел кешедә кунып йөрсәң, үз өеңнән колак кагарсың, кайт әйдә.

— И, Ходаем, әллә сугыштыгызмы?

— Юк, өйне бүлештек.

Әни кабаланып кул эшләрен төйнәштергән арада Хаҗәр апа сүзгә катышты. Катышмады — миңа атап әйтте:

— Менә, күрше, сәгать төзәтерлек егет булдың... Син барында айга карап ач бүре анасы шикелле улап йөрмәм инде моннан ары...

Әни аны ишетмәмешкә сабышты, мин берни аңламаган атлы кыландым.

***

Күчмә кошларның кайтасылары кайтып, нигез ипләде, ояларда яңа авазлар ишетелергә тора. Язгы җилләр кемгә дә ярарга белмичә аркылы-торкылы исә. Кышкы йокымсыраудан уянып чыккан бал кортлары гыйшыклы тал песиләрен кытыклый. Җимеш агачларында чәчәк бөреләре бүрткән. Кояшы да хәтта җанга сеңеп, күңел түренә кереп байый. Клубта кеше бик юктыр инде. Язның яшьләрне авыл читендәге кичке уеннарга тарата торган мәле. Алтын-көмеш туйлар үткәреп, тигез гомер кичкән парлар күз алдыма килә дә шул бәхетлеләрне кызганып куям — аларга кичке уенга чыгу юк! Мин инде бер атна дигәндә үк, көмеш телле гармун чыңлап торган ял кичәләрен, парлашып вальс әйләнүләрне, тыпырдаулары белән тун йөрәкләрне уятырлык кызлар биюен сагындым... Бәхетлеләр өйдә ничекләр итеп түзеп утыралардыр?..

Кичке уенга чыгып киттем... Тиз киттем. Зәмзәмиянең еларга яратканын беләм. Күз яше минем аяк-кулымны тышаулый, хыялларымны кимсетә, көрлегемне мескен итә.

Ашыгычлык белән ике җөмлә генә ыргытышып алдык.

«Мин дә синә иярәм!»

«Урманга утын төяп бармыйлар!»

Без — кичке уеннарның соңгы малайлары...

Туп-туры Сәвияләр тавына киттем, аякларны тыяр хәл юк. Мин килгәндә

инде яшьләр озын коридор булып парлашып баскан. Гап-гади «Наза» уены — аны таң атканчы, көтү куганчы туктаусыз уйнап була. Парсыз кеше алга килеп баса. Иң әүвәл ана такмак жырлыйлар. Аннан күмәкләшеп яр сайлыйлар.

Мич башыннан поезд килә,
Итекләргә абынып.
Күрәсем дә килми үзен,
Үләм инде сагынып.

Монысын дежурный Хөрмәтуллага жырладылар.

Кимә итек, ки читек,
Аякка жиңел итеп.
Күн авылы егетен сөй,
Шәлеләргә үч итеп...

Минем Сәвиягә әлкте бу жыр. Сайлау ыгы-зыгысы тынган арада иң алга үзем килеп бастым. Такмакның миңа насыйбы корычлы-борычлы иде:

Келәт эчендә келәт,
Нәселегез белән түгел,
Син үзең генә б... !

Күмәкләшеп көлсәләр, кыен икән ул. Алай да бирешмим, «наза» кычкырганны көтәм.

Пар ат килә, кемне ала?
Кемне сөйсә, шуны ала!
Ак кирәк, күк кирәк, безгә...

Шулчак уен өзелгәндәй булды. «Наза»чылар миңа Сәвия кирәген беләләр ләбаса, ник дәшмиләр? Ялыктыргыч, һай сау-таза жирдә жәрәхәт ясый торган тынлык иде бу. Түзмәдем сайлауны үзем дәвам иттем.

Ак кирәк, күк кирәк,
Безгә Сәвия кирәк!

Капка булып баскан яшьләр арасыннан үтеп, Сәвия янына килеп бастым. Кулын ычкындырмый тора. Күн авылыннан килгән кунак егет Касыймга чытырдап ябышкан.

— Уен кагыйдәсен бозасың, парлашыйк! — дим.
— Өйләнгән мужиклар өчен түгел бу уен! — ди.
— Мин әле өйләнмәгән! — дим.
— Корсаклы хатының килеп житәр хәзер! — ди.

Күз алларым кинәт караңгыланып китте, әйтерсең лә авыл өстендә бөтен йолдызлар да берьюлы сүнде. Мин үзем дә хәзер кул сандыгын күтәреп кайткан Зәмзәмия хәлендә түгелме соң?! Керер капкам берәү генә...

Абау, язның яшьләрне харап итәр чагы!..

***

Район газетасында шигырьләрем басылганда, мине кызлар күбрәк ярата иде. Ай саен әдәби сәхифә чыгып бара, сәхифә саен катнашырга тырышам. Кызыл шигырьләрне аеруча хөрмәт итәләр бугай — бәйрәмнәр житсә, «Алга»ның иң

алгы битенә урнаштыралар. Әллә махсус көтеп торалар шунда... бүген илтеп бирсәм, икенче көнне үк гәҗит булып өйгә килеп керә. Шигырем басылып чыккан көннәрдә клубка иртәрәк чыгам, мактау сүзләре көтеп йөрим. Фойеда биюләр бүленеп, гармунчы яңа көй эзләгән арада, яшьләрнең пышым-пышым сөйләшүе гел минем турыдадыр кебек. Горурлык хисемне тыяр хәл юк: гәүдәм турая, борын чөелә, карашларым белән клуб түшәменнән йолдыз чүплим, колак икеләтә сизгерләнә. «Шигырең чыккан, үзең күрдеңме соң?.. Шигырьгә бик исем китмәсә дә, синекен укыдым әле... Миңа багышлап та берәрне яз инде...» дигән сүзләрен кабат-кабат әйттерәсем килә.

1967 елның 19 июлендә, «Яшь Ленинчы» газетасында беренче хикәям басылып чыккач аптырап калдым — ник берәрсе мактасын!.. Беләм бит юкса, пионерларның өлкә газетасына ярты мәктәп языла. Авылның газета укымый торган көненә туры килде ахрысы.

Китапханә мөдире Халисә апа гына аркамнан сөеп алды. Өлкә матбугатында чыга алгач, сиңа артист булу турында хыялланасы юк, ничек тә район газетасына эшкә урнашырга тырыш, институтка читтән торып керерсең, ди. Конкурстан уза алмаслыгыма төрттерүе инде «ызбач» апаның. Бер урынга ундүрт абитуриент гариза биргәнне ишетеп белә иде инде ул.

— Миңа көндезге бүлек кирәк шул.

Шактый гына масаебрак әйтеп ташладым ахрысы.

— Читтән торып укыдым әле менә, аңа карап укам коелмады! — диде Халисә апа, үртәлүен яшермичә.

— Читтән торып уку, ул — читтән торып яшәү, читтән торып ярату, читтән торып эшләү кебегрәк килеп чыга түгелме соң, Халисә апа?

— Абау, хәерченең теле әче! — диде дә Халисә апа, минем хикәям басылган гәҗитне өстәл астындагы кәгазь өеменә ыргытты.

И, тиктормас телем — утлы корал шул син! Һич кирәкмәгән җирдә яралап куясың. Дәшми торса, җүләр кеше дә акыллы булып күренә бит... Дәшмичә калырга ничек өйрәнәсе?!.

***

Газиз башкаемны кая куярга белмичә кайгырып йөргән чагында «Алга» гәҗитеннән чакыру килде. Бармас җиреңнән йөгерә-йөгерә барырсың — берьюлы дүрт язучы белән очрашу диелгән. Хатны Зәмзәмия миннән алдан ачып өлгергән иде инде. Мөһерсез, штемпельсез кәгазьне кичке уенга качар өчен уйлап чыгарылган хәйлә дип кенә кабул иттеме, мине җавап тотар өчен әзерләп, авызын турсайтып йөри башлады.

Әдәби берләшмәбезнең исеме «Мишә дулкыннары» дип аталса да, утырыш ни өчендер Мишә ярында түгел, ә урман авызындагы аланда оештырылган. Печән кибәннәренең төбәсен каплый торган олагаем, калын брезентны быелгы чалгы тимәгән үлән өстенә келәм итеп җәйгәннәр. Аның зурлыгына карап, бүгенге очрашуда егермеләп кеше катнашасын чамалавы кыен түгел. Үзем шикелле, штаттан тыш хәбәрче, дигән яшьтәшләрем белән исәнләшеп өлгердем. Күн авылыннан Мөхәммәт Садыков, Әлбәденнән — Павел Апушев, Кокушкинодан — Сәетбаттал Закиров, Янсуардан — Ринат Рәхимов һәм тагын бер-ике иптәш аерым төркем корып гәп куерта, безгә алар белән кул биреп күрешергә иртәрәк әле.

Хаҗәр апайның күкеле сәгате ике тапкыр кычкырганны көткәннәр диярсең, төп-төгәл ике тулганда «Алга» редакциясенең «Москвич — 402» машинасы брезент келәм янына килеп туктады. Дүрт ишеге дә берьюлы ачылды. Шофёр янәшәсеннән төшәсе кунак китап нәшриятыннан — Сафа Сабиров булып чыкты

— жиргә аяк басканчы ук Павел Апушев аны кочаклап, күтәреп диярлек алды... Абдулла Сәләхетдинов белән Рәшит Гәрәй җинел сөякле Раил Шакировны уртага алып утырганнар иде, алар өчесе дә машинадан үзләре төште.

Кунакларның райкомга кереп тормыйча, туп-туры аланга килеп туктаулары икән. «Алга»ның әдәби хезмәткәре Раил Шакиров аларны Казанга ук барып алган. Ул шыплап тутырылган багажниктагы дүрт-биш шешә «Шифалы су»ны брезент өстенә тәгәрәтте, кибет кәгазенә төрелгән стаканнар китереп куйды. Машинаны урман ешлыгындагы күләгәгә яшерергә кушып, шофёр колагына тагын бер ике кәлимә пышылдады.

Чын шагыйрь булу өчен ничек киенергә, үз-үзенне ничегрәк тотарга, сөйләшү манераларын отып калырга дипме, мин зур абзыйларны җентекләп күзәтәм...

Рәшит Гәрәй май кояшы үтеп кермәслек итеп куе зәңгәр костюм кигән, башында җинел эшләпә. Ул үпкәләгән кебегрәк итеп, алан читенә барып басты, наратлар арасыннан үрелә-үрелә, Мишәнең кояшка каршы ярын яулап алган Питрәч бистәсен күзәтте. Аннан соң, кунаклар ягына борылып, кулындагы тузганакны өреп туздырды.

Абдулла Сәләхетдинов билен кыстырмыйча гына кыска җинле житен күлмәк кигән. Кысан машинада оеган идеме, уң аягына сизелерлек аксап бераз йөренде дә, күн чабатасын салмый гына брезент читенә кырын ятты. Бармагы белән төртеп күрсәткән шешәдән ана су салып бирделәр.

Сафа Сабиров әле һаман да Павел Апушевның илтифатлыгыннан котыла алмый иде, чуар пинжәген салып иненә элгән, вак шакмаклы, ачык изүле күлмәгенең яка астына ашъяулык хәтлек кулъяулык тыгып, тирләгән муенын сөрткәли, үзе иренен бер читкә бөрештереп, яшь шагыйрьгә туктаусыз нидер нәсыйхәтли.

Бигрәк тә мин Раил Шакировны үз иттем. Яшь авторлар белән, берсен-бер аермыйча, кул биреп күрешеп чыгуы да — үзе ни тора! Бу егетне Әгерже ягыннан килгән, диделәр. Уртача буйлы, киң җилкәле, җыйнак гәүдәле. Шагыйрь әйтмешли, әллә кайдан күренеп тора — солдатта булган, диләр. Кара тутлы йөз, чем кара чәч, көдрә зөлефләренә карап, аның Әгерже ягында удмурт туганнары юктыр диясе килә. Шагыйрь буларак та мин аны брезент келәм тирәсенә җыелганнар арасында өстенрәк итеп күрәм. Алдан ук санап үткән язучыларның бөтен иҗатын яттан беләм дип әйтмим, шулай да Раил Шакировның «Хакым бар» дигән китабын кат-кат укып торам, шигырьләре яттан өйрәнергә җинел, теләсә кайсы сәхнәдән кычкырып сөйләргә була, әйтелгән фикере төгәл, фәлсәфәсе анлаешлы — йокыны китерми, рифмалары кыланчык түгел, геройлары җирдә яши. Абыем кебек якын ул миңа. Ни өченме?..

Мәктәпне тәмамлагач, Педагогия институтына документлар тапшырыр алдыннан мин «Алга» редакциясенә кереп чыккан идем. Шунда ул минем ике хыялымны да җентекләп тыңлады, тыңлаган арада өч-дүрт тәмәке тартып бетерде.

— Артист булырга хыялланмаган авыл баласы юк! — диде ул, тагын бер тәмәке кабызып. — Шигырьләрең кызык кына, сиңа татар теле бүлегенә керергә кирәк.

Һәм Раил Шакиров, минем ике хыял арасында икеләнеп торуыма бик исе китмичә генә, зур кәгазь бите алды. Китап битенә автограф биргән ише кыйгачлап шактый язды, аны дүрткә бөкләп конвертка салды. Тышына эре хәрефләр белән «Гөлшат Зәйнашевага — Раил Шакировтан» дип куйды. 1967 елның 14 июлендә, мин әлеге хатны тотып Бауман урамындагы Язучылар

союзына беренче тапкыр аяк бастым. Гөлшат Зәйнашева, катлаулы тормыш юлы кичкән Раил Шакировның шигырьләрен мактый-мактый, мине җитәкчеләр янына алып керде. Ярты сәгать үттеме-юкмы, институтның татар әдәбияты кафедрасы мөдире Абдулла Сайганов исеменә юллама язып бирделәр, Язучылар оешмасының председатель урынбасары Зәки Нури кул куйды.

Әлбәттә, бу «направление»нең ярдәме тимәде... Мәктәпне алтын-көмеш медальгә бетерүчеләр, колхоз-совхоз исеменнән килгән стипендиатлар, төрле олимпиада җиңүчеләре, спорт мастерлары, армиядән кайткан медальле егетләр — болар инде конкурстан тыш керергә тиешлеләр квотасына алдан ук өлгергәннәр. Мин егермеләп көнгә соңга калганмын. Үземә күрә ашыгып яшәсәм дә, татлы хыялларыма гел соңрак ирешә торган булдым; 26 яшьтә — көндезге бүлек студенты; 31 яшькә чаклы хатын эзләдем; 50 яшьтә машина алдым; инде 15 ел буе авылда өй салам; 60 яшемдә, ниһаять, кулыма онык тоттырдылар... Кеше гомере кыскадыр да, язмышы озын аның. Ниһаять, яшьтәшләрне куып җитәм бугай инде...

Хәер, мактанчык кеше гел киләчәк турында сөйләр... Әгәр Зәмзәмиядән малай туса, аңа Раил Шакировның исемен кушарбыз. Һәм шагыйрьне өебезгә кунакка алып кайтырмын да: «Менә, абый, бишектә сезнең адашыгыз!» — дип мактанырмын, сыйлармын үзен. Хәтта өйдән чыкмыйча гына тәмәке тартырга да рөхсәт итәрмен!..

Әдәби берләшмә утырышны тиз тотты. Өйдән алып килгән кульязмаларны тикшереп тормадылар, район газетасында басылган шигырьләргә брезент өстендә генә күз йөгертеп чыктылар да уртак кимчелекләребезне санап, уңышларыбызны түгәрәкләделәр.

Саубуллашу сүзен Ринат Галәвиннан көттеләр. Казан язучылары алдында сер бирми — фикерен тупларлык пауза ясар өчен, күзлеген салып, баш бармак бите белән сөрткәләп алды. Линзалары пыяла шарны урталай ярып кына куелган булдымы — күзлеген салгач, аның элеккеге зур күзләре тәмам кечерәеп калды.

— Кадерле кунаклар, төбәгебезнең горурлыгы дип саналган иҗади яшьләр һәм дә яшь хәбәрчеләребез! — Ринат Галәвин кәгазьдән укымады, шулай да күзлеген еш төзәткәләде. — Бу көннәрдә «Алга» редакциясе юбилей эшләре белән мәшгуль. Дөрес, республиканы шаулатырлык зур вакыйга түгел... Шулай да 35 ел эчендә районыбыз газетасын зур шәхесләр күтәрде, Гурий Тавлин, Марат Мөлеков, Касыйм Фәсәхов, Мәхмүт Хәсәнов, Абдулла Сәләхетдинов, Флорид Әгъзәмов, Рахмай Хисмәтуллиннарның хезмәт кенәгәсенә «Алга» газетасының мөһере сугылган...

Якташ язучыбыз, Иске Йорт егете Сафа Сабиров — Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият редакциясе мөдире. Аның ярдәме һәм кереш сүзе белән якташыбыз Павел Апушевның «Сукмагым» дигән беренче шигырьләр җыентыгы чыгып килә. Сезнең иҗатны да Казан редакцияләрендә менә шундый игелекле шәхесләр көтә. Языгыз!

Сәгать биштә Казан кунакларын Райкомның I секретаре Обухов кабул итә. Таралышмагыз, хәзер без урман авызына чыгып фотога төшәбез, бәйрәм санында беренче биттә күрерсез... Раил, плёнкаң җитәрлекме? Оештыр халыкны, Георгий Константинович соңарганны яратмый!..

***

Авылдан мин үзем генә чакырулы идем. Рәхәтләнеп җәяү кайтыйм әле. Урман аша тәпиләсәм, юлы бермә-бер кыскарак, ләкин су буйлап тәвәккәлләдем... Мишә буенда шигырь күбрәк! Язгы ташуларның әүхәте беткән, су чистарып, үз эзенә төшкән. Ата кошларның сайрап торган мәле. Агым уңаена, дулкыннарга

ияреп, әниле балачагым иленнән кайтып киләм. Ашыкмыйм. Шәвәли комлыгына җиткәч, Мишә Казан юлына борыла. Исән калган хыялларымны тәртипкә саласым бар. Таң атуга охшаш кояш баешы, тирән ярда тургайлар кайтавазы, кичке җилгә ияргән көтү тузаны исе, язның япь-яшь киче... Нәкъ менә хәзер ялгызлар үзенә пар эзләп ыргыла, парлыларның сөелер урын эзләр чагы... Ә мин ошбу илһамияттән үземә шигырь эзләрмен. Кем өчен? Атна саен хат алыша торган Сәрия, Ләйлә, Назлыгөл, Илсөяр, Наиләләр өченме?

Әллә соңгы «наза» уенында мина такмак чыгарып, Күн авылы егете Касыймга юри чытырдап ябышкан Сәвия өченме? Ябышканнар кияүгә дә ябышып чыгар, соңгы хатлар араны өзәр... Аларның берсенә дә минем шигырьләр кирәкми инде хәзер...

Ә мин поэма язам... Зәмзәмия исемле кыз бала язмышы турында... Яна Җизни авылында ялгыз хатын яши. Ул, иптәш кызларына ияреп, Чиләбе өлкәсенә бәхетен сынарга дип чыгып китә... Магнитогорски ПМСына, тимер юл салучылар бригадасына килеп эләгә. Шпалларга башмак кагучы булып ирләр эшендә эшли. Яшәүләре — тимер юл вагонында... Үзләре салган юл буйлап вагон да гел күчеп тора... Борис исемле башкорт егете белән таныша. Борис телгә оста, белмәгәне юк, шома егет, шигырьләр дә яза. Балага узганын белгәч кенә, егет армиягә алына. Йөкле хатын туган авылы Яна Җизнигә кайтып төшә. Шунда кыз бала таба. Зәмзәмия исеме куша. Шуннан... Борис боларны эзләми. Армиядән соң Каспий далаларында газ ятмалары бораулаучысы булып киткән дип ишетәләр... Зәмзәмиянең әнисе гомер буе «Агыйдел» журналын алдыра.

Поэманың икенче бүлеге Зәмзәмия Борисовна турында. Кыз әтисез үсә... Чибәр. Тиз өлгерә. Егетләре күп. Араларында берсе — Хәтим исемлесе аеруча әрсез булып чыга. Яклаучысыз кызны чыгарылыш кичәсеннән кайткан чакта урманда көчли. Өйләнәм дип юмалап йөри. Өйләнми. Бәлзәмия исемле кыз белән авылдан чыгып кача.

Поэманың өченче бүлегендә Зәмзәмия Казанга китә. Иптәш кызына ияреп кунакка кайта. «Мин»ем белән таныша. Язмышын бәйнә-бәйнә сөйләп бирә. Мин аны бәхетле итәргә вәгъдә бирәм... Ләкин үзем бәхетсез...

Поэманың морале: Тол хатынның язмышы кыз балага күкрәк сөте белән күчә...

Поэмага гыйшыкланып тотындым.

Тавыклар кунačага менүгә, өстәл артына утырам. Таң әтәче кычкырганчы күчмә лампаны сүндермим.

Бер атна дигәндә төгәлләдем. Исемен: «Яна Җизни сукмаклары» дип куйдым. Язучылар оешмасының адресын беләм. Туп-туры Гөлшат Зәйнашева исеменә җибәрдем. Дөрес, теге вакытта Гөлшат апа Тукай клубының директоры булып эшләгән икән. Минем поэманы ул яшь язучылар белән эшләүче әдәби консультантка тапшырган.

Һәм, атна үтте дигәндә, миңа Илдар Юзеевтан хат килеп төште.

2/VI-69 ел.

«Хөрмәтле...!

*«Яна Җизни* сукмаклары» исемле шигъри кульязмагыз белән таныштым. Мораль темасына язылган әсәрләр бик кирәк, әлбәттә. Кайбер урыннарда Сез шигырьне дә «үрә» беләсез. Ләкин, кызганычка каршы, поэма кебек катлаулы жанрда Сез югалып каласыз. Беренчедән, алдаучы азгын ир һәм алданган кыз фаҗигасе турында безнең әдәбиятта бик күп язылды. Сезнең язмагыз художество-эчтәлек ягыннан алардан нык калыша. Геройларыгызның поступоклары, кичерешләре тормыштагыча табигый түгел. Икенчедән, бу

теманы хәл итү өчен, Сезнең шигъри осталыгыгыз җитми. Шигырь язарга өйрәнмичә торып поэмага тотыну, әлбәттә, читен эш.

Киләчәктә шуларны искә алырсыз дип уйлыйм.

Сәлам белән,

ТАССР Язучылар союзының

әдәби консультанты (имза) Илдар Юзеев.

Миңа әле унтугыз да тулмаган.

Шагыйрьлеккә өйрәнүнең чиге юктыр.

Яшьлек хаталары һәркемнең дә бертөрледер, ләкин язмышлар күптөрле. Поэманы яңадан язасы бар. Аның өчен әдәби язмышларны кабат-кабат өйрәнәсе, Зәмзәмиянең туган авылына кайтып, үскән нигезен, суга йөргән чишмәсен, фаҗигане шаһитлары булган яшьтәшләрен күрәсе бар.

Зәмзәмия үз авылына алып кайтырга бигүк ашкынып тормый. Солтания апасы: «Бәбиеңне тап әле әүвәл, шуннан соң нүешенә күренеп шапырынырсың!» — дигән... Чемодан белән кайткан йөге өч айлык булса... 31 декабрьдән башлап санап чыгардым — сентябрь азакларына туарга тиеш. Ким дигәндә биш ай хәзер. Бу килеш Саескан тавында паромнар белән идел кичеп, 230 чакрым буе «ПАЗ»икларда сикәлтә санап кайтырлык итеп сагынмагандыр әле авылын. Дөрес, Зәмзәмиянең гәүдәсе — һаман да сылулыгын югалтмаган — мин бәбиле дип бүлтәеп тормый. Сыны авырайды, каенанага ярарга тырышып, артыгын тыпырдамый, башын исә, икенче ияге сызылып куя. Әни әйтә, беренче көмән бик җыйнак була ул, ди. Белгән нәрсәм түгел, моңарчы безнең өйгә корсаклы килен төшкәне юк иде әле.

Июль челләсендә Зәмзәмиянең биле тартылды, авыры кием белән генә каплап бетерерлек түгел хәзер. Җиләккә баргач та Көрәксә болынында тезләнеп кенә җыеп йөрде.

Сентябрь җитте. Урам шаулатып балалар мәктәптән кайта, ә безнең «Раил Шакиров» һаман тумый әле.

Бөек Октябрь Социалистик революциясенең 52 еллыгын бәйрәм иттек...

Кыш җитте. Танышуыбызның 1 еллыгы дип Яңа ел төнен дә каршыладык... Тумый да тумый.

Иске поэма шул килеш ята.

Әни әйтә:

— Җиде айдан туучылар бар. Ну, ана карынында ел буе ятмыйлар ич инде?!. — ди.

Мин әйтәм:

— Икәүдер алар — син алдан чык, юк үзең чык алдан, дип берсен-берсе үгетләп яталардыр.

Әни көлми.

Зәмзәмия көлә-көлә әйтә:

— Саный белмәгәнсез!

Әни әйтә:

— Тугызга хәтлек кенә санар өчен минем өч класс белемем дә җитә!

Мин әйтәм:

— Чемоданың апрельдә кайтты, гыйнвар азагында тумый калмас...

Зәмзәмия әйтә:

— Каян белим инде мин аны. Моңарчы бала табып караганым югые ич!

Әни әйтә:

— Син белмәсәң, Солтания апаң белгәндер...

Шуннан соң малай туганчы сөйләшмәдек... Кәбисәле февраль башында малай туды.

Һәм, кояш баеганда очар канат биреп, шигъриятле киләчәк белән туктаусыз рухландырып торган мәхәббәт алиһәсе — музам җәяүле бураннарны, чатнама суыкларны кичеп, сагышлы көннәрдән шыксыз төннәргә күчеп, ком бураннарына кереп адашты.

Поэманы оныттым...

***

Иртәгә бөтенләйгә аерылып китәм. Тагын. Өченче тапкыр инде(!) Фельдшер Мәүлидә апаның «ашыгыч ярдәм» сумкасы хәтлек кенә кулсандыгымны күтәрәм дә чыгып качам. Ияргән малым: шактый ук киелгән ак нейлон күлмәк, өстемдәгесе өлгереп җитмәгән әфлисун төсендә; җиде-сигез төрле куен дәфтәрем, басылып чыккан шигырь-хикәяләремне кисеп ябыштырган калын дәфтәр. Коңгырт костюмның чалбарын үтүкләп тормыйм, юкса Зәмзәмия шикләнеп, бусагага аркылы ята... Икесендә дә эзләп тапты. «Синнән башка фатирыбызга кайтып керәсем юк. Баланы минем әни үстерер әле... Бөтен гаилә дә шулай этле-мырлы яши инде. Сиңа гына гел мәхәббәт кирәк. Каян килгән шаһзадә?!» дигән сүзләрне күз яшьләре белән ныгытып куйгач, ике тапкыр кире кайттым. Күңелем кәлҗемә бит минем — күз яшенә әсир төшәм.

Китәм дигән көнемнең таңы атып килә.

Соңгы елларда минем өчен таңнар көн саен бертөрле: кояшы да шул ук, күге дә, офыкның бу тәрәзәдән күренеп торган өлешендә агач сурәтләре, биек йортлар күләгәсе дә, тургайсыз болытлары да шул ук.

Таңның кызыл сызыгында Җир белән Күк аерылды. Яктылык чатнавы торган саен ныграк зураеп, ниһаять, кояш кыерчыгы күренде. Авырттырып туа яңа көн...

Мин бу тәрәзәне таңнары белән Зәмзәмиягә калдырып китәм.

Сервант шүрлегендәге калай будильникка кояш төште бугай. Башка көннәрдә аның кыңгыравы миңа язгы тәнәфесләрдән озаклап чакыра торган еракттагы мәктәп елларын искә төшерә иде... Бүген ул кибетләрдә тәрәзә янагына кадакланган «Разбой!» кыңгыравы булып янрый, кыңгыр тынлыкны дер селкетә: «Талыйлар! Качалар! Тотыгыз!..» Менә хәзер, сиренасын үкертеп, патруль машинасы килеп туктый. Аннан ике милиционер бәреп керә: «Кем? Кайчан? Нәрсәләр югалган?!.»

Ир белән хатынның аерылышуы ул — үзенчә гаилә эчендә башланган гражданнар сугышы. Бер түбә астында кулга-кул тотынып гомер иткән ике кеше кинәт кенә сыйнфый дошманга әверелә. Һәм кем җиңә — шул хаклы! Кем җиңелә... шул чигенә. Шәһәреңне, өеңне, мөлкәтеңне ташла да кач! Татуланган атлы кыйланып, күпме генә солых төзесәң дә, барыбер туктамый ул гражданнар сугышы.

Зәмзәмия әнисе белән бергә эшли — икесе дә фәнни-тикшеренү институтында кече лаборантка. Аларны оешманың автобусы йөртә. Юл уңае малайны да яслегә озатып өлгерәләр. Яшәү рәвеше шулай көйләнгән иде. Миңа ышаныч юк, эш урыным җәен-кышын кырда иде.

Яңа туган көннән миһербанлык көтеп, кояш хозурында хыялланган килеш, хезмәт кешесе өчен уяну сәгате җиткәнне дә сизми калганмын.

Кухняга Зәмзәмия чыкты, зал ишеген япмады, аннан әле әнисенең чыгасы бар. Тәрәзә төбенә таянган җиремнән, борылмыйча гына мин аларны җилкәм аша тоеп торам.

Зәмзәмия, кирәкмәсә дә, сыер җилене тарткан ише генә чыжылдатып краннан бер йотым су өстәгәч, тулы чәйнекне газ плитәсенә ыргытты. Әйе, әйе, куймады — ыргытты!

Ә н и с е: Шагирь моңаямы?

З ә м з ә м и я: Буровойда калган курчакларын сагына.

Ә н и с е: Әллә кичәдән бирле шонда тора?

З ә м з ә м и я: Мендәрендә гүр суыгы.

Ә н и с е: Шыксыз гәүдәсе генә калкына. Җанын кемнәргәдер калдырып кайта хәзер, хәсис.

З ә м з ә м и я: Ул сыкасын да эзләп табам. Башкалар белән яшәтмим дидемме?!. Үрмәләп кайта торган итәм сөйрәлчекне.

Әрләшү ул — кискен диалоглар бәрелеше... Ә боларның зарлануы парлы монолог кына. Әгәр шушы минутта берәр кәлимә өстәсәм — сүз зурга китеп, әче таңнан кара тавыш кубачак. Мин каршы дәшмәгәч, боларның гайрәте тиз сүрелде.

Ә минем җан чынлап та үземне ташлап качкан, ул инде атна буе өйдән-өйгә кереп, Әмәт тавы бистәсендә баш төртерлек почмак эзләп йөри. Гаиләсеннән кача-поса яшәргә җыенган ирне кем фатирга кертсен инде?.. Парлы гаиләдә ирләр хатыныннан көнләшә. Тол хатынга туры килсәң — нәкъ минем кебек үк ташлап киткән иренә әйтелми калган тозлы-борычлы кинаяләрен йөзеңә бәрә. Ә кемнендер кызы үсеп буйга житкән... Ашык-пошык салынган өйләрдә түбә саен икешәр-өчәр гаилә тыгылып ята. «Теплоконтроль», «Соцгород» тирәләрендә почмак табуы жинелрәк, диләр... Ләкин миңа шушы тирәдән табарга кирәк, укырга керергә теләгән институтка якынрак итеп.

Ниһаять, Косогорная урамының очына чыктым дигәндә генә, «ярар...»га охшаган сүз ишеттем. Кычкырып әйтмәделәр, ыңгырашып кына. Сиксәннән узган ятимә карчык урын өстендә Әҗәл килгәнне көтеп ята иде. Фатир хакы да сорамыйм, ди, өемнең искелегенә, идәннең череклегенә түзсәң, җаның теләгән кадәр яшә, ди.

Әхмәт морза бистәсендә (безнеңчә — Аметьево) бөтен урамнарны да «Косогорная» дип атап булыр иде — кая карама, кыек тауны кисеп кереп, рөхсәтсез салынган такта өйләр, рәтен-чиратын югалткан тыкрыклар. Тауны тигезләп түтәлләр ясаганнар. Ятимә карчыкның җепсә-баганалары гөмбәләнгән рәшәткә эчендә яшьлегеннән калган ике алмагачы да бар хәтта. Исемен бик тиз әйтте: әллә Хәтимә, әллә Фатыйма диде шунда, кайтарып сорамадым. Минем өчен ул гелән Әби булып калды.

Әби хәзинәдә ни барын күрсәтергә теләпме, унөч тиенлек күмәч батоныннан кыерчык сындырып, кырлы стакандагы сары чәйгә манып капты. Өстәл хезмәтен үтәгән арка терәвечле такта утыргычта яртылаш ачылган маргарин пачкасы белән касәдәге шикәр комыннан гайре нигъмәт юк.

Без дә бу вакытта буровойда төшке ашка туктала торган идек инде. Чемоданымны карават астына шудырдым да «Роторная» тукталышындагы гастрономга йөгердем. Кесәмдә акчам юк әле, ләкин берсе-берсе егерме тәңкә торган отышлы дүрт заемым бар, шуларны почта бүлекчәсенә кертеп сиксән сумга алмаштырдым. Ай саен өчәр-дүртәр йөз сум акча эшләгән мужикның яшерен «чумарасы» булгандыр инде диярсез. Юк. Су бораулауда эшләүче агайларның бөтенесе диярлек хатыннарына ел дәвамына ярарлык ышаныч кәгазе язып тоттыра. Агрегатны туктатып, эшне ташлап, контор тирәсендә акча көтеп йөрүчеләрне начальство бик өнәми, еллык планны арттырып үтисе бар.

Мин дә, башкалар алдында вакчыл ир булып күренмәс өчен, зарплата алуны тулысынча Зәмзәмиягә тапшырдым. Кесә төбендә запас акча йөртү мөмкин түгел, үзем сизмәгән арада барыбер әнисе белән икәүләшеп тентү ясыйлар иде.

Гастроном киштәләрендә «завтрак туриста», «дингез кәбестәсе», вафли, печенье, карамель ишеләре өелеп тора. Колбаса, атланмай, каймак кебегрәкләрне комбинаттан китергәннәрен сагалап торырга кирәк. Көндәлек ризыкның талонга калачагын яшермиләр инде. Кичен радиоалгычлардан «Голос Америки»ны тыңлап яткан агайлар, ишегалдына җыйнаулашып домино уйнарга чыккач, артык тел яшереп маташмыйлар, азыкның һәр төренә аерым төстәге купоннар бастырыласын, шәһәрдәге кеше башына ничә грамм пай тиясен, хәтта аракының да талонга каласын өстәл сугып сөйлиләр. Ил кысмырланганчы дип ашап һәм эчеп калу шаукымы көннән-көн ныграк сизелде.

Минем кебек шәһәр белән авыл межасында калганнарның тамак шарты хөртиләнәчәк алайса. Бу хәлдә яна эшкә урнашу, прописка табу һәм алга таба укырга кереп карауны ашыктырырга туры килә.

Казанның 700 мең кешеле чагы. Чат саен игъланнар тактасы: безгә кил, безгә кил, дип чакырып торалар... Эшнең тулай тораклысы кирәк кирәген, ләкин мин әле буйдак түгел, Зәмзәмиядән бүген генә чыгып качтым, законлы аерылу өчен утлар-сулар кичәсем бар.

Менә кайчан кирәк ул тормыш тәҗрибәсе! Мәктәпне тәмамлап, укырга керә алмыйча калгач, Мех берләшмәсенең 2нче фабрикасында тире юучы булып эшләп алган идем: хезмәт кенәгәң кирәкми, гаиләң бармы, юкмы — аларга барыбер, яшеңне сорамыйлар, килгән көнне үк гариза яздырып, фабрика эчендәге барак-торактан караватт биреп, өч сменалы эшкә җибәрделәр... Пешеккән тире исенә ике ай түздем. Гомерем озын булса, мутон тун кигән кызларга борылып та карамам дип, бишмәтле авылыма кайтып киткән идем... Ярый әле «тәүбә» әйтмәгәнмен, күпме ел үткәннән соң, аякларым үзеннән-үзе тагын шул якка каера. Ни дисәң дә, таныш як, белгән җир, үги туганым кебек... Алай да килгән хутка тире чокырына сикерәсе итмәдем әле, ни дисәң дә, бораулау остасы дигән һөнәр иясе, нәфсем сайлана, берләшмәнең фабрикаларын күздән кичерәм, дөбер-шатырына колак салам... Кайдадыр вак торба бушаталар. Киттем шуларны эзләп... Идел ярын үз эченә алып, эш урыны күтәргәннәр: түбәсез капкалары ябык, баганасына берни язылмаган. Тик куе яшелгә буялган кирпеч коймасы бу биләмәнең һичшиксез мех берләшмәсенә катышы барлыгын күрсәтеп тора.

Кайчаннан бирле торба тавышы «Чың!.. Чың!.. Чың!..» итә... Әйтерсең лә кешедән качып, Ленин башы төшерелгән юбилей тәңкәсен саный-саный бер кучкә өяләр... Капкалары бикле түгел икән, тәвәккәлләп этеп караган идем — ачылды. Күз алдымда кинәт кенә эшчеләр дөньясы пәйда булды. Үземне су бораулау оешмасының склад мәйданына килеп эләккәндәй хис иттем. Анда-монда бушатылган төрле җиһазлар, насос-шланглар, кислород баллоннары, янган металл һәм көек исе, машина әрҗәсенә менеп баскан ике агайның үз үлчәмнәреннән шактый зур «Х.Б». киемнәре... барысы-барысы бергә, күптәннән таныш мохиткә охшап, кәефемне күтәрде.

Ул арада килеш-килбәте, өс-башы белән бигүк «кара эшче»гә охшамаган ир уртасы кеше цех эченнән чыгып, туп-туры минем янга килеп басты.

— Чит кешеләргә керергә ярамый! — диде ул, цех ишегенә кадакланган язулы калайдагы сүзләрне кабатлап. Аннан, хәрби сер кебегрәк аңлашылмасын тагын дипме, өстәп куйды. — Куркыныч! Ут, су, тимер-томыр!

— Мин эш эзлим.

— Кадрлар бүлегеннән җибәрделәрме?

— Юк. Торба бушатканны ишетеп килдем.

— Слесарь мәллә үзең?

— Юк. Бишенче разрядлы бораулау остасы. Су буенча. Алтынчы разряд

та биргәннәр иде... Эштән китүемә ачу итеп, хезмәт кенәгәмә приказын язмадылар.

— Ник киттең соң?

— Гел юлда йөрү романтика кебек иде. Хәзер чегән тормышы белән яшәү кызык түгел. Казаннан чыкмыйчарак эшләп, укырга кереп карыйсым килә.

— Синең әзерлегеңә күрә урын юк шул бездә... Әгәр IV разряд белән слесарь булып урнашырга ризалашсаң, мөмкинлек бар.

— Ярап куяр иде... Прописка мәсьәләсе четерекле бит әле, хатын тиешле кеше мине «домовая книга»дан сыздырып атты. Паспортта пичәте бар-барын.

— Боларын кадрлар бүлегендә әйтеп торма. Аларга төгәллек кирәк, ә миңа тәртипле белгечләр җитми. Цех начальнигы Әхәт Хәмитович белән сөйләштем, ике айга вакытлыча алып торырга риза, диярсең... Соңыннан тагын ике айга озайтырбыз да, үзеннән-үзе даими эшкә күчү булыр...

— Рәхмәт инде сезгә!

— Рәхмәтеңне укырга кергәч әйтерсең.

Әхәт Хәмитович чандыр гәүдәле булса да, әллә ни җинел сөякле кеше түгел, адымнары салмак, тавышы басынкы, гәүдәсе Ил йөген үзенә алгандай бөкрәя төшкән. Чырае, илле яшьлек ирләргә хас булмаганча, гел җыерчыктан гына тора. Һәр сүзе иренен каплаган калын мыектан сөзелеп кенә чыга. Күз карашында кешене бер күрүдә фаш итә алырдай сизгерлек бар. Белемем-һөнәремә, хыялларымның ихласлыгына ышанып, документларымны караштырмыйча да эшкә алырга ризалашуы аның күрәзәлек тәҗрибәсеннән киләдер.

Яңа урын мине үзенә бик тиз җәлеп итте. Эшкә йөрүнең дә кыенлыгы юк. Газовая урамындагы соңгы тукталышка чыгып, 6нчы трамвайга утырам, Мех берләшмәсендәге соңгы тукталышта төшәм. Юлга күп китми — барып кайтуың — нибарысы алты тиенлек бакыр. Мин урнашкан җир берләшмәнең «Теплосиловой» дип аталган мөһим цехы икән. Авыл көтүендә тигәнәк сарып, тузанга батып, корчаңгыланып беткән сарык тиреләрен чит илгә чыгарып сатардай затлы тун итәр өчен, әлеге цех җылылык һәм суны тәүлегенә егерме сәгать буе өзлексез өлгертеп торырга тиеш. Иртән сөенә-сөенә киләм, канатланып эшлим, кичен алҗымаган килеш кайтып китәм. Автоген белән эретеп ябыштырудан гайре бөтен эшкә дә тыгылам: сүтеп җыябыз, төзәтәбез, алыштырабыз, яңаны корабыз, чуен юл аркылы «ТЭЦ»ка барып тоташкан колач җитмәстәй пар торбаларын чем-карага буяп, пыяла мамыгы белән төреп куябыз...

Фатир хуҗасының пенсиясен юмалап алып, күрше сәрхуше, әбине ипи белән суга калдырган икән. Мин ташыган тәм-томнардан авыз итә торгач тернәкләнде, эштән кайтырыма ашарга әзерләп куярдай хәлгә җитеп аякка басты.

Культура институтының кабул итү комиссиясенә барып, укырга керү шартларын белешеп йөргәндә, бер студенттан биш сумга курай сатып алдым. Чаңгы таягыннан гына эшләнгән нәмәрсә булгач, бик ышанып бетмәгән идем, егет, буш аудитория табып, сатлык курайда үзе уйнап күрсәтте. «Салкын чишмә» җырын болай ук моңлыдыр дип уйламаган идем... Озын көйнең ахырынача тыңлап бетерергә сабырлыгым җитмәде, кулыннан тартып диярлек алдым да, рәхмәт әйтеп, чыгып йөгердем.

Инде кич җитте исә, әбинең ике алмагачлы өй түренә чыгып сызгыртам. Гармун уйнаган кешегә курай өйрәнү кыен түгел икән. «Салкын чишмә»не Сәвия тыңларлык итеп уйный алам...

Һич көтмәгәнчә, яңа тормыш ачылды. Язгы ташкын җәелеп, тынчыган судан зур елгага качкан күл балыгы кебек очынам. Миңа әле нибарысы егерме өч яшь кенә тулып килә, бәлки бу минем яшьлегемдер әле?! Өр-яңадан яшәп карап, бәхетле булырга бер мөмкинлегемдер? Зәмзәмия күпсенер бу бәхетне.

Дистә еллар буе эзәрлекләп, сукмакларыма киртә корып, олы юлыма каршы төшеп, якын туганнарым белән арабызны бозып, ямьсезләнеп, рухымны сындырырга маташыр. Ләкин шушы түбәнсенүе, явызлыгы, әшәке хатлары, гайбәт һәм янаулары белән ул мине киресенчә әрсезлеккә, үҗәтлеккә, ялган күз яшьләренә бирешмәскә, җыйнап әйткәндә, үз бәхетем өчен көрәшергә генә өйрәтте, чыныктырды.

Хәер, болары әле киләчәктә һәм берьюлы түгел, әз-әзләп...

Ә бүген яна эштә хезмәт хакы бирделәр. Кесәгә акча керү белән, иң беренче теләгем кальбемдә тыпырчына башлады: «Авылга кайтам, авылга, Сәвияне күрәм!»

Казаннан безнең авылга кайта торган юл Космонавтлар урамыннан башлана. Курай кесәдә, күчтәнәчләр алып тормадым, авылда хәл белергә кереп чәй эчеп чыгардай якыннарым юк. Килен кавеменә калганчы, дип әни ашыгычлык белән өйне сатып өлгергән иде инде. Хәзер ул абыем янында Кындырлы бистәсендә яши.

Мин Сәвиянең хәл-әхвәленнән шактый гына хәбәрдар. Ярты авылыбыз Меховайда эшли, күргән бере: «Зәмзәмия белән аерылышкансыз дип ишеттек. Чынмы шул?» — дип башлый да ахырда никтер Сәвия турында сөйләргә тотына. Кыз матур гына чәчәк атып ята, диләр. Авылда зур тегү цехы ачканнар, шунда эшләп йөри ди. Күн авылы егете урларга маташкан бугай, шуннан куркып, кичләрен клубка бик чыкмый ди әле. Казанга китеп, бертуган апасы янына урнашырга да исәбе бар, имеш...

***

Авылның «кара баганасы» янында узгынчы автобустан сикереп төшеп калдым.

Урманны чыгасым бар. Шәфәкънең сүрән яктысында әйләнә-тирәнең рәсемнәре куерды. Былбыллар аһәңе, наратлар пышылдавы, кичке җил сулышы — һәр тарафка гыйшык, сөю-сәгадәт өләшә.

Ул минем кайтасымны, күпме сагынганымны, гомумән, бүген аны эзләячәгемне белми дә әле. Шуңа күрә дә өенә барып, артык күзләргә чалынып, кеше сүзенә керергә ярамый. Туп-туры клубка юнәлдем, ашыгуымны сизәм, тик үземне тыя алмыйм. Юк, ул анда юк... Эш урынына киттем, бәлки ул икенче сменададыр... Тегү цехы... Иске мәчетне эчтән ямап, көн лампалары элеп, егермеләп кыз-хатынны мәктәптәгечә өч рәткә тезеп утырткannar. Һәрхәлдә эш өстәлләре партага охшаган, тегү машиналары гына килешсез тора.

Безнең белән бергә укыган Хәмит кызларның начальнигы булып алган, мине күрү белән яныма килеп басты.

— Нихәл, шагирь?! — ди бу миңа яна кушамат тагып. — Әйдә, шушы цех турында гәҗиткә язып чыгар әле. Или син язмыйсыңмы инде хәзер, укырга керә алмагач?

Бәхәсләшеп торыр чакмы — язарга ризалашкандай баш изәп, рәт арасы буйлап киттем. Кайсының аркасыннан сөеп, кайсының колагына иелеп: «Нихәл, сеңлем, тегеләмә?.. Кай арада өйрәндең?.. Кыен түгелме?.. Икенче сменада чагында клубка чыга алмыйсыз икән...» дигән булыплар сүз юктан сорау булсынга илтифатлык кылам. Ә үзем һаман саен Сәвиягә якынаям. Яныннан үтеп китешли генә сөйләндереп өлгерергә исәбем.

— Җой тегәргә өйрәнгәнсең икән.

— Сезне тракторга укытканда, безгә домоводство дәресләре керә иде бит.

— Сине күрәсем килде... — дидем мин, тегү машинасы тавышын чак җиңәрлек итеп кенә пышылдап.

— Сизәм мин аны. Икенче смена бик соң бетә. Ардыра да. Безнең очтан кызлар бик күп монда. Сүзе чыгар. Киләсе атнага кайт.

— Китмим. Иртәгә ял көнегез ич.

— Кемнәрдә кунарсың икән?

— Белмим әле. Клубка чыкма. Кич җиткәч, үзәнлектә курай уйнармын, — дип сүземне тәгәлләвем булды, машинасын әйләнүдән кинәт туктатып миңа текәлде. Күзләрендә сәерсенү, кызыксыну, сорау һәм елмаю — бөтенесе бергә чагылып алды. Сәвиянең әле моңарчы миңа болай күтәрелеп караганы юк иде!

— Иртәгә... — Ул әйттеме моны, әллә мин үземме... белмим инде. Барыбер ярату сүзенә тиңдәш пышылдау иде бу.

Авыл җирендә, кешеләр белән күрешкән чакта, туганлыкны искә төшереп, нәсел агачының сыек чыбыкларын барлап алу гадәте бар... «Беләсең микән, без әтиең ягыннан... әниең белән безнең әни туган тиешле... минем бабай әбиегезгә җиңги дип дәшә торган иде...» кебегрәк искәртүләр бер колактан керсә — икенче колактан чыгып та китә торган иде. Туганнарыбыз арасындагы үзара гамьсезлекнең ачысын шактый татырга туры киләчәк әле миңа.

Төн уртасында япа-ялгызым калгач, әтиемнең туганнан-туган сеңлесе Разыя апам барлыгы исемә төште. Уятып керә алсам, куып чыгармас әле. Өйләренең кайдалыгын балачактан ук беләм. Шушы тыкрыкка көтү каршы алыр өчен җыела идек. Авыл зур булгач, көтүдәге маллар да ишле, сарыкларыбыз туры кайта алмыйча мингерәп, бәрәннәре адашып йөрмәсен өчен, үзебезгә ияртеп китә идек. Көтү соңарган көннәрдә Разыя апаларга кереп чәй эчеп алам.

Апа гомер буе авыл советы секретаре булып эшләде. Пенсиягә чыккач, өйдә тик утыра алмады, бакча башына терәлеп торган урманнан җәй буе кайтып кергәне юк, сазга йөри, чикләвектән калмый. Чоланы тулы табигать хәзинәсе. Кергән саен таба ашына туры килә идем.

Киңәш сорап килүчеләр күптер, Разыя апаның капка баганасында электр кыңгыравы төймәсен шәйләп алдым. Төн уртасында олы кешенең йокысын бүлдереп йөрү кыен инде, беләм. Нишлим соң, башка чарам юк.

Өй эчендәге кыңгырауның чыңы урамга чаклы ишетелде. Башта ишегалдындагы көчек уянды, ул өреп туйгач кына, корылган пәрдә артыннан апаның жете тавышы ишетелде:

— Кем бар анда?!.

Хуҗасы аркамнан сөйгәч, аяк астында бөтәрләнгән көчек өрүеннән туктады. Апа, күңелендәге шик-шөбһәсен зарга салып, битәрләп алып керде.

— Кояш баеганнан соң килгән хәбәр хәерлегә булмас... Таң алдыннан килгәне дә юньлегә түгел, диләр... Ике шәфәкъ арасында нинди хәвеф йөртә икән үзеңне?.. Әнием үлгән караватка ятып торганыем, шул килеш йокыга киткәнмен... Саташып беттем, әле дә ярый уяттың... Күңел сизенә ул...

— Бернинди дә хәвеф-хәтәр юк, апа... Авыл ягына кайтучы автобус күргәч, менеп утырганымны сизми дә калдым. Күчтәнәч алырга да өлгермәдем.

— Нинди күчтәнәч ди ул. Казаныгыз талонга калып бара. Авылда Ходайга шөкер әле, бөтен кеше каладан кайткан балаларына күчтәнәч төяп җибәрә. Ник ялгызың гына? Зәмзәмияң кая?

Мин ни дип тә җавап бирергә белмәгәч, апа артык төпченәсе итмәде.

— Ярар, ярар, үзегез беләсездер. Юкса, сорау алган кебегрәк килеп чыкты... Ниме, аш җылытыйммы?

— Юк, юк, апа, тамак тук, берүк мәшәкатьләнә күрмә, — дигән булам. Үзем ашъяулык читеннән күренеп торган балан бәлеше кисәгенә текәлдем. — Чәй куйсаң, кыен булмаса...

— Ничек инде, кунакны чәй эчермичә яткырасың ди?! Йокы көн саен килә ул. Ә дәү абыемның төпчек малае безнең өйгә сукмакны оныткан иде инде.

Авылыбыз чишмәләренең суы каты — самавырлар озак итеп көй чыгара. Чәй кайнаганчы ук бәлеш кисәгенә үрелдем.

— Син ярата торган шомырт бөккәне дә бар шунда. Кайтасынны сизгән кебек — махсус пешергәнмени...

— Апа, жил тегермәнендә «Шомырт көне» бармы ул хәзер?

— И-и!.. Күптән юк инде. Тегермән канатын да яшен сукты. Өрдереп тарта торганын көйләделәр.

Электрын өзгәч, самавырның да көе бетте... Тамак тук... Ут сүнгәч, казан артындагы чикерткә дә сөенде... Ястык куенында, үземнең туып-үскән авылымда, кеше өендә йоклап ятам... Тегермәндә «Шомырт көне»...

Мишә елгасының безнең авыл бәхетенә тигән өлеше шомырт урманына төренгән. Гасырлар буена үсә торгач, шомыртлык әкренләп күрше-тирәне яулап, күл читләрен, сазлыкларны, хәтта урман юлларын да басып алды. Нәрсәң бар — шуны ашыйсың, мәжлесләрдә ашъяулыкны ачып жибәрсәң: бәрәнге пәрәмәче, алма паштеты, балан бәлеше, шомырт бөккәне булыр.

Жәйге каникулның соңгы аена кергәч, мәктәп кибетенә яңа дәреслекләр кайта. Сугыштан соң ятим үскән кыз-кыркын, малай-шалай төркем-төркем булып шомыртлыкка ябырылабыз. Чем-караның чигенә житеп, сусылланып жемелдәп торган эреләрен генә сайлап эмаль чиләккә жыябыз. Монысы — Казан базарына. Стаканын — ун, ике стаканын унбиш тиеннән сатсаң да, чиләгеннән дүрт сум чыга... Уку әсбапларына рәхәтләнеп житә!

Сәвия тигезлектә үсә, шомыртны да базар өчен жыймый. Ул гел мина иярә, сәбәбен ерактан эзлисе юк — минем кебек кәйләр агач башына житез үрмәли. Ә шомыртның иң симез тәлгәшләре — очында. Саллы ботакларны сындырып жиргә ташлыйм, Сәвия аларны кучкә өеп бара, башкаларга бирмичә саклый. Аннан икәүләшеп бөрчибез. Башкалар һәммәсе аерым-аерым жыя. Иң күбесе безнеке. Икешәр-өчәр чиләк киптерәбез.

Яңа икмәк ындыр табагыннан амбарларга күчкән арада жил тегермәнендә «Шомырт көне» булып ала. Авылның аргы очы Карурманга йөри. Карурманның шомырты ашсыз, Мишә буендагы кебек баллы түгел. Сәвия белән без тегермән кәүшәсенә бергә бушатабыз, шомырт онын карурманныкы белән бутамаска тырышабыз...

Тегермән канаты иренебрәк әйләнсә, бөтен малай бер булып сызгырабыз — жил чыгарабыз. И, шуннан чыр-чу күтәрелә. Табигатькә жан керә... Тегермәндә «Шомырт көне»...

Төн уртасында кайтып, көндез һич көтмәгәндә саубуллашып чыгып китүемне Разыя апам ни-нәрсәгә юрарга да белмәде.

Үз хәлемне үзем генә беләм... Сәвия искә төшкән саен, вакыт туктап ала: жил исми, сулар акмый, кояш авыл түбәсенә ябышып тора, көн озынлыгы сәгатен югалта. Кич житми дә житми...

Шәһәрдә булсамы?!. Бауман урамына чыксаң — кыз белән егет көпә-көндез култыклашып йөри ала! Иртәнге тугызда кино-театрга рәхим ит! Күлмәк-ыштаныңны салып, Казансуның Кәжә Бистәсе комлыгында кызынып ят. Сиңа беркем дә сүз әйтми!

Ә авылда боларның берсе дә юк — ярамый! Монда кеше сүзе кеше үтерә! Авылда кыңгыр эшләр энгердә башлана, кавышу сәгатьләре төнлә генә йөри, караңгыда гавам яңадан туып ала...

Кайткан юкка нибарысы биш ел үткән. Ә күпме үзгәреш!.. 720 баланы ел дәвамында укыта алган ике катлы агач мәктәпне утынга сүткәннәр... Авыл

уртасында «Яшьләр үзәге»нә әверелгән Мәдәният йортын хуҗалык кирәк-яраклары сата торган кибет иткәннәр. Борынгыдан Сабан туе аланы була килгән «Мәдрәсә бакчасы»н бүлгәләп өйләр салганнар. Җыеннар мәйданы олы юл тузаны өстенә күчкән...

«Шомырт тегермәне»н яшен суккан, пардан киенгән ир уртасы наратларны егып, җиләкле аланнарны каезлап, шомыртлы әрәмәләрне күмеп, Чаллы ягына юл җәяләр. Туган ягым манзарасы кире кайтара алмаслык итеп җимерелгән. Яшьлегенне сагынып кайтсаң эзләп табарлык түгел...

Ә барыбер кайтам әле мин сиңа, газиз туган ягым! Казан каласында зур хыялларымны тормышка ашырам да авылыма багышланган романнарымны күтәреп; Татар илендә бары тик минем өчен генә үскән саф тәнле, тугры җанлы, кайнар чәчле, ягымлы бер кызны җитәкләп; өй салырга, агач утыртырга, оныклар үстерергә дип бөтенләйгә күчеп кайтам...

Авыл тирәли бер әйләнеш ясап, Сәвияләр ягына юнәлдем. Куен кесәмдә курай кызуын тоям. Әйтеремне, акланасы сүзләремне барлыйм, хисләремне төзәтәм, купшы җөмләләр корам. Ниһаять, урамнарда эленеп торган көтү тузаны җиргә төште. Шәфәкъ нуры сүрелгән саен, үзәнлектә энгер куерды. Тау башындагы өйләр генә әле һаман нурга күмелгән. Күбенә түздем, тагын бераз гына көтәргә...

Көтәргә! Миңа әле көтәргә өйрәнәсе, бәхетемне эзләр өчен, өр-яңа сәфәргә чыгасы, көрәшәсе, тырышасы, ирешәсе бар.

Курай җылысы иренемә тиюгә «Салкын чишмә» көе тын үзәнлек буйлап җәелде. Моң кайтавазы, ярдан ярга бәрелеп, тау башына күтәрелде. Өйдән-өйгә күчеп, Сәвия тәрәзәсен эзләп тапты. Бер өлгедә сизгер пәрдә кыймылдап алды. Ишетсен... килсен... күрсен...

Үзем уйныйм, үзем күңелемнән генә кураема кушылып җырлыйм:

> Тау астында салкын чишмә
> Чылтыр-чылтыр агадыр.
> Иҗтиһат[2] кыл кавышырга,
> Гомер үтеп барадыр...

Ниһаять, югарыда Сәвия сурәте пәйда булды. Ул! Кечкенәдән күз алдымда йөргән, миңа ияреп үскән, моңарчы ни өчендер кадерен белмәгән, бүген исә җаным өчен якын — бик якын булган кешем. Таудан төшкәнен көтимме, әллә үзем үрмәләп менимме?

Сәвия, озак икеләнеп торырга ирек бирмәде, кул болгап сәламләде дә үзәнлеккә ашыкты. Мине сагынудан түгелдер, тау битенең текә сукмагы ашыктырды аны. Бик хутлы төшеп килә. Аякны нык терәп, горур басып, колач җәеп сукмагын кистем... Курайлы куеныма килеп бәрелде. Сулышы тигезләнгәнче кочагымда тынып калды. Мин дә маңгай чәченә яңагым тигән килеш телсез-өнсез торам. Берәр сүз дәшсәм шушы күрешү сөенеченең садәлеге, табигыйлеге челпәрәмә килер кебек.

«Исәнмесез» юк, «нихәл» юк — Сәвия, куптәнге гәпләшүне дәвам иткәндәй, сүзне уртадан башлады.

— Ишеткәнең бар идеме икән?.. Күршебез Госман абый комбайнын капка төбенә апкайтып куйган. Ул көнне яңгыр коеп яуды. Вәт, комбайнын ашык-пошык сүндергән дә өенә кереп киткән. Иртән чыкса — комбайны юк. Тормозга куярга оныткан. Тау бит ул капка төбеннән үк башлана. Тәгәрәгән. Тетелеп беткән. Җыеп төзәтерлек түгелие. Житмәсә урак өсте.

[2] Иҗтиһат — тырышлык.

— Госман абыйны нишләттеләр инде?

— Нишләтсеннәр... Түләттеләр!

— Жәл, — дидем мин, Сәвиянең куеныммнан чыгуына көрсенеп. Ә ул аңламаганга сабышты.

— Кайсысы жәл? Госман абыймы, әллә комбайнымы?

— Икесе дә жәл. Малай чакта сезнең таудан машина көпчәге тәгәрәтеп уйный идек, сикерә-сикерә төшеп китә. Безгә кызык...

— Ярар. Мең хужалыклы колхозда ниләр булмас. Авыл хәлләрен сөйләргә тотынсам, синең Казанга китәр вакытың житәр...

— Рәхәтләнеп сөйлә! Тавышыңны сагындым.

— Че[3] һе... Кызык икән... Бәдәнне ныгыткансың. Таудан теге комбайн кебек очып төштем, тотып калдың, егылмадың.

— Бүтән егылмаска инде исәп.

— Йә, безнең өй түрендә нишләп йөрисең, чишмә башына гайбәт өстәп?

— Сагындым.

— ...Че... Мин дә класстшларымны сагынам инде ул.

— Ул мәгънәдә түгел. Мин сине башкача сагынам. Яшьлегемнән, бала чагымнан бердәнбер исән калган кешем икәнсең.

— Исән дип, кияүгә чыкмый калган запас, дип әйтәсең киләдер инде. Ник соң шушы сүзләреңне Зәмзәмиянә ябешкәнче әйтә белмәдең? Теге Яңа ел кичендә шул кунак кызын озата киткәнеңне күргәч... и хурландым, и хурландым!

— Чынлапмы?

— Че... Шуны да сизмәгәч... Түшең кызган чак булгандыр шул.

— Сәвия... Биектау судына аерылышырга бирдем. Өч тапкыр повестка жибәреп тә килмәсә, аннан башка да аера алабыз, диделәр. Икеләнәсем юк. Хәл ителгән инде... Әйт син миңа, шушылай кайткалап торсам, күрешүдән качып йөрмәссеңме?

— Ашыктырма әле, яме... Әти-әнинең йөрәген бозып, бик күренеп йөрмә.

— Вәгъдәләшкән егетең бардыр инде...

Кәефемнең кырылганы тавышыма чыкты булса кирәк, ул, тәртип бозган малайны орышырга жыенган укытучы апа кебек, иягемнән тотып башымны күтәрде.

— Вәгъдәләшсәм — өсте-өстенә вәгъдәләр жыеп йөрмәм. — Жаның тыныч булсын. Кат-кат кияүгә дә чыкмам. Бер икән — берәгәйлесенә, юк икән — лутчы утырып калам.

Турыдан-туры бәгыремә төзәп ата кызый. Әгәр хәзер үпкәләшүгә китсә, авылга соңгы кайтуым булачак. Иякне жибәр, дигәндәй читкә каерылсам да, каршы дәшмәдем.

Ике арада сәер тынлык урнашты — өянкеләр ешлыгында өзгәләнгән ялгыз былбыл моңы да үтеп керә алмаслык сагышлы тынлык... Ләкин мин Сәвиянең өй түренә тынлык тыңларга дип килмәдем.

— Кадереңне белер өчен, сине югалтып карарга кирәк булган икән, Сәвия!

— Әйтәм ич, ашыктырма! Без чит кешеләр түгел. Әкренләп гафу итәргә өйрәнермен. Мөнәсәбәтебез дә элеккеге хәленә кайтыр... бәлкем.

— Юк, Сәвия, мин балачактагы дуслыкка гына риза түгел. Син мине бүген үк гафу ит!

— Кызык... Ә нигә соң Зәмзәмиянне гафу итәргә теләмисең?

— Ул кем беләндер яратышып ялгышкан. Андыйларны гафу итеп булмый. Ә минем әле, шушы яшемә житеп, берәүгә дә «яратам!» дип әйтә алганым юк.

[3] Че — сәерсенү мәгънәсендәге ымлык.

— Ярар, сине күрәсем килми димәдем ич. Казанга китәрмен. Миңниса апам балалар бакчасында повар булып эшли. Үз янына чакыра, нянялар кирәк, ди. Авылда яшәп, гомер буе җөй тегүче булып, картаер хәлем юк... Болай да кулымның исән җире калмады — энә тишкәләп бетерде... Син цехка килеп кергәч сискәнеп киттем... Баш бармагым машинага эләгә язды.

Сөйләшүне былбыл көенә салырлык шарты килде. Мин, ашыгыч ярдәм күрсәтергә теләгән дәвалаучы кебек, җәһәт кенә Сәвиянең ике кулын кушучыма алдым.

— Кайсы бармагың? Кил, «өф!» итәм.

— Егетләр сыйпардай кул түгел, кишер угычы шикелле кытыршыланып бетте инде. Җибәр... — дигән була, ә үзе кулын тартып алырга уйламый да.

Офыкта Сәвиянең йөзенә нур сирперлек кенә шәфәкъ сызыгы бар иде инде.

— Мин синең иреннәреңне бу тиклем якыннан күргәнем юк иде әле... Тәмам чияләнгәнсең.

— Күз тидер тагы...

— Карангыда күз тими, Сәвия...

— Әнинең әтиемә әйтә торган бер сүзе бар: «Ир кеше үзе картаер, күзе-колагы картаер, әмма теле картаймас!» — ди.

— Синекеләр белән сөйләшеп карыйм мәллә?

— Үзеңә-үзең яучы булып, әти белән әнигә курай концерты куясың киләме?

— Гармун күтәреп кайтырмын. Хромканы.

— Син... гармунга да өйрәндеңме? Кай арада? Авылда чакта сизелгән һөнәрең түгелие.

— Сагыш өйрәтә икән ул. Буровойның беренче зарплатасыннан ук гармун алдым. Вагонда йөрде. Кырга чыгып шыңгырдата идем.

— Кызык. Тыңлап карасаң ярый...

— Кавышсак... Гармун белән уятырмын, кубызыма биетермен, курай белән йоклатырмын. Бик беләсең килсә, курайда тургай тавышы бар... Йә, кинәшү хакында ни уйлыйсың?

— Ике дә уйламыйча әйтә алам: әти-әни каршы булачак.

— Сине миңа каршы үгетли башласалар?..

— Әйтәм ич, Казанга китәм. Эштә гариза яздым инде.

— Алайса, син бу араларда клубка чыгып йөрмә, йә урларлар...

— Бандитлар турындагы киноларда гына ул... Ә болай, кыз бала үзе риза түгел икән — аны бирәү дә мәҗбүр итә алмый. Минем өчен җаның тыныч булсын...

Сәвия белән саубуллашканда, урам эчендәге күләгәләрнең рәсеме ачыла башлаган иде инде. Болай иртүк олы юлга машина ауларга чыгып бассаң, кем туктасын ди?!. Авылдан һич китәсе килми, кайтасы гына килеп тора. Җил тегермәне хәрабәләрен урап узыйм. Коры Кәвәл ерганагында җилләр уянган... «Чишмәле күл» өстеннән күтәрелгән болыт эчендә тургай сайрый. «Торна күле»ннән дә бер болыт күтәрелде. Аңа «Песмән» күленеке кушылды. Тургайлар симфониясендә иген кыры икмәк пешерә...

***

Мин хәзер Карл Маркс белән Красин урамы кисешкән җирдә, яслегә йөрим. Сәвия шунда килеп урнашты. Ял көннәребез дә бергә үтә. «Локомотив» комлыгында су коенабыз, билетлары кыйммәт булган өчен генә «Татарстан» залына кинога йөрибез. «Кольцо»дагы универмагның буфетына сугылып

коктейль эчәбез. Еш кына, Ленин урамы буйлап атлап, Кремльгә килеп терәләбез. Мин, Үзәк ЗАГС каршында махсус тукталып, Спасс манарасының ерактан ук күренеп торган тарихи сәгате белән кул сәгатемне дөресләгән булам. Сәвия минем ни әйтергә теләгәнне бик яхшы белә, шуңа күрә аллы-гөлле тасмалар белән бизәлгән машиналар яныннан тизрәк алып китәргә тырыша:

— Иртәрәк әле, башта син мине урларсың. Авылга кайткач, планын корырбыз, — ди. — Такси белән кайтырсың да клуб юлында күтәрсен. Иптәш кызым берәр сәгать үткәч кенә әниләргә кереп әйтер, — ди.

Ә мин кыз урлауга ике куллап каршы! Институтка укырга керәм дип хыялланып йөргәндә, кыз урлап җинаять кыл, имеш! Хаталарны матур төзәтергә кирәк. Законлы төстә язылышып, туйлар ясап, соныннан зөфаф кичәсенә кереп...

Сәвия белән икебезнең дә эш сәгатьләребез сигездә башлана, кичке биштә бетә. Мин, мазутлы кулымны комлы сабын белән ашык-пошык юам да Яңа Бистәдән Ирек мәйданына ашыгам... ашыкмыйм, «очам» гына. Трамвайлар тукталыбрак торса, җәяүләп йөгерәм. Ирек мәйданыннан яслегә ерак түгел. Кайбер көннәрдә бер-ике баланың әти-әнисе соңга калып килә, Сәвия аларны берәр сәгать көтеп утыра. Киресенчә, чебен тимәс — чер итәр балаларны дүрт тулганчы ук алып бетергән көннәр дә булгалый. Ул очракта мин туп-туры сөйгән кызымның фатирына, ягъни Миңниса апасына киләм, ире дә, үзе дә әлегә караңгы чырай күрсәткәннәре юк. Безнең авылның бик күп кызлары Казаннан тиз генә фатир алыр өчен урам себерүче булып килеп урнашкан. Миңниса апа да яследәге эшенә барып җиткәнче, иртүк торып, Некрасов урамын себереп-тазартып өлгерә. Фатир алганына дистә еллап бар бугай инде. Казанны бик яхшы белә. Шәһәрдә 700 меңгә якын кеше яшәгәнен, 200дән артык урам барлыгын иң беренче булып аннан ишеттем. Халкы миллионга житсә, монда да Мәскәүдәге кебек метро салыначак, имеш...

Безнең эше — авылдан качкан бәхет эзләүчеләргә ике йөз урамның әллә ни кирәге юк. Кольцо тирәсендә бөтереләсең. Сәвиянең бүген кәефе кырылды — бер малайны «родителе» жиденче яртыда гына алды. Чәкән пумаласы кебек кызыл сарыга буяган чәчен малайларча кистергән, калын иреннәрен иннеккә манган, тырнакларына ачык коңгырт лак сөрткән ханымны икәүләшеп көтеп утырдык. Малае белән, агач шакмаклардан гараж ясап, сәгать буе машина-машина уйнарга туры килде. Суыра торган ирис конфеты гына ханымнан аңкып торган аракы исен җиңәрлек түгел иде. Няня белән «родитель» әйткәләшеп тә алдылар.

Һавага чыккач, бераз тынычлансын дип, ләм-мим дәшмичә бардым, алай да култыклап алган килеш Бауман урамы чатына каерам, анда түткәйләрнең аяклы базары, Сәвияне чәчәк белән юатырга исәп. Җәйнең гөлгә күмелгән чагы!

— Җаның теләгәнен сайлап ал! — дигән булам.

Ә ул, сатучы белән алдан ук сөйләшеп куйган кебек, туктаган жиреннән туп-туры, сулы чиләктә көлтәләнеп торган чия кызыл чәчәкләргә үрелде.

— Гла-ди-олус! — диде ул, сокланудан бигрәк кызыгуын сиздереп.

— Жидене төрегез! — минәйтәм.

Сатучының да күңеле булды, жидегән букетны үтә күренмәле чытырдавык кәгазьгә төргәндә:

— Туй чәчәге! — дип ычкындырды.

Мондый ук юрамыш көтмәгән Сәвия сискәнеп куйды, чәчәккә үрелгән кулын кая яшерергә белмичә бәргәләнде. Һәм шул арада ук сораулы-сынаулы карашымны күреп, үзен бик тиз җыйнап алды.

Минем уйлавымча, «Туй чәчәге» күтәреп кайтып кергән Сәвияне Минниса апасы елмаеп каршы алырга тиеш иде. Юк, хуҗабикәнең никтер сөмсере коелган, өй эченең нуры сүнгән, әйтерсең лә ачык тәрәзәдән кара болыт килеп кергән дә... менә, менә хәзер яшен яшьнәргә тиеш.

— Күнел ачып йөрисезме? Берегез дәҗҗалыннан котылып бетмәгән, икенчегез шуңа ышанып башын югалтып йөри. Ярты Казан тулы авылыбыз халкы, Бауман урамында култыклашып бик балкымасагыз да яраган кана...

— Апа, нәрсә булды сиңа?! — Сәвия туган апасын танымагандай каушады.

— Кургәннәр. Житкергәннәр. Зәмзәмиян әниләрне эзләп тапкан. Ирем кызыгыз белән качып ята. Барыбер бергә яшәтмим. Иске Жизни колдунына барып бозык эшләтәм. Бетерәм кызыгызны. Зурга киткәнче аралап алыгыз, дигән. Өстәлләренә пычак кадаган.

— Че... Зәмзәмияме?! — дип ярсыдым мин, Минниса апа сөйләгәннәрне күз алдыма китереп өлгерә алмыйча.

— Әти түгел инде, Зәмзәмиян булмыйча!

— Соң... беләсез ич, аерылыштык инде без аның белән.

— Ир бирмәк — жан бирмәк димәсләрие.

— Мин аңа бервакытта да ир булмадым!

— Белмим, белмим, жанашларым. Мөнәсәбәтләрегез бик тирәнгә китмәгәндер әле шәт. Сәвиягә тимәгәнсеңдер ич?

— Апам, син нәрсә сөйлисең? Авызы бер пешкән егет белән язмышымны ашыктырырга?

— Вәт, вәт, алайса арагызны өзегез дә мондый хурлыктан котылыгыз. Кара еланны жинәр өчен, юха булырга кирәк. Безнең нәселдә иркә песиләр генә.

— Мин Сәвиясез яши алмыйм. Үләм лутчы...

— Сөйгән кызын югалткан саен үлә башласалар... ирләр кырылып бетәрие... Ну, үзегезгә карагыз. Югалыгыз күземнән. Жан көеге булып йөрмәгез. Китегез Казаннан. Илдә чыпчык үлмәс! Чыгып качыгыз дөнья читенә, жаһилләр эзләп тапмаслык итеп.

Сәвия тынын чыгармыйча гына елый иде. Бер кавымнан тынычлангач, яшьле күзләрен миңа төбәде.

— Син дөнья читенең кайда икәнен беләсеңме? Алып китәсеңме мине? Укырга дигән хыялыңнан ваз кичәсеңме?

— Сәвия, әйт кенә!.. Бирегез берәр карта, эзләп табам дөнья читен.

Өендә мәктәп баласы булгач, Минниса апа Жир шарының географик атласын бик тиз табып алды. Караватт өстенә жәйдем дә, батыраеп, Сәвия белән парлашып яшәргә яраклы урын эзли башладым. Ә ул минем һәр сүземне жөпләп торды.

— Чит илгә чыгармаслар — без икебез дә комсомолда.

— СССРдан ары китмик.

— Ростовны беләм, мастерлыкка бер ел укыдым. Әйдә!

— Якын-тирә ич...

— Үзбәкстанда апам яши. Караком чүлендә.

— Адресы билгеле — бик тиз табарлар.

— Латвиянең Огре шәһәрендә ике ай урман кистем.

— Никтер кире як. Халкы катлаулы...

— Оренбург якларында чирәм жир иктем. Әйдә шунда.

— Бик якын.

— Төньяк боз океанына! Уренгойга бораулаучы булып урнашам...

— Чүлдән дә, бозлыктан да курыкмыйм. Алып кит!..

— Юк, Сәвия, Уренгойга юл ябык икән. Анда Зәмзәмиянең Хисбулат дигән бер туганы эшли.

Бармак уйнатып, СССР тирәли йөри торгач, тайга урманнарына килеп төртелдек.

— Себергә! — дидем мин, иң аулак урын тапканыма сөенеп. — Анда да кешеләр яши!

Моңарчы, безнең бәхет эзләү сәяхәтенә кәмит итеп кенә карап утырган Минниса апа, түзмәде, тайгада яшәү мәсьәләсендә план коруга каршы төште:

— Котырмагыз инде! Берәр атна кочаклашып ятарсыз да аю-бүреләр арасыннан ничек чыгып качарга белмәссез аннары... Урманда яшәп калыр өчен, үги ямщик[4] гаиләсендә туарга кирәк.

— Алайса Магаданга! Юра Дзебук дигән егет белән Ростовта бергә укыдык. Шәп кеше. Әти-әнисе янында яши. Килеп төшәргә урын бар! — дидем мин, өметемне сөенеч белән житкерергә теләп. Шушындый зур илдә ике гашыйкка сыеныр урын да юк икән ләбаса, дип күнеле сүрелә күрмәсен. Магадан — Сәвиямне югалтмас өчен иң соңгы тукталыш!

— Кызык... Анда алтын чыгаралар түгелме соң? — диде Сәвия, апасына күтәрелеп карарга куркып кына. Минниса каршы дәшмәгәч, батыраеп, тизрәк ризалыгын сиздерергә тырышты.

— Хет Магаданга!

— Ачуым килмәгәе, туганнарын да эзләп табарлык жир түгел! — дип ризалашты апасы да.

***

Магадан ерак икән ул...

Әгәр, Сәвия Ырымбур ягына ияреп китәргә ризалашкан булса, без инде атна-ун көннән кузгаласы идек.

Аэрофлотның Болак буендагы кассасына кереп белештем, самолёт Казаннан атнасына ике тапкыр оча. Колыма якларына барып житкәнче ярты тәүлек үтә ди: сигез сәгать һавада, дүрт сәгате жирдә уза. Ягъни, Свердлау белән Яңа Себер каласында заправка ясаганда ял итеп-итеп алышлы ди. Ераклыгына түзәрсең, тик билет хакы гына шаккатмалы: Магадан бәясенә Ташкенттан — дүрт, ә Ростов-Дон каласыннан алты тапкыр әйләнеп килергә була. Төгәлрәк итеп әйткәндә, Сәвия белән Жир читенә барып житәр өчен, өч айлык получканы җыеп куярга кирәк иде.

Гашыйклар җилкәне өчен җил бер генә уңайга исә. Минем өчен иң мөһиме — Сәвияне әти-әнисеннән йолып алып, ничек тә булса кавышу ягын карарга. Кире кайту ниятем юк... Ләкин, дияргә туры килә, мин инде хәзер насыйбыма ике куллап ябышырга өйрәнеп киләм. Унжиде яшемдә үк аллы-гөлле, алмалы-хөрмәле Ташкентта паспортсыз һәм бер тиен акчасыз калып, сукбай хәлендә авылыма кайтып егылган кеше буларак, юл уңмау ихтималын да онытмаска тиеш. Менә шундый, ачы тәҗрибә белән сыналган сәяхәт арифметикасы бу!

Магаданга әзерләнгән арада җәй дә үтеп китте. Озын-озак көз житкән иде, анисының да алтыны коелды. Яңа исәп белән кышның беренче атнасына кердек. Уйланылган эштән кире чигенергә ният юк. Тизрәк хыялны тормышка ашырып, бәхетле буласым килеп тора...

Сәвия белән, дошман тылында яшәгән көрәшчеләр кебек, яшерен яшәү рәвешенә күчтек. Көпә-көндез Казан урамнарында култыклашып йөрмибез. Эше ни сәгатьтә

[4] Үги ямщик (диал.) — объездчик.

бетәсен белер өчен, яслесенә «2» тиенлек автомат телефоннан гына шалтыратам. Яшәгән фатирларыбызда икәүләшеп күренмибез. «Вузовец» кинозалына, автовокзал каршындагы «Яңа өйләнешүчеләр» паркына иялäштек — анда безнең ишеләр күпләп йөри. Сәвия хәзер авылга кунакка кайтуын да сирәгәйтте.

1973 елның 25 декабренә Магаданга билет алдым. Башта үзем барып урнашам. Аннан «Немедленно приезжай!» дип телеграмма сугам.

Ниһаять... Иртәгә мин һава юлыннан Бәхет иленә сукмак салам. Казаннан ераграк киткән саен, Сәвиямә таба якынаям!

Иртүк тордым, будильник куеп, төнне юри өздем. Романтик төшләр, хыялый саташулар самолётка калсын, йоклап очсаң, юл кыскара.

Мин бу дөньяга юлда бәхет эзләп, йөрер өчен генә яратылган ахрысы. Тапкан-табынганым, өлешемә тигәнем бер чемоданга сыйган, елның-көннең хет теләсә кайсы вакытында күтәреп чыгып кит — гел шулай әзер килеш тора: бер конвертта мәктәп елларында төшкән һәм хат алышкан кызларым фотолары; район газетасында басылган язмаларымны кисеп ябыштырган альбом; китап рәвешенә китереп кулдан төпләнгән калын дәфтәрләрдә шигырь дә шигырь генә; һәм шул шигырьләрне кире борып кайтарган редакция хатлары...

***

Хөрмәтле иптәш...

Татарстан китап нәшриятына җибәргән «Бөре шыта» исемле шигырьләр кулъязмагызны шагыйрь Рәдиф Гатауллин укыды. Кулъязмагыз белән бергә Сезгә аның рецензиясен дә җибәрәбез.

Нәшриятның баш редактор урынбасары — К.Фәсәхов.

17 гыйнвар, 1968 ел.

***

«Чаян» журналы

Хөрмәтле иптәш...

Хикәягезгә салынган орлык ярыйсы ук булса да, ул шытып чыга алмаган. Шул сәбәпле журналда файдалана алмабыз ахры.

Сәлам белән — Т.Миңнуллин («Чаян»)

27 май, 1968 ел.

***

«Татарстан яшьләре» газетасы

...Шигырьләрегездә кайбер уңышлы гына детальләр очрый. Шунда ук уңышсыз һәм инде башка авторлар тарафыннан күп кабатланган юллар тезелеп китә.

«Татарстан яшьләре»нең

пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире — Ж.Кәлимуллин.

8 апрель, 1968 ел.

***

«Яшь ленинчы» газетасы

...Шигырьләрегезне газетада файдалана алмадык бит. Аларда яңа автор тавышы юк.

Әдәби хезмәткәр: Рөстәм Мингалимов.

2 июнь, 1969 ел.

***

...Шигырьләрегезне башка авторлар — «Татарстан яшьләре» газетасының әсәрләре белән берлектә, язучы Әнәс Камалга консультация өчен биргән идек. Аның фикерләрен газетабызның алдагы саннарының берсендә укырсыз.

Әдәби хезмәткәр — Ш.Маннапов.

12 февраль, 1969 ел.

***

Хөрмәтле иптәш...

...«Йөгерек сулар акканда» дип исемләнгән кульъязмагызны Сез сонет жанрына керткәнсез. Ә үзегез сонетның нәрсә икәнен белмисез. Бу форма белән ныклап танышасыгыз килсә, Вильям Шекспирның мәрхүм Шәрәф Мөдәррис тәржемәсендә чыккан «сонетлар» китабын һәм алдагы кереш сүзне укыгыз...

Сәлам белән, ТАССР Язучылар союзының әдәби консультанты Илдар Юзеев.

29 июль, 1970 ел.

***

«Казан утлары» журналы

Хөрмәтле иптәш...

...Сезгә менә шушы киңәшне бирергә булдык: әйдә, булмастай эш белән азапланганчы, үзегезнең төп эшегезне — коелар казуыгызны яхшырак итеп башкарырга тырышыгыз Сез...

Ихтирам белән, әдәби хезмәткәр — В.Нуруллин.

27 май, 1971 ел.

***

«Социалистик Татарстан» газетасы

...Ике шигырегезне алдым. Сезгә сөенеч хәбәр итә алмыйм...

Культура бүлеге мөдире — Р.Гарипов.

5 август, 1971 ел.

***

«Татарстан яшьләре» газетасы

Хөрмәтле...

Мөмкинлек булу белән файдаланырга тырышырбыз. Безнең белән элемтәгә керсәң икән.

Пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире — С.Хәйретдинов.

***

Мин, хөрмәтле иптәш...

Бүтән шигырь язмыйм. Бетте-китте! Кулдан килмәс эш белән редакция хезмәткәрләренең башын катырмыйм. Агач тулпарга атланып үткән балачак белән араны өздем. Бу хатларны, шигырь-поэмаларымны җан көеге итеп үзем белән йөртмим. Мин аларны, агач капсулага тутырып, Сәвия белән корыласы яңа гаиләмнең нигезенә күмәм... Юк, крематорийга ягам!

— Әби, менә бу язу-сызуларны мичкә ягарсың, яме! Өенне бер көн җылытырга җитәр.

— И-и, улым, кыш чыгарлык утын китерттең ләбаса, шөкрана!.. Өең салынып бетмичә, йомычка якма, гомерең бетмичә, язу чыгарып атма, дигән борынгылар.

Калдыр кәгазьләреңне. Жыеп куярлык кына урын табармын. Тәүбәләп китүең түгелдер, туган-үскән ягыңа бер кайтып килми калмассың әле...

Атнаның икенче эш көне. Сәвия, аэропортка тизгә генә килеп китте. Яследә үз урынына калдырырга кеше тапмаган. Озатып калмавы хәерлерәктер бәлки, бөтенләйгә аерылышкан кебек авыр булыр җә... Күңелемнең тулган чагы...

Саубуллашканда, кеше күп дип тормадым, пәлтә якасыннан ташып чыккан өрфия шарфына төртелдем. Муенын үбәм. Мин белеп бетермәгән ислемаеннан җиләге жыелмаган кайнар болын исе килә.

— Берүк суырып үбә күрмә, муенда эзе калыр, родительләр каршында яланөс йөрисем бар.

— Сәвиям, миннән телеграмма алуга, шул көнне үк очып килгән бул, яме. Гомеремдә дә Магаданга хәтле чыгып китәрмен дип уйламаган идем. Синең хакка гына. Ышанам, яме?!

— Ярар, дидем ич инде! — Юатып түгел, ачуланыбрак әйтте ул моны.

Куенымнан чыгарасым килми. Шулкадәр кысып кочакладым үзен — хәтта күзләремнән яшь атылып чыкты...

Сәвия дә инде бу минутта үзенең егерме өч еллык тынычлыгын җуйган, дулкынланудан күкрәге бәргәләнә — ике йөрәк булып тибенә кебек...

— Өлгергәнсең инде син, Сәвия!

— Кесәдәге фотомны бөгәрлисең, — диде ул, мине читкә этәргә азапланып. — Кытай границасына китмисең ич, бәхилләшмә шул хәтлек.

Ул миңа ателье конвертына салынган фотосын бирде, ә мин хат тоттырдым.

— Эшеңә кайткач кына ачып укырсың, төне буе утырып яздым, — дидем.

Күз алдымда ук ачып караса, юлга дип хат арасына кыстырган акчамны алмыйча, кире бирәчәген беләм...

«Колхида» рамына кендекләп тагылган ишексез-тәрәзәсез арбага төяп, әллә ит комбинатына чаклы алып киттеләр? Аэровокзал янындагы «ИЛ-14», «АН-24» кебек ике моторлылары уенчык самолёт кебек кенә күренеп калды.

Ниһаять, кичтән яуган яңа кар өстенә коелдык. Сиксәннән артык пассажир санадым.

Аһ, ул самолётның илаһилыгы!

Декабрь кояшының бөтен яктысын үзенә җыеп, шомарган көмештәй ялтырый! Канатлары киң, гәүдәсе — «Нух» көймәсе чаклыдыр, билләһи! Шушы дүрт мотор нечекләр итеп күтәрә торгандыр моны? Үзйөрешле авыр баскычка менеп баскач, Космонавтлар урамында автобус көтәргә тиешле якташларым ягына карадым: күрегез — салам түбәле алачыкта үскән ятимегез, Политбюро кешеләрен йөртә торган иң мактаулы «ИЛ-18» самолётына кереп бара!!!

«Совет мәйданы» өстендә борылыш ясап, Самосырово төтеннәрен аста калдырып, күтәрелә башладык. Самолёт күләгәсе авылыбыз өстендә уйнаклап алды. Сәвияләр урамын аерымачык күреп өлгердем, шунда сөйгән кызымның күкрәк кесәмдәге фотосы искә төште. Авыл кызлары Казанга килү белән, иң беренче эш итеп, фотога төшәләр. Ленин урамындагы ул салонның талдан үрелгән көяз урындыгы меңәрләгән гаилә альбомына кергәндер инде... Самолётыбыз һава чокырларында атынган чакларда, күңелем болгана башласа, Сәвиянең урындыклы сурәтенә карап юанырмын.

***

Сәвиягә охшаган стюардесса бөтнекле конфет өләшеп чыкты. Утыргыч каешларын эләктерергә кушты. Баш очындагы радионың: «Температура за бортом самолёта минус сорок два градуса...» дигәнен бик күпләр ишетмәмешкә сабышты. «Ишеттегезме» дигәнрәкләре, ясалма елмаю чыгарып, як-

ягындагыларга ым какты... Менә шулай, Сәвия... Раштуа каласын сайлаганбыз икән...

Иллюминатордан күренгән утлардан чамаласаң — Магадан бездәге Әлмәт хәтлек бар бугай...

Багаж бушатуны тиз тоттылар, туңып та өлгермәдек. Самолёттагы эсселек ялыктырган иде инде. Колыма суыгын мин аэропорт дип аталган пыяла павильонга кергәч кенә тоеп алдым.

Бораулау осталары әзерли торган мәктәптә укыганда, Магадан егете Юра Дзебук бар иде. Һәр уку йортына хас күркәм гадәт буларак, таныклык алган көнне, күмәк фотога төшеп, адресларыбызны алышып, альбом ясаткан идек. Кирәге чыгар әле, дип кем уйлаган! Куен дәфтәремә адресын күчереп яздым, ләкин телеграмма сукмадым. Бәлки каршы алган да булыр иде... Тик минем аны борчып, мәшәкатьләп торасым килмәде. Эшкә урнашып, Сәвияне алып килгәч, Юра белән күрешүне сюрприз итебрәк күз алдымда тота идем. РСФСРның төрле почмакларыннан җыелган ишләр өчен Ростов каласы үги ата кебегрәк иде. Төннәрен бик чыгып йөрмәдек, буш вакытыбыз күбрәк тулай торакта үтте. Һәркайсыбыз күргән-белгән маҗараларын сөйли, үзе яшәгән төбәкне мактый. Магадан турында Юра Дзебук сөйләгәннәрнең бөтенесе дә онытылып бетмәгән әле, хәл-хәл булып искә төшә.

Юраның миңа гына түгел, гомумән татарларга карата хөрмәтен тоя идем. Серен соңрак аңладым. Моннан 100 ел элек үк Магаданда беренче алтын кисәгеен Шәфигуллин дигән кеше тапкан икән. Җан иясе аяк басмаган җирдә, ничекләр итеп исән-сау калып, бер ялгызы алтын юа алган соң ул?.. Монысы татарлык могҗизасы инде... Аның ачышыннан соң унбиш ел үткәч, Колыма алтынына юл салыр өчен, Алпамшадай 12 мең тоткын җибәрелә һәм беренче кышны ук бөтенесе кырылып бетә...

Магаданда җәй дүрт ай чамасы гына икән. Озын берлек артыннан килгән агайлар, җир өсте эрү белән, алтын приискаларына таралышып бетә. Бульдозерлар озын-озын канаулар казып ком чыгара, ә тырыш «старательләр» аны юдыра-юдыра бөртекләп алтын җыя. Эше пычрак, ялыктыргыч һәм дә хәвефле. Шуңа күрә дә аена бер «Урал» мотоциклы алырлык хезмәт хакы түлиләр икән. Ә инде килгән кеше бер-ике ел эшли алса, аннан бөтенләй китә алмый, ди...

Җәй буе «сухой закон» — бер грамм да эчәргә ярамый. Әгәр аракы исен сизсәләр, минутында эшеңнән куалар һәм синең урынга шундук каяндыр шулай куылган икенче берәүне китереп куялар, ди. Ә Магаданда эш табуы ком арасыннан «самородок» эзләүгә тиң икән.

Беренче салкыннар башлануга, сулар ката, ачык ысул белән алтын чыгару тагын җәйгә чаклы тукталып тора... Җәй буе алтынлы мохитнең кырыс кануннарына түзеп яшәгән тырыш халык дүрт айлык хезмәт хакын туздырырга керешә. Һәм шултиклем тырышып туздыралар ки — күбесенең материктагы туганнары янына кайтып егылырлык акчасы да калмый. Икенче сезонга чаклы, тәмам сукбайлыкка чыгып, Колыма кышында ничекләр итеп исән-имин калалардыр, монысын инде язмыш камчысын үз җилкәсендә татыган бичлар[5] үзләре генә белә. Магаданның бер кунакханәсе бар икән, акчасызларны хәтта коридорына да кертмиләр. Урын мәсьәләсе дә акчадан гына тормый, җылы яктан очып килгән җимешчеләр караваТ өчен бер еллыкны алдан ук түләп куялар, ди. Тагын шәһәрдә бер автовокзал бар — анысы кичке дүрттә йозакка бикләнә, көндез кереп җылынып алсаң гына. Кыш көне диңгез порты эшләми. Шулай

[5] Бич — сәрхушлеккә чыккан сукбайларны Магадан халкы шулай дип йөртә.

итеп бер аэропорт кала. Бичлар кереп тулгач, шултиклем тыгызлана ки, залда пассажирларга урын бөтенләй калмый. Шуны гына көтеп торгандай, тәртип сакчылары килеп керә. Сукбайларны, милициянең бөркәүле машиналарына дыңгычлап төяп, шәһәрдән кырык-илле чакрымдагы сүнгән янартау итәгенә илтеп бушаталар. Алар аннан җәяүләп кайтып житкәнче, аэропортта ике-өч көнлек бушлык хөкем сөреп ала...

Мин Казан самолётыннан төшәрәк, бичларны яңа гына төяп киткән булганнар. Дерматин белән тышланган сәкеләрдә сайланырлык урын бар. Бер кырыйга килеп утырдым да чемоданымны ике тез арасына кыстырып, урланмаслык иттем. Пәлтәмнең чабуын төзәткәләгән булып, чәнти бармак белән генә капшап, майка чабуына тегелгән акчалы бөтине капшап алдым — шөкер, барлыгы белән җанымны җылытып тора. Юра Дзебук әйткән Магадан миңа балалар мәйданчыгындагы уенчык шәһәр кебек кенә күз алдыма килә иде, ә яшәү өчен көрәш мажаралары сабыйларга йокы алдыннан сөйләнә торган әкият сыман гына иде... Менә: бүген исә мин кырыс чынбарлык белән бергә-бер калдым; Сәвиягә вәгъдә иткән хыялый дөнья белән күзгә-күз карашып торам; чемоданымны кочаклап йоклаганда да күземне йоммаска тырышам, йомсам, бичлар арасында калырмын да алтын таулар арасында адашып үләрмен төсле...

Иртәнге унга чаклы бүтән самолёт киләсе юк икән. Көтеп утыру залында тынлык оеп бара. Төн уртасы дигән вакыт бушлыгы пассажирларның көрлеген сүндергән дә өнсез гавамны үзе теләгәнчә сыный, фаш итә, чырайларын боза, гәүдәләрен көлке рәвешләргә кертеп үрти дә хәтта... Синематографиянең башлангыч чорындагы тавышсыз-тынсыз һәм дә ки шыксыз бер кино бара гүя. Вокзал йокысы...

...Түшәмдәге утлар көлтәсе, сәке аркавычына башын салып, аягын сузган агайның күзен әчеттерә. Ул бит юган ише күзен ышкый да йөнтәс бүреге белән каплый. Бүрек идәнгә шуып төшкәч, йолкыш төлке баласына әверелеп ала. Агай аны тагын эзләп таба, тагын күзенә каплый.

...Нечкә сыйраклы, капкорсак, кысык күзле, ялан башлы әби, йон итеген салмыйча гына, аягын туктаусыз кашый. Төенчекләре тышыннан билгеле — зур шәһәргә ризык алып кайтырга дип килгән.

...Үзен үзе кочаклап, мех бияләйле кулын култык астына тыккан кыз-ханым бер күзен генә йомган. Бия картасына охшаган сумкасын беләгенә элгән. Ясалма күн белән тышланган пәлтәсе күптән инде төсен югалтканга охшый. Каршы алучымы, китеп баручымы? Әнә ул, мех бияләй эченнән кулын чыгарып, муенына уралган кәҗә шарфы астыннан нидер эзләргә кереште. Тапты. Бакты. Идәнгә атты. Табан очы белән ышкып сытты... Бераздан тагын тапты. Минем йокым качты. Ул арада каеш иренле пыяла ишек киерелеп ачылды, яшел погонлы дүрт солдат килеп керде. Ни рюкзаклары, ни чемоданнары юк. Күренеп тора — төннең бу вакытында самоволкада йөри болар... Өч кешелек сәкегә бишесе дә сыйды. Кыз-ханым торып та китмәде, исе дә китмәде. Сул ягына туры килгән солдат колагына нидер пышылдаганда, аның инде икенче күзе дә ачылган иде. Кыз-ханымның урам әйләнеп кайтканын калган өч солдат сабыр гына көтеп утырды. Артык җылынып тормастан, икенче солдат белән дә һава сулап керде... Өченчесе белән дә... Ә инде дүртенчесе белән чыгып киткәндә, беренче солдат чалбар кесәсенә кулын тыгып кашына башлаган иде. Йокым качты: «Бу фетнә без сыенган сәкегә дә утыргалагандыр әле...» — дигән уйдан минем дә акча тегелгән майка чабуымда кырмыска тыпырчынгандай булды.

Йокы качты, дип ашыгыбрак әйтеп ташладым. Сәвия белән икебезнең арада хәзер сигез сәгатьлек вакыт аермасы. Ярый әле самолётта йокы симерттем, көнем белән төнем буталып бетте. Татарстан яшәешенә көйләнгән сәгатемнең

телләрен Магадан поясына күчерергә ашыкмыйм, көн яктысына ияреп яшәп карыйм. Юкса Сәвиянең кайчан уянганын, эшкә киткәнен, кайткач, миннән телеграмма көткәнен күз алдыма китерүе кыенрак булыр.

Аэропорттан Магаданга бер сәгать чамасы кайттык.

Ниһаять, дингез аръягыннан якты көн туып килә. Озын-озак, ярты офыкны биләп, таң атканны күрергә теләсәң — менә кая кил икән! Мондагы кояшның йөзенә туры карап була. Ул сагышлы, сүрән, шәһәрне читсенеп ерактан ук әйләнеп уза. Ерак Көнчыгыш кояшы беркемнеке дә түгел.

Шәһәрдә берәү генә булгач, «Гостиница»га исем кушып тормаганнар. Мин аны бик тиз эзләп таптым. Урамда иртәнге сабыр хәрәкәт. Кешеләр бер-берсен уятудан курыккандай тавышсыз-тынсыз гына эшкә ашыга. Мин кунакханәне сорагач та, тел әрәм итеп тормыйча, бармак төртеп кенә күрсәттеләр. Ишеге биксез иде үзенең. Кизү торучысы кая олаккандыр — вестибюльдә үле тынлык, җан әсәре юк, таракан агулаганнар дияр идең — дару исе сизелми.

Шактый гына тамак кыргалауның ярдәме тиде. Җинсез сырма кигән абзый пәйда булды. Халык сүзгә бик саран икән монда. Сүзгә саран кеше елмаюга да саран буладыр... Паспортымны сузып, авыз ачып өлгермәдем, җинсез абзый өстәл өстендәге аншлагка ымлады. Анда эре хәрефләр белән: «Мест нет и не будет» диеп язылган иде.

...Юра Дзебук мине күрүгә үк фамилиям белән дәште. Ростовта укыганда, журналларда безнең фамилияләрне генә тутырып язалар иде. Педагогларның инициалларыбызны төпченеп, такта янына исемнәребез белән чакырганнарын хәтерләмим. Хәтта «Бораулау остасы» дигән таныклыкка да исемнәребезнең баш хәрефе генә куелган иде. Сине эш урыныңнан акча түләп ел буена укытып яткыралар икән, димәк, иң мөһиме Ленин бабай кушканча: көнгә унышар сәгать укырга, кемнең ничә яшьтә булуына карамастан, бергәләшеп укырга һәм дус-тату укырга!

Юра эш эзләп килүемне аңлап өлгермәде әле. Ул шушы көннәрдә генә башлы-күзле булган — теләгәненә өйләнгән, һаман да зөфаф киче агониясендә йөри. Мине языльшулары хакында дусларыннан ишетеп, сонарып килгән кунак рәвешендә каршылады. Мәҗлескә дип хәстәрләнгән нигъмәт тагын бер туйга җитәрлек калган иде әле. Туктаусыз сыйладылар. Юра минем хәмер белән дуслык юкны Ростовтан ук белә иде инде, анысына артык кыстамады.

Магаданның беренче көне кунак уены белән үтеп бара: ашыйбыз да никах альбомы карыйбыз; чәй эчәбез дә кәләшнең кино артистлары кебек сәнгатьчә төшкән фотосына сокланабыз, ул үзе инде табын артында килен хезмәте үтәп маташа, Юра күрмәгәндә генә күз салам, рәсеме белән чагыштырам, анын туй көлмәген күнелемнән генә Сәвиягә кидереп карыйм, шуннан кәефем күтәрелеп куя. Юра гаиләдә бердәнбер бала. Әти-әнисе пенсия яшендә, зал ягына бик чыгып йөрмиләр, сәгатен белеп кенә тамак ялгап алалар да ял бүлмәсенә бикләнеп телевизор карыйлар. Алар хакында мин Юрага ике генә сорау биреп өлгердем.

«Алтын эзләп килмәгәннәрдер ич инде?» — дигән соравыма, Юра, Көнбатыш ягынарак туры китереп, кул гына селтәде, сугышта Европа илләренең ничек яшәгәнен күреп кайткан офицерларның язмышын беләсең ич инде, янәсе.

«Минем татар кешесе булуымны онамиләрме әллә?» — дигәч, Юра пырхылдап көлеп җибәрде. «Магадан краенда ярты миллион кеше яши, һәркайсы үзе бер милләт!» — ди ул.

Юра — шат күңелле егет. Чамасын белеп елмая, кирәгенчә шаярта, тәмен белеп кенә көлә... Ә менә әти-әнисенең йөзендә кырыслык оеп калган, әйтерсең лә аларга елмаю гомергә тыелгандыр кебек.

Ике көн... өч көн кунак булдым. Инде туйдан калган ризыклар үтми

башлады. Дүртенче көн дигәндә, иртүк торып киендем дә бусага төбенә килеп бастым. Юра, мина хәзер «эшләргә, эшләргә һәм эшләргә!» кирәк, — дидем.

— Эзләргә, эзләргә һәм тагын бер кат эзләргә кирәк! — дип өстәде дустым.

— Мин аны шаярта дип торам...

«Биржа труда»га бардык. Чиратка язылдым. Безнең Казандамы?! «Эшкә чакырабыз... Тиз арада фатир бирәбез... Килегез, күп түлибез... Һөнәрегез булмаса, үзебез укытабыз... Ашыгыч төстә белгечләр кирәк...» кебек белдерүләр белән баганалар төрелгән, газлы су сата торган автоматлар бизәлгән, ишекләр түшәлгән, газеталар күмелгән. Кәефеңне кырсалар: «Эштән китәм!» — дип гариза язып кертүең була — тотыналар ялынырга, үгетлиләр, акчаңны арттыралар, вәгъдәләнгәнен ашыктыралар.

Ә Магаданда... Теләсә нинди генә эшкә риза булып килгән чират, биржа залыннан урамга чыгып, кар бабайлар — кар кызларга әверелгән. Ярты көн буе торып, ирләрнең икесенә вакансия табылды: берсе — Педагогия институтына сантехник кирәк ди, икенчесе — Нагаево портында каравылчы агай әллә өшеп, әллә эчеп үлгән шунда...

Сигезенче көнне чират торырга хурландым. Максатыма ике куллап ябышыр чак житте. Мине хәзер Юра озатып йөри алмый, аның үз эше бар — транспорт цехында механик икән. Зур шәһәр түгел — адашмадым. Биржаның игъланнар тактасында «Главдальводстрой» трестын күреп алдым, Пролетарская урамы, 13нче йорт диелгән. Кәеф кенә юк, бер уйласаң, көлке хәл инде бу — Сәвия дә Пролетар кызы, әтисенә армиядән ягылып кайткан кушамат бу! Унышка юрыйк, минәйтәм... «Отдел по использованию трудовых ресурсов» дигән бүлегенә кердем. Инспектор абзагыз, миннән күзен алмыйча жентекләп сораштырды. Тәҗрибәле психологтыр — документларымны карап тормыйча гына имтихан алды. Иренмичә, бүлдермичә әңгәмә корды да нәтиҗә ясады:

«Безгә мастерлар кирәк, ләкин һөнәр профилегез туры килеп бетми. Ростовта сезне су белән юдырып бораулау ысулына укытканнар. Ә бездә мәңгелек туң, июль чилләсе дә 15 градустан ары жылытмый... Артезиан су чыгарыр өчен, боз катламын һава белән өрдереп бораuларга кирәк. Сез безнең технологияне белмисез... Бораулау оешмасы бер без генә түгел, әнә геология идарәсенә барып карагыз..».

Документларымны ике куллап тоттым да өлкәнең геология идарәсен эзләп киттем. «Эш белешеп йөрим, дигәч, Сәвиям кебек бер чибәр секретарь урынбасар бүлмәсенә юл күрсәтте.

Шунысы сәер: урынбасар мина күтәрелеп карамады да, хәреф хатасы эзләгән корректор кебек, документларыма кадалды... Һәм канцеляриянең «кырык тартма»сыннан лотерея билеты чаклы гына кәгазь алып яза ук башлады.

— Мә, — диде ул отышны мина сузып. — Сусуман автобусына өлгерәсең әле. Карамкен тукталышында төш. Моннан кырык чакрымда булыр.

Рәхмәтне ике-өч тапкыр әйттем бугай... Урамга чыккач, отыш билетын укыйм:

> Начальнику Карамкенской экспедиции
> т. Асееву Н.А.
> Направляю вам на переговоры,
> на предмет трудоустройства пом. бурильщика
> или затем на курсы бурильщиков.
> Судя по документам —
> хороший работник.
> Зам. нач. Упр. (Имза) Колчинов
> 30/XI-73.

Карамкен Магаданнан 40 чакрымда урнашкан эшчеләр бистәсе булып чыкты. Автобустан төшеп калганда кояш күренә иде әле. Күренә дип шуна әйтүем,

тирә-якта таң атуны яисә кичке шәфәкъне балкытырлык ачык офык юк, өйләр һәм бараклар гел сопкалар итәгенә чәчелгән. Чит-ят манзарага аптырап карап торам, урман юк, елга эзе юк, урамда кеше заты күренми. Этләр дә өрми. Мәгәр яшәеш билгеләре сизелә: барак тирәсендәге чүп арбасына буш шешә, апельсин кабыгы һәм консерва савытлары өелгән. Киртә-коймалар, ишегаллары булмагач, бөтен тормыш аерымачык күз алдында.

Бер баракны өчкә бүлеп, административ үзәк иткәннәр: почтасы, кибете бар, экспедиция начальнигының эш бүлмәсе дә шунда. Сәвиягә телеграмма сугарга дип кул кычытып тора, көчкә түзеп йөрим.

Геология идарәсеннән алып килгән кош теле хәтлек кенә кәгазь үз көчен күрсәтте, иптәш Асеев артык сораулар биреп төпченмәде, хезмәт кенәгәмне сейфка салып, шундук эш турында сөйләшүгә күчте.

— Жир астына төшеп бораулаганың бармы? — ди экспедиция начальнигы.

— Моңарчы туры килмәде, — дим, каушамаска тырышып.

— Сопкалар төбенә шахталар казылган, ташкүмер чыгаргандагы кебек, шуннан як-якка бораулап керәсең. Һәр метр саен тау токымын алып тикшерәсең.

— Керн[6].

— Әйе, кернга ияреп алтын самородогы чыгамы, көмешме — анысы инде бәхет эше. Шуннан, син бораулаган эздән шахтёрлар казып керә, бөтен катламны жир өстенә чыгара.

— Һәм без, яңа урынга күчеп, тагын алтын минералы тапканчы бораулыйбыз.

— Татариядә алтын эзләдегез мәллә, бик белеп сөйләшәсең.

— Юк, Николай Арсеньевич, ни дисәгез дә Ростовта бораулау мәктәбендә укыдым бит. Шунда ук практикасын да үттек.

— Алайса, «ЗИФ-650»[7] агрегатын беләсең инде.

— Эшләп караганым бар.

— Вәт, монысы шәп булган. Атна-ун көн стажировка үтәрсең. Иртәгә үк вахтага. Автобус иртәнге 7дә шушы контор янында кўтә.

Асеевның шат күңел белән сөйләшүе миңа да күчте, тәмам ачылып киттем.

— Николай Арсеньевич, мин бит сөйгән кызымны, ну хатынымны инде, монда алып килергә телим, кайда яшәрбез икән, ә?

— Яшәр урын табарбыз. Бу якларда хатын-кыз өчен эш урыны — кытлык...

— Иртәге өчен ишәк кайгырсын, ди татар. Тизрәк килсен генә. Мин әйбәт эшләсәм... икебезгә дә житәр.

— Әйбәт эшләгән кеше әйбәт яши бездә.

— Алайса мин бүген үк телеграмма сугам.

— Тизрәк сук. Юкса монда ирләре ташлап качкан хатыннар бик күп, буйдак икәненне белсәләр, кесәнә кереп утырырлар, сизми дә калырсың...

Иптәш Асеев үзе юраган мажарадан рәхәтләнеп көлеп калды. Ә мин, почта бүлегенә кереп, Сәвиягә хәбәр жибәрдем: «Срочно приезжай! Мой адрес: Карамкенская экспедиция».

Казан аэропортында вәгъдәләшкәнчә, билет алгач, Сәвия дә миңа хәбәр бирергә тиеш.

Магаданнан срочная телеграмма ике сәгатьтә барып житәчәк, диделәр.

[6] Керн — бораулап алынган жир асты токымының бер өлеше.
[7] «ЗИФ-650» — горизонталь юсул белән бораулау станогы.

Күнелдән генә ике билгесезле математик мәсьәлә чишеп алдым. Кайчан ала, кайчан килеп житә? Хәзер Магаданда кичке дүртләр тирәсе. Димәк, алтыда, Казан вакыты белән төнге икедә... Юк, Сәвия йоклый әле, почтальон минем телеграмманы иртәнге сигезләрдә тапшырачак. Шул көнне үк билет алып, атнаның икенче уку көнендә килеп житәчәк...

Иртәнге 7дә, вахта автобусына утырыр алдыннан, тагын бер телеграмма суктым, монысын инде көндез тапшырачаклар. Шөкер, Карамкенда почта тәүлек буе эшли, геологларның бөтен элемтә үзәге шушы почтада, диделәр.

Жир астында, дөресрәге сопка эчендә сәгатьләр шултиклем әкрен йөри... Көне-көне берәр гомер чаклы!

Алтын күргән юк әле...

Сәвиядән дә хәбәр юк...

Мондагы жир катламнарының катылыгы искитмәле — алмаз тешле бур түгәрәкләп кимергән чакта сүнгән янартау дер калтырап тора һәм ул, түзәр-түзәр дә, ачудан кинәт уянып, вулканы бәреп чыгар төсле.

Ниһаять! Чираттагы кернны алып карагач, мастер, имән бармагын тырпайтып: «Есть!» — дип куйды. Сменада алты кеше идек, барыбыз да табылдыкка ябырылдык. Егетләр — «Магадан сандыгыннан» хәзинә эзләүдә күптән инде азау тешен алтынга алыштырган кешеләр, чынлап торып уйласаң, алар хәзер төсле металл табуга көндәлек эш итеп кенә карарга тиешләр кебек. Юк шул, сокланалар, моңарчы бер дә алтын күрмәгәндәй кыланалар, шушы вулкан төкереген кулдан кулга сикертеп суытырга телиләр, күз буучыга әверелгәндәй, кесәдән кесәгә күчереп качырышлы уйныйлар... Алтынгаияләнеп, күнегеп, битараф калып булмый ,күрәсең... Ә мин... Әби үлгәннән соң, әнигә калган колак алкасыннан гайрене белмәгән, талир тәңкәләрне бары тик мультфильмнарда гына күргән, хәтта никах балдагына да лаек булмаган авыл малае, Сәвия көзгесе чаклы алтынны күргәч нишләргә тиеш идем?!.

Егетләр уйнап туйгач кына минем хәлне аңлап алдылар.

Чын алтын табигый хәлендә бөртек-бөртек йә балык тәңкәсенә охшаш формада очрый икән. Ә монысы — консервы капкачы кебек түгәрәкләп киселгән калай сыман иде. Уч төбемә шапылдатып салдылар. Менә нинди икәнсең син «самородок»! Тәме юк, тешкә — йомшак, тырнак белән сызсаң да, эзе кала, кургаш кебек жиңел бөгелә... Көмеш кушып койгач кына тауарга әйләнә — катылана икән.

Мастерның сабырлыгы бетте, кирәк-яраклар шкафыннан сувенирга охшаш үлчәү алып килде. Чынаяктай тәлинкәсе, вак-вак ялтыравык герләре — нәкъ химия кабинетындагы көянтәле үлчәү кебек. Без аны дәрестә лаборатор эшләр вакытында куллана торган идек.

Мастер үлчәде дә шундук рациядән кемнәр беләндер озаклап сөйләшеп алды. Соңгы сүзен, без ишетерлек итеп, кычкырып һәм мактанырак әйтте:

— Егерме өч грамм! Әле моның симез тамыры жир куенында калды.

Табылдык смена ахырында охранага тапшырыла икән, мастер аны платформа читенә беркетелгән сейфка бикләп куйды. Ачкычын кесәсенә салгач, двигательне сүндерде дә:

— Демонтаж! — диде.

Димәк, башка урынга күчәбез. Ә без тапкан алтынның калган өлешен алыр өчен, проходчиклар килеп, шахта казып керәчәк.

Магадан өлкәсенең чик сызыгы бар барлыкка. Ләкин ул чиксез... Магадан жир астында, аның янар таулар күмгән хәзинәсе бихисап, диләр. Тик мин

монда байлык эзләп килмәдем. Минем чын алтыным — Сәвия! Йомшак телле, карашы ягымлы; кирәк чакта кырыс та, ягымлы да була белә; әти-әнисенә хәзинә, ә миңа — байлык... Бүген егерме өч граммлы табылдыкны кулымда тотуым да яхшы фал — Сәвиягә дә егерме өч яшь! Менә күрерсез, бүген аннан һичшиксез телеграмма киләчәк...

Җир астында эшләгәндә, әллә нинди хорафатларга да ышанырсың. Сәвияне искә төшерүем булды — мастерның бил каешына кыстырылган рация сискәндереп сызгыра куйды.

— Телеграмма? Кому... кому? Что передавать? — дигән чакта мастерның рациясен кулыннан тартып алыр чиккә җиткән идем.

Ник миңа гына сөйләшергә ирек бирми инде? Хәзер бит хәбәрнең миңа иң кирәкле сүзен йә ялгыш ишетәчәк, йә төшереп калдырачак.

— Почтада сиңа телеграмма бар, — диде ул, исе китмичә генә.

— И? Нәрсә дип әйттеләр? Нәрсә дип?!!

Соравым катырак янгырады бугай, мастерның чырае сытылды.

— Гафу ит, килә алмыйм, дигән.

— Ничек инде?! Точномы, миңамы?

— Сиңа, сиңа! Безнең сменада бүтән татарин юк!

— Ялгыш ишеткәнсездер... Тагын кабатлап сорагыз, зинһар өчен, дип әйтәм...

Ташкүмер шахтасы түгел — арканга эленгән лампаларны сөрем капламаган, мастер минем өзгәләнүне чыраемнан күреп алды булса кирәк, почта белән кабат элемтәгә керде. Ләкин аңа карап җавап үзгәрмәде...

Әллә минем өчен якты җир өстендә тормыш бетте... Сүнгән тау эчендәге шахталарга ләхет салкынлыгы үтеп керде. Бәхеткә өметләнгән йөрәгем күкрәк читлегемә йодрыклап суга башлады, кан әйләнешем кирегә борылды.

Сәвиянең юлына аркылы төштеләрме? Янаулар, мыскыллаулар белән түбәнсетеп мәхәббәтеннән яздырдыларамы? Без бит инде монда явызлык куып житә алмаслык ераклыкта идек. Кем өчен чыга соң бу алтын-көмеш? Сәвия янымда булмагач, тимер-томырның нигә кирәге бар? Ник бу кешелек алтыннан туймый? Мин монда кала алмыйм... Соңгы чиккә чаклы туздырмыйча, җаным теләгән чакта туган авылыма кайтып җитәрлек булсын дип саклаган юллык акчам исән.

Җир читенә барып, икебез өчен буш оя кордым. Хезмәт кенәгәмдә 1973 елның декабрендә килеп китте, дип Магадан мөһере суктылар. Материкка кайткач, Карамкен приискасы турында 40 ел буе беркемгә дә сөйләмәскә, дигән серле кәгазьгә кул куйдырдылар...

«Ник килмәдең, Сәвия?!.»

Минем бу дөньяга бүтән бер соравым да юк...

Очты-очты, самолётлар очты...

*Ахыры киләсе санда*



Рәниф
Шәрипов

# ҮЗ БӘЯСЕН АЛСЫН ВАКЫЙГА

## Аерылышу

*Акыл сатмыйм бу дөньяда туганнарга.*
*Акча белән бергә юкка чыга туганнар да.*
*Әйе, шундый якын булып тоелганнар,*
*Үз булып, якты булып җан-бәгырьгә уелганнар...*
Л.Шәех

Кара уйлар белән уйнар чакмы?
Дәшми генә, мыштым, астыртын
Йөргәннәрне Ходай үз алдына
Җавап сорап беркөн бастырсын.

Кара уйлар уйлап,
Кеше белән уйнап,
Керсез җанга тамга салганның,
Бер ягына куйсын догаларын,
Бер ягына куйсын ялганын.

Догалары кабул булыр микән
Кара уйлар белән укылган?
Ихлас түгел, хәлсез догаларны
Кара уйлар тарта упкынга.

Кара упкын — кара тәкәбберлек.
Ихласы юк дога — файдасыз.
Хөкем итә безне тик бер Ходай!
Без хөкемгә әзер...
Кайда сез?

Без тәүбәгә килдек инде күреп
Бу дөньяда кемнең кемлеген.
Бер-беребезнең ялганнарын күрә
Бер-беребездән күбрәк кем бүген?

Бер ягында кылган догаларын,
Бер ягында кылган ялганың.
Дәшми генә таралышыйк шулай,
Ходай үзе белер калганын...

Рәниф Шәрипов (1950) — *шагыйрь; «Ян, учагым», «Мәңгелек сер», «Азатлык көне» һ.б. китаплар авторы. «Татнефть» һәм Язучылар берлегенең С.Сөләйманова исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

## Җиңү байрагы

Җиңү байрагының юл башында
Брест кирмәненең канлы-яшьле таңы.
Ким-хур түгел, киң, зур булып анда
Татар каны акты, татар каны.

Газинурдай күп гомерләр аша
Үтте Җиңү байрагының юлы.
Александр атлы Матросов та
Шакиржан бит, газиз татар улы.

Батырларча яу кырында түкте
Күп гомерен, соңгы көчен татар.
Моабитта аккан татар каны
Җиңү байрагының төсендә бар.

Рейхстагка байрак алып менде,
Тик югалды аның дан-исеме.
Бәйрәм бүген! Ләкин нидер җитми...
Җиңү көне бүген! Җиңү көне...

Җиңү көне бүген! Җиңү көне...
Хакыйкатьне еллар юганнармы?
Бәйрәм бүген, ләкин нидер җитми,
Искә алыйк газиз туганнарны...

## Татар түрәсе

Урыска да, яһүдкә дә
Вакытын тигез бүлә —
Кайда бәйрәм, шул тирәдә
Бусага таптый түрә.

Яһүдләрдә «ханука»мы,
Урыс музей ачамы,
Ничек инде түрә калсын
Шунда чыгыш ясамый?

Тамашалар булып торсын,
Булсын «Ханука»... Музей...
Никтер бер генә сорауга
Булмый берничек түзеп —

Болгар номерында Тукай
Икенче тапкыр үлә!..
Шул йорт җимерелгән чакта,
Кайда идең син, түрә?

## Бер фаҗига

*Мәрхүмнәр үз-үзләрен,*
*якыннарын яклый алмыйлар.*

Кабер өсте алтын мөнбәр түгел,
Чүп-чар, өчсыз, шикле сүз өчен.
Танылачы килгән тапсын икән
Үзе эшли белгән үз эшен.

Чит кайгы да җайлы сәбәп түгел,
Тотынырга тизрәк каләмгә.
Сүз уйнатып, күз яшьләре сыгу —
Барысы да бушка, әрәмгә.

Хакыйкатьне Алла гына белә,
Ә дөреслек ята кабердә.
Бу фаҗига артык якын әле,
Дәшми торыйк әле хәзергә.

Чит кешенең зур кайгысын күреп,
Дәшми үтсән, кайчак яхшырак.
Җир астында, сүз әйталмый елап,
Карый безгә бирәү аптырап...

## Такташ

Шулай, якташ,
Күп ул вак таш.
Күрәсеңме,
Олы, ак таш?
Бусы — Такташ.

Кемгәдер җан,
Кемгә гәүдә.
Мәхәббәт юк,
Бар тик сәүдә.
Бусы — «тәүбә».

Кояшта да,
Ак ташта да
Бераз тап бар.
Шигъри җанны
Хыял саклар.
Бусы — «хатлар».

Дөнья — кара,
Шагыйрь — бала.
Мәхәббәт тә,
Киләчәк тә
Узып бара...
Такташ кала!

## Әлфия Авзалова

Җан сулышы кирәк, сулар өчен,
Еракгагы җырлар һавасын.
Җырны башлап була,
Тының җитсә әгәр
Кабатларга чорлар авазын.

Аңа язмыш кирәк,
Бераз сагыш кирәк,
Күңеленә уеп моң салган.
Чор сулышы бүген
Җыр сулышы түгел,
Күр, сәхнәдә тагын кем калган?

Көчәнмәгез юкка, гамьсез җаннар,
Изге җырда ялган булмасын!
Чорны аңлап була,
Җырны алдап булмый,
Җыр ул үзе сайлый юлдашын.

Әнә, килә алар еллар ерып —
Тынчу булса да чор һавасы —
Моңлы күңел язы,
Ерак җыр авазы,
Җылы янгыр булып явасы...

# Мөхәррир

*Кукмара районы «Хезмәт даны» газетасының баш мөхәррире Рәсим Ризванов истәлегенә.*

Ул куркусыз шәп мөхәррир иде,
Ачык йөзле, ачык күңелле.
Жыры, моны тулы бәллүр гомер
Кинәт ауды, кинәт түгелде...
Дөнья кызу. Кайнап чыга Кеше
Йә чайкалып, чәчрәп атыла.
Ул югалта кайчак йөзен, үзен!
Ләкин дәшми... Тик кем хакына?..
Ул дәшмәде озак... Дәшми китте...
Хәтта беркем, берни сизмәде.
Күрми калды беркем жанындагы
Бу дәшмәүнең яра эзләрен.
Казан куркып кире борган сүзне
Ул бастыра иде яратып.
Ул яратты эшен. Туган Илен —
Иркле ил диеп санады...
Таш бәгырьле түгел беребез дә.
Бер карыйсың — барысы да чит!
Бер аңлыйсың — син бик яратасың,
Ә ул сиңа үги икән бит!
Чагалар да чагалар бит һаман...
Бу дөньяга ничек сыясы?
Соңгы сүзе аның шул булгандыр:
«Эх, дөньясы — елан оясы!..»
Нәрсә безгә бер кешелек гомер!
Нәрсә безгә бәла-казалар!
Чит үгиләр хәзер баш еланга
Рәхмәт юллап хатлар язалар...
Уйламагыз, дөньясы шул диеп,
Онытылыр диеп, барыбер...
Дөнья андый түгел! Онытылмас!
Хәтер булып кайтып бәрелер!
Ә сәбәбен аңлашучы бармы?
Кеше китте! Чүпме вакыйга?
Оятсызлар рульгә ябышканнар,
Оят кучә бара бакыйга.
Ә онытсак, чүп булырбыз жирдә,
Бәя булыр безгә бер тиен...
Үзебез дә шуңа дучар булып,
Туфрак калыр бездән бер өем.
Сикәлтәле юлда берни күрми,
Кәперәйгән денсез түрәләр,
Чайкалдырып илне уңга-сулга,
Гомерләрне гүргә түгәләр.
Тәкәбберләр дөньясына сыймый,
Бер дустыбыз күчте бакыйга.
Чын сәбәбен белеп калсын дөнья!
Үз бәясен алсын Вакыйга!
Ул куркусыз, шәп мөхәррир иде,
Ачык йөзле, ачык күңелле!
Кинәт түгел! Кинәт түгел һич тә,
Ул чайкалып ауды, түгелде...

## Җиләк

Тау итәгендә авылым,
Тау бите тулы җиләк.
Җиләк җыясы килгәндәй,
Талпынып ала йөрәк.
Бала чагым мизгелләрен
Җыяр идем тезләнеп.
Адым саен анда минем
Ялан тәпи эзләрем.
Камыт кебек, богау кебек,
Аягымда гер минем.
Җыя алмам, тик янында
Утырып торыр идем.
Җиләге дә тансык түгел —
Базарда күпме кирәк.
Вакыты аның бәясез,
Мизгеле аның җиләк.

Җиләкле җәйләр уза да,
Җитә җимешле көзләр.
Таптала чит аяклардан
Ялан тәпиле эзләр...

## Кыя

Сынды тотка. Ауды терәк.
Дүрт кыйбламы дүрт ягым?
Арлы-бирле, бәрелеп-сугылып,
Зиһенем чуалган чагым.
Батам-калкам... Як-ягымда
Шаулы, болганчык агым.
Шул агымда сүз әйталмый,
Исемем югалган чагым.
Җисемем — кыя. Зиһенем җыям.
Калды соңгы бер адым —
Шул кыяга исемем уеп,
Җисемем уалган чагым...

Рәдиф
Сәгъди

# МИН ДӘ БЕР ТАТАРЫҢДЫР...

ДОКУМЕНТАЛЬ БӘЯН

## Татар һәм ат

Нишлисез сез, кешеләр! Нигә бүгенге көн белән генә яшисез икән!!! Алда бит әле балаларыгызның да, оныкларыгызның да Ходай бүләк иткән гомере бар. Сындырасыз, ватасыз, җимерәсез. Иң зур гөнаһ саналган җинаятькә барасыз – үтерәсез! Нинди Алла каргаган ил соң бу? Җиңел генә хәл ителәсе эшләр төрле каршылыклар, диварлар аша эшләнә. Кемнәрдер шулай җиңел генә тормышка ашырыласы гамәлләрне эчпошыргыч шөгыльгә әйләндерә. Барысына да нәрсәдер төртергә, ришвәт бирергә туры килә. Кайсы гына тармакны алма, бер кешенең табышына ике-өч паразит ябыша. Ничек бу ил алга китсен дә, киләчәк якты булсын! Дәүләт бит үзе үк бәндәләрен караклыкка, угрылыкка этәрә. Эшләп-эшләп, тир түгеп тә тиешлесен алалмаган адәм тора-бара барысына да кул селти. Ә бу селтәнү киләчәктә күтәрелеп чыгачак афәткә бер ым гына. Андый селтәнүләр көннән-көн ешая. Ил үзенең алдынгы тырыш затларын югалта гына бара. Ул урынга соңыннан бөтенләй үзгә затлар килеп тула. Менә алардан син яхшылык көтмә инде. Юкка гына адәм балалары, бигрәк тә авыл халкы Совет властен сагына башламады. Чөнки ул чорда хезмәт алдынгыларының урыны түрдә иде. Орден-медален дә, ял йортларына юлламаларын да бирә килделәр. Төрле бүләкләр турында сөйләп тә торасы юк. Мотоцикл, суыткыч, хәтта зур дефицит саналган җиңел машиналарга хәтле тырыш, уңган хезмәткәрләргә табыла иде. Кыр батырларына багышлап меңләгән пьесалар, роман-повестьлар, җыр-шигырьләр иҗат ителде. Чын мәгънәсендә мәдхия җырланды ил алдынгыларына.

Үзгәртеп кору башлангач, түрәләр башлап җибәргән комсызлык, талау, тора-бара җинаятьчел элементлар кулына да күчеп, кан коюлы бизнеска әйләнде. Күпме асыл егетләр, җиң сызганып эшлисе, гаилә корып гөрләтеп яшисе урында талап-үтереп тиз генә яхшы тормыш кормакчы булдылар. Нәтиҗәдә йөзләрчә, меңнәрчә корбаннар... Шушы талау нәтиҗәсендә илнең индустриясе, авыл хуҗалыгы юкка чыгарылды. Ярый әле иксез-чиксез җиребездә нефть-газ ятмалары хәттин ашкан. Ни генә булмасын, яшәргә кирәк. Шөкер, таянырга тырыш халкым бар. Аны алдарга гына ярамый, тотынса, таулар күчерә ул. Ләкин инде хәрәмләштенме, гаиләсен ала да бәхет эзләп сәфәр чыгып китә ул! Чит җирләрдә дә югалмый үзе, андый фидакарьләр кайда да кирәк. Тик милләт буларак нигезен җимерә ул. Бер-ике буын алмашынганда, татар халкы руска әйләнә дә куя. Чөнки бер кеше сине тикшерми, «татарва, чаплашка,

---

*Ахыры. Башы узган санда.*

басурманин» дип мыскыл итми. Шулай итеп, рус халкы гасырлар буена иң беренче чиратта татар халкы исәбенә тулылана, ишәя килде.

Бу чорда татар авылларына чын мәгънәсендә афәт килде. Колхозлар бетерелде, хуҗалыклар таланды. Кайчандыр меңләгән баш эре терлеге булган авыллар хәерчелеккә төшерелде. Хезмәт хакы түләнми башланды. Шул сәбәпле, яшьләр шәһәр җиренә агылды. Бер дистә ел эчендә күзгә күренеп картайдылар салалар. Эшләргә кеше калмагач, әлеге дә баягы Мәскәү авылда хезмәт кылучы халыкка терлек асрарга мөмкинлек бирде. Менә сиңа парадокс. Эшче куллар ташып торганда ярамый иде, авылда карт-коры гына калгач хет ун, йөз сыер асра, мең баш сарык тот, каршы торучы юк. Ничәмә-ничә еллар шәхси хуҗалыгында ат тоту «запрещён» иде, бүген хет унны асра, хәлеңнән килсә. Ә бит атсыз татар татарга саналмаган. Атсыз яшәү, әлбәттә, халкымның милли рухына каты сукты. Ат белән бергә безнең халык Европа илләренең азатлыгын, бәйсезлеген генә саклап калмаган, тыныч тормышта иген игеп, үзеннән артканын якын күршеләренә дә биргән. Мал асрарга мөмкинлек бирелгәч, татар халкы иң беренче чиратта бахбайлы булды. Сабан туйларында чапкыннар бик күпкә ишәйде. Колхоз, авыл, район житәкчеләре төрле җирләргә барып нәселле атлар юнәтә башладылар. Бу мәсьәләдә бигрәк тә Татарстан әйдәман иде. Аңа карап башкалар да кузгалды. Шул исәптән, ул елларда колхоз рәисе булып эшли башлаган Әлфиттә дә борынгыдан килгән атларга мәхәббәт инстинкты яңадан уянды. Ул «ничек тә булса яхшы чапкын алып кайтырга» дигән ошбу нияте белән янып, хыялланып йөри башлады...

## Орнамент

Кече яшеннән үк яратты атларны Әлфит. Әтисе өйгә берәр сәгать ял итеп алырга дип кайтса, Лачынга атланып рәхәтләнеп чаба иде. Үзен ул ат өстендә хәрби җайдак итеп тоя. Битеннән кайнар җәй һавасы сыйпап кала. Рәхәт аңа Лачыны белән дөнья гизүләре. Ләкин бик озак сәфәр кылып йөрергә вакыт юк. Әтисе ял итеп алган арада, байталга да тамак ялгап, көч тупларга кирәк. Әлфит үсте, ишек алдында атлар да алышынып торды. Очкын да, Йолдыз да, Бөркет тә, Чичин дә – барысы да күңелгә уелып калды. Бигрәк тә — Йолдыз. Аягын сындырган иде ул. Рәткә кермәячәген аңлаган авыл абзыйлары иткә чалдылар аны. Әле, жанкисәккәем, аякларын бәйләп, тартып еккач та, каерылып зур, яшь тулы күзләре белән Әлфиткә карап, гасабиланып кешнәп җибәргән иде. «Мин бит сезгә тугры хезмәт иттем, ә сез минем башыма житәсезме», дип әйтүе булгандыр. Нишлисең, тормыш шундый: кайчагында без яраткан, безгә игелек кылган хайваннарга карата рәхимсез. Үзенең яраткан атына карата эшләнгән явызлыкны күрмәс өчен Әлфит елый-елый өенә йөгереп кереп китте. Әнисе шунда Хөрмәтулласын: «Баланың йөрәген бозып күз алдында чалмасагыз, беткәндер урын», — дип сүгеп алган иде. Йолдыз аның күңеленә мәңгегә авыр хатирә булып уелып калды.

Әлфит мәктәпне тәмамлады. Совет армиясе сафларына китәргә ярты елы калып бара иде. «Әткәй, мине ат дурына эшкә куй әле», — дип сорады. «Мин куйсам, сүзе күп була аның, улым. Шуңа күрә андый эшләргә мине беркайчан да кыстырма. Бар, әнә ферма мөдире Гайфулла абзаң янына бар, шуннан үзең: «Армиягә киткәнче генә ат алачыгында берәр эш табылмасмы икән», диген. Шулай итеп булачак никрут егет көз айларына хәтле ат көтүе көтте. Болында ул, татлы хыялларга чумып, йолдызларны, серле, могҗизалы күк йөзен күзәтергә ярата иде. «Их, Фәния белән космик корабльгә утырып, бергә башка планеталарга барып житәсе, алар тормышы белән дә танышасы

иде. Андагы атларны, сыерларны, башка жан ияләрен дә күрәсе иде», дип хыялланды. Кайчан булса да андый заманнар да җитәр. Әйтик, ике сәгатьтән син Марста. Марсианнар йөгереп килеп чәчәккә күмәләр. Фәния белән кушылуына шатланалар. Иртәгә, Алла боерса, клубтан соң сөйгәне белән дә очрашасы бар шул анын, чөнки ял көне, атларны җәйләүгә Шәһидулла абзасы алып чыгачак. Ә ул төне буе Фәниясе белән йолдызларга сокланып йөриячәк. Иң мөһиме: янгыры гына яумасын. Шунысы кызыклы, әле әнисе Фәниягә күз салып йөргәнен белмәгән чакта ук, улына: «Әлфит, әгәр дә өйләнергә уйласаң, улым, әллә каян читтән әллә кемнәрне эзләп баш ватма. Әнә Габдерәхим абыйларыннын бик акыллы, бик чибәр, бик унган Фәнияләре бар, шуны үзенә карата алсаң, унарсын», — дигән иде. Кәбирә ханымнын улына үзенең иң яраткан укучысын тәкъдим итүе Әлфитнең йөрәгенә сары май булып ятты. Үзе исә, шаяртып кына: «Мина карамас ул, әнкәй, буем да зур түгел», — дигән булды. «Карар, әдәпле генә йөрсәң, буйга үсмәсән дә, бәхеткә үсәрсен, улым, шуны бел», — дип ана кеше сүзен бетерде.

Ул заманнардан бирле шактый сулар акты. Менә бүген ул Ижауда институтта укып йөри. Ипподромда практика үтә. Остазы төз гәүдәле, зәңгәр күзле Беловны беренче күрүдә үк үз итте ул. Зыялы, тәрбияле икәнлеге күзгә ташланып тора. Сары чәчен артка сыпырып куя да, Әлфиткә үзенен кул астындагы чапкыннар турында сөйли. Нәрсә ашатканнарын, ничек йөгертергә чыгарганнарын аңлата. Инде менә Василий Николаевич белән бер атнага якын аралаша, ник бу рус кешесеннән бер сүгенү сүзе ишетелсен. Ник үзенә карата да, кул астындагы малкайларга карата да кечкенә генә тупаслык күрсен. Кайтып китәренә бер көн кала Әлфит остазы Беловтан: «Мин, Василий Николаевич, үземнең колхозга да сездәге кебек берәр затлы чапкын эзлим, ничек юнәтергә икән?» — дип сорады.

— Әлфит, үзеңә сер итеп кенә әйтәм. Безнең хуҗа салган баштан ат белән бер бабайны таптатып имгәтте. Милициягә әйтмәсән, бер ат бирәм, дигән. Хастаханәдән чыгуга килде бабай атны сорап. Татар буларак, кайсы атның нинди икәнен әйбәт чамалый. Иң яхшы чапкыныбызны сайлады да алды. Теге гаепле җитәкчебез ялынып та карый, башкасын сайлагыз дип, кая ул! «Орнамент»ыбызны алып китте. Кычкырып-кычкырып еладым аны югалту сагышыннан. Бабай бит аны сугымга, казылык ясарга алып китте. Гәүдәгә зур иде шул, жанкисәгем. Разве шундый затлы атны иткә чалалар? — Белов зәңгәр күзләреннән атылып чыккан яшь тамчыларын кесәсеннән кульяулык чыгарып сөртеп куйды. — Әлфит сынок, мин сиңа бабайның адресын да бирәм, Башкортстанның Янавыл районында яши ул. Син бит татар, татар татарны аңлар, алыштырып кайт син аны, ике ат биреп булса да коткар «Орнамент»ыбызны!

Әлфит шул ук кичне поездга утырып бабайны эзләргә чыгып китте. Башында бер генә уй: «Соңга гына калмаган булсам ярый инде!». Тапты ул хуҗанын йортын. Таза, бай ихата. Ишегалларына да таш җәелгән, каралты-курасы да алпавытларныкыча. Шулчак абзарда чапкын кешнәп җибәрмәсенме... Исән, димәк, чалырга өлгермәгәннәр, болай итеп нәселле, затлы атлар гына кешни ала. «Әй, өйдәләрме сез? Өйдә кеше бармы?» — дип кычкырды ул. Күлмәк өстеннән сарык тиресеннән тегелгән жилән бөркәнгән, чалбарын йон оекларынын эченә кертеп кигән, башына затлы түбәтәй элгән, коңгырт күзле, ап-ак сакаллы бер бабай килеп чыкты. Әлфит сәлам бирде:

— Әссәламәгаләйкүм, абзый!

— Вәгаләйкүмәссәлам, энекәш!

— Мин, абый, Мари иленнән, колхоз рәисе. Сездә чапкын ат барлыгын ишеттем дә кызыксынып килдем. Үзегез беләсез, акча юк заман, алыштырып булмасмы? Мин Сезгә бартер тәкъдим итәм.

— Нәрсә инде ул бартер?

— Әйтик, мин сезгә бер ат, шуңа өстәп бер «КамАЗ» солы бирәм.

Бабай бераз уйланып торды да әйтте:

— Давай, энекәш, болай эшлибез, син миңа бу чапкын урынына ике ат бирәсен, үзең күрерсен, шуңа тора ул. Килештекме? — картлач кулын сузды.

Әлфит бер мәлгә аптырап калды. Аңа колхозын бер ат бәрабәренә ике атсыз калдыру да кызганыч иде. Ә менә солыга килгәндә, быел нык уңды. Хет ике машина төяп китсен.

— Вагыйз абый, әйдәгез инде, бер ат та ике «КамАЗ» солы төяп җибәрәм. Татар татарны аңларга тиеш бит инде! Абзый ишек кырыенда торган култаягын алды да шуның белән башта бер галошын, аннан икенчесен тартып китереп башта бер аягына, аннан авырлык белән икенчесенә киде. Ул уң аякка чатанлый иде. Алар абзарга керделәр. Йа Хода, могҗизадыр бу? Озын муенлы, әкиятләрдә генә була торган сылу гәүдәле кашканы күреп сихерләнде, телсез калды Әлфит. Ат та ике ирне күреп тыпырчына башлады. Тирә-юньне яңгыратып кешнәде дә арт аякларына басты. Әйтерсең лә, «Әлфит, менә кара минем матурлыкны, алып кит биредән, мин мондый коллыкны күтәрә алмыйм», дия иде. Хуҗа кеше: «Йә, күрдеңме, мондый малкайга ике колхоз атың җәлме», — дип куйды. Әлфиткә бүтән юл калмаган иде. Бу чапкын аныкы гына булырга тиеш, бары тик аныкы гына. Мондый гүзәллекне югалтырга ярамый. Әнә бит кара ялларын селкетеп, койрыгын болгап каядыр ашкына. Ут яктысында затлылыгын белдереп, ялтырап тора. «Яхшы, Минвагыйз абый, берсекөнгә минем машина сезне килеп алыр. Орнаментны минем «КамАЗ» белән кайтарасыз, сөйләштекме? — дип кулын сузды. Бабай да теләр-теләмәс кенә үзенекен бирде һәм «Башта синекеләрне дә күрик әле», — дип әйтеп куйды.

Әлфит килер микән, юк микән дип төне буе борчылып чыкты. Төрле төшләр күреп саташты. Имеш, Орнаментка атланган да, очалар гына. Аларны нур сибеп балкыган ай да, бихисап йолдызлар да озатып кала. Алар чабалар да чабалар. Ул да түгел дингезнең текә яры, аста коточкыч дулкыннар. Ул чапкынны йөгәнен бар көченә үзенә тартып туктатмакчы, тыймакчы була. Хәле генә житми, Орнамент, киресенчә, тизлеген арттыра барган килеш чабып килеп упкынга томырыла. Әлфит саташып: «Беттек», — дип акырып кара тиргә батып уянды. Вакыт иртәнге бишенче яртыны күрсәтә иде, димәк, тиздән таң атачак! Фәния кая соң әле, ә ул сыер саварга чыгып киткән, күрәмсең, юынырга, киенергә дә, терлекләргә печән салып керергә кирәк. Аннан тамак ялгап алгач, конторга менәрмен. Бабай килгәнче иң таза, иң эшчән атларны конюшнядан икенче җиргә күчереп торырбыз. Югыйсә алачак та китәчәк менә дигәннәрен. Ә атлар ферма тирәсендә алыштыргысыз. Әле бит монда хуҗалык эшләрен алып барырга да тазалары, ныклары кирәк!

Көндезге 12ләр тирәсе булгандыр, Арча тимер юл станциясеннән бабайны утырткан «УАЗ»игы кайтып керде. Әлфит машинасын тәрәзәдән үк күреп, аннан төшкән Вагыйз бабасын да шәйләгәч, каршы алырга чыгып китте.

— Юллар бик ялыктырмадымы, Вагыйз абый? — дип егет ике кулын сузып күреште.

— Ай-яй бу Әтнә белән ике арагыз бигрәк тә әшәке икән, немецлар бомбит иткәннәр диярсең.

— Юк инде, юк, Вагыйз абый, Рәсәйдә рәтле юл, шуңа күрә Казанга да әйләнгечтән, Йошкар-Ола аша йөрибез. Кайчан булса да турыдан гына рәтле-башлы асфальт салынырмы, белмим. Ярар, немецлар бәреп керсә, яхшы ул. Шул юлларда үзләре үк батып үләчәкләр. Без ияләшкән инде, как-нибудь. Вагыйз абый, әйдә әле берәр чынаяк чәй эчеп килик, төш вакыты да җитте бит, — егет абзыйны өенә чакырды.

Кунак бабай бик үткен, дөнья күргән кеше булып чыкты. Сталин чорында аның гаиләсе дә Себергә кулак итеп сөрелгән икән. Ул чактагы биш яшьлек малайга әти-әнисе, сеңел-энеләре белән репрессия җилләренең ачысын да, төчесен дә хәттин ашып татырга туры килгән. Рәнҗетелгәннәр арасына кертелгән булса да, Вагыйзнең әтисе Миңлегали абзый биредә дә югалып калмый. Оста куллы икәнлеген белеп алган түрәләр, колония җитәкчеләре мунча салырга да, шкаф ясатырга да үзен гел алып китеп торалар. Эше табылган — ашы да табыла, дигәндәй интегеп яшәргә туры килми алар гаиләсенә. Җирле Красноуха халкы да үз итә Казаннан сөрелгән басурманнарны. Ишегең ватылса — ишек, баскычың сынса баскыч ясап, мунча мичең искерсә, мич чыгарып бир дә, ничек инде үз итмисең ди. Әле Сталин үлеп амнистия булгач та, ярты авыл озата килә үзләрен. Күбесе: «Китмәгез инде, Миша, йорт салырга да булышабыз, сыер да табып бирербез», — дип ялына. «Спасибо Вам, дорогие, бик зур рәхмәт, ләкин мин туган җиремнән башка яши алмыйм шул», — дип, саубуллаша ул. Әле бик күп еллар үткәч тә, Вагыйзнең читтә яшәп калган якташлары кунакка кайткач сөйләүләренә караганда, әтисе Миңлегалине һаман Красноухода сагынып искә алалар икән. Ул төзегән мунча-каралтылар, ул өйгән ызбалар аны искә төшереп, авылга ямь биреп торалар. Кире туган җирләренә кайткач та тик ятмый: каралты-куралар, мунча-өйләр сала. Үзеннән малайларны да калдырмый, кул астына кертә. Дөньялар бераз рәтләнеп киткәч, умартачылык-бакчачылык белән шөгыльләнә башлый. Үз авылында да аны хөрмәт итәләр. Ни кызганыч, атлар яраткан әтисе ат асрый алмый кала, чөнки рөхсәт юк. 90 яшен тутырырга ике-өч ай тулмый, ул якты дөньядан китеп бара. Ә менә улы Вагыйзгә атлы заманнарны күрергә дә насыйп була. Хәзер ул ел саен атлар сатып алып симертә дә йә итка сата, йә казылык ясый. Ошбу кәсебе аны Әлфит җитәкләгән колхозга китереп җиткерә дә.

Төшке аштан соң алар дворга төште.

Бөтен конюшныйны җентекләп карап чыккан Вагыйз карт әйтеп куйды: «Рәтле-башлы аргамаклар, юртаклар юк икән сездә. Бигрәк вак бит, Әлфит энем, мал-туарың». Ул атларны тагын бер карап чыкты. Ошаганын тапмады түбәтәйле кунак бабай.

— Гаеп итмә, энем, мин китим инде. Шофёрың кире поездга илтеп куйсын.

— Вагыйз абый, ике атым синең Орнаментыңа тора бит инде. Ничек кызганмыйча шундый аргамакны казылыкка чалырга була инде?

— Энем, болар — авыр йөк ташып, беткән-картайган. Начар казылык чыгачак. Ә менә минем өйдәгесеннән затлы ризык җитештереләчәк. Ярый, юлчының юлда булуы хәерле, дигән халык — абзый кесәсеннән кульъяулык чыгарып маңгаена бәреп чыккан тир тамчыларын сөртте дә урам якка юнәлде. Аңа мал карауочы Гатаулла, рәиснең шофёры Камил белән Әлфит үзе дә иярде.

— Вагыйз абый, үтенеп сорыйм, әйдә килешик инде. Харап итмик шундый яхшы нәселле атны. Татар татарны аңларга тиеш бит инде, — дип ялынды Әлфит.

— Менә син дә татар булгач, шуны аңла инде, энем. Син рәтле-башлы малларыңны яшергәнсең дә, мина вак-төяген төртеп маташасың. Җүләр дип белдеңме әллә Вагыйз абыеңны.

— Юк, Вагыйз абый, яшермәдем, өч-дүрте чыннан да эштә. Фермага фураж ташыйлар, калганнары биредә». Вагыйз абзый «сау бул» дигән кебек уң кулын селтәде дә, ферма кырыенда торган машинага таба чатанлый-титаклый китеп барды. Камил аптырап хуҗасына карады. Әлфитнең борыны салынган иде. Аның күз карашында үпкәләү катыш рәнҗү чаткылары да сизелә иде.

— Ярый. Бар илтеп куй Арчага, алдыннан арты яхшы, — диде ул шофёрга һәм правлениегә төшеп китте. Кабинетына кергәч, сейфын ачып, коньяк тартып чыгарды. Аның бөкесен ачу белән борып ачты да эчемлекне шешәсеннән генә авызына койды. Чыраен сыткан килеш тимер шкафыннан, кәгазь араларыннан шоколад тартып чыгарды. Аның ике шакмагын сындырып алып, чәйнәргә тотынды, үзе шунда: «Бигрәк тә мәнсез карт икән, тәгәрәп үлгере», — дип, үзен үпкәләтеп китеп барган кунак бабайны сүкте. Шулчак урам якта бер машина килеп туктаганы ишетелде. Тәрәзәдән караса, Вагыйз абзыйны илтә киткән «УАЗ»игы иде. Машинаның ишеге ачылды, таягын тоткан карт чыга башлады. Шофёры аны култыклап алды, чыгарга булышты. Җиргә ныклап баскач, Вагыйз абзый әле дә аны тотып торучы шофёрдан кулын тартып алды да, таягына таяна-таяна идарәгә таба юнәлде. Әлфит: «Күр әле син аны, карт булса да, чатан булса да, нинди горур», — дип бабайны тагы бер кат сүгеп алды. Ләкин, үзенең эченә җылы йөгерә башлаган иде инде. «Димәк, бабай, ниндидер фикергә килгән. Әллә өч атыма алыштырмакчы була микән», дип, уйланып куйды ул. «Юк, өчкә мөмкин түгел, сүзе дә күп булачак, йә ике малкайга, йә сау булыгыз» дигәч, ул өстәлдә торган коньяк шешәсен кире сейфка тыгып, ишеген бикләде. Ул да түгел бүлмәгә кунак абзый үзе килеп керде.

— Әллә китеп булмадымы, Вагыйз абзый? — дип төксе генә каршы алды ул кунакны. — Тик сразу әйтеп куям, өч атка алмаштырмыйм «Орнамент»ны.

Кунак авыр сулап куйды да.

— Өч ат сорарга бөтенләй оятсыз дип беләсеңме әллә мине. Әгәр дә зур гәүдәле, шәп атың булса берсе дә җитәр иде дә... Ярый, чёрт с ним! Син дә кызганыч, үземә дә бик унайсыз! Теге ике малкайга өстәп, үзең әйттең бит, солым бик күп дип, шуны бирсәң, ике-өч айда яхшы ашатып рәткә китерермен кебек мин аларны. Шуңа ризамы? — ул үзенең авыр хезмәттән тупасланып, яргаланып беткән кулын сузды. Әлфитнең эченә җылылык йөгерде. «Бу бабай турында начар уйлап, гөнаһ җыйганмын икән, Ходай Тәгаләм, зинһар, берүк кичерә күр», дип уйлады.

— Рәхмәт, Вагыйз абый, миңә монысы ичмасам җегетләрчә, — хуҗа абзыйны кочып алды.

***

Аргамакны карарга бөтен халык җыелды. Озын юл үтеп кайткан чапкын, башын боргалап: «Болар мине ни эшләтергә җыеналар икән», дигән кебек зур кара күзләре белән тирә-юньне күзәтте. Зур, озын керфекләрен астан-өскә, өстән-аска йөртте, күзен челт-челт йомгалады. Чыннан да, «Орнамент» сокланып туймаслык гүзәл ат кызы иде. Авыл халкының күпчелегендә төрек каны үзен сиздерде. Кайберләренең елкылдап торган арт сыртына сикереп менеп атланасы һәм чабып китәсе килә башлады. Гомере буе көтү көтеп лаеклы ялга чыккан, хөрмәткә лаеклы Хәйрулла карт түзмәде: «Әлфит энем, бер шушы затлы атка менеп чабып килим әле. Мондыйларны күрергә туры килмәде шул безнең заманга. Хет үлеп киткәнче бер атланып калыйм», — дип үтенде. Карчыгы Сәрбиҗамал тәтә генә: «Шул гына җитмәгән ди син карт җүләргә, очып төшсәң, сөякләреңне дә җыеп бетереп булмас. Туймадыңмыни гомер буе ат өстендә көтү көтеп. Әлфит энем, бирә күрмә тагын аргамакны! Бәласеннән башаяк. Әнә кайткач капка төбендәге бүрәнәгә атланырсың, аңа да көчкә генә менә ул хәзер!

— Ат дагалаганда бака ботын кыстыра ди. Тукта әле, карт пәри, Әлфит энекәш белән сөйләшкәндә тыгылма әле. Бар, әнә кайтып чәеңне чөмер, ирләр эшенә кысылма, — дип куйды 80гә якынлашып килүче бабай. Аларны тыңлап

торган бала-чага, хатын-кыз хихылдашып куйды. Сәрбиҗамал тәтә уенынчынын бергә кушып, болай диде: «Яшь чагымда бер дә карт пәри дип үртәләми идең. Аягыма кигән галушыма хәтле үбәргә риза идең, имансыз. Хәзер кеше янында мыскыл иткән буласыңмы. Өйгә генә кайт әле, күрсәтермен мин сиңа?» Үткән ел авыл Сабан туенда чабышта беренчелекне алган Илбрус атлы малай да түзмәде: «Әлфит абый, ярыймы үзем атланып чаптырып килсәм», — дип сорады. Ул да түгел, башка малайлар да: «Мин дә чапсам ярыймы, миңа да бирегез инде, Әлфит абый» — дип ялынырга тотындылар. «Тавышланмагыз әле, җәмәгать. Ат озын юлдан кайтты, әкрен генә иялəшсен, аякларын язсын. Хәзер әнә теге буш кардага кертәбез. Син, Хәйрулла абый, аргамакны карарга үзең алынмыйсыңмы соң, колхоздан шуның өчен әллә ни күп булмаса да хезмәт хакы билгеләрбез. Көнгә өч мәртәбә яхшы итеп ашатсаң, шул җитә», — диде председатель. Хәйрулла карт бу тәкъдимнән тураеп, күкрәкләренә хәтле киереп куйды. Читтән карап торсаң, аны яшь тавыклар күргән карт әтәч белән чагыштырып булыр иде. Ул тырт-тырт басып, атны тагын бер кат тикшереп чыкты. Шуннан соң Әлфит каршына килеп: «По рукам» дип кулын сузды. Тик карчыгы Сәрбиҗамал бу юлы да кысылмыйча кала алмады:

— Кая инде сиңа, карт җүләргә, ажгырып торган атны карарга, өйдәге сыерыңны да җиренә җиткереп тәрбияли алмыйсың бит хәзер. Яшьләр беткән ди авылда.

— Сыер – сыер инде ул, синең кебек күшәйт итәргә генә белә. Ә бу — ат! Атларның аты! Монда инде тәҗрибәсе булган ир-ат кирәк! Ягъни, мәсәлән, минем кебек. Понятно!

— Белмим инде, теләсәң нишлә, ат карап тир, тизәк исе сеңгән киемнәреңне үзең юарсың, алайса!

Шунда халык арасыннан сыер савучы Тәслимә: «Борчылма, Хәйрулла бабай, без сиңа кереңне дә юарлык, үзеңне дә тәрбияләрлек яшьрәк хатын табып бирербез», — дип әйтеп куйды. Аның шаяртуын башка чәчбикәләр дә күтәреп алды. «Үземә генә өйлән, Хәйрулла абый! Икәү атын да карарбыз! Чөкердәшеп яшәрбез», — дип кычкырды берсе. Рәхәтләнеп көлештеләр. Сәрбиҗамал әби тагын кабынып китте: «Өйләндерми генә торыгыз әле, өч баласын, алты оныгын, үзен караган хатынын ташлап чыгып китсәме.... Ходай Тәгалә каршына ничек барыр икән ул. Әйдә, Хәйрулла, өйгә кайтабыз. Әйдә, Хәйрулла, дурга төшеп атны карасаң карарсың, кайтып бер рәхәтләнеп чәй эчик әле», — дип әмер бирде. Тегесе исә: «Шаярталар гына бит алар, карчык, барысын да чынга аласың! Яшьләр бит!» — дип әбине җайларга керешә, аннары председательгә борылды.

– Ярый, Әлфит энекәш, эш килешенгәнчә кала, чәйләр эчкәч, правлениегә кереп чыгармын. Нәрсә, ничек ашатасын аңлатырсың. Бу бит гади генә жан иясе түгел, бу — затлы ат!» – карт карчыгына иярде. Әлфит: «Сәгать өчләргә кил, Хәйрулла абый», — дип артыннан кычкырып калды. Аргамакны машина әрҗәсеннән төшерүләре җиңел эшләрдән булып чыкмады. Башта калын идән такталары тезеп кенә бу мәсьәләне хәл итмәкчеләр иде, рәтле такталарның да булмавы, төшәсе юлның текәлеге дә ачыклангач, нишләргә белми баш ваттылар. Мескен Орнамент адәм балаларының озакка киткән фикер алышуларыннан туеп тыпырчынып кешнәп җибәрде. Теге Илбрус атлы малай шунда: «Әлфит абый, әгәр дә «КамАЗ» арты белән буш силос базына барып терәлсә», — димәсенме. Бу турыда Әлфит үзе дә уйлап куйган иде куюын. Тик яшүсмер өлгеррәк булып чыкты. Бу тәкъдимне тәмәке пыскытып торган сала мужиклары да хуплады: «Силос базы кәкераз булачак. Атны җәфалаганчы, шунда китик. Ну, Илбрус энем, укуың әлли-һәлли генә булса да чамалыйсың икән үзең!» — диделәр.

Ижевскида ипподромда эшләвенең файдасы тиде. Әлфит нәселле атларны

ничек тәрбияләргә кирәклеген Белов үткәргән эшлекле дәресләрдә өйрәнеп калган иде инде. Иң мөһиме — чисталык! Аннары витаминлы азык. Һәр көнне ат белән күнегүләр үткәрү. Шикәр һәм шуның кебек баллы әйберләр генә бирергә ярамый, хайваннарга наркотик кебек тәэсир итә ул. Атлар тыңламый, ярсый, гел шикәр таләп итә башлый.

Әлфит иртәнге җыенны үткәрде дә, кардага төшеп китте. Үзенең төп уйлары һаман Орнамент тирәсендә бөтерелде. «Ияләшә микән инде яңа урынына. Хәйрулла абзый яшькә олырагын олырак инде дә, тик атларны аннан да яхшырак белүче юк шул. Ашату-эчертү мәсьәләсендә чамалый ул, үзем дә белгән хәтлесен әйткәләп торырмын. Тик менә көндәлек күнегүләрне кем үткәрер?! 80 яшьлек карт атланып чаптыра алмас бит инде ажгырып торган Орнаментны. Аллаһы Тәгалә үзе сакласын, берәр җирдә бәреп калдырса. Яшьрәк, житезрәк кеше кирәк чаптырыр өчен! Мал караучы Гатаулла да якын килми бу эшкә. Өстәвенә, бик еш кына «урыс чәен» дә куллана. Атлар, җанкисәкләрем, салган кешене өнәмиләр. Бүтән кеше куяр идең ат дворына, каян табасың рәтлерәген. Яшьләр шәһәр тирәсенә китүне хуп күрә. Каян табарга янып торган бер җайдак?» Колхоз рәисе уйланып, баш ватып бара торгач, «дурга» төшеп житкәнен сизми дә калды. Эчке яктан Орнаментның кешнәп җибәргәне ишетелде.

Чапкын янында Хәйрулла бабай үзе генә түгел иде. Ат караучы Гатаулла да, Илбрус атлы теге чая малай да шунда кайнаша. Өлкәннәр нәрсәдер бүлеп бәхәсләшәләр. Әлфитнең колагына Хәйрулла картның: «Бүтән Орнаментка юылмаган кишер бирәсе булма, ат абзарын чистарт та, ашату-эчертү эшләренә кысылма, белдеңме?» дигән сүзләре колагына керде. Тегесе исә аңа каршы: «Нәрсә булсын синең бу атыңа? Әнә башкаларына бәрәңгесен дә, чөгендерен дә юып торган юк. Тыгыналар гына. Беркая да китмәс бусы да», — дип үзсүзлеләнә иде.

— Ни хәлләрегез бар? Нәрсә булды, Хәйрулла абзый? — дип сорады хуҗа кеше.

— Нихәл, Әлфит энекәш? Менә Гатаулланы сүгәм әле, атка пычрак, юылмаган кишер биргән. Үз эшен генә белсен иде дә, юк бит, мин монда конюшный хуҗасы, дип җикеренә.

— Хәйрулла абый дөрес әйтә, Гатаулла! Олы кешене тыңларга кирәк! Атка бит пычрак ашатып, инфекция эләктерүең мөмкин. Икенче юлы алай кыланма, аңладыңмы?

— Аңлашылды инде, аңлашылмаган кая! Моңа хәтле юып тормый идек әле, берсе дә егылып үлмәде, — дип ат караучы Әлфиткә акаеп карады.

Колхоз рәисенең борынына көмешкә исе китереп бәрде.

— Фу, Гатаулла, иртә таңнан тыгынмасаң! Бар, бар, урамга чыгып кит әле, атларга гомумән аракы исе ярамый, — дип сәрхушне үзе яныннан куды.

— Моңа хәтле ярый иде, бүген ярамый, имеш. Менә тотып Казанга китеп барырмын әле, исегезгә төшәр дә, соң булыр!

Гатаулланың салып алса, китеп барырмын әле, дип куркыта торган гадәте бар иде, шулай сөйләнеп олыгаеп бетте. Беркая да китмәде дә, өйләнмәде дә. Күрше Әлфит үгетләп тә карады үзен. Әллә ничә хатын-кызны димләде. Тик Гатаулла гына «тегесе болай, монысы тегеләй», дип, кире кага торды. Хәзер сиксәнгә якынлашып килгән әнисе Галия апа белән тора. «Хет шундый буйдакларның яртысы гына өйләнсә дә, күпме бала туган булыр иде, — дип хыялланды колхоз рәисе. — Юк шул, булмады, Гатаулла да, тагын унлап ир-ат өйләнмичә картаеп баралар. Әнә шул өйләрендә рәт булмаганга да, күрәмсен, бик еш җыелышып эчәләр. Күбесе хәтта колхоз эшенә дә йөрми. Кайберләре елына бер тапкыр Татарстанда «шабашка»да йөреп кайткан була

да... Тик араларында әти-әнисе жилкәсендә ятучылары да житәрлек. Үзгәрде татар авыллары да, начар гадәтләргә өйрәнде. Совет чорында диннең кысылуы да, өлкән абзый кебек типтереп яшәргә кызыгу да ошбу хәлгә китерде бугай. Татар үзенең асылына кайта алыр микән?! Әллә инде рухи кыйммәтләрен, гореф-гадәтләрен, хезмәт сөючәнлеген югалтып, тарих упкынына батып, зур, бөек халык булудан туктармы? Әлегә Аллага шөкер, кырларыбызда мул булып икмәк үсә. Мал-туарларыбыз да житәрлек. Халкыбыз да тырышып хезмәт куя бабаларыбыздан мирас булып калган изге жирләребездә! Әлфит уйларыннан арынып, ат араны янындагыларга борылды.

— Ә син нишләп укуыңда түгел, Илбрус?

— Безнең бит озын тәнәфес, мин тиз генә Орнаментны күреп китмәкче идем, Әлфит абый.

— Бар, бар, энем тиз бул, дәресеңә сонга калма!

— Әлфит абый, ярыйммы укудан соң атны үзем чаптырып килсәм, Хәйрулла бабай барыбер аны йөгертә алмый.

— Нинди чаптырып килү ди, чөеп атса үзеңне?!

Сүзгә Хәйрулла карт та кушылды:

— Бу малайга бирергә була атны, булдыра ул, колхозның иң кире атларын өйрәткән үсмер ул.

— Колхоз аты колхоз аты инде ул, ә бу ыжгырып торган аргамак! Үзем атланып чабарга да шикләнәм әле мин! — Әлфит чиләктән бер кишер алды да, су тутырылган зур лакан янына килеп, аны яхшылап юды. Аннары аран янына якынрак килеп, Орнаментка кишер сузды. Ләкин атның тамагы тук идеме, кишерне ашамады, конюшныйны янгыратып кешнәп жибәрде. Илбрус шунда:

— Ай-яй моның тавышы, көтмәгәндә ишетсәң, астыңа пес итәргә була, — димәсеңме.

— Әй, пес итүче малай, мин сиңа нәрсә дидем, тиз бул, йөгер мәктәбеңә.

— Әлфит абый дим, ә ярыймы дәрестән соң бер атланып чаптырып килсәм?

— Ярый-ярый, бар-бар, соңыннан күз күрер, башта үзем атланып карыйм әле, ни дип әйтер...

Орнамент та сүзнең ни турында барганын аңлаган кебек тагын кинәт кенә кешнәп куйды, чыгарга тыпырчына, сорый башлады. Хәйрулла карт:

— Чыннан да бәгырькәемнең чыгасы, жилдертәсе килә бугай! Нишлибез, Әлфит Хөрмәтуллович? — дип сорады.

— Әйдә, Хәйрулла абый, ни булса да булыр, алып чыгып карыйк инде! — Әлфит атны беренчеләрдән булып үзе сынап карарга булды.

Ат караучы аранны ачып, ат янына керде, малкайның яныннан йөгәнен тотып алды. «Трр, трр, жаным! Тынычлан, без сиңа бернинди дә начарлык эшләмибез, без сине яратабыз, трр-трр, жаным, дип жайлап кына алып чыкты. Алар артыннан Әлфит белән Илбрус та атлады. Каядыр ашкынган атка менеп атланулары жиңелдән булмады. Егәре ташып, каны уйнап торган аргамак сөлек кебек боргаланды. Шулай да Хәйрулла атны жайлый, Әлфит этләнә торгач, атлана алды. Йөгәнен рәтләп тоткач, бабайның жибәрүе булды, Орнамент шуны гына көтеп торгандай ук кебек алга ыргылды. Колхоз рәисе әздән генә очып төшеп калмады. Ярый әле тезгенен ныклап тоткан иде. Жайдак атын кыр ягына юнәлтте. Орнамент әйтерсең лә чабып түгел, очып кына бара иде. Менә алар арыш кыры уртасындагы юлдан үтәләр, ул да түгел үлән кыры. Аргамак тизлеген югалтмыйча чабуын белде. Әлфит, ике чакрымлап ара узгач, атның тизлеген әкренәйтеп кире борды да, инде хәзер авыл ягына элдертте. Колхоз

атларына атланып чапсаң, бөтен арт саның авырта. Ә монда сизмисең дә. Иң мөһиме, өстеннән очып кына төшеп калма. Хәйрулла карт аларның кайтканын капка төбендә көтеп тора иде. Ул хужа килеп җитеп, ат өстеннән төшкәч, еш-еш сулаудан борын тишекләре киерелгән малкайга карап:

— Йә ничек, Әлфит энекәш? — диеп сорады.

— Хәйрулла абый, ат түгел, кош бу, Тулпар бу! Билләһи канатлары бар диярсең. Молодец, матурым, рәхмәт сиңа, — Әлфит Орнаментның башыннан үбеп алды.

— Менә күрерсең, Сабан туенда беренче урын безнеке булачак. Тик яхшы җайдак кирәк.

— Илбрустан да рәтлерәк кандидатны күрмим дә әле мин авылда. Үзе җиңел, үзе үткен, ат өстендә дә кавалеристлар кебек йөри.

— Бала-чага бит әле, аты дулап китеп бәреп калдырса! Имгәнсә малаең, мин җавап бирәм ич аның өчен, Хәйрулла абый.

— Килеп йөрсен, ат — аңа, ул атка ияләшсен, соңыннан кырга чыгып сынап карарга була! Бик үткен малай ул, менә күрерсең, искитмәле җайдак чыгачак үзеннән! Иң мөһиме: атларны бик ярата.

— Шулай дисеңме? Ярый, алайса, бер сынап карарга туры килер үзен! Килеп сиңа булышкалап йөрсен, тик дәрес вакытында түгел! Аздырма малайны, Хәйрулла абый. Укуына хилафлык китермәсен. Сөйләштекме?

— Яхшы, Әлфит энем, чын кеше тәрбияләрбез аннан, — дип, бабай колхоз рәисенә күз кысып алды.

## Кыш чыгу

Орнамент яңа хуҗаларына бик тиз ияләште. Хәйрулла картны да, Әлфитне дә әллә каян сизеп, кешнәп каршы ала башлады. Ләкин теге чая малай Илбрусны аеруча ярата иде. Үсмер килсә, араннан чыгарга тыпырчына, ярсый башлый. Башы белән бүреген бәреп төшерә. Тегесе дә, «хәзер, җаным, хәзер, Орнаментым» дип, тәмле теллеләнеп атны җайлый, бер телем ипи каптыра, битләреннән сыйпый, иреннәреннән үбеп ала. Чапкын да малайга мәхәббәтен белдереп кулбашыннан авырттырмыйча гына тешләп ала. Бу хәлләрне күреп Әлфит тә, Хәйрулла карт та: «Аллага шөкер, атыбыз ышанычлы кулда», — дип сөенә. Чыннан да, үсмер, дәресе бетүгә ат абзарына килеп җитә. Хәйрулла бабасы: «Булды, улым, бар кайт, тамагың да ачкандыр, дәресеңне дә әзерләргә кирәк», — дип өенә куа. Илбрус бабасын тыңлый, белә ул аның яхшылык теләгәнен. Орнамент белән кар бураннары туздырып чабып кайталар да, тагын бер кат малкаен иркәләп сөйгәч, теләр-теләмәс кенә өенә юнәлә. Кайтмас иде, Әлфит абыйсы: «Начар укысаң, ат янына якын да килмисең», — дип кисәтеп куйды. Кая барасың, атларга мәхәббәт көчле булгач, өчкә-дүрткә булса да, укырга тырышасың инде. Физкультура белән хезмәттән «бишле»ләре дә бар әле аның. Ә бит колхоз рәисе бу затлы атны алып кайтканчы, үзен классташ кызлары: «икеле капчыгы» дип тә үртиләр иде. Ниһаять, тындылар чәчбикәләр. Әтисе әйтмешли, чәчләре озын, акыллары кыска аларның. Алай дисәң, Таһирә белән Рәмзия «бишле»гә генә укыйлар. Өстәвенә, алгебра белән геометриядән гел булышалар үзенә. Бу ике кызны хөрмәт итсә, өченче берәве аның күңел түренә бөтенләй башкача кереп урнашты. Калын толымлы, шомырт кара күзле Җәмилә кереп оялады үсмернең күңеленә. Ул бу кызый алдында надан булып күренмәс өчен китаплар укый башлады. Аларның күпчелеге атлар, сугыш турында. Бигрәк тә аңа «Алтын йолдыз» дигән мәхәббәт романы ошады. Гомерендә булмаганны өч кат укып чыкты ул аны. Шул китап аша үзе дә хыял

дингезенә чумды. Имеш, ул да Орнаментка атланып сугышка китә дә, кылычын унга-сулга болгап кыра гына дошман гаскәрен. Күкрәк тулы орден-медальләр белән кайтып төшә ярсу атында. Аны каршы алырга Әлфит абыйсы да, Хәйрулла бабасы да, Таһирә белән Рәмзия һәм башка авылдашлары да авыл башына чыга. Ул халык арасыннан Жәмиләне эзләп таба да, аргамак өстеннән сикереп төшеп, кыз алдына килеп тезләнә һәм кулындагы чәчәк бәйләмен суза. «Жәмилә, мин утлар-сулар кичкәндә дә, йөрәк түрендә син идең. Синең исемең белән исән чыктым афәттән, мин сине үлеп яратам, чык мина кияүгә», — ди. Кыз, чәчәкләрне күкрәгенә кысып: «Рәхмәт сина, Илбрус, мин дә синең исән-сау йөреп кайтуыңны теләп тордым», — ди. Менә алар ике яклап Орнаментның йөгәненнән тоткан килеш авыл ягына атлыйлар. Алар артыннан авыл халкы да иярә. Кайберләре: «Ай-яй» кыю малай да булып үсеп житте инде Илбрусыбыз. Күкрәк тулы орден-медаль. Ат өстендә дә лачындай оча! Бәхетле генә булсыннар инде», — дип имеш аларга изге теләкләр тели. Ләкин әле үсмернең тагын бер зур хыялы бар. Быел ул жиденче сыйныфны тәмамлый. Аннары — Сабан туйлары. Менә ат чабышында Орнамент белән беренче урынны да алсамы, шул чагында инде Жәмиләгә сүз катып караса да булыр иде. Нишләп әле сөйләшеп карамаска ди. Ул чагында бит инде ул сигезенчегә күчкән була. Их, Сабан туенда беренчелекне алып булса икән! Әлфит абыйсы алдында да абруе үсәр иде, Хәйрулла бабасын да шатландырыр иде...

Ләкин дөньялар без хыялланганча гына бармый шул. Кайчагында көтмәгәндә күңелсез хәлләр килеп чыга. Февраль ахырлары иде. Хәйрулла карт салкын тидереп урын өстендә ята, Сәрбижамал тәтәсе мыр-мыр килә-килә, төрле үлән төнәтмәләре, бал белән 80 яшьлек бабайны дәвалап маташа. Хәзер Орнаментны тәрбияләү тулысынча атлар карауччы Гатаулла абзасына калды. Тик затлы чапкынның жене сөйми аны. Аранына кертмәскә тырыша, тибенә, тешләп алырга да күп сорамый. Тегесе, салмыш килеш аты-маты белән сүгенә. Хәйрулла бабасы булса, аны куып жибәрә иде. Хәзер барлык атлар да шул сәрхүш кулына калды. «Тизрәк бабай терелсен иде инде!» дип теләде малай.

Бүген ял көне. Илбрус иптәш малае Шамил белән иртән иртүк ат абзарына китте.

— Быел Сабан туенда аны узарлык чапкын табылмаячак, менә күрерсең, әйтте диярсең, — дип шапырынды Илбрус.

— Әлфит абый сине чаптырамы соң?

— Яхшылап укысаң, Орнаментны да әйбәтләп тәрбияләсәң, чабарсың, диде.

— Их, миңа да бер атланып чабып карыйсы иде шул атында. Илбрус, миңа да бирерсең әле.

— Үпкәләмә, Әлфит абый ат янына беркемне дә якын китермәскә кушты. Үзеннән сора, миннән түгел, дип үтенечне кырт кисте. Өстәвенә, Гатаулла абый көне-төне шунда, үпкәләмә, миннән генә тормый, — дип тә өстәде.

Алар конюшныйга килеп кергәндә, эчтә ыгы-зыгы бара иде. Гатаулла абзасы: «Башың беткере, тәгәрәп үлгере, типтерермен мин сиңа», — дип себеркесе белән Орнаментны кыйнап ята.

— Син нишлисең, алкаш тәре, ник тиясең атка, — малай ярсып кычкырып жибәрде, ул да түгел, атылып барып тегенең себерке сабыннан эләктереп алды, үзенә тарта башлады. Гатаулла бер мәлгә югалып калды, соңыннан каршында борыннары да кипмәгән ике малай торганын шәйләгәч: «Кара син аны, салаганы, яле, жибәр әле себеркене, маңгаеңа берне биргәнче», — дип янады. Кая ул, яшүсмер себерке сабына бөтен көченә ябышкан килеш: «Тагын бер сугып кына кара Орнаментка, сугып кына кара, алкаш. Күрмәгәнеңне күрерсең,

белденме», — дип, ярсыды, малай. Аның тавышына чапкын кешнәп җибәрде, араннан чыгарга тыпырчына башлады. Себеркесен тартып алырга маташкан исерек Гатаулла дулады. «Ах, салага, шулай итим, әле син шулаймы», — дип, бар көченә Илбрусны абзарның пычрак идәненә әйләндереп ыргытты. Малай идәндә яткан килеш: «Кыйна, кыйна, мине кыйна, атка гына тиясе булма, алкаш тәре», — дип елап җибәрде. «Синнән сорап торалар ди, маңка тәре. Бирермен мин сиңа алкашыңны, малакасус! Ат дурында буталып йөргәнче, әнә дәресеңне кара. Дуй әйдә отсюда, икегез дә дуегыз, бүтән эзегез булмасын, шалапайлар», — дип, теге себеркесе белән селтәнде. Малай идәннән торып, чалбарын каккалый-каккалый: «Син үзең дуячаксың моннан, Әлфит абый белсәме, бәреп үтерә, белденме», — дип кычкырды. «Куркытма, курыккан бар инде безнең, әйтмәгән саен, бик ачуымны китерсә, Казанга киттем-бардым, менә карасыннар шунда тизәкле атларын», — дип, сөйләнә-сөйләнә себеркесен уң яктагы аранга атып бәрде дә абзарның түр башына китеп барды. Шамил Илбрус янына килеп дустының бишмәтенә кунган чүпне каккалады. Үзе шунда: «Әлфит абыйга әйтеп иманын алдырырга кирәк!» — дип киңәш бирде. Илбрус исә: «Иманын мин аның үсеп җиткәч үзем алам, менә унны гына бетерим әле. Тик әләкләп йөрмәячәкмен, егетләрчә түгел», — дип, аранга кереп китте һәм яраткан атын муеныннан кочып алып юатты: «Сиңа кул күтәрәме, кабахәт, бер гөнаһсыз җан иясенә. Тынычлан, җаным, тынычлан. Хәйрулла бабайны сагынгансыңдыр инде, менә терелеп кенә җитсен дә... Ул янадан синең янында булыр. Иркәләр, назлар үзеңне, тәмле итеп ашатыр». Ат, барсын да аңлаган кебек, бөтен дурны яңгыратып кешнәп җибәрде.

Малайлар атны күнегүләр ясарга алып чыгып киткәндә, Гатаулла абзалары абзар почмагындагы печән өстенә авып, гырылдап йокы симертә иде.

Ат караучының Орнаментны себерке сабы белән дөмбәсләве колхоз рәисенә барып иреште. Шамил өендә әти-әнисенә әйткән, тегеләре — күрше-күләнгә, шулай итеп, чыбыксыз телефон аша бу вакыйганы бөтен авыл белде.

Әлфит белән Гатаулла арасында сөйләшү кыска булды:

— Нишләтим мин сине хәзер!? Нишләтим! Бер гөнаһсыз хайванны себерке белән кыйнарга ничек кулың күтәрелде. Белмим инде, белмим, нәрсә эшләргә дә синең белән. Ул бит гади ат кына түгел, ул бит нәселле, затлы ат, син аңлыйсыңмы шуны, җир бит. Әйт, сволочь, нишләтим мин сине?

— Кертми аранга, кертми астын чистартырга, Әлфит Хөрмәтуллович. Керсәм, артын борып тибәргә маташа, әле беркөнне беләгемнән тешләп үк алды, — дип акланды, авызыннан махмыр исе аңкып торган агай.

— Бар, ычкын моннан, бүтән якын киләсе булма ат янына! Әниең Галия апа гына кызганыч, ул булмаса, конюшнядан артыңа тибеп куар идем...

## Сынау

Тагын Сабантуй житте. Илбрус белән Орнамент өчен ярты авыл борчылды. Бигрәк тә колхоз җитәкчесе Әлфит кайгырды. Малайны күргән саен: «Борчылма, улым, иң мөһиме: тәвәккәл бул, Орнаментның үзенә ирек бир, кирәк-кирәкмәгәнгә тезгенне тарткалама!» — дип, аркасыннан кагып алды. Өйдәгеләр: «Бәлкем, улым, өлкәнрәкләр чабыр, иртәрәк түгелме соң әле сиңа, очып төшеп ат асларында кала күрмә инде, балакай», — дип кайгырыштылар. Малай: «Миннән башка беркемне дә тыңламаячак ул, тыя алса, Әлфит абый гына тыя, ләкин ул гәүдәгә авыр! Өстәвенә, кыш буена мин шөгыльләндем аның белән», — дип тынычландырды аларны.

Ат карауч Гатаулла салып алгач күкрәк сукты:

— Тапканнар бит шул малакасуска ат ышанып тапшырырга! Азындырып бетерде теге салаганы Хәйрулла карт тәре. Миңа бирергә кирәк иде ул атны Сабан туенда чабарга. Минем тәҗрибәм 30 елдан артык.

Шунда Рафаэль шешәдәше каршы төште:

— Синме!? Сиңа тагын, теге юлы, помнишь, ат өстеннән очып төшеп битең сыдырылды, ай буена май сөртеп йөрдең. Нинди Орнаментта чабу ди сиңа! Сөйләнеп торасың тагын! Айны башта, аннан Әлфит сиңа бирә диме затлы чапкынны, бирсә дә беренче чатта ук бәреп төшереп калдыра ул сине!

— Минеме? Бәреп төшерде ди! Күтәп тор.

— Бәреп төшерә дим, әйтте диярсең! Очкыннан мәтәлгәнне.

— Төшерми генә торсын әле, ике як кабыргасына итекләр белән төртсәмме...

— Әйдә алайса спордан. Әгәр дә Орнамент сине ярты чакрым арада ташлап калдырса — син миңа бер литр куясың, әгәр дә инде ташлап калдырмаса — мин куям! Сөйләштекме? — тегесе кулын сузды.

— Яхшы, Сабантуйлар гына үтсен дә, чабып күрсәтәм әле мин сиңа! Менә күрерсең, ат өстендә ничек йөрергә кирәклеген — Гатаулла ризалыгын биреп тегенең учына үзенекен шапылдатып салды.

***

Сабантуйның ыгы-зыгысы иртә таңнан мал-туарны көтүгә озатуга ук башланды. Каникулында төне буе чабып, көн уртасына хәтле йокларга яраткан Илбрус, ни гаҗәп, бүген сарыклар бәэлдәшкән, сыерлар мөгрәгән тавышка уянды, урыныннан сикереп торды. Тормас иде, бүген аны зур эшләр көтә. Эш кенәме, бәлки әле данга күмелер. Кем белә, ат чабышында Орнамент белән беренчелекне алсалармы, кунакка кайткан туганнарын да, дус-ишләрен дә шаккатырачак. Иң мөһиме, Әлфит абыйсы әйтмешли: «югалып калмаска кирәк!» Аргамакка менеп кыр буйлап чабуы бер хәл ул, ә менә менләгән кеше алдында, дистәләгән чапкын арасында ярышып кара! Ярыш буласын сизеп Орнамент та борчыладыр инде. Тиз генә юынып, капкалап алырга да ат абзарына төшәргә кирәк.

— Әнкәй, мунчада җылы су калмадымы, коенып чыкмакчы идем? — дип әнисенә дәште.

— Бар, улым, бар! Суы да бар, яңадан кунаклар кайтышына ягып та җибәрәсем бар! — Нәсфирә ханым кием шкафын ачып сөлге тартып чыгарды.

Юынып чыккач, Илбрус өстәл янына утырды. Әнисе аны кайнар коймак белән сыйлады. Үзе улы өчен борчыла иде.

— Кайгырма, әнкәй, барысы да шәп булыр. Беренче генә чабуым түгел ич инде. — Ул арада әтисе Гайфулла абзый кайтып керде.

— Нәсфирә, Сабантуйга чалырга дигән сарыгың су сорап бәэлдәп ята, нишләп тынычландырмыйсың аны, — диде ул керә-керешкә, аннары Илбрусны күреп алды.

— Нихәл, улым, яшь чапаевчы? Борчыласыңмы? — Аның малаеннан бик канәгать булуы сизелә иде, ханнар гына менеп йөрер атта бүген аның улы ярышачак бит!

— Әз-мәз генә бар инде, әткәй! «Әз генә дә борчылмаган, курыкмаган адәмнән кеше чыкмый аннан», — ди Хәйрулла бабай.

— Улым, ике яктан да китереп кысмасыннар дисәң, бик урталыкта калырга тырышма. Урының башта кырыйдарак булсын. Соңрак, хәлсезрәкләр артка калгач, уртага кер. Икенче атка килеп бәрелүдән саклан! Килеп җитәрәк, улым, бар көчеңә куарсың, аңладыңмы?

Илбрус ризалыгын белдереп баш селкетеп куйды. Ул да түгел, капкан ризыгын да йотып бетермичә чыгып китәргә ашыкты. Нәсфирә ханым түзмәде:

— Утыр, башта чәйнәп бетер. Үзең дә атка әйләнмәгәнсеңдер ич, аягүрә ашыйсың. Нәрсәмә кирәк иде сиңа ат чабышы, нәселдә булмаганны, — диде.

— Ничек инде нәселдә булмаганны, — Гайфулла абзый да сикереп торды, — мәсәлән, бабам Минлешәриф драгунский полкта беренче мировойда хезмәт иткән, Гражданнар сугышында кавалериядә бөтен Урта Азияне әйләнеп чыккан, Аллага шөкер. Әти дә фин сугышында атлар белән пушка тарттырган! Ат ярату безнең канда ул.

— Ярар инде, җаным, ярар, ат өстеннән очып төшмәсен дип борчылуым. Миңа димәгәе... Әллә тагын салып кайткансың инде, телең ачылган. Мине түгел, менә аны сүгәр идең син, шушы яшеннән ат менеп ярышмакчы була. Егылып төшеп имгәнсә?! Эчеп кайтасың да, улыңны котыртып утырасың. Бала гына бит әле ул! Акыл бирәсе урынга, нәселеңне мактап, баланы азындырасың. Эчмә бүтән, кунакларны каршы аласы бар. — Нәсфирә ханым иренең бер сүзенә бише белән җавап кайтарды.

— Эчсәм соң, биш грамм аракы капкан идем, исереп кайткансың, ди бит. Синнән сорап тормам, бәйрәм көн, — Гайфулла ир булуын күрсәтеп алырга булды. Илбрус гадәттәгечә алар тавышыннан туеп, ризыгын чәйнәп йотты да:

— Ярый, сез сөйләшеп бетерегез, мин, әнкәем, ат абзарына төшеп Орнаментны тынычландырасым бар, ашыгам, — дип урыныннан сикереп торды.

Гайфулла абзый гына улына соңгы күрсәтмәләрен биреп калырга тотынды:

— Улым, атыңа көч өстәр өчен ике-өч кисәк шикәр дә ала төш.

— Син нәрсә, әти, атларга бит ул наркотик кебек тәэсир итә икән, Аллам сакласын. Әлфит абый әйтә: «Татлы ризыктан хайваннар кирегә, агрессивныйга әйләнәләр, гел тәм-том сорый башлыйлар», — ди. Аңа Ижауда укыганда бер акыллы кеше әйткән.

— Хем! Шулайдыр, улым, шулайдыр. Укыган кешеләр күбрәк белә шул. Ярый, әйбәт кенә йөр, яме, улым. Менә Казаннан җизнәң белән апаң кайткач, Сабантуй карарга без дә төшәрбез.

Илбрус чыгып киткәч, Гайфулла абзый токмач кисеп маташкан карчыгын кочып алды.

— Нишлисең, әллә җүләрләндең инде, көпә-көндез, кеше килеп керсә, — дип, хатын ирен сул җилкәсе белән этеп җибәрде.

— Сагындырдың әле бу араларда, әйдә әле, карчык, түр бүлмәгә кереп чыгыйк!

— Кермим дә, йөрмим дә, әй шушыны, әз генә кабып алса, дәрте кабына! Көпә-көндез урын өстендә аунар идеңме. Эшнең очы-кырые юк. Кунакларны каршы аласы бар! Терлекләр рәтле-башлы каралмаган.

— Терлекләрен дә үзем карыйм, суын да ташыйм, тик бәхетемнән генә аерма инде, газизем, — дип абзый төчеләнергә үк тотынды.

— Ай-яй син, кеше килеп керер дип тә курыйкмыйсың, оялмыйсың да, Илбрус янадан кайтып керсә, юк-юк, көпә-көндез... Эшемнең дә очы-кырые күренми! Бакчадан яшел суган-укроплар да җыеп керәсем бар.

— Карчык, дим, яшелчәләрен дә үзем алып керәм, үтермә генә мине! Сине яратсам бит мин әллә нинди эшләр майтарырлык көч алам! Әйдә инде, җанкисәгем, — ташы кызган ир-ат хатынына ялынды. Иренең тәмле теле хатынын йомшартты.

— Уф, үтерәсең син мине, төне буе гырылдап йоклыйсың да... Көпә-көндез бит, эшемне бүлдереп әй.... Кунаклар каршы аласы бар...

— Карчык дим! — ире ризалаша башлаган хатынын артыннан килеп күкрәкләреннән үк кочып алды. Нәсфирә ханым үзе дә арты белән ана сыенды.

Гайфулла карчыгының муеныннан үбеп, чәченнән иснәп алды. Үлән, икмәк исе килә иде аннан. Ир кеше рәхәтлектән тыела алмыйча ыңгырашып ук җибәрде.

— Бар, капканы элеп кер, хет булмаса. Кеше килеп керә күрмәсен инде тагын, — дип пышылдады унган хатын.

Илбрус килгәндә барлык атларны кардага куып чыгарганнар иде инде. Бияләр, байталлар, алашалар, тайлар, колыннар төрле почмакларга өер-өер булып тупланганнар. Карданың уң чатында бияләр белән алашалар төркеме. Урталыктагы яшь бияләр, колыннар, тайлар. Сул яктарак тагын ике-өч яшь бия, ике байтал һәм ике тай. Араларында карданың горурлыгы, үзенең матурлыгы, төзлеге белән аерылып торган, быел яз беренче тапкыр колынлаган Елгыр да күренә. Елгырның уң ягында — нәсел айгыры Лачын. Читтәрәк нидер бүлешеп ике тай тешләшә, кушаяклап тибешә үк башладылар. Бу ыгы-зыгы, бер кирәкмәгән тавыш нәсел айгырына ошамады. Ул бу ике җилбәзәккә кешнәп кисәтү ясады, тегеләре аның сүзенә колак салмагач, ярсып, кешнәп чабып килде дә, тегеләрнең борын төпләрендә арт аякларын өскә чөеп җибәрде. Яшен тизлегендә сызгырып үткән айгыр тояклары бик тиз аннарына китерде ат егетләрен. Икесе дә тиз генә атлар арасына кереп посты, чөнки тегенең холкын беләләр. Бер кат кисәтә дә, аннан тибеп очырырга да күп сорамый. Тәртипсез колыннарның берсенең арт саны Чулпан атлы биянең каршысына туры килде. Ул күп уйлап тормады, теге зимагурның мул жиреннән тешләп алды. Аның шулай итүе көтү башлыгы Лачынга яхшы булып күренүе иде. Әтиегезне тыңламасагыз, тәртипсезләнсәгез, күрсәтәм әле мин сезгә, диюе. Кайбер атларның пошкырып куюларын исәпкә алмаганда, кардада тынлык урнашты. Шулчак ат абзарыннан көчле кешнәү яңгырады. Бу — Орнамент иде. Илбрус аның кешнәве нәсел айгырына ничек тәэсир итәр икән дип күзәтә башлады. Лачын колакларын торгызды, башын күтәреп игътибарын тавыш килгән якка юнәлтте. Теге матурның үзе күренмәгәч, тирә-юньне, су буйларын, ферма тирәләрен яңгыратып хәбәр салды, аны үзләре янына чакырды, әйтерсең лә: «Әй, матурым, сылукаем, чык бирегә, минем иң яраткан назлы биям булырсың», дию иде. Эчке яктан: «Чыгармыйлар шул мине», — дигән үпкәле тавыш ишетелде. Айгыр кардадан ат абзарына керә торган урта ишеккә юыртып кына килде дә башы белән төрткәләп ачарга маташа башлады. Үзе канәгатьсезлеген белдереп тамак төбе белән гөлдердәде. Капка берничек тә ачылмагач, алгы аяклары белән дөмбәсли үк башлады. Ул Орнаментны ни өчен чыгармауларын аңлый да, төшенә дә алмый иде. Бар гаепне ишек-капкадан күрде. Нәсел айгырының бу тилмерүле галәмәтен күреп, гаремдагы чибәрләрнең чибәре Елгыр бия өердән чыгып аның тарафына юнәлде. Аның бу адымын хуплап ике-өч өлкәнрәк бия дә җинелчә генә кешнәп куйдылар. «Әллә каян килгән нәмәстә азындырып ятмасын әле үзен, безнең кайсы жиребез ким шул килмешәктән», имеш. Ләкин нәсел айгырының бөтен игътибары абзар эчендә иде инде. Ул кабат бөтен тирә-якны тетрәтте, эчке яктан да тилмерүле җавап килде. Лачын бикле капканы тояклары белән бәргәли башлады. Теге яшь бия генә тәҗрибәсезлеге аркасында тагын да якынрак килеп әйдаманның артын тешләре белән кашып алды, айгырның игътибарын үзенә юнәлтмәкче иде. Ләкин яшь бия көткән нәтиҗә килеп чыкмады, айгыр, кинәт борылып, мескен

елкының муеныннан тешләп алды. Бия авыртуга түзә алмыйча ынгырашып читкә тайпылды да атлар өелешеп торган якка чабып китте. Илбрус яшь бияне кызганса да эченнән генә: «Орнамент булганда сиңа карыймы соң инде ул», дип уйлап бетермәде, урта капка кинәт ачылып, эчке яктан гадәттәгечә салмыш, кулына камчы тоткан әлеге дә баягы Гатаулла абзый килеп чыкты. Ул ярсып: «Ах, башың беткере, тәгәрәп үлгере», — дип Лачынның битенә китереп сукты.

«Тагын капка төбенә генә килеп кара, иманыңны алам шушы камчы белән. Ишегалды тулы бияләр, һаман житми икән сиңа?! Янадан капкага тибеп кара, ярам астыңа пес иткәнче», — дип, читкә китеп барган нәсел айгырына янады. Бу вакытта тәнендә чыбыркы эзе әрнегән Лачынның ташы суынган иде инде. Ул рәнжеп, үзенә җылырак урын эзләп, бияләр арасында басып торган Елгыр янына кереп китте. Биянең җилкәсенә башын салып, кашыштыра башлады. Үзенчә баягы дорфалыгы өчен гафу үтенүе иде, күрәмсең. Елгыр да берни булмагандай айгырның сыртын назларга тотынды. Яшь биянең ике айлык колыны да каяндыр килеп чыгып, әнисенең астына башы белән чумды, имәргә тотынды. Илбрус бу хәлгә карап торды да, Гатауллага кабарган ачуын тыя алмыйча: «Үзенә хатын-кызлар карамагач, айгырдан үч аласыңмени, кансыз тәре, явыз», — диде. Ул ат абзарына килеп кергәндә Хәйрулла бабасы аран тирәсендә кайнаша иде инде. Шулчак каршысына сәнәгенә печән элгән Гатаулла килеп чыкты. Бермәл алар бер-берсенә юл бирә алмыйчарак тордылар. Икәүләшеп әле унга, әле сулга тайпылдылар. Салдым абзыйга шул житә калды. «Йөриләр шунда булыр-булмас башлары белән ат абзарында буталып! Бар әйдә, бар, әнә теге карт тәрең көтә торгандыр, шул гына аздырып бетерде син малакасусны! Авызында селәгәе дә кипмәгән малайга ике ат бәясенә төшкән затлы чапкынны доверять итәләр», — диде ул ярсуын тыя алмыйча. Илбрус дәшмәскә булды, түзде. Сабантуй көнне, ярыш алдыннан сүзгә килмәскә тырышты. Үсмернең килүен аяк атлауларыннан ук чамалаган Орнамент кешнәп сәлам бирде.

Малайны Хәйрулла бабасы каршы алды.

— Нихәл, улым, кәефләр ничек соң?

— Әйбәт, бабай, үзендә ничек, тәртипме, Сәрбиҗамал тәтәй исән-саумы?

— Ана нәрсә булсын инде, улым! Иртә таңнан мыгыр-мыгыр килеп йөри. Телевизор караганда гына бераз тынып тора. Белеп тор, улым, хатын-кыз картайган саен эчпошыргыч нәмәстәгә әйләнә дә куя икән! Исең китмәсен бер дә. — Оланның күз алдына чәчәкле яулык бәйләгән, бөтен битен җыерчык баскан, авызында ике-өч кенә теше калган, бертуктаусыз мыгырдап йөрүче, әз генә бөкрәйгән Сәрбиҗамал әбисе килеп басты. Аннан Жәмиләне күз алдына китерде ул. Чем-кара, калын чәч толымы аркасына асылынып төшкән. Шомырт кара күзләреннән нур бөркелә. Калын матур иреннәре чия кебек кызарган, көлгәндә ике бите уртасында чокырлар хасил була. Ә йөреше фәрештәнеке кебек инде. Жәмилә картайса да Сәрбиҗамал әбисе кебек бөрешеп килмәячәк, матур булып калачак, чөнки андый чибәр кызлар дөньясында юк. Аны уйларыннан, татлы хыялларыннан арындырып Орнамент кешнәп җибәрде. Хәйрулла карт:

— Әз генә тамак ялгатып алдым. Ярыш алдыннан бик нык ярамас, соңыннан, Алла бирса! Кайткач су эчерә күрмә тагын, улым, бетерәсең аргамакны. Килеп житкәч тә кинәт кенә туктатма, кан йөреше, йөрәк тибеше жайланганчы йөрт, — дип малайга киңәшләрен бирде.

— Хәйрулла бабай! Үзең дә төшәсеңме соң Сабан туен карарга?

— Төшәм, улым, төшәм! Әле Сәрбиҗамал әбиең дә жыена! Барсын әйдә, тавыкларын шул арада күтәреп китмәсләр әле, бер туйганчы бәйрәм карасын, өй саклап арыгандыр инде ул да нибуч, шулай бит, улым.

— Әлбәттә, шулай, Хәйрулла бабай! Елга бер килгән Сабан туена бармаска! Ял итәр бер рәхәтләнеп. Аларны колакларын торгызып тынлап торган Орнамент янадан тыпырчына, чыгарга сорый башлады, авызы белән жинелчә генә малайның жилкәсенә бәргәләде, авызлыгы чылтыр-чылтыр килде.

— Хәзер, матурым, хәзер чыгабыз, — дип Илбрус Орнаментның муеныннан кочаклады. Орнамент исә борын тишекләрен кинәйтеп, көчле итеп мышный башлады. Малайны башы белән күтәреп чайкарга тотынды. Әйтерсең, бишеккә салып тирбәтә иде. Аларны читтән генә күзәтеп торган бабай:

— Сизенә, жанкисәгем, ярышка талпына, өченче көн шулай инде ул. Каян белә, каян сизә диген син бу хайван затын. Кара ничек ашкына бит балакаем, — дип куйды.

Шулчак ат абзарының икенче түреннән жыр агылырга тотынды. Бу әлеге дә баягы Гатаулла моңая иде: «Мине әнкәй тапкан чакта ак биләүгә биләгән, ак биләүләргә биләгән, бәхете булсын димәгән».

— Тавышы матур үзенең, моны бар, — дип бабай сәрхушне мактап куйды. Өйләнеп гаилә дә кора алмаган моңлы тавышлы Гатаулла кызганыч иде. «Тормышын жайлаган булса, бала-чагалар туар иде. Аның кебекләр барысы да башлы-күзле булсалар, авыл урамы балалар тавышыннан гөрләп торыр иде. Беренче класска да быелгы кебек өч кенә сабый бармас иде. Сайланып йөри торгач, Әлфит абый әйтмешли, тәки картаеп, олыгаеп беттеләр, ә менә ул, Жәмиләгә, ризалыгын гына бирсен, шундук өйләнәчәк, сигезне бетерүгә алып кайтачак. Бәлкем, сигезне тәмамлагач иртәрәк булыр, ну унны бетергәч, аттестат ала да, туп-туры авыл советына язылышырга китәләр. Ул армиядә чакта Жәмилә балаларын үстерә тора. Кимендә өч-дүртне таптыра инде ул ана. Шуннан да әзне алып кайтырга ярамый, югыйсә туган авыллары тарала бит. Шамил белән Фәрит тә өчәрне алып кайтсалар, башка малайлар — кимендә икешәрне. Алар сыйныфы гына да егерме кешегә арттыра ала авыл халкын. Димәк, беренчегә өчәү генә түгел, егерме-утызлап бала барачак! Их, Жәмилә риза булса.... Үзем атлар карар идем, ул өйдә сабыйларны тәрбияләр иде».

Шундый татлы хыялларга чумган малай ашыкмый гына урамга чыкты.

— Ярый, хәерле сәгатьтә, улым! Мин дә хәзер кайтып сакал-мыекларымны төзәтәм дә, чабыш мәйданына киләм, — дип Хәйрулла карт тезгенне үсмергә тоттырды.

Ярыш алдыннан үзен шактый гына кыю тотарга маташкан Илбрусның, стартка килеп басуы булды, каушавыннан башы әйләнеп китте. Ул бүтән жайдакларга күз салып алды. Барысы да диярлек тәжрибәле, инде бик күп мәйданнарны күргән абзыйлар иде. Шулар арасында үткән ел унынчыны бетергән күрше авыл малае Хәбир дә бар. Кайберләре, нишләп мондый яшь бала-чаганы шундый юргага атландыралар икән, дип, гажәпләнеп карадылар. Ярыш халәтенә кергән малкайларның тыпырчынуы, йөзләгән, меңләгән күзләрнең төбәлеп аларны күзәтүе, үзенең арада иң яшь икәнлегеен белүе, шуны бертуктаусыз уйлап борчылулары Илбрусның бөтен тәнен калтырата башлады. Аягының дерелдәүләрен тыйса, калтырау муенга күчә. Аннары кире аякларга төшә. Үзенең шул халәтен сизәләрдер инде дигән күңелсез уйларыннан малайның йөрәге әрни. Читкә карарга да ояла башлады. Тизрәк старт бирсеннәр иде дип теләде ул. Ләкин судьялар атларны бер рәткә тезеп, тигезлекне сакларга тырышып, тәк буталып йөриләр. Ярый әле янәшәсендә атның йөгәненнән тотып, жайлап, тынычландырып торучы Хәйрулла бабасы бар! Чапкын исә бермәлгә ярсуын тыйган була да, бераздан тагын боргалана, тыпырчына башлый иде. Илбрус үзе дә: «Тынычлан, Орнамент, тынычлан, мин синең белән бит», — дип атның ялларыннан сыйпады. Ул үзе дә нык дулкынлана иде.

## ҖӘЛИЛ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕН ТӨЗИК!

**Татар халкының каһарман улы — герой-шагыйрь Муса Җәлил энциклопедиясен төзү ихтыяҗы — заман таләбе.**

**Хәзерге вакытта энциклопедияләр төзүнең бай тәҗрибәсе тупланган: Данте, Шекспир, Бетховен, Гёте, Шиллер, Пушкин, Лермонтов, Шевченко, Нәвои, Абай энциклопедияләре язылган, тиздән Тукай энциклопедиясе дә дөнья күрәчәк.**

**Муса Җәлил — СССР дип аталган элекке биниһая зур, куәтле дәүләтнең берьюлы иң югары ике бүләгенә лаек булган бердәнбер шагыйрь. 1956 елда аңа, Бөек Ватан сугышында тиңдәшсез ныклык һәм батырлык күрсәткәне өчен, Советлар Союзы Герое исеме, 1957 елда әсирлектә тудырган «Моабит дәфтәрләре» исемле шигырьләр циклы өчен Ленин премиясе бирелде.**

**«Моабит дәфтәрләре»нең икесе безгә килеп ирешкән; өченчесенең КГБ архивына тапшырылуы мәгълүм, тик әле аны эзләп табасы бар; дүртенче дәфтәрнең булуы турында да хәбәрләр бар, ләкин анысы хәзергә бөтенләй билгесез. Эзләп табасы башка материаллар да байтак.**

**Герой-шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗатына багышлап йөзләрчә мәкалә, фәнни хезмәт, монографияләр язылган, әдәби әсәрләр иҗат ителгән. 1976 елда 1919-1973 елларда басылган әсәрләрне, хезмәтләрне эченә алган, Җәлилгә багышланган библиографик күрсәткеч нәшер ителде, анда барлыгы 2691 библиографик мәгълүмат урын алган. Бу библиографик күрсәткеч басылып чыкканнан соң, 40 ел чамасы вакыт узып барса да, икенче кисәге төзелмәгән әле.**

**Җәлил энциклопедиясе берничә бүлектән торырга тиеш дип беләм. Анда төп урынны хронологик рәвештә һәр әсәренә аңлатма биргән сүзлек-күрсәткеч; иҗаты турында яңа библиографик белешмә; истәлек-хатирәләр, хатлар; шәхси бәйләнешләрне чагылдырган мәгълүматлар; шагыйрьнең тормыш географиясе; әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге һәм элемтәләре; иҗат һәм тормыш биографиясенең җыр, театр, кино, рәсем һәм сәнгатьнең башка төрләрендә чагылышы булырга тиеш.**

**Патриот-шагыйрь Муса Җәлил татар халкын бөтен дөньяга танытты, ул — безнең горурлыгыбыз һәм алга, киләчәккә барыр юлыбызда иң ышанычлы, иң якты маякларыбызның берсе.**

**Россия Федерациясе Президенты В.Путин: «Каһарман шагыйрь иҗаты — күпмилләтле, бай Русия мәдәнияте, аның кыйммәтле әдәби мирасының аерылгысыз өлеше, ә тормышы — үз-үзен аямыйча, югары әхлакый максатларга хезмәт итү, патриотизм, батырлыкның чын, асыл үрнәге, — дигән иде М.Җәлилнең 100 еллыгы уңаеннан тәбрикләү сүзендә. — Аның күңелгә үтеп керә торган шигырьләре бүген дә укучыларның йөрәкләренә тәэсир итүдән туктамый, алар тарихи хәтерне һәм буыннар арасындагы ныклы бәйләнешләрне саклауда бик тә гүзәл миссия башкара», — дип бәяләде.**

**Ил башлыгының бу сүзләре дә Җәлил энциклопедиясенең ни дәрәҗәдә кирәклеген бик ачык итеп аңлата.**

**Хәнәфи БӘДИГЫЙ**

Ниһаять, «Әзер булыгыз!» дигән әмер янгырады. Хәйрулла бабасы: «Аллага тапшырдык, тезгененне ныклап тот, улым, кинәт ыргылып киткәндә очып төшеп калма», — дип кисәтте. Үзе читкә китте. Атлар тагын да ныграк чыгымлый, борчыла башладылар. Каршы яктан малайның битенә җил исеп куйды. Җәй кояшыннан, каушаудан тирләгән йөзен җин очы белән генә сөртеп алды ул. Старт! Илбрусның ярсу аты алга ыргылды. Ул кинәт тартылудан очып калмас өчен өзәнгеләре белән атны кочты, бар көченә тезгененә ябышты. Бер мизгел эчендә каушавы да, кылтыравы да юкка чыкты. Колакта — дага-тояк тавышлары. Атлар оча. Юл кырыенда басып торган халык көч-куәт биреп кычкырып кала. Илбрусның колагына да үз исеме килеп ирешә. Ул тиз генә тирә-юньгә карап алды. Як-ягында очкан аргамаклардан башы әйләнеп китте. Карамавың, иң яхшысы офыкка төбәлеп чабуың хәерле. Стартан киткәндә бер-берсен уздырмаска тырышып тигез чапкан атлар көтүе бераздан сузылды. Иң артта колхоз юргалары сөйрәлде. Шулай да унга якын чапкын беренчелек өчен көрәшүне дәвам итте, шулар арасында Орнамент та бар иде. Юлның яртысын диярлек узганда, аргамакларның бер өлеше тизлекне тота алмыйча койрыкка күчә барды. Алда чабучы атлар белән койрык арасы озынайганнан-озынайды. Икенче әйләнештә алда — Орнамент белән бергә тагын ике ат. Көндәшләрнең берсе Башкортстанның Дүртөйле районыннан булса, икенчесе Арчадан иде. Нәселле юргалар бер адым да калмыйча чаба. Тәҗрибәле, Россия дәрәҗәсендә призлы урыннар яулаган юртаклар иде болар. Тагын әле дүртесе артларыннан бастырып килә. Араларында үткән елны Йошкар-Олада беренчелекне алган кара байтал да, Арча районында икенче урынны алган ала бия дә бар. Вакыт-вакыт Орнамент белән башны-башка терәп диярлек чапкан кара байтал алга ыргылды. Өстендәге җайдагы бертуктасыз камчылый бәгырьне. Илбрусның гына атка сугарга кулы күтәрелмәде. «Түзәргә, җан дустың камчы белән рәнҗетмәскә кирәк, Әлфит абыйсы да кирәк-кирәкмәгәндә кауламаска кушты бит! Болай да шәп чаба. Берсе аз гына алга чыктымы, шундук куып тота. Үсмер җәт кенә яңадан артка күз салып алды. Тагын өч җайдак аларны куып җитеп килә иде. Менә шунда инде Илбрус вакыт җиткәнен аңлап алды. Бүтәннәр кебек уңлы-суңлы камчыламады ул атын. «Әйдә, жаным, вакыт җитте», — дип, өзәнгесе белән атына җинелчә генә төртеп алды. Орнамент шуны гына көтеп торгандай, җәя кебек тартылды да ук кебек алга ыргылды. Менә кара байтал Орнамент тәкъдим иткән тизлекне тоталмады, артта калды. Тик алтын яллы коңгырт аргамак кына бирешмичә бастырып килә. Хәзер алар икәүләшеп финишка якынлаша. Ат шундук малайны аңлап алды, сөлек кебек сузылып тизлекне тагын да арттырды. Алтын койрыклы бияне артта калдырып финиш сызыгын беренче булып үтте. Илбрус атын туктатмыйча тагын шактый гына юл узды. Аннары кире борылды. Бөтен киеренкелек артта калган иде. Әле үзенең җиңгәнлегенә ышанып та бетә алмаган җайдакка авылдашлары «молодец, молодец» дип кычкыра, кул болгый, аның каршысына йөгерә иде. Ул арада Әлфит абыйсы килеп җитеп, аркасыннан сөйде, Орнаментның кара тиргә баткан битләреннән сыйпады, муеныннан кочаклап алып үпте. Ул да түгел, түбәтәен салып болгаган Хәйрулла бабасы, әти-әнисе күзенә чалынды. Әнә классташлары Фәрит белән Шамил дә бирегә якынлашалар. Сыйныфташ кызлары да күзгә ташлана, араларында Җәмилә дә бар. Бөтен дөнья тоnык кына гөжли кебек тоелды аңа. Өнме бу, төшме?!

«Төш әйдә, Илбрус энекәш, молодец, сынатмадыгыз, беренчелек безнеке», — Әлфит абыйсының бу сүзләреннән соң малай чынбарлыкка кайтты. Халык тонык кына гөжләми икән, бар тугайны шаулатып акыра, сөйләшә, йөгерешә икән. Ат өстеннән төшүгә әнисе килеп, малаен башкалардан араларга тырышкан

кебек, кочып алды. «Әй, улым, балакаем, синең өчен борчылып котым очты. Йөрәгем ярыла дип торам, бүтән шул ат өстенә мәңге менгерәсем юк үзеңне», — дип Илбрусның башыннан сыйпап елады.

— Хәзер чабам да чабам инде мин, әнкәй, чирканчык алдым бит», — дип сөйләнде малай. Шул арада дус-ишләре, туганнары үзен уратып алды, кулын кысарга тотындылар. Мондый зурлауларны гомерендә дә күрмәгән малай кабат югалып калды. Бик уңайсыз иде аңа.

— Мондый атка кем генә менсә дә җиңәчәк инде ул, — диде тыйнак кына.

Төркемне икегә аерып: «Яле, балалар, яле күрим әле үзен, Илбрус улымны», — дип Хәйрулла бабасы килеп керде.

— Булдырдың, улым, афәрин! Безнең авылда гомердә булмаган хәл бит бу! – Аксакал үсмерне аркасыннан чәбәкләде. Ул да түгел, тавыш көчәйткечтән «Ат чабышында катнашканнар мәйдан уртасына чакырыла», дип хәбәр бирделәр. «Әйдә, Илбрус энекәш, менеп атлан, киттек», — дип, Әлфит абыйсы атның тезгененнән тотты. Өлкәне, яше, малае, кызы алар артыннан иярде. Мәйданда чапкыннарны тагын бер рәткә тезделәр. Малкайлар инде бая чабып киткәндәге ярсу атлар түгел иде. Хәлләре бетеп, тынычланып калганнар. Менә бүләкләү башланды. Иң әүвәл өченче урынны алган кара байтал хуҗасына – суыткыч, икенче килгән алтын койрыклы биянең җайдагына – зур телевизор бирделәр. Ниһаять, Орнамент һәм Илбрус. Атның муенына сөлге-яулыкларның иң матурларын бәйләделәр. Малайның үзенә компьютер бүләк иттеләр. Иң соңыннан килгәнгә — магнитофон.

Җинүче алган бүләкләрен әти-әнисенә илтеп тапшырды да, Орнаментка атланып авыл ягына юл тотты. Атка ике яклап иптәш малайлары Шамил белән Фәрит тә ияргән иде.

— Ай-яй малай, теге Арчадан килгән ала бия дә оча гына икән! Безнең Орнаментны узып китә дип торам, котым очты, — диде Шамил.

Фәрит тә тәэсирләрен уртаклашырга ашыкты:

— Ә теге алтын койрыклы чапкын тоже шәп бит! Тик Орнаментка гына житә алмады, финишка җитәрәк ничек томырылды безнеке. Тегеләргә «ых» итәргә дә урын калдырмады бит!

— Тик мин бер нәрсәдән шикләнәм әле. Менә күрерсез, икенче елга Татарстаннан иң яхшы аргамаклар киләчәк. Бу хурлыкны күтәрә алмаячаклар алар. А то киләләр дә җиңеп китәләр, киләләр дә җиңеп китәләр иде. Менә быел шиш сезгә, хватит, өегездә генә чабыгыз, — дип шапырынды Шамил.

— Теге Президент атларын җибәрсәләрме!? Ай-яй, малай, җиңә алырбызмы, бик күп медальләр, призлар откан ди бит ул. Имеш, Рәсәйдә иң беренче юрга ди. Орнамент аны да отса, вәт, кызык булыр иде, ә?! – хыялланып барган Фәрит дусты, ат өстендә барган Илбруска карап куйды.

— Орнамент берешә торганнардан түгел. Ул чапканда барысын да тоя, ни уйлаганыңа хәтле аңлый, малайлар. Бүген мин аның сизгерлегенә үзем дә исем китте. Ләкин президент атларының монда мәңге киләсе юк. Алар бит миллион долларлы ярышларда гына чабарга өйрәнгәннәр. Ә монда килгәннәренә күрсәтәбез әле без, шулаймы, Орнамент, — Илбрус атының муенын чәбәкләп алды. Малайларның бөтен уй-хыяллары бүгенге Сабан туе тирәсендә булды. Тик Илбрус кына дусларының әңгәмәсенә бүтән кушылмады. Аның уенда Җәмилә иде.

Ел буена көтеп алган Сабан туе бер мизгелдә үтте дә китте. Зур күтәренкелек һәм киеренкелек белән узган бәйрәмнән соң, көнелләрдә бушлык барлыкка килде. Илбрусның да эче пошып көнне ничек үткәрергә белми йөргән чагы.

Ялыктыргыч, пычрак-тузанлы чәчү эшләре беткәч, печән өстенә төшкәнче жир кешесе бераз ял итеп ала. Табигать шулай көйләнгән. Печән чабарга, аны киптереп өяргә көч җыю өчен мөмкинлек бирә. Шуннан файдаланып Сабантуй үткәрәбез. Башка халыклар үзләренә генә хас бәйрәмнәр, гореф-гадәтләр, йолалар уйлап чыгарганнар. Без — башка халыклар, шул исәптән чуаш, мари, рус, удмурт белән гасырлар буена аралашып, иген кырларында бергә эшләп, бергә гомер сөргән халык. Сабантуйда да бергә без. Милләтләрне берләштерә, дуслаштыра торган изге бәйрәм ул — Сабантуй! Әлфит юлда шул хакта уйланып барды. Юлы исә — Казанга. Аларның печәнгә төшкәнче цирк, театр карап кайтырга барулары. Арттагы ике «УАЗ»да — колхоз алдынгылары. Араларында Сабан туенда ат чабышында җиңү яулаган Илбрус та бар. Эч пошып ни эшләргә белми аптырап йөргәндә Сабантуй җиңүчесе буларак аңа да татарның башкаласын карап кайтырга насыйп булды. Рәхмәт инде Әлфит абыйсына, шулай зурга санап чакырганы өчен. Аның ташкаланы күргәне юк әле. Юлга чыгар алдыннан колхоз идарәсеннән һәрберсенә биш йөзәр сум акча бирделәр. Әнисе дә, ач йөрмә улым, теләгәненне ал, дип кульяулыкка бәйләп, тагын өч йөз сум тыкты. Малайның нияте — ул акчага күчтәнәч алу. Кәнфит алыр инде. Җәмиләгә нәрсә бүләк итәргә икән? Яулык-мазар алса, акчасы җитәр микән. Өйдәгеләре дә кемгә алдың бу яулыкны дип төпченмәсләрме? Ләкин аның күнелен тырнап, борчып торган уйлар да бар иде. Сабантуйның икенче көнендә Хәйрулла бабасын район хастаханәсенә илтеп салдылар. Кан басымы нык югары тора икән. Терелә генә күрсен инде, Илбрус белән Орнамент ансыз нишләр? Орнаментны берьялгызын сәрхуш Гатаулла белән калдырдылар. Аңа ышан син! Кул күтәрергә дә күп сорамас! Казанны күрәсе дә, тизрәк әйләнеп кайтасы иде. Яраткан атын ялларыннан сыйпап, муеннарыннан кочып назлар иде. Чапкын исә калын иреннәре белән битеннән үбәр иде. Борыны белән күкрәгенә төрткәләр иде....

Тимер юлны чыккач, машина уңга борылды, урман буйлап алга чапты. «Менә кайчандыр шушы юлдан Габдулла Тукаебызны да асрамага бирергә ияртеп алып килгәннәр», — дип әйтеп куйды кемдер. Илбрус янадан хыял диңгезенә чумды. «Их, шул заманнарга кире кайтып, Габдулла Тукай белән күрешсәң икән! Ул чактагы кешеләрне, юлларны, урманнарны күрсәң икән... Ятим малайны кәнфит-прәннек белән сыйлар иде. Асрамага бирдергәнче үзләренә алып кайтып китәр иде ул аны. Өйләре зур бит, бергә яшәрләр иде әле. Балыкка да, мәктәпкә дә бергә йөрерләр иде. Әле Тукайга Орнаментка атланып чабарга да рөхсәт итәр иде. Нишләп рөхсәт итмәскә ди Тукай хәтле Тукайга. Әлфит абыйсы да сүз әйтмәс иде. Андый яхшы тормышта яшәсә Габдулланың үпкәсенә дә салкын тимәс иде. Ул егерме жиде яшькә хәтле генә түгел, озак, бик озак, бер туксаннарга кадәр яшәр иде. Тагын бик күп шигырьләр язар иде. Рәхмәт йөзеннән берәрсен Илбруска багышлар иде. Үсмер янадан тәрәзәгә капланды. Икешәр, өчәр катлы баракларны, бишәр катлы, соңрак тугызар, унҗүртәр катлы йортлар алыштыра торды.

Казан шушы икән бит инде!

***

Сабантуйдан соң өч көн үтсә дә, «алашалар» төркеме айнып бетмәгән иде әле. «Алашалар» дип авылда өйләнмичә йөргән унлап егетне атыйлар. Күпчелеге утыз тирәләрендә булса, кырыкны, илленe тутыручылары да бар! «Алашалар» дигән кушамат ямьсез яңгыраса да, күпмедер дәрәҗәдә үзләренә туры да килеп тора тагын. Печелгән атларны биеләр кызыксындырмаган кебек, боларның да хатын-кызга әлләни исе китми. Кардада бәхетсезлеккә дучар ителгән алашалар

гел бер төркемгә җыелып торса, ирләр дә әле бер җиргә, әле икенче төшкә җыелышып эчәләр иде. Дөрес, «алаша» дисәң, үпкәли тагын үзләре. Авыл халкы, тукта, күнелләренә тиеп берәрсе булса да өйләнмәсме икән, дигән ният белән дә әйтә бу сүзне. Ләкин файдасы күренмәде әлегә хәтле. Шул «алаша»ларның Рафаэль дигәне бүген, көндезге уннарда гына уянып китте. Хәле яхшыдан түгел иде аның. Ул сарайдагы ятагыннан торып утырды. Нишләптер ут та янып тора. Каршыдагы өстәлдә өч буш шешә, ике стакан, өч чәркә, тозлы кыяр белән ипи калдыклары күзенә ташланды. Өстәлнең бер кырыенда сигез литрлы чиләк белән су тора. Рафаэль сәкедән шуып төште дә, теге шешәләрне тикшереп чыкты. Ләкин аларда куанырлык бернәрсә дә калмаган иде. Шулай булуга карамастан, ир кеше барысын да алып, авызына селкеп карады, өч-дүрт тамчы сыекча махмыры аңкып торган авызына тамды микән? Тамса да, ул тамчыларның ни файдасы булсын. «Да, эчеп тә караганбыз икән. Ник похмельгә йөз-йөз илле грамм хотя бы калдырылсын!» Рафаэль чүмеченә су алып йотлыга-йотлыга эчеп тә бетерде. «Ярый әле шушы чишмә суы бар, ул да булмаса, точно бетәсең, көеп үләсең!» Озакламый бөтен тәненә салкын тир тамчылары бәреп чыкты. «Нәрсә эшләргә икән, махмырдан үлеп булмый бит инде. Гатаулланы кысып карарга инде, бер генә яртылык булса да фураж бирмәс микән?!»

Ул, битенә бәреп чыккан тамчыларын җиң очына сөртә-сөртә, түбән очка, фермалар ягына төшеп китте. Баганасы череп уңга янтайган капкасы гына озатып калды аны. Ул да түгел, җимерек капкадан ямьсез тавышлар чыгарып, мыраулап, ярсый-ярсый сугышып ике ата мәче дә атылып чыкты. Коңгырт мәче, карасының эзәрлекләвенә түзә алмыйча, рәшәткәгә үрмәләп менде дә, бәрәңге бакчасына сикерде. «Әй, тәгәрәп үлгерләре, йөрисез шунда кеше куркытып, мур кыргырлары. Сез генә җитмәгән иде тагын!» — Рафаэль юлын дәвам итте. Ахиры Заһитка да сугылырга ниятләде. Тегесе капка төпләрендәге урындыкка утырып тәмәке көйрәтә иде.

— Кая киттең, Гатауллагамы? — дип каршы алды аны Заһир.

— Шунда! Кичә ничәгә хәтле утырдык соң без?

— Төнге беренче яртылар булгандыр, син утырган килеш гырылдап йокыга да киттең...

— Үләм, малай, бөтен җир авырта, берәр нәрсә табарга кирәк! Югыйсә хәл мөшкел, Гатаулла ике-өч капчык фураж бирсә, җайлыйбыз инде без аны! Әйдә, төшеп менәбез! — дип шешәдәшен дә үзе белән ияртте.

***

Гатаулланың жигүле аты ат абзары алдында тора иде. Үзе эчкә кереп киткән, ахры. Ирләр түргә уздылар. Аяк тавышларын ишетеп Орнамент кешнәп җибәрде. Рафаэль сорап куйды:

— Нишләп Орнаментны тугайга алып төшеп китмәгәннәр икән соң бүген?

— Соң Илбрусны бит пред Казанга алып китте. Хәйрулла бабайны район бүлнисенә салдылар. Гатаулла бүген пулный хозяин биредә, — дип аңлатты Заһит.

— Аларның булмавы яхшы! Сүзләреннән башаяк! Гаташ, син кайда әле? — кыюланып киткән Рафаэль кычкырып җибәрде.

Келәт сыман бүлмә эченнән киемнәре фуражга баткан ат караучы үзе күренде.

— О, о, о... агылый белән таглый! Нәрсә, башыгыз авыртамы?! — дип каршы алды ул кунакларны, мыскыллы караш ташлап.

— Үзеннең хәлең дә әллә ни түгелдер әле, берәр нәрсәң юктыр ич, — Рафаэль башын келәт ишегенә тыгып, күзе белән эчке якны айкап чыкты.

— Мин бит сезнең кебек бездельник түгел, Аллага шөкер, эшен дә эшлибез, акчасын да алабыз.

Гатаулла келәткә кереп китте. Иптәшләре дә ана иярде. Бүкән өстендә — башланган бер ярты белән ипи кисәкләре, йодрык хәтле ит. Моны күргәч егетләрнең кәефе күтәрелде. Ә инде берәрне тондыргач, телләре үк ачылды. Рафаэль шунда кош кебек үк сайрарга тотынды: молодец син, Гаташ, кысмыр түгел син, булса бүлешә беләсең!

— Нишләп соң бүген Шәүкәт янына бармадыгыз, үзегезнең яртыгыз булса, шунда чабасыз ич. Ат караучы чакырылмаган кунакларга сынаулы караш ташлады.

— Соң, Гаташ брат, монда сиңа гел-гел килеп тә булмый бит, то Хәйрулла бабай бирелә, то теге салабун Илбрусы йөри буталып. Алар күзенә чалынсаң, бөтен авылны сасыталар инде нибуч, — дип Рафаэль акланырга тотынды. Үзенә терәк эзләп Заһитка: «Теге юлы бит, хәтерлисеңме, бер яртыны кыстырып кергән идек синең белән», — диде һәм иптәшенә күз кысып алды. Тегесе аны аңлап алды. «Әйе шул, кергән идек», — дип дустының сүзен хаклады.

— Шыттырмагыз, нишләп соң, алайса, мин күрмәдем сезне, — дип сорау бирде Гаташ.

— Синеме? Кая анда сине күрү?! Орнамент янында Әлфит Хөрмәтуллович үзе кайнаша иде. Тайдык тизрәк, — дип куйды Заһиты.

— Шиш кыләсез сез, яртыгыз булса, бөгештермәгез. Югыйсә кудым чыгардым булыр икегезне дә.

— Ярар инде, Гаташ, юкка бәйләнәсең. Менә килдек бит әле дус итеп! Гел килеп торабыз бит, Аллага шөкер, — Рафаэль ат караучыны җайларга тотынды.

— Мине дурак дип беләсезме әллә! Шул рәтегез калмаганда гына пәйда буласыз! Йә, ярый, миннән булсын яхшылык. — Гатаулла пластик стаканнарга шешәдә калган аракыны койды. — Тотыгыз, әйдә, пока я добрый.

— Без Шәүли белән классташлар бит, Гаташ! Ахириләр дә әле без аның белән! Шуңа күрә барыла да инде, — Рафаэль аклана башлады. Сүзгә Заһит та кушылды.

— Без бит ана да барабыз, сиңа да киләбез!

— Менә хәзер аракы бетте, мин алганы бетте, әйдәгез, калганын үзегез юллагыз инде. Бер бездән, бер сездән булса яхшы ул, брат! Ник дәшмисез? Хәлегездән килмиме? — дип басым ясап сорады абзар хуҗасы.

Шулчак конюшный эчен яңгыратып ат кешнәп җибәрде.

— Эчәренә бирергә кирәк, су сорый, — дип куйды Гаташ.

Шунда сәрхуш Рафаэльнең Сабантуйга хәтле булган бәхәс исенә килеп төште.

— Үзең безне сүгәсең дә сүгәсең, син дә бит сүзеңдә тормыйсың, — ул Гаташка текәлеп карады. — Онытмыйнмыни Сабантуйдан соң: «Минме, мин Орнаментка менеп атлансаммы, канатлы кош кебек очам», — дип мактанган идең. Ике яртыга кул да сугышкан идек әле!

— Нишләп хәтерләмәскә ди... Аллага шөкер, хәтерем бик әйбәт минем!

— Давай, алайса! Әгәр дә аргамак сине очырып төшереп калдырмаса, без сиңа бер литр куябыз. Әмма дә инде чаба алмасаң, син безне сыйлыйсың.

— Яхшы! Сез мин атланганда атны яхшылап тотып торыгыз! Күрсәтәм әле мин сезгә ничек ат өстендә йөрергә кирәклеген! Әллә теге салабун кадәр генә чабалмас дисезме! — дип әтәчләнде Гатаулла.

— Илбрусны үз итә, тыңлый ул, ә менә син атлангач нишләр икән?! — Заһит эшне тагын да кыздырып җибәрде.

— Тьфу, анагызны сөлек-мөлекләр, онытттыгызмыни ун ел элек Очкынны ияр астына кертүнемне? Ул да бит ажгырып тора иде. Монсын да үз урынына куям мин, менә күрерсез.

Чыннан да, күп дисәң бер дистә ел элек Гаташ яшь аргамакны ияр астына керткән иде. Дөресен әйткәндә, Гаташ ат өстендә йөрергә кечкенәдән өйрәнде. Өстәвенә тәвәккәллеге дә җитәрлек. Әгәр бүгенге сала ирләрен барлап чыксаң, аннан да житезрәк, ныграк кеше калмады диярлек. Элеккеге кыю ирләр олыгайды. Лачын кебек егетләр шәһәрләргә китеп барды. Әлфит белән Илбрусны санамасаң, Гаташны уздыручылар юк кебек! Менә бүген авызлыклый алырмы затлы, нәселле атны. Бу бит ферма аты гына түгел, чын мәгънәсендә очар кош бит аның монысы. Элек мондый мәһабәт юргаларны авыл халкы рәсем-сурәтләрдән генә күреп белә иде. Тормышта Орнамент кебек аргамаклар бик күпкә күркәмрәк икән, чөнки монысының җаны бар. Сөлектәй янып, ялтырап тора. Әйтерсең лә, лак сибеп чыкканнар. Гәүдәсе дә унсигез яшьлек кызларныкы кебек җыйнак, ник бер артык җире булсын да, ник бер җире бүлтәеп торсын. Бүген шушы гүзәл ат кызы белән кайчандыр ин зәһәр, иң тыңлаусыз байталларны да тәртә астына керткән Гаташ арасында көрәш булачак. Кем — кемне? Бу сорауның җавабы гына әлегә билгесез!..

***

Орнаментны аранынннан алып чыгу бик авыр булды. Гаташ якынаюга юрга тынычлыгын югалтып тыпырчына, боргалана башлады. Гаташка бик сак булырга кирәк иде. Чөнки чапкын аны яратмый, күралмый. Күп сорап тормас, типте очырды булыр. Шулай да Гаташ, кулына яңа чабылган печән тоткан килеш, тәмле сүзләр белән җайлый-җайлый, бер мизгелне туры китереп, атны авызлык кырыеннан эләктереп алды. Орнамент арт аякларына күтәрелеп, бөтен абзар эчен янгыратып кешнәп җибәрде, күкрәге белән Гаташны аран арасындагы рәшәткәгә китереп сылады. Бу әле аргамакның кисәтүе генә иде, әгәр дә ал аяклары белән күкрәгенә китереп типкән булса, белмим, ат караучы исән калыр иде микән?! Ул арада Рафаэль белән Заһит аран ишеген ачып та өлгергәннәр. Чапкынның артка чигенә-чигенә чыгуын сизми дә калдылар. Куркуыннан агарынып чыккан Гаташ: «Трр-трр, җаным», — дип атның тезгененә ябышты. Рафаэль дә тиз генә эләктереп алды. Тезгеннен ике ягыннан тотып, юрганы җайлый-җайлый урамга гына чыкканнар иде, Орнамент кешнәп җибәреп кабат арт аякларына басты. Киеренкелекнең икенче сериясе урамда башланды. Ат болардан ычкынырга теләде, ирләр аны карда кырыена кысрыклады.

Шулвакыт Гатаулла:

— Заһит, син минем урынга кил, башыннан тот әле! Мин хәзер карда рәшәткәсенә менәм дә, сез атны якынрак китергәч өстенә сикерәм, — дип кычкырды.

Аргамак Гаташ читкә киткәч, тынычланып калгандай булды. Аны ат караучы менеп кунаклаган карда рәшәткәсе кырыена, ниһаять, якын китерә алдылар. Шуны гына көтеп торган Гатаулла юрганың өстенә сикерде. Ат исә көтелмәгән хәлдән кабат арт аякларына басты. Ат караучы, очып төшмәс өчен, Орнаментның куе кара ялларына чатырдатып ябышты. Үзе исә: «Тезгенне, тезгенне бирегез», — дип, аста басып торган Рафаэль белән Заһитка кычкырды. Тегеләре ничек кирәк шулай, тезгенне Гаташка ыргытып, читкә тайпылдылар. Җайдак тезгенне тотып алды да бар көченә тартты. Орнамент ук кебек алга ташланды. Аннары әле ал аякларын күтәреп, әле артын сикертеп җайдакны бәреп төшерергә

тырышты. Аны алга-артка чайкый башлады. Ләкин Гатаулланың да осталыгы, тәҗрибәсе җитәрлек иде. Итек үкчәләре белән атның кабыргаларына каты итеп төртеп алды. Мондый тупаслыкны гомерендә дә күрмәгән чапкын арт аякларын да тагын бер күтәрелеп алды да, бар көченә чабып китте. Чүттән генә Гатаулланы каршыдагы электр баганасына китереп сыламады. Ул, бар көченә тезгенне тартып атның башын сулга каерды. Орнаментны авыл кырыена, кырга алып чыгып китү иде нияте. Ләкин ат бар көченә каршылык күрсәтте. Гүя аның өстенә ат караучы сәрхуш Гаташ менеп утырмаган, гүя, куркыныч дию пәрие кунаклаган. Күзе-башы алышынган аргамак аны тыя алмаган Гатаулланы киресенчә, уң якка алып китте. Күпме генә тырышмасын, күпме генә көч түкмәсен, җайдак атны кырга юнәлтә алмады. Шул килеш алар авыл кырыенда, Кәрим аганың мунча бурарга дип өеп куелган бүрәнәләре өстенә барып керделәр. Ул да түгел, ат өстеннән очып төшкән җайдак, сыны катып, җирдә ята иде инде. Бүрәнәләр өеменә егылган ат исә кызганыч тавыш белән кешнәп җибәрде. Рафаэль белән Заһит килеп җиткәндә, Гатаулла ике аягына да баскан иде. Ул чатанлый-чатанлый Орнамент янына килде. Атның күзеннән яшь ага, бөтен гәүдәсе дерелди иде. Алар өчәүләшеп малкайны бүрәнәләр өстеннән шудырып төшерә алдылар. Орнаментны көчкә аякка бастырдылар. Ләкин ул өч аякка гына басты, сул аягы шешеп, кабарып чыкты. Заманында ветврачка укып алган Заһит диагнозны тиз куйды:

— Аягы сынган монын!

— Нишләргә соң миңа хәзер, нишләргә? Әлфит абый үтерә бит мине! Үтерә! — Гатаулла елап җибәрде.

— Хәзер үк колхозның ветврачы Халитне чакыртып укол кадатырга, атның аягын бәйләтергә кирәк. Тик мин шуны гына беләм, мондый бәлагә тарыган малны ит комбинатына гына озаталар иде, — диде Заһит.

Бу сүзләр Гатаулланың йөрәгенә кадалды.

***

Әлфит Казаннан кайтканда ат караучы авылдан чыгып качкан иде инде. Карданың бер өлешен такталар белән аралап алганнар да, астына мул итеп салам түшәп, Орнаментны яткырганнар. Бинтлар уралган аягын күтәреп, авыртуга түзә алмыйча калтырап ята бәгырькәй. Зур, матур күзләреннән яшь ага. Әлфит, яраткан атын кочкан килеш, әрнеп, кычкырып җибәрде:

— Кайда ул кабахәт, кая качты, үтерәм заразаны, — дип үзенең күз яшьләрен сөртте.

Читтәрәк карда рәшәткәсенә сөялеп Илбрус үкси иде. Мал табибы Халит тә шунда. Председатель аңа дәште:

— Ни генә булмасын, Халит, аякка бастырырга кирәк Орнаментны. Шалтырат, белеш! Ничек дәваларга кирәклеген сораш! — дип таләп итте.

— Сораштым инде, хәтта Татарстандагы дусларга да шалтыратып белештем. Юк ярдәм итәрлек кеше. Барысы да: «Без андыйларны пычак астына озатабыз», — диләр. Ни әйтергә дә белмим, Әлфит Хөрмәтуллович.

— Тагын берәздән авыртуны баса торган дару кадарсың. Төнлә үзем саклап чыгармын инде, — дип куйды председатель.

— Әлфит энекәш, без Илбрус белән сакларбыз! Син кайтып дус-ишләреңә шалтыраткалап кара әле, берәрсе белми микән? Ә без монда как-нибудь чиратлашып карарбыз, — дип сүзгә кушылды бүген генә больнистән чыккан Хәйрулла карт.

— Күңелем сизгән иде ул мөртәтнең ни булса да китереп чыгарасын. Сизгән иде! Ярый, бахбаем, күз нурым, түз инде, түз! Алла боерса, аякка басарбыз

әле без, — Әлфит иелеп хәлсезләнгән, авырту-әрнүләрдән суырылып калган чапкынның битеннән үбеп алды.

Аннары карданың аркылы жирдалары арасыннан иелеп чыкты да, кайгыга батып өенә юнәлде. Авыл үзе дә әле күптән түгел генә Сабан туенда беренчелекне алып куандырган аргамакның хәлен белеп хәсрәт утында янды.

## Түз, аргамак!

Атның хәле икенче көнне дә, өченче көнне дә яхшырмады. Киресенчә, начарланганнан начарлана барды. Кемгә генә чыгып карамады Әлфит. Казан да, Йошкар-Ола да, Әтнә белән Арча да, Киров каласы да калмады. Жавап бер генә иде: «Үлеп киткәнче, чалырга! Ат жәфаларыннан котыла, үзегезгә ит була». Әлфит укытучысы Беловны исенә төшерде. Ул идарәдәге телефон номерлары белән чуарланып беткән дәфтәрдән мөгаллименекен көчкә эзләп тапты. «Үзгәрмәгән генә булса ярый инде», дип борчылды ул. Шөкер, телефонны Белов үзе алды. Әлфит, елар дәрәжәгә житешеп, эшне аңлатып бирде. Бер генә көнгә булса да үзләренә килеп китүен үтенде, бүген үк, хәзер үк Ижевскига машина жибәрәсен дә әйтте. Укытучысы: «Жибәрмә, кайчан килеп житә әле ул, хәзер үк үз машинам белән юлга чыгам, — диде. Үзе килгәнче атны корсагыннан асып куярга кушты. Атларга озак ятарга ярамый, кан йөреше бозылырга, органнарга зыян килүе мөмкин икән.

Белов юлның Арчага хәтлесен әйбәт белә икән. Туганнарына еш кайтып йөргән. Әтнәдә очрашырга килештеләр. Белов белән сөйләшкәннән соң Әлфит телефонлы авылдашларына шалтыратып чыкты, балта-пычкыларын алып кардага килүләрен сорады. «КамАЗ» машинасында эшләүче Рамилгә өч-дүрт егетне алып, авылдан өч чакрым ераклыкта урнашкан урман хужалыгыннан уртача юанлыкта ун-унбиш бүрәнә алып кайтырга кушты. Күп тә үтмәде, кардада зур таганны хәтерләткән жайланма барлыкка килде. Аны ат яткан урынга урнаштырдылар. Орнамент мескен кешеләргә өметле күзе белән карап, ярдәм көтеп ятты. Ниһаять, аны брезенттан ясалган киң тасмалар белән уратып алдылар. Хәзер инде брезент жәймәләрнең почмакларына бәйләнгән калын бауларны һәм тасмаларны жайланма аркылы ыргытып тартасы гына калды. Алты ир кеше атны тырыша-тырыша күтәрде. Малкай исә хәлне аңлады, авыртуга түзде, вакыт-вакыт ыңгырашып куйса да тыпырчынмады. Менә, ниһаять, ул асылынып калды. Әлфит аңа көрпә болгатылган су китерде. Орнамент башта иснәп кенә карады, хужасы бик кыстагач, ашыкмый гына эчәргә тотынды. Мал табибы чапкынның йөрәк тибешен тынлап карады. «Егетләр, жайлаша бу, тизрәк Белов килеп житсен иде инде, — диде. Атның тамагына капкалавы, кешеләргә рәхмәт йөзеннән тутырып-тутырып каравы күңелләргә өмет, жылылык өстәде. Тик кайчан гына кош кебек очкан юрганың мескен хәлдә асылынып торуы кызганыч иде. Яраткан чапкынның хәлен күреп Илбрус үзе дә ашаудан калды, суырылды. Көне-төне ат янында бөтерелде ул. Битләреннән сыйпый, иреннәреннән үбә. Орнаментның хәлсез сулышын тоеп йөрәге әрни. Абзардан чыгып китә дә, яшел үләннәр йолкып кереп, атына каптырырга тырыша. Тегесе исә теләр-теләмәс кенә, Илбрусның кәефен төшермәс өчен генә ашаган була.

— Икенче көнне Василий Николаевич килеп төште. Эшне озакка сузмас өчен туп-туры кардага юнәлделәр. Жайланмага асып куелган мескен атны күргәч, Беловның күзе чыланды. Орнамент та элеккеге хужасын танып алды, башын аның битенә куйды. «Всё будет хорошо, красавица моя, потерпи чуть-чуть, — диде Василий Николаевич һәм уралган бинтны кисеп төшерде. — Да, Алфит дорогой, аягы сынган икән. Асып куеп дөрес эшләгәнсез. Срочно кызыл балчык табыгыз. Шуны изеп сыларга һәм бәйләп куярга кирәк. Башта

сынган урынны чистартасы, ябагаларын лезвие белән кырасы булыр». Мондый эшләрдән хәбәрдар булган колхоз рәисе яхшы кызыл балчык та, лезвие дә әзерләп куйган иде инде. Авылның иң яхшы чәч алучысы Габдерәхим ага өч литрлы алюмин кәстрүлдә әзерләп куелган сабын күбегенә пумаласын манып алды да атның сынган аягын сак кына майлый башлады. Аргамакның авырткан җиренә ялгыш тиеп киткәндә ат мескен асылынып торган дүрт аягын да селкетеп куйгалады. Ниһаять, чәч алучы җайлап кына ябагаларын кырырга тотынды. Аның кулы шифалы, җинел икәнен авылдашлар белә иде, тик шулай да борчылып, ат түзәрме икән дип күзәттеләр. Габдерәхим ага эшен тәмамлады. Ник бер киселгән, кан чыккан урын булсын. Балчык сылап бәйләүне Белов үзе эшләде. Мал табибы Халиткә барысын да аңлатып барды:

— Бинтны өч-дүрт көн саен алыштырып торасы. Бер айдан атны аягына бастырып карарга була. Башта бераз аксаклап йөрер. Тора-бара үтә ул. Сөяк дөрес ялганмаса, гомергә аксак калырга мөмкин. Ну Орнамент белән андый хәл булмас, дип ышанам. Ә балчыкка килгәндә, ул акрын гына кибә, аякны кыса барып сөякләрне урынына утырта. Шешне дә үзенә суыра, бөтенесе гади генә.

Василий Николаевич китәргә теләсә дә Әлфит аның калуын, бер-ике көн булса да кунак булуын үтенеп сорады. «Ну не удобно, Әлфит сынок», — дип мөгаллим каршы килеп маташты. Ләкин шулай да яраткан укучысы янында бер генә көнгә калырга булды. Икенче көнне чәй табыны артында колхоз җитәкчесе Беловтан сорап куйды:

— Хөрмәтле Василий ага! Сез урыс булсагыз да, атларны яратасыз, аларны яхшы беләсез! Нидә икән моның хикмәте?

— Бабамнан килә бу мавыгу. Ул ат карады. Кызыл балчык белән бик күп атларның гомерен озынайтты. Барысы да — русы, татары, удмурты, башкорты аңа килә иде. «Беренче бөтендөнья сугышында татар кавалериясендә хезмәт иттем, анда күп нәрсәгә өйрәндем, дип әйтә торган иде. Мин үзем дә, слава богу, татарча яхшы аңлыйм. Шуңа күрә минем янда не шухри-мухри. Сезнең телгә, гомумән атларга хөрмәт безнең нәселнең тамырыннандыр инде ул. Без бит 1630 елга хәтле татар байлары булганбыз. Бабам Нурлыҗан мал-мөлкәтен, нәселен хәерчелектән саклап калыр өчен чукынган, шулай итеп, тора-бара урыс булып йөри башлаганбыз. Шуна күрә татар халкына җан тарта. Дөресен генә әйткәндә, кайсы гына рус кешесен алма, күпчелек очракта аның тамырларында данлыклы татар каны ага. Белмиләр генә, беләсергә дә теләмиләр. Мин беләм һәм шуның белән бик горурланам. Менә шулай, татар туганнарым, атларны каян беләсең дисез, менә шуннан беләм дә инде. Диннәребез төрле булса да нәселебез бер безнең. Күп сөйләп ташладым бугай, үпкәләмәгез.

Табында утыручылар кул чапты. «Что вы, что вы, мин бит әллә ни сөйләмәдем», — дип аптырашта калды аксакал. Әлфит аңа каршы:

— Алар татарга булган хөрмәтегезгә кул чаба, — дип әйтеп куйды.

Бер атна да үтмәгәндер, Орнаментның аягындагы шеше бераз кайтты. Ашавы да яхшырды, суырылып калган тәненә ит куна башлады. Тагын бер атнадан җайланманың бауларын бушатып, атны төшереп өч аягына бастыргаладылар, ләкин аргамак сынган аягын, инде рәтләнеп килсә дә, җиргә тидерергә курка иде әле! Өченче атнаның ахырында шеш бетеп, аяк элекке хәленә кайтты, шулай да яна гына ябышкан, әле ныгып җитмәгән сөяккә чапкынны бастыру иртәрәк иде. Белов бит: «Кимендә бер ай вакыт кирәк, — диде. Ат янында күбрәк Хәйрулла бабасы белән Илбрус кайнашты. Халит исә атнага ике килеп аягына балчык сылады, белән Илбрус кайнашты. Тора-бара мал табибын да үз итте Орнамент, һәр атны тәмле теле белән иркәләде. Аның яхшылык кына теләгәнен аңлый иде. Аләм килүендә кешнәп сәламләде. Аның яхшылык кына теләгәнен аңлый иде. Аләм баласына гына түгел, башка җан ияләренә дә җылылык, наз кирәк икән шул.

Илбрус шлангыдан су сиптерә-сиптерә Орнаментны рәхәтләндереп коендырды, юды. Әлфит абыйсы рөхсәт бирсә, иртәгә йөртеп карарга исәпләре. Инде хәзер, Аллага шөкер, жайланмадан астына түшәлгән саламга төшергәч, дүрт аягында да басып тора башлады.

Икенче көнне, чыннан да, Әлфит абыйсы атны азат итәргә рөхсәт бирде. Дүрт ир-ат бауларны чишә дә башладылар. Ниһаять, Орнамент иректә. Ул тоткынлыктан котылу шатлыгыннан кешнәп жибәрде. Ниһаять, айдан артык жайланмада асылынып торган чапкын аягына басты. Бу инде Әлфит, Хәйрулла, Халит, Илбруслар өчен генә түгел, бөтен авыл өчен зур шатлык иде.

Ә инде Гатауллага килгәндә... Ул ай буена кайдадыр качып йөргән-йөргән дә район милициясенә бирелгән. «Нишләтик без аны?» — дип Әлфиткә шалтыраттылар. Председатель барды милициягә. Күрде Гатауллары. Элеккеге ат караучы танымаслык булып үзгәргән иде. Пычрак, сасып беткән киемнәрдән. Үзен сакал-мыек баскан, ябыккан, бөрешеп беткән. Колхоз рәисен күргәч, үксеп елап жибәрде.

— Кичер, Әлфит туган, кичерә алсаң! Мин жинаять өчен күпме бирсәләр дә утырырга риза, — дип шыңшыды ул.

Инде ачуы суына төшкән колхоз рәисе дә аны эченнән генә кызганып куйды.

— Билләһи, бәреп кенә үтерер идем мин сине, әниең Галия апа гына кызганыч, ни рәхәт күрде инде ул синнән?! Ни гаиләң, ни рәтләп башкарган эшең булмады. Жыен әйдә, авылга кайтабыз, колхоз сыерларын көтәрсең.

— Димәк, сез мине утыртмыйсыз, — барсына да әзер булган Гатаулла, башын күтәреп, колхоз рәисенең күзенә карады.

— Сине утыртып, Галия апаны теге дөньяга озатыйммы. Болай да кара кайгыдан бетереште инде ул. Григорий Афанасьевич, алып китәм инде мин аны, — Әлфит өстәл артында утырган милиция майорына эндәште.

— Без проблем, Әлфит Хөрмәтуллович! Аның өстеннән гариза кермәде бит, эш ачылмаган, ихтыярыгыз, — майор урыныннан торып, Әлфиткә кулын сузды.

Милиция бүлегеннән чыккач та колхоз рәисе Гатаулланы туп-туры авылга алып китмәде, район үзәгендәге мунчага алып барды. Көндез юынучылар юк иде. Әлфит Хөрмәтуллович администратор Гарафетдин абыйга үтенеч әйтте: «Шушы сүрәбәткә мунчала-сабын, шампунь, кырынырга да бирәр нәрсә табып бир әле. Адәм рәтенә керсен, әнисе янына кайтасы бар. Акчасын әйләнеп килгәч түләрмен, киемнәрен чүплеккә чыгарып ыргытыгыз инде, зинһар». Гарафетдин абзый: «Хәзер кеше ясыйбыз без бу сукбайдан», — дип ризалыгын бирде.

Әлфит әле яңа гына универмагтан сатып алган өр-яңа күлмәк, кәчтүм-чалбар киеп куйган Гатаулла. Кеше рәвеше керде үзенчә.

— Менә болары әниенә күчтәнәч! Кайларда йөрдең, дип сораса, Казанда заводта эшләдем диярсең инде. Хет гомереңә бер мәртәбә сиңа карап сөенсен әле. Аннан иртәгә үк көтүгә! Житте, кырыкны тутырдың. Күрше авылда доярка Әкълимә бар. Шуны алып кайтабыз. Алла боерса, балалар да табып бирә әле ул сиңа, — диде председатель.

— Ә ул миңа чыгар микән соң, Әлфит Хөрмәтуллович?

— Чыгар! Эчүеңне ташласаң, чиста-пөхтә киенеп йөрсәң, чыгар. Чыкмыйча кая барсын — мин кодаласам.

***

Район житәкчесе Әлфит Хөрмәтуллович, буш вакыты булдымы, үзенең уйларына чумып, үткәннәренә кайтып ала. Сагына гомере буе жиң сызганып колхозны күтәргән әтисе Хөрмәтулланы да, алдынгы механизатор, оста

гармунчы Абрар абзыйсын да, моннан ике ел элек якты дөньядан китеп барган изге күнелле мөгаллиме Василий Николаевичны да сагына ул. Гомере буена атлар караган Хәйрулла бабасы белән мыр-мыр килеп гел картын сүгеп йөрүче Сәрбиҗамал түтине дә бик сагына. Тагын озак еллар шулай әйткәләшә, төрткәләшә яшәсеннәр иде әле. Анын яраткан нәселле чапкыны, Орнаменты да күптән юк инде. Ләкин үзе генә калган чакларында сылу гәүдәле, дүрт ел рәттән район Сабантуйларында беренчелекне тоткан аргамагы күз алдына килә дә баса. Әле ул сонрак та беренчелекне беркемгә дә бирмәс иде. Олыгая барган саен сынган аягына кабат аксый башлады. Аяксыз калдырмас өчен, ярышларга чыгармадылар. Илбрус та үсеп житеп ир булды инде. Хәрби хезмәттән туп-туры туган авылына кайтты. Читтән торып Ижау шәһәрендәге техникумда мал табибы булырга укып йөри. Ни кызганыч, беренче мәхәббәте Жәмилә генә аны көтеп тормады, Казанга укырга китте дә кем беләндер гаилә корып жибәргән. Анын каравы, Илбруска күрше авыл Келәтледә икенче бер сылу, Жәмиләдән дә чибәррәк, дүрт елга яшьрәк Флюрасы табылды. Дөрес булса, көзгә кушылырга икән ниятләре. И, Ходаем, шулай гына була күрсен. Күбрәк калсыннар иде шундый затлы яшьләр, авылда эшләп тапкан малларынын куанычын күреп, матур итеп яшәсеннәр, урамнарыбызда бала-чага тавышы янгырап торсын. Хөкүмәтебез дә игенчегә, төрлекчегә йөз белән борылса, ярдәм итеп торса, вазгыять үзгәрер, Россиядә халык саны артыр һәм илебез көчәер иде... Чыннан да, илнен ныклыгы ин беренче чиратта авылга барып тоташа икән. Авылнын бетүе Рәсәй кебек иксез-чиксез жирләре булган дәүләт өчен һәлакәт ул.

Әлфит «Джип»ын туган авылы ягына борды. Анын бүген Сабантуй узачак урынны карап кайтырга иде исәбе. Шулвакыт каршыга томырылып чапкан бер атны күреп алды ул. «Кемдер Сабантуйга әзерләнә», дип уйлап куйды. Район житәкчесе машинасыннан төшеп, атны һәм жайдакны каршы алды.

— Нихәл, Илбрус, Сабантуйда сынатмаска инде...

— Әлбәттә, Әлфит абый, без жинәргә тиеш. Әнисе Орнаменттан бер жире дә ким түгел. Жинәбез, Алла боерса, — егет аргамакнын битеннән чәбәкләп алды.

— Ышанам. Шәп егет син! Атын да шәп! Чат әнисе инде. Охшаса да охшар икән. Әллә мин дә атланып бер әйләнеп килим микән?.. Яшь чакларны искә төшереп. Хөрмәтулла улы атка якынлашты.

Ләкин юрга кырыйга тайпылды. Пошкырып канәгатьсезлеген белдерде.

— Әлфит абый, сездән ятсына әле ул, бәлкем, кирәкмәс.

— Шулай шул! Ярый, бәласеннән башаяк! Яле, үзен күрсәт әле, әнисе Орнаментка тин микән?

— Хәзер, Әлфит абый, күрсәтәбез без сина, очабыз гына, шулай бит, Орнавил! — Илбрус аты өстенә жинел генә сикереп тә менде.

Орнавил кешнәп ике арт аягына күтәрелде. Аннары алга ыргылды. Әлфит абыйлары сокланып, сөлек кебек сузыла-тартыла чапкан атка кызыгып карап калды. Нинди хозурлык, әй! Туган якнын кабатланмас яме бит алар — житез аргамаклар. Айлар, еллар, гасырлар аша чабалар да чабалар. Ул атларны күргәч, рух күтәрелә, ышаныч арта, тагын да матуррак итеп яшисе килә. Тугай-болыннарда юргаларнын кешнәве мәнге тынмасын! Аяк эзләре суынмасын иде.

# ИЖАУ — ИҖАТ МӘЙДАНЫ

1991елда Ижауда «Яңарыш» газетасы чыга башлагач, әдәби иҗат белән шөгыльләнүчеләргә зур мөмкинлекләр туды. Удмуртиядә һәм Әгерҗе районында яшәп иҗат итүче шагыйрьләр, прозаиклар анда үз әсәрләрен бастырып, каләмнәрен чарлады. «Әдәби сәхифә», «Ижау — иҗат мәйданы» битләре, һичшиксез, халыкка кирәклеге, якынлыгы ягыннан да әһәмиятле булгандыр. Инде, 1997 елда, җирле авторларыбызның 350 биттән торган «Язмышлар авазы» дигән беренче шигырьләр җыентыгы басылып чыгу күпләрне зур иҗат мәйданына тартты. Удмуртия җиреннән иң беренче булып Риза ага Шәфи Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алынды. Газета каршында әдәби түгәрәк оешты, җитәкчесе Ибраһим Биектаулы иде. Соңгы 11 елда «Яңарыш»та каләм чарлаган 23 авторның 45 китабы Казан, Ижау, Чаллыда дөнья күрде.

Татарстан һәм Удмуртия Язучылар берлекләре арасында төзелгән килешүнең (аңа 2005 елның 16 декабрендә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов һәм Удмуртия Язучылар берлеге рәисе Егор Загребин кул куйдылар) нәтиҗәсе буларак — Удмуртия төбәгендә яшәп иҗат итүче биш язучыбыз Татарстан һәм Удмуртия Язучылар берлекләренә әгъза итеп алынды. Удмуртия Язучылар берлеге каршында Риза Шәфи исемендәге татар язучылары бүлеге оешты. Казан, Әлмәт, Чаллы Язучылар оешмалары белән элемтәләребез ныгыды. «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга» газеталары, «Казан утлары», «Мәйдан», Удмуртиядәге «Луч», «Кизили» журналларында авторларыбызның шигырьләре, хикәяләре, публицистик язмалары еш басылу аларга иҗат дәрте өстәде. «Яңарыш» газетасының «Әдәби сәхифә», «Ижау — иҗат мәйданы» битләрендә классик татар язучылары, бүгенге көндә иҗат итүче авторларның әсәрләре даими басыла. Шулай ук удмурт, рус язучыларының хикәяләрен, шигырьләрен татар теленә тәрҗемә итеп, газета битләрендә чыгару традициягә әверелде. Язучыларыбыз Гыйлман Сафин, Ибраһим Биектаулы, Гөлфия Исхакова тәрҗемә өлкәсендә уңышлы эшлиләр. Удмурт язучылары Егор Загребин, Вячеслав Ар-Серги, Өлфәт Бәдретдинов, Алексей Елцов, Ада Диева һ.б. авторларның әсәрләрен укучылар яратып кабул итәләр. Воткинск каласында Риза ага Шәфи һәм Удмуртиянең Пирогово авылында Биктимер Гәрәев яшәгән йортларга мемориаль такта куелды. Шулай ук Риза Шәфи исемендәге премия булдыру да зур әһәмияткә ия.

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең Удмуртия төбәгендә иҗат итүче авторларга игътибары артуы, Татарстан Конституциясенең 14нче маддәсе, нигезендә, читтә яшәүче милләттәшләребезгә ярдәм итүен тою безгә иҗади көч өсти. Казан, Әлмәт, Чаллы язучыларының Удмуртиядә үткәрелә торган чараларда катнашулары, мәктәпләрдә һәм районнарда халык белән очрашулары традициягә әверелде, онытылмаслык хатирәләр калдырды. Татарстан Язучылар берлеге тарафыннан эзтабар язучы, шагыйрь Шаһинур Мостафинның

Удмуртия төбәгендәге иҗат эшләренә күзәтүче, ярдәмче булып билгеләнүе безнең иҗатчыларга терәк булды. Ул язучыларыбызны, шагыйрьләребезне якыннан белә, әсәрләре белән танышып, аларны китап итеп яки газета-журнал битләрендә бастырып чыгарырга булыша.

Иҗат итүчеләр арта бара. Гүзәл Исхакова, Кәүсәрия Нуруллина, Асия Корбангалиеваларның иҗатларына әдәби берләшмә утырышында уңай бәя бирелде. Проза өлкәсендә Гөлфия Исхакова, Зөһрә Вәли, Наилә Харисова, Дилфәр Хәсәнов, Гыйлмран Сафин, Шиһабетдин Садыйков, Әлфирә Низамова, Гөлфидә Мәрдәнова актив иҗат итә.

Барысы да ал да гөл генә түгел, билгеле, хәл итәсе проблемалар бихисап. Иҗат мәйданына яшьләрнең аз килүе борчуга сала. Сер түгел, 60-70нче еллар Ижауда «Ижмаш», «Ижсталь» кебек заводларның шаулаган чоры булды. Татарстан һәм Башкортстаннан күп гаиләләр Ижауга күчеп килде. Шулай ук ул елларда югары уку йортларын тәмамлаган яшьләрне башка төбәкләргә эшкә җибәрү гамәлдә иде. Мәсәлән, мөхтәрәм шагыйрьләребез Ибраһим Биектаулы, Гыйлмран Сафин Казан Авиация институтын тәмамлаганнан соң, 1970 елда Ижау «Радиозавод»ына килеп, аннан иҗат эшенә актив кушылды. Шагыйрә Гөлфия Исхакова да Татарстанның Лениногорски районыннан Воткинск каласындагы машиналар төзү заводына эшкә билгеләнә. Хәзер алар — Татарстан, Удмуртия Язучылар, Россия Журналистлар берлекләре әгъзалары.

Хәзер исә хәлләр башкачарак — яна агым тукталды, диярлек. Ижауга күчеп килүчеләр бик аз. Димәк, язучыларны, журналистларны үзебезнең төбәктәге яшьләр арасыннан табарга һәм үстерергә тиеш булабыз. Шул максаттан җирле язучылар, «Яңарыш» редакциясе хезмәткәрләре Удмуртиянең татар сыйныфлары булган мәктәпләрендә очрашулар үткәрәләр. Шигырьләре, хикәяләре, әкиятләре «Яңарыш»та басылган талантлы балалар белән редакциядә түгәрәк өстәл артында утырып, иҗат итү серләренә өйрәтәләр. Шигырь һәм берникадәр әкият жанрында эш бара кебек. Бу урында, шагыйрь Ибраһим Биектаулы, «Яңарыш»ның «Алтын йомгак» битен алып баручы Рилия Закирова, Ижау татар гимназиясенең татар теле укытучысы Рәзинә Гафурова нәтиҗәле эшли.

Шуны да өстәп әйтим: яшь буенча без инде өлкән. Бүгенге көндә язучыларыбызның уртача яше 60тан артып китә. Бу исә, яшьләр белән эшләмәсәк, яшь талантларны барламасак, шактый аяныч хәлдә калуыбыз хакында сөйли. Иҗат берлегебезне саклап калыйк, яшәтик дисәк, безгә бу хакта бүгеннән ныклап уйларга кирәк.

**Ринат БАТТАЛОВ,**
*Удмуртия Язучылар берлегенең*
*татар язучылары бүлеге җитәкчесе*



# Ибраһим Биектаулы

## Мөселманнар

Жиргә Иман гүзәллеге инсен өчен,
мәҗүсилек-наданлыкка чик куярга
Аллаһ бирде үз әмерен Рәсүленә –
ышанычлы сөйгән колы Мөхәммәдкә...

Шул көннәрдән мөселманнар күнеленә
саф нур чәчә гарәп иле, шәһри Мәккә...
Бу изге җир лаек чиксез мәхәббәткә –
адәмнәргә юл яктырта киләчәккә.

Мөселманнар — сабыр халык, фида җаннар –
Матурлыкны, Тынычлыкны яхшы аңлар!
Кем акыллы — үткер күздән дөнья багар –
Мөселманда ышанычлы дусны табар!

Ир гомере — ел гомере — фасылларда.
Коръән сүзе — Аллаһ сүзе — гасырларда...

## Безнең язмыш

Ходай безгә шундый язмыш биргән –
Теләмичә риза булырга:
Илне ташлап Жиргә таралырга,
Баскыннарга фида булырга...

Ходай безгә куәт-гайрәт өргән:
Көрәшләрдә исем акларга,
Кавеменнән сеңгән иманыңны
Жаның-тәнең белән сакларга!

Максатыбыз түрдә — якты, изге:
Тарихлардан сабак алырга,
Киләчәккә яңа юл салырга –
Бөек халык булып калырга!

Ибраһим БИЕКТАУЛЫ (1937) – *шагыйрь; «Бәйрәм белән», «Җирдән җиде җиһанга», «Галәм серләре» һ.б. китаплар авторы. Ижау шәһәрендә яши.*



Гыймран
Сафин

# ФРОНТОВИКЛАР

ЦИКЛ

## 1. Кайту

*Удмуртиянең Сарапул шәһәреннән сугышка китеп, хәбәрсез югалган солдатны эзтабарлар исеме һәм адресы чокып язылган алюминий кашык ярдәмендә табып, 2014 елда исәлеген туган шәһәренә кайтаралар.*

Күпме алар кайтмый калганнар,
Хәбәрсез-эзсез югалганнар?
Жиде кат күктәдер жаннары,
Табылмаган медальоннары.

Нинди гөнаһ өчен бу жәза?
Ә кайчак була бит могжиза!
Ияреп алсу таңның жиленә,
Соңгы хәбәр кайта иленә.

Кемдер жиде ят жирлегендә,
Кем туганнар каберлегендә.
Мәңгелеккә ятып калганнар,
Шунда соңгы сулыш алганнар.

Жиңүгә күпме ел үтсә дә,
Язмыш йомгакларын сүтсә дә,
Күпләрнең әле кайтасы бар,
Хәтерләрне уятасы бар.

## 2. «Герман бүләге»

*Әтиләре сугыштан кайтканнан соң туган балалар турында авыл кешеләре «Герман бүләкләре» дип шаяртып сөйлиләр иде.*

Ике йөзне авыл озаткан,
Тик алтмышы әйләнеп кайткан.
Кемдер кулсыз, кемдер аяксыз,
Адым атлый алмый таяксыз.

Гыймран САФИН (1943) – *шагыйрь; «Язлар кәтә күңел», «Гомер бер генә», «Туган җиргә мәдхия» исемле китаплар авторы. Ижау шәһәрендә яши.*

Сугыш кырын үткән солдатлар,
Тыныч кырда куркып калмаслар.
Иген үстереп тир түгә ир,
Мул уңышын бирә туган жир.

Аз-маз шатлык килә һәр өйгә,
Тамак туя башлый ипигә.
Ай артыннан айлар агалар,
Авылларда туа балалар.

Кан-үлемнән туйган әтиләр
Чиксез шатлык хисен татыйлар.
Сабыйларда яшәү теләге —
Атамалар — «Герман бүләге».

Жиңүчеләр! Сезгә сүнмәс дан!
Күпләр инде китте дөньядан.
Сез шаяртып көлгән малайлар
Үзләре дә инде бабайлар.

## 3. Пленда булган

*Пленда булып, сугыштан орден-медальләрсез кайткан авылдашым Хәким абый бакыйлыкка киткәнче плен газапларын һәм аннан соң булган ГУЛАГ газапларын искә алып, гомере буе кимсенеп яшәде.*

Жиңү таңы һәркем өчен дә
Якты нурлы булып атмаган.
Плен газабында булганнарның
Күген кара болыт каплаган.

ГУЛАГ тоткынлыгы, мең газаплар...
Авылга кайткач та акланып,
Гөнаһсыз гаепләнүдән куркып,
Һәр адымын атлый сакланып.

НКВД чакыра. Допрослар
Күңелендә калган уелып.
Тавыш чыкса... «Син пленда булган...»
Искәрмәстән төшә коелып.

Сталин үлгәч, сулыш жиңеләя,
Башка газапламый «органнар».
Тик күңелен кимсенүләр борчый,
Алар жиңеләйми торганнар.

Хезмәт белән хөрмәт яулап ала,
Авылдашлар аңлыйлар кебек.
Жиңү көне, күкрәктә орден юк...
Һәркем аңа карыйдыр кебек.



## Ринат Баттал

# Әй авылым

*Әй авыл, син мең шәһәрдән*
*Мең кабат ямьле вә хуш.*

С.Рәмиев

Әй авылым, матур мең шәһәрдән,
Бай илләрдән син бит бай идең.
Туган телнең моңлы бер бишеге,
Күк йөзендә якты ай идең.

Әдәпле дә идең, ярдәмле дә...
Кешеләрең — эштән сынмый торган.
Синдә минем тәүге мәхәббәтем,
Синдә минем тәүге шигырь туган.

Төшләремдә әл дә йөгереп үтәм
Ялан тәпи болын чыкларыннан.
Моң тарала авыл өсләренә
Таллыктагы чалгы чыңнарыннан.

Болгавырлы каһәр еллар иде,
Салкын иде көннәр себердән дә.
Үксеп үптем әткәм кабере ташын,
Туган жирдән читкә сөрелгәндә.

Офыкларга карап чыгып киттем,
Ач-ялангач хәлдә аргамагым.
«Су астында кал», — дип, ялгышып та,
Авылкаем, сине каргамадым.

Илле еллар читтә интексәм дә,
Каргамадым тирән Иж суларын.
Ямансулап, авыру күкрәгемә,
Чит һаваны иртән мин суладым.

Ринат БАТТАЛ (1948) – *шагыйрь;«Гомер сагышларым», «Агымсуда – акчарлак», «Гомер учагы» һ.б. китаплар авторы. Ижау шәһәрендә яши.*

Әй авылым, изге милегемә
Күз яшьләрем кабат таммас инде.
Җырларымда күпме җырласам да,
Яшьлегемә кайтып булмас инде.

«Авылым!» — дип, җиргә иңәрмен мин
Иж сулары иңле, тын чагында.
Баш очымда елга шаулап торыр
Ятканда да җирнең кочагында.

## Чалгы чыңы

Соры-кучкыл борчак кыры,
Ара-тирә — алабута.
Алабута ышыгында
Шыр-ялангач бала ята.

Кара икмәк кыерчыгы
Бөре кебек кулларында.
Ә әнкәсе борчак чаба, —
Пакус тезә юлларында.

Ана туктап дога укый,
Бала астын алыштыра.
Һәр икесен сискәндереп,
Чалгы чыңы — сагыш тора.

Кызу җилләр хөкеменә
Алар ничек түзде икән?
Ни гаҗәп бу, шушы бала —
Еллар аша үзем икән.

Еллар узган... Борчак кырын
Ажаганнар теле ялый.
Урылган кыр кырыенда
Тал куптара теге малай.

Тал суыннан саргайган кул,
Исем китеп карап торам.
Бәгырькәе өзелгән чак —
Ник дип әле сорап торам?

Әткәсенең баш очында
Мәдхияләр тезгәндер ул.
Орчык кадәр монсу малай
Телен тешләп түзгәндер ул.

Зур югалту, кайгыга да
Түзә малай, ул бит — Кеше!
Әнкәсенең догасына
Үтә алмый кайгы теше.

Эшли малай, үрсәләнә,
Яшен ташы — түзем икән.
Ни гаҗәп бу, шушы түзем —
Еллар аша үзем икән.

Иннәренә корал элеп,
Чит илләрдә йөри егет.
Тозлы яше тама җиргә,
Ятимнәрнең йөзен күреп.

Ярдәм сорап кычкырса да,
Язмыш тарта кулларыннан.
Чәч агара, тәне сула
Локаторның нурларыннан.

Сакта тора, җаны утта
Өзгәләнә телеп-телеп.
Көзге гөлдәй калды кибеп
Төз гәүдәле сөлек егет.

Ак морҗадай йөзен күреп,
Кызганмыймын: «Әй, дим, егет!
Борчак кырын, авылыңны
Су баскан бит, диңгез кебек».

Тыелмадым: нигә өздем
Сабыр гөлен, җанын, телен?!
Икмәк белән бердәй күргән
Өмет хисен — соңгы телем?

«Сабыр төбе — сары алтын» —
Сыналганнар сүзе икән.
Ни гаҗәп бу, шушы сабыр —
Еллар аша үзем икән.

Әй чайкала тормыш-дәрья,
Ярларына суга-суга.
Дулкыннарда без йөзәбез,
Гомер һаман чаба-ага.

Дулкыннарга карап багам
Гомеремнең күзләрендә.
Бер Ходайдан сабыр сорыйм,
Тезләремә тезләнәм дә.

Илгә рәнжеп, күнеп яшәү —
Җирдә гонаһ кылганнарга.
Ай-һай, авыр сынау икән —
Эчендә җан булганнарга.

Гомер — дулкын, шаша кубып,
Ярларына аша тулып.
Заман — упкын, ә колакта
Чалгы чыңы һаман шул ук.

Теге малай еллар аша
Сөрән сала миңа көн дә:
«Туган илең «Улым», диеп
Эндәшәме син ятимгә?»

Тешем кысып түзсәм түзәм,
Читкә чәчмим зарларымны.
Мин бит сөям саф йөрәктән
Мең ел түзгән Татарымны!

Җавап эзлим: үткәнемә
Каш җыермыйм — бу иң чыны.
Тик колакта һаман да шул —
Үзәк өзгеч чалгы чыңы.

Янар кояш! Еллар гына
Күз нурларын алып китә.
Дуслар китә... Кем чираты?
Күке-сәгать «келт-келт» итә,
Гүя әйтә: вакыт үтә...
Вакыт үтә... вакыт үтә...

### Әйтмә син

Кисмә җанны: «Хисчән!» — диеп,
Ил үгие — хиследер мин.
Гамьсезләрне җиңәр өчен
Хисем белән көчледер мин.

Әйтмә миңа: «Йомшак!» — диеп,
Ташка үскән гөлҗимеш мин.
Чәнчеп алса, кем юатыр,
Кышын өзсәң гөлҗимешен.

Әйтмә миңа: «Мескен!» — диеп,
Төшсәм шундый дәрәҗәгә,
Бәгырькәең көяр, бәгърем,
Күрсәң сыным тәрәзәдән.

Әйт мең кабат: «Хисчән!» — диеп,
Чыдыйм инде бер чыдагач!
Әйттең бүген: «Сөям!» — диеп,
Елыйм инде бер елагач.



# Әлфирә Низамова

## Шөкер ит

«Мин бәхетсез», — дия күрмә берүк,
Үпкәләмә, зинһар, тормышка.
Бу дөньяга тууларың белән
Рәхмәтле бул тормыш-язмышка.

Алсуланып һәр көн таң атканын
Бисмиллалап каршы алсаң син,
Кызарып кына кояш баеганын
Дога белән озатып калсаң син...

«Мин бәхетсез», — дия күрмә берүк,
Әйтә күрмә, Ходай ишетер.
Уйлан бераз кулсыз-аяксызга,
Сукырларга дөнья ничектер?!

«Мин бәхетсез», — диеп кабатлама,
Булганына шөкер ит әле...
Ин бәхетле кеше сыман көлеп,
Урамнардан балкып үт әле...

## Солдат аналарына

«Кайгы кайгыга охшамый,
Һәр кешенеке үзгә,
Шатлыклар да төрле була», —
Дисәләр әгәр сезгә.
Ышанмагыз, бер үк хисләр
Беләмсез, кемгә таныш?
Озату, көтү, юксыну,
Сагыну, ачы сагыш...
Кайнар ашың өлгергәндә,
Йөрәктән каннар таму,

Һәрбер сүзен назга төреп,
Кичләрен хатлар язу,
Хәбәр көтү, төшләр күреп,
Аны юрап юану,
Газизенә гомер теләп,
Төннәр буе уйлану...
Беләсезме кемнәргә хас? —
Солдат аналарына.
Сабырлык телик аларга,
Саулык — балаларына.

Әлфирә НИЗАМОВА – *шагыйрә; «Язмышым канатында», «Кояш исе», «Һәр бәйрәмнең үз гаме» исемле китаплар авторы. Әгерҗе районында яши.*

## Гөлфия Исхакова



### Шахталарга киткәннәргә

Сагынадыр киткәннәр.
Шахтада бил бөккәннәр,
Тарта язмыш нужасын –
Тормыш атын җиккәннәр.

Сулыш алу авырдыр,
Җанында гел давылдыр.
Яттыр читләр иләндә,
Балта бардыр биләндә.

Йөзендәдер алсулык,
Канындадыр ярсулык.
Төкермәс ул чит барда,
Авызы торса кан тулып.

Татар булыр исеме,
Көч, куәтле җисеме.
Кайтыр юлы Казандыр,
Ишетер моңы Азандыр.

### Язмыш

Аз төйдеме безнең башны
Язмыш дигән бу тормыш?
Куккә чөйде, ярдан атты,
Юлда текә борылыш.

Аз суктымы кул-аякка
Язмыш атлы бу еллар?
Тоташ сынау, җәбер, җәза,
Түзмәс, диептер, — елар!

Салкын җилләр үзәкләргә
Тиде дә өтеп алды.
Маяк булган өмет сүнде,
Үкенеч кенә калды.

Сыпырып төшерсәң чәчтән
И бу ап-ак карларны!..
Язып кәгазьгә калдырам
Җанга сыймас зарларны.

Сагышым салам шигырьгә,
Бушасын, тынсын күнел.
Гомер гел бәхеттә узмый,
Хыялда очу җинел.

Гөлфия ИСХАКОВА – *шагыйрә; «Язларыма кайтам», «Ак моң алып каеннардан», «Сукыр мәхәббәт» исемле китаплар авторы. Воткинск шәһәрендә яши.*



*«Татарстан яшьләре» газетасы редакциясенә Камал театрының зур кунаклары – СССРның халык артистлары килгән. Беренче рәттә (уңнан сулга): артистлар Габдулла Шамуков, Фуад Халитов, Шәүкәт Биктимеров; журналист һәм язучылардан – Рина Зарипова, Ислам Әхмәтҗанов (баш редактор); икенче рәттә: Фирдәүсә Гафиатуллина, Госман Гомәр, Харрас Әюпов, Рәшит Әхмәтҗанов, Илдус Сафин, Нәбирә Гыйматдинова, Рәфикъ Юныс, Барлас Камалов, Рашат Низамиев, Светлана Привина. 1983 ел.*



*Дөньякүләм билгеле галим-химик Вил Мирзаянов һәм галим-филолог Хатыйп Миңнегулов. Истанбул. 2005 ел.*



*Язучы Җамит Рәхимов (1935-1996). «Батырша» романы авторы.*



*Шагыйрь Хәниф Хөснуллин. (1935-1994).*

# ХАЛКЫБЫЗ ГОРУРЛЫГЫ



*Илһам Шакиров сәхнәдәш дусты — баянчы Рөстәм Вәлиев белән*

Татар халкының бөек җырчысы, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Илһам Шакировны еш кына «халкыбыз илһамы» дип йөртәләр. Әйе, исеме җисеменә туры килә шул, аны лаеклы рәвештә «халкыбыз Илһамы» дип атап була. Татарлар гына түгел, ә тугандаш төрек, башкорт, казакъ, үзбәк, кыргыз, төркмән, әзәрбайҗан һәм башка бик күп төрки халыклар, шулай ук музыкаларының нигезе пентатоникага корылган Кытай, Корея, Япон һәм Азиядәге башка төрки булмаган халыклар да аны «халкыбыз илһамы» дип әйтә алырлар иде. Якын күршеләребез славян, фин-угыр, ерак күршеләребез булган Европа, Америка, Азия, Африка, Австралия кыйтгаларында да Илһам Шакиров җырын яратып тыңлаучылар күп. Әйтик, узган гасырның илленче елларында Илһам Шакировның Чехословакия башкаласы Прагада үткәрелгән халыкара музыка бәйрәмендә татар халкының бөек җыры «Кара урман»ны акапеллада башкаруын тыңлаучылар бу җырны һәм аның башкарылуын бөтендөнья күләмендәге музыкаль казаныш дип бәялиләр.

1974 елда дөньяның бөек музыканты Мстислав Ростропович беркемгә дә әйтмичә генә Илһам Шакировның бөтен Мәскәү музыка сөючеләрен аякка бастырган концертына килә. Анда Илһамның «Кара урман»ны башкаруын тыңлый һәм шакката. Концерт беткәч, ул сәхнә артына керә һәм Илһамның «Кара урман»ны башкаруына соклануын: «Ты убил меня этой песней», – дип белдерә. Бөек музыкант бөек татар җырчысы белән икәү төшкән фотога автограф язып бирә. Бу фото Илһам Шакиров архивында бүген дә кадерләп саклана.

Атаклы дирижёр, озак еллар Татарстан дәүләт симфоник оркестрын җитәкләгән Натан Рахлин да Илһам Шакировка хөрмәт йөзеннән автографлы фотосын бүләк итә. Анда: «Любимому Ильгаму — от Натана», – дип язылган. Бу — талантлы музыкантның талантлы җырчыга мөнәсәбәтен ачык күрсәтә.

Илһам Шакиров иҗатына уңай мөнәсәбәт белдерүчеләр арасында күренекле дәүләт эшлеклеләре, музыкантлар, җырчылар, галимнәр, язучылар, гади музыка сөючеләр күп. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, беренче президентыбыз Минтимер Шәймиев, Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, күренекле язучыларыбыздан Нәкый Исәнбәт, Хәсән Туфан, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Салих Баттал, Сибгат Хәким, Башкортстанның күренекле язучылары Мостай Кәрим һәм Нәҗәр Нәҗми, татар нәселеннән булган рус язучысы Михаил Львов, күренекле татар режиссёры Марсель Сәлимҗанов, галимнәр Мансур Хәсәнов һәм Миркасыйм Госманов, драматург Туфан Миңнуллин, дистәләгән шагыйрьләребез Илһам Шакиров иҗаты турында матбугатта язып чыктылар.

Сүз дә юк, Илһам Шакировның татар музыка тормышындагы феномены безнең бөтен сәнгать төрләребезнең дә иң югары бәягә лаек икәнен раслаучы бер күренеш ул. Бүген гомумсәнгатебез турында сүз алып барганда без: «Шигърияттә – Тукай,

музыкада — Сәйдәш, сынлы сәнгатьтә — Урманче, сәхнәләрдә — Илһам», — дип әйтергә яратабыз. Бу билгеләмә бүген генә туган күренеш түгел. Әле узган гасырның утызынчы елларында ук күренекле татар язучысы, сәнгатебезнең төрле төрләре белән тирәннән кызыксынган Гадел Кутуй Салих Сәйдәшев иҗатына багышланган бер мәкаләсендә, татар шигъриятен билгеләүче — Тукай, музыкасын билгеләүче — Сәйдәш, дигән фикер әйткән иде. Илленче елларда сәнгать белгечләре бу билгеләмәне үстереп «шигъриятта — Тукай, музыкада — Сәйдәш, сынлы сәнгатьтә — Урманче» дип яздылар. Алтмышынчы елларда җырчы артистларыбыз турында даими рәвештә мәкаләләр язып торган күренекле шагыйребез Сибгат Хәким бу билгеләмәгә Илһам Шакиров исемен дә өстәде. Шулай итеп, бүгенге көндә канатлы сүзгә әверелгән «Шигърияттә — Тукай, музыкада — Сәйдәш, сынлы сәнгатьтә — Урманче, сәхнәләрдә — Илһам» дигән гыйбарә барлыкка килде. Бу билгеләмә чын мәгънәсендә егерменче гасыр татар сәнгатенең төрле төрләре үсешен, аның ныклы нигезен билгели.

Үзенең бөтен иҗаты, табигать биргән гаять үзенчәлекле, моңлы, бик тә милли, үтемле, җанга якын тавышы белән бергә Илһам Шакиров халкыбызның бөек һәм катлаулы тарихы, бу өлкәдәге фәнни эзләнүләр белән кызыксынучы, сәнгатебезнең һәр тармагы — әдәбияты, театры, сынлы сәнгате, архитектурасы, классик музыкасы белән һәрдаим кызыксынучы, ул гына да түгел, шушы өлкәләрне һәм гамәли, һәм фәнни яктан яхшы белүче иҗтимагый шәхес тә. Ә бит җыр сәнгате, сәхнә әһеле булу ягыннан бик талантлы, ләкин туган халкыбыз тарихы белән аз кызыксынучы яхшы, ярәткан артистларыбыз да юк түгел. Алардан аермалы буларак, Илһам Шакиров туган халкыбыз тормышының, рухының борынгыдан килгән чын милли үзенчәлекләрен тирән белгән, алар турында теләсә нинди әңгәмәгә, бәхәскә фәнни төгәллек белән катнаша ала торган сәнгать эшлеклебез. Аның бу үзенчәлеген инде узган гасырның алтмышынчы елларында, ягъни моннан 40 еллар элек ук тотып алган, ул чактагы яшь археолог, тарихчы, соңыннан Татарстанның атаклы галиме Равил Фәхретдинов 1973 елда Илһам Шакировның тәрҗемәи хәле һәм иҗаты турында «Җырчы» дигән китап бастырып чыгарды. Бу — Илһам Шакиров турындагы беренче китап иде. Шул ук вакытта галим Равил Фәхретдиновның да дөнья күргән беренче китабы иде. Бу китап һәм анда әйтелгән фикерләр бүген дә актуальлекләрен югалтмаганнар. Әлбәттә, яшь галимнең яшьләрчә дәртле китабы 30 яшьлек җырчы исеменең дөньяга тагын да киңрәк таралуына шактый зур этәргеч булгандыр.

Илһам Шакиров... Без, җыр, музыка сөючеләр, бөек җырчы Илһам Шакиров исемен, аның җыр-моңнарын никадәр генә яхшы белсәк тә, ана чиксез соклансак та, күбебез әле аның нәсел-нәсәбе, тарихи әби-бабалары турында аз беләбез. Менә, беренчедән, Совет чорында аерым шәхесләрнең революциягә кадәрге булган нәсел-нәсәпләре, туган-тумачалары, аларның тормышлары белән кызыксынуга игътибарсызлык, ул гына да түгел, аны өнәмәү хакимлек итсә, икенчедән үзебезнең шәхси тарихыбызны оныта баруыбыз сәбәпче. Ә бит безнең тирән тарихка нигезләнгән иҗтимагый гореф-гадәтебез буенча һәр кеше үзенең җиде бабасына кадәр булган нәсел-нәсәбен белергә тиеш. Большевиклар хакимияткә килгәнче татар халкы арасында шәҗәрәләр төзү, нәсел агачын булдыру һәр кешенең изге бурычы булып саналган. Аллага шөкер, соңгы елларда күп кенә зыялы гаиләләрдә шәҗәрәчелек, ерак нәсел-нәсәпләр тормышын өйрәнү хәрәкәте янадан яңарып килә. Әйтик, Татарстан хакимиятендә эшләүчеләрнең һәрберсе диярлек үз шәҗәрәләрен, нәсел агачларын булдырдылар.

2005 елда, Илһам Шакировка 70 яшь тулган елны Татарстан Республикасының Татар телен һәм мәдәниятен саклау һәм үстерү фонды «Җыен» тарафыннан бөек җырчыга багышлап чыгарылган китапта Илһам Шакировның шәҗәрәсен һәм нәсел агачын төзеп нәшер итүне максат итеп куйды. Бу эш күренекле язучы, бөек шәхесләребезнең борынгы нәсел-нәсәпләрен архивлардан эзләп табып тәртипкә салучы галим Дамир Гарифуллинга йөкләнде.

Хәзер инде без бөек җырчыбызның нәсел-нәсәбе турында билгеле бер күләмдә мәгълүматка иябез. Дамир Гарифуллин Илһам Шакировның атасы ягыннан сигез буын бабаларын ачыклый: Илһамның әтисе Гыйльметдиннең әтисе Габделнасыйр. Аның әтисе Габделхалыйк. Д.Гарифуллин тарафыннан Теләнче Тамак авылында табылган ике китап эченнән чыккан кәгазьләрдә Илһам Шакировның бу бабаларының балалары,



*Илһам Шакировның шәҗәрәсе*

оныклары һәм оныкларының балалары турында мәгълүматлар бар. Аларның барысы 80 кешегә җыела. Ә Илһамның дүртенче, бишенче, алтынчы, җиденче, сигезенче буын бабаларының (Габделгазиз бине Габдулла бине Ишкилде бине Үтәгән бине Алпар) бала-чагалары турында мәгълүмат юк.

Шулай итеп, Илһам Шакировның бүгенгә билгеле булган иң ерак сигезенче бабасы Алпар була. Татар тарихында, аның топографиясендә һәм кеше исемнәре арасында киң билгеле булган бу исемнең килеп чыгышы турында тарихи белешмә табылса бик кызык булыр иде. Әмма бу мәсьәлә киләчәккә кала бирә.

Инде Илһам Шакировның әти-әнисе һәм үзенең тормышларына, тәрҗемәи хәлләренә күз салсак, монда да бик гыйбрәтле хәлләр күрербез.

Илһам үзе Сарман районының Яңа Бүләк авылында туып-үсә (хәзер бу авыл Тукай районына керә). Аның әтисе Совет чорында гына төзелгән бу авылга гаиләсе белән күрше Таулык авылыннан күченеп килә һәм шунда төпләнеп кала. Аңлашыла ки, бу вакытта Илһам әле тумаган була.

Оста тимерче буларак Гыйльметдин абзый Яңа Бүләк һәм күрше авыллардан килеп тимер чүкетүче авыл кешеләре белән якыннан аралаша, алар белән тормыш хәлләре турында гәп кора. Авыл кешеләре арасында да төрлеләре бар бит, утызынчы елларда, шәхес культы котырган чакларда, кемдер аның теле озын дип КГБга шикаять яза. 1937 елның 8 октябрендә Гыйльметдин агайны кулга алалар. Бу вакытта әле Илһамга ике яшь ярым чамасы гына була, һәм ул, әлбәттә, әтисен хәтерләп бетерми.



*Бөек җырчыны дөньяга тудырган әнисе – Нуриәсма*

Гыйльметдин агай 1940 елның 4 мартында 5 нче хезмәт белән төзәтү колониясендә ачлыктан һәм авырудан җәфаланып җан бирә.

Гаиләдәге алты баланы тәрбияләп үстерү Илһамның әнисе Нуриәсма өстенә төшә. Ул чактагы газапларны Илһам еш искә ала. Булачак җырчы авылдан-авылга хәер сорашып та йөри, үзе һәм абыйсы үргән чабата сатып та аз-маз тамак туйдыралар. Ул чакта авылдан-авылга соранып йөргән хәерчеләрнең күп булуы аркасында Илһам кебек бәләкәй генә малайга хәерне бик күп тамызмыйлар. «Җырлый белүемнең файдасын мин шул чакларда ук күрдем — хәерчелектә йөргәндә моңлы итеп җырлап җибәрсәм, мине кызганып каткан ипи сыныкларын һәм чикмәнле пешкән бәрәңгене башка хәерчеләргә караганда күбрәк бирәләр иде», — дип хәтерли ул. Болар — атаклы Илһам Шакировның беренче гонорарлары була.

Шушы интегүләр, хәерчелек белән Бөек Ватан сугышы да үтеп китә. Тумыштан башлаегы белән җырга гашыйк Илһам Шакиров күрше Teләнче Тамак мәктәбендә урта белем ала. Укыганда көн саен булмаса да, атнага берничә мәртәбә туганнарын, туган йортын сагынып Яңа Бүләккә кайта. Юлда һәрвакыт япа-ялгызы бар тавышына җырлап йөри ул. Яңа Бүләк һәм Теләнче Тамак урманнары, чәчәкле болыннары, иген кырлары әле бүген дә яшүсмер Илһамның моңлы тавышын саклыйлардыр, сагыналардыр кебек.

Теләнче Тамакта урта белем алган һәм педагогия институтына укырга барып та, анда җан азыгы тапмаган, бөтен җаны-тәне белән җыр дөньясын гына яраткан Илһам Шакиров 1954 елны Казанга, музыка училищесына юл ала. Ул Казанга китүен беркемгә дә әйтмичә авылыннан качып диярлек чыгып китә. Моңа кадәр инде ул Теләнче Тамак мәктәбе үзешчән түгәрәгендә катнашып, тирә-як авыл сәхнәләрендә, туйларда беренче чирканчык ала, җыры белән авыл кешеләрен шаккатыра.

Училищеның беренче курсында ук Илһам Шакировны Татарстан радиосына чакырып эфирдан җырлата башлыйлар. Озак та үтми, радиокомитетка радиотыңла-

учыларның йөзәрләгән хатлары ява. Аларның барысы да радиодан тагын-тагын-тагын Илһам Шакировны җырлатуларын сорыйлар.

Әмма җыр сөючеләрнең әнә шулай яратулары яшь егет өчен бик күңелле булса да, ул чорда көндәлек тормыш алып бару, киемсалым бөтәйтү, тамак туйдыру бик җиңел булмый. Музыка училищесында укыган еллар турында Илһамның шәриктәше, соңыннан күренекле татар композиторы булган Фасил Әхмәтов «Без өчәү идек» дигән мәкаләсендә болай дип хәтерли: «Аның торыр җире дә юк иде, без аны шул училищеның подвалында яшәүче ятимә апаның бер бүлмәле фатирына урнаштырдык.



*Язучы Гәрәй Рәхим белән алар тормышта да, иҗатта да дуслар*

Ел буена аның аягыннан шул кирза итек төшмәде. Менә шундый иде яшь Илһам Шакиров. Мирсәет Яруллин, мин, ул — өчәү бергә Кекин йорты ашханәсенә йөрибез, беребезнең акча бетсә, икенчебездә кырып-себереп табыла...»

Илһам Шакиров җырчы буларак киң аудиториягә нәкъ менә радио аша таныла. Әмма ул чын профессиональ җырчы булу өчен радиотыңлаучыларның йөзләгән, меңләгән мактау хатлары гына җитмәячәген яхшы аңлый һәм музыка училищесының беренче курсын тәмамлауга ук, Казан дәүләт консерваториясенә укырга керә. Ул инде училищеда укыганда ук халыкка танылган җырчы булса да, аны консерваториягә ике куллап кабул итәләр.

Консерваториядә ул чит ил, рус һәм татар композиторларының классик әсәрләре белән таныша, рояльдә башка студентлардан яхшырак, профессиональ дәрәҗәдә уйный, музыка теориясен һәм тарихын тирәнтен өйрәнә. Консерваториядә ул тәҗрибәле музыка укытучысы Елена Абросимовадан дәресләр ала, аның иң яраткан укучысы була.

Консерваториядә укыганда аны танылган татар композиторы Мансур Мозаффаров аеруча якын итә. Ул Илһам Шакиров башкаруы өчен махсус җырлар яза.

Инде иҗади яктан шактый өлгергән һәм халык арасында танылуга ирешкән җырчы консерваториядә укыган һәм аны тәмамлап Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшләгән чакларында чын мәгънәсендә киң халык массалары арасына чума — ел буенча диярлек гастрольләрдән кайтып керми. Бу чорда ул Татарстан һәм Башкортстанның бөтен татар авылларында диярлек концертлар куя, СССРның төп шәһәрләрендә һәм татарлар тупланып яши торган төбәкләрендә чыгышлар ясый, чит илләргә турнега чыга. Дөнья картасының ул гастрольләрдә булган урыннарын карасаң гаҗәпкә калырлык: Хельсинки, Истанбул, Киев, Баку, Ашхабад, Ташкент, Фрунзе, Алма-Ата; Россиядә: Мәскәү, Ленинград, Саратов, Әстерхан, Уфа, Куйбышев, Омск, Новосибирск, Томск, Красноярск, Иркутск, Владивосток һәм башка йөзләрчә кечерәк шәһәрләр, меңнәрчә авыллар.

Шушы бетмәс-төкәнмәс гастрольләрдәге сәхнәләрдә, радио һәм телевидениедә башкарган, патефон тәлинкәләренә язылган йөзләрчә исемдәге җырлары белән Илһам Шакиров бөтенхалык мәхәббәтен казана.

Әмма иң мөһиме — Илһам Шакиров һәр җырында туган татар халкының бәгыреннән ташып чыккан илаһи моңны, көйне үзенә генә хас булган кабатланмас тавыш, гүзәл аваз, көчле рух белән тамашачы күңеленең иң тирән, иң нечкә кылларын тибрәтә, шуның белән чын халык җырчысы биеклегенә күтәрелә. Әгәр дә Илһам Шакиров бер генә дәүләт бүләге алмаган булса да, барыбер «халык җырчысы» дигән бөек исемне йөртер иде. Ләкин Татарстан хакимияте Илһам Шакиров иҗатын һәрвакыт югары бәяләп килде. Республикабыз хөкүмәте тәкъдиме белән ул «Татарстанның халык артисты» дигән мактаулы исемне алды, «Россиянең халык артисты» булды, ана республикабызның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт

премиясе бирелде. Әле күптән түгел, 2000 елның 28 апрелендә Россия мәдәният министрлыгы һәм музыка сәнгатен үстерү буенча Чайковский исемендәге фонд Илһам Шакировка Россиядәге иң дәрәҗәле бүләкләрнең берсе булган «Алтын Апполон» премиясен тапшырды. Ә бит бу премиягә Россиянең мәшһүр җырчылары һәм музыкантларыннан Ирина Архипова, Андрей Эшпай, Татьяна Устинова, Михаил Шишкин кебек атаклы сәнгать әһелләре генә лаек булган иде.

«Алтын Апполон» премиясен алганда инде Илһам Шакировка 65 яшь иде. Профессиональ җырчы өчен бу шактый зур яшь. Гадәттә җырчылар иҗаты 40-45 яшьтә табигый рәвештә сүрелә башлый, күп җырчылар инде бу яшьтә сәхнәгә бик сирәк чыгалар, чыксалар да җырларын фонограмма ярдәмендә генә тыңлаучыга тәкъдим итәләр. Ә табигать Илһам Шакировка тавышны шул кадәр мул итеп биргән, ул әле бүгенге көнгә кадәр сәхнәдә фонограмма (артистлар аны «фанера» дип йөртәләр) кулланмый. Сиксән яшьлек артистның сәхнәдә һаман табигать биргән үз тавышы белән җырлавы күпләрне гаҗәпкә калдыра, чиксез сокландыра.

Сиксәнгә җиткән җырчыбыз хәзер инде сәхнәгә бик еш чыкмый, чыкса да берике җыр башкару белән чикләнә. Тамашачы зәвыгының нәзберeклегeн, нечкәлeгeн тирән тойган җырчы үз бәһасен, димәк профессиональ артист бәхәсен төшермәү өчен шулай эшли. Илһам Шакиров җырын тыңларга теләүчеләр өчен хәзер әллә күпме аудио һәм видео язмалары, ягъни дисклар чыгарыла. Рәхим итегез, Илһам Шакировның яшьлек тавышы, яшьлек моңнары белән танышыгыз!

Сәхнәгә еш чыкмаса да, Илһам Шакиров әле бүген дә татар сәнгате әһелләре — музыкантлар, композиторлар, театр артистлары, язучылар, галимнәр белән якыннан аралашып, алар белән гөрләшеп яши. Менә инде ун елдан артык ул җәйнең иң матур бер көнендә Казан янындагы атаклы Аккош күле ярында «Илһам сәйраны» дигән күңел ачу җыены оештыра. Ул анда ким дигәндә 50-60 күренекле сәнгать әһелләрен, дусларын чакыра, үз куллары белән бик оста һәм тәмле итеп шашлык һәм пылау пешерә. Бу осталыкка ул ярты гасыр буе йөргән гастрольләрдә өйрәнгән.

«Илһам сәйраны»нда күренекле сәнгать әһелләре тәмле азык белән сыйланалар һәм бүгенге сәнгатьнең торышы, аның уңышлы һәм кимчелекле яклары, сәнгатебезнең һаман үсә баруы өчен нинди эшләргә кирәклеге турында сөйләшәләр. Әлбәттә, сәнгать кешеләренең һәрберсе сәйранда әйтелгән фикерләрне үзләренең киләчәк иҗатларында файдалана.

Күптән түгел Илһам Шакировның туган төбәгендә, ул үзе, аның якташлары, туган-тумачалары татлы суын эчеп үскән чишмәне тантаналы рәвештә ачу булды. Якташлары тарафыннан матур итеп төзекләндерелгән ул чишмәгә «Илһам чишмәсе» дип исем биргәннәр. Чылтырап аккан чишмә янына бик күп авыл кешеләре, артистлар, язучылар, журналистлар җыелган иде. Шагыйрьләр ялкынланып шигырь сөйләделәр, Илһам Шакиров чишмә чылтыравына кушылып моңлы җыр җырлады. Чишмәне ачуда катнашучылар ел саен «Илһам чишмәсе» янына җыелып хезмәткә көч-куәт, иҗатка илһам алырга дип килештеләр.

Узган елның җәендә Бөек Болгар җирендә борынгы ата-бабаларыбыз, бүгенге милләттәшләребез һәм кунаклар, бала-чагалар һәм киләчәк буыннар хөрмәтенә архитектура һәм сәнгать ягыннан гүзәл итеп төзелгән Акмәчет ачылды. Республикабызның «Янарыш» фонды рәисе, Татарстан Республикасының Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев чакыруы буенча, Илһам Шакиров бер төркем әдәбият-сәнгать әһелләре белән Акмәчеткә сәяхәт ясады. Республикабызның күренекле сәнгать әһелләре илаһи Акмәчеткә һәм изге Болгар җиренә сәҗдә кылдылар. Бу сәяхәт, бу очрашу күпләрнең күңеленә тирән уелып калды. Илһам Шакиров бу изге җирдә озаклап дога кылды.

80 еллык гомер... Шуның 65 елы диярлек даими рәвештә сәхнәләрдә, радио, телевидение микрофоннары алдында үткән. Һәм шушы 65 ел буе җырланган һәр җыр, һәр көй халыкның күңел түрендә нурланып, балкып, моңланып, дәртләнеп яңгырап тора. Бу — Илһам авазы... Бу — Илһам җыры... Чын мәгънәсендә халкыбыз илһамы!..

**Гәрәй РӘХИМ,**
*Татарстанның халык язучысы*

# ТАБЫНУ



Илһам абыем турында язарга дип утырдыммы әле мин, әллә үзем турындамы? Икесе дә бергәдер инде, чөнки Илһамсыз мин юк, минсез... Ай-һай, бигрәкләр дә эредән чирттерергә маташа бу, дияргә ашыкмагыз. Әйтәсе килгәнем — минсез, синсез, сезсез, безсез була алмый ич инде бер генә иҗатчы да, килешәсездер. Әгәр дә ул, Робинзон Крузо кебек, утрауда бер ялгызы яшәмәсә, билгеле. Чын иҗатчының һәркайсына да тыңлаучы, укучы, күрүче, бәяләүче кирәк. Бушлыкка иҗат итүнең мәгънәсе юк. Кыскасы, Тукай шигырендәге кебек: *«Кем белер кадренне, жаным, дәртле күнел булмаса, / Наз итәр кемнәргә гөл, каршында былбыл булмаса...»*

Ерактан килгән моңыбызның милләт паспорты кебегрәк аерым бер таныклык икәнен, аны беркайчан югалтырга ярамаганын аңлаучы һәм шул моңнарны үз йөрәге аша сугарып яшәүче буын кешеләре, ни кызганыч, картая, китә бара. Һәр яңа буын үз әлгәреләреннән акыллырак, сизгеррәк, нәзегрәк хисле була, дигән сүзгә тамчы да ышанмыйм. Дөньяда яңадан-яңа ачышлар, технологик уйлап табулар алга таба ыргылган саен, кешедә белем түгел, ә яңа төр җайланмаларга, әйтик, шул ук компьютер, машиналар, телефонның яңадан-яңа төрләренә ияләшү һәм, инструкцияләр кушканча, аларны куллану күнекмәләре генә арта, ә менә белем ягы да, күңеле дә баемый. Күп яшьләр бүген тапкырлау таблицасын да юньләп белми хәтта. Аның өчен машина тапкырлый бит, нигә ятлап интексен ди! Ә дөньяны хис-тойгы аша кабул итү дигәне елдан-ел, күзгә күренеп саега бара. Шуңа күрә инде олыгаю чигенә якынлашкан минем буын кешеләре, ягъни теге гасырның илленче-алтмышынчы елларында туганнар буыны бу җәһәттән соңгы могиканнар булмагаек. XXI гасырның без яшәп яткан елларында музыка-җыр сәнгатен дә, әдәбиятны да, киноны да, рәсем сәнгатен дә коммерцияләшү чире басып алды. Әле әби-бабалары, әти-әниләре моңлы булган буын яшьләренең дә колаклары мүкләнде, күзләре акча сурәтеннән томаланды. Шуңа күрә дә Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Фәридә Кудашева җырларыннан милләт йөзен алар инде тиздән таный да алмый башлар, мөгаен...

Безнең балачак, үсмерлек һәм яшьлек елларыбыз, яшәү шартлары ягыннан шактый кырыс вакытка туры килсә дә, милли сәнгатьнең күп төрләре гөрләп чәчкә аткан бәхетле чор булган икән ләбаса! Партия диктаты, һәртөрле кысаларга кертү заманасы димәссең: әллә халыкның моңарчы йомылыбрак килгән дәрте, көч-куәте, милли республикага тиенү белән, өскә бәреп чыкканмы, ул чордагы профессиональ белем бирү (бу очракта бигрәк тә иҗади профессияләрне күздә тотам) бик көчле булганмы, әллә барысы да бергәме, һәрхәлдә Солтан Габәшиләрдән, Салих Сәйдәшләрдән ургылып чыккан иҗат чаткысы, беренче оркестрлы-театрлы аһәннәрдән күтәрелеп, алга таба чын халыкчан музыкаль спектакльләр, милли опералар, Фәрит Яруллинның кабатланмас «Шүрәле»се, соңра, Европа музыкасы калыбында булса да, Җиһанов симфонияләре, опералары дәрәҗәсенә менеп чарланган. Һәр яңа буын кешеләре үз әлгәреләреннән көй-моң, яңа яңгырашлар алып үсә. Бердән, халык үзе — беренче чиратта, татар авылы халкының күңеле чишмәсе, аннан килеп, радиодан, театрларда, сәхнәләрдә яңгырап торган музыкаль әсәрләр — һәр булачак иҗатчының күңелен сугарып киләдер. Илһам Шакиров әнә шул төрле дулкыннар кагышын үз күңеленә җыеп, үз моңында чайкап-юып, тәмам үзенеке итеп, аннары шуны чын халыкчан,

шул ук вакытта югары профессиональ дәрәҗәгә житкереп, халыкның үзенә кире кайтаручы моң иясе булып житешкән. Үз чиратында, аның моның тыңлап үскән безнең буын кешеләре — Илһам мәктәбе балалары.

Шәхесне заман үзе тудыра дигәннәренә ышанмый кара! Чыннан да, берни дә бушлыкта хасил булмый, күрәмсең. Илһам Шакиров исемле авыл егетенең, татар халкы бәхетенә, Алабуга педагогия институтына керә алмыйча (сәбәбе үзендә түгел, ул хакта инде язганы бар), Казанга юл тотып, жырчылыкка кереп киткән еллары нәкъ менә татар музыка сәнгатенең яңа ыргылыш алган вакытына туры килүен күр син! Бүгенге жыр китапларының күбрәк битләрен әле дә булса илленче, алтмышынчы, житмешенче елларда искитмәле затлы көйләр язган композиторларның (кайберәүләре композитор дигән исем күтәрмичә дә чын халыкчан көйләр язган!) жырлары алып тора. Саный китсәк, Илһам абыйның консерваториядә Мансур Мозаффаровтан белем алып, композиторның яңа табадан төшкән күп жырларына гомер бирүен, Александр Ключарёвның югары пафослы жырларын башкаруын, Рөстәм Яхин, Исмай Шәмсетдинов, Заһид Хәбибуллин жырларын халыкка житкерүен, ә исән чагында үзен аздан гына күреп калган Салих Сәйдәшевнең «Зәңгәр шәл» спектакленә язган көйләрен Камал театрында, актёрлар уены барышында жырлавын, үзе белән бергә баянчы сыйфатында гастрольләргә йөргән Зиннур Гыйбадуллинның көйләрен сайлап алып башкарганын тәфсилләп сөйләп булыр иде. Әле тагын Фәтхерахман Әхмәдиев, Арслан Батыршин, Әкрам Даутов, Рим Хәсәнов жырларының нәкъ менә Илһам абыйның жинел кулыннан, дөресрәге, затлы тавышыннан халыкка таралуы! Ә сөекле Монсарабыз — Сара апа Садыйкова белән ижади дуслыгын сөйләп тә торасы юк инде! Тагын бер жимешле ижатташы — композитор Ренат Еникиев. Моң эзләп, Өфедән күчә-күчә Казанга барасы юлымда — Чаллыда, КамАЗ автозаводы һәм яңа Чаллы үзе төзелгән елларда, штукатур-маляр булып эшләп йөргән чакларымда, китапханәдә Ренат Еникиевнең «Сигез жыр» исемле ноталы жыентыгын табып карап утырганым истә. Андагы «Кораб», «Бер алманы бишкә бүләек»не һәм тагын берничәсен радиодан ишеткәнем бар иде инде. Болары Илһам абый элеккерәк елларда радиога яздырткан авыл көйләреннән өскәрәк күтәрелеп, эпик-фәлсәфи югарылыкта эшкәртелгән һәм симфоник оркестрга кушылып башкарылган булганга, алардагы тарихи тирәнлекне, гасырлар авазын сеңдергән аһәңнәрен сизмәскә мөмкин түгел иде.

...Диндә потка табынуның гөнаһ икәнлеге әйтелә. Бер Аллалы диннәр иңгәннән соң, Аллаһының берлегенә, бердәнберлегенә өндәүдән калган өйрәтмәдер инде бу. Күчерелмә мәгънәсендә, әлеге өндәү үзенә пот ясама, ягъни, урысча әйткәндә, не сотвори себе кумира, дип әйтелә. Психологлар күзлегеннән караганда да дөрес инде бу: кемнәндер үзең өчен Алла, табыну объекты ясау кешене иләсләндерә, тормышның бүтән төсләрен күрергә комачаулый. Ул гына да түгел, андый гамәл гомереңне бер генә төрле эзгә сала, хәзергечә әйтсәк, программалаштыра. Минем гомеремне Илһам Шакиров дигән пот программалаштырды. Үзенең бу эшкә шәхсән катнашы булмаса да, бу шулай. Мине Өфедә укып яткан жиремнән кубарып Казанга китерүче дә, анда үткәргән кырык елга якын гомеремдә жыр белән шигырь, жыр белән журналистика арасында буталып йөрүемдә дә Илһам Шакиров «гаепле».

...Алтмышынчы еллар башында безнең Башкортстанда бердәнбер радиодан Мәскәү белән Өфе генә сөйләп тора иде. Өфе радиосы үз тапшыруларын нигездә башкортча алып барса да, республика халкының зур күпчелеге татарлар булганга күрә, концертларда татарча жырларны да еш тапшыралар иде. Илһам Шакиров дигән яшь жырчыдан иң элек кайсы жырны ишеткәнемне хәтерләмим, алай да «Иманнәр шаулый», «Яшь наратлар», «Әниемә хат» жырлары исемдә калган. Жырчының әллә нинди йомшак-куе тавыш белән, иркен бер рәхәтлек, хөрлек тойгысы биреп жырлавын, сөттән каймак аерткандай аерып алып, сабый күңелемнең иң югары киштәсенә салып куйганмындыр, күрәсең. Жырлавын күтәп ала торган булып киттем. Соңрак күрше-тирә авыллар өчен зуррак бер үзәк ролен үтәгән Иске Турай авылындагы радио-ноктадан, ял сәгатьләрендә, Казан радиосы каналын тоташтырып кую гадәткә кереп китте. Кибет янындагы багана башыннан да, өйләрдә дә жырлый Казан — үзе бер бәйрәм! Зифа Басыйрова, Гөлсем Сөләйманова, Фәхри

Насретдинов, Рәшит Ваһапов, Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова исемнәрен һәм тавышларын, әнә шулай, әле Өфе аша, әле Казан радиосыннан ишетеп-танып үстек. Әти дә, әни дә җырларга ярата, әти гармунда уйный. Калага барсалар, яна чыккан җыр тәлинкәләрен алмый кайтмыйлар. Өйдә алар инде бер киштә, әмма Илһам абыйныкын күпкә соңрак, мәктәпне тәмамлаганда гына кулга төшердек. Мин авылда әле дә иске патефоныбызны боргалап, ана иске пластинканы урнаштырып, Илһам абыйның «Гөлмәрьям»ен, «Казакъ кызы сөйгәнем»ен тыңлап алам. Әйтерсең лә яшьлеккә кайтып киләм. Ә ул җырлар бүген дә искерми икән бит: беркөн Өфенең «Юлдаш» радиосыннан яшь бер җырчы башкортчалап Заһид Хәбибуллинның «Казакъ кызы...»н җырлап ята...

...Мәктәптә укыганда, үзебез куйган концертларда Илһам Шакировтан откан җырларны башкармый калмый идек. Тугызынчы-унынчыны күрше авылда, Иске Турайда укыдык. Шул елларда радиодан Мансур Мозаффаровның Мөнир Мазунов сүзләренә язган «Туган як» җырын еш тапшыралар иде. Отып алып, сәхнәдән мин дә җырлый идем шуны. Үзем җырлыйм, үземнең колагымда гел Илһам тавышы яңгырап тора, аның аһәне, аның тавышы белән җырлыйм, янәсе. Хәзерге караокеларда еш кына очрый бу җыр көе. Ритмын тизәйтеп эшкәрткән булсалар да, көйнең бүген дә тансык икәнен танымый булмый. Илһам абый башлап җырлаганга шулай озын гомерледер ул. Соңрак Мансур абыйның «Хәерле иртә»се колакка килеп керде. Студент чакта мин аны радиога да яздырттым әле. «Дулкын» җыры да Илһам абыйдан соң халык күңеленә үтте. Менә Нәкый Исәнбәт шигыренә үзе иҗат иткән көй — «Син сазыңны уйнадың». Бу җырны күңелсез тыңлый алам: аны тыңлаганда, бүген бездән нык ерагайган, ә кайчандыр мәдәниятебезнең затлы бер өлеше булган Шәрык мотивлары, әкияти баглар-бостаннар, колыбыздан төшкән сазлар, сорнайлар күз алдына килә...

Тукай әйткәнчә, сүз башым бит Шүрәле иде. Үсмер чакларымнан ук Илһам Шакиров җырлары дөньясына чумуымны сөйли башлаган идем бит әле. Казанны күрәсе бик килсә дә, әллә кайда — җиде җир читендәге калага ничек барып җитмәк кирәк? Ул елларда турыга юллар юк, автобус маршрутлары салынмаган. Кырык чакрымдагы Туймазы станциясеннән Уфа—Казан поезды үтә дә үтүен, моннан Казанга бер тәүлек чамасы барырга кирәк, диләр, Бөгелмәне, хәтта Ульянны да узып. Кая инде җыр дип, шигърият дип, кесәндә җилләр уйнап торганда, өстенә кияргә юньле кием булмаганда, шулкадәр еракка китәсең ди! Өфе якынрак, анда таныш-белешләр дә бар. Мәктәпне тәмамлагач, нефть институтына укырга барып кердем. Өфе — ул сиңа Шах авылы түгел инде, зур кала! Биредә филармония бар, «һөйләп-йырлап» тора. Ара-тирә Казаннан да концертлар килгәли. Берзаман, ни күзем белән күрим, Илһам Шакиров афишасы! Черниковка бистәсендәге иң зур Мәдәният сараена йөгердем — тизрәк билет алып калырга кирәк! Минем өчен ул көнне шул концерттан да мөһимрәк эш булмагандыр. Чөнки тулай торактагы бүлмәмдә, ятагым каршында инде күптән Илһам Шакировның, «Азат хатын» журналыннан кисеп алып, үзем матурлап кысага куйган фотосы эленеп тора. Начар гына сыйфатлы булса да, мин күргән беренче төсле (!) фотосы! Кыскасы, мин инде җырчыдан үземә пот ясап өлгергән, аның моңының татлы агуын эчкән идем. Сәхнә җыр белән ачылып китте:

*Килдем сезгә, Идел-диңгез кичеп,*
*Сезне сагынып, канатланып-очып,*
*Кош канатлары түгел иңемдә,*
*Җыр канатлары минем күңлемдә...*

Соңрак, күпкә соңрак, инде Казанга килеп, үзем табынган җырчы белән якыннан танышып, күрешеп-сөйләшеп йөри башлагач, ул бу сәламләү җырының, концертка башлам буларак кирәк булганга, үзе җырлый торган «Кама буе — туган як» җырыннан үзгәртеп-кыскартып «мәтәштерелгән» икәнен көлеп сөйләде. Аның каравы, концерттагы бүтән җырлары нинди бит — авыл көйләре «Өнсә», «Күн», Сәйдәшнең «Җәй айлары»...

Ул төнне йоклап та тормадым шикелле — кичә концертта күргән сап-сары кримплен кәчтүмле, озын, зифа буйлы җырчымны кабат-кабат күз алдыма китереп, аңа беренче шигыремне яздым:



Җырчының иҗат коллективы

*Сары каз бәбкәсе кебек*
*Сарыны кигән идең,*
*Агач яфраклары күек*
*Саргаям, дигән идең.*

*Иделен сагынган йөрәк*
*Озакка түзәмени, –*
*Өфе җиле, вак яңгыры*
*Үзәкне өзәмени?*

*Шулкадәрле моңаюга,*
*Елмайсын кояшмыни:*
*Болытларның, еламаска,*
*Күңелләре ташмыни!*

Икенче көнне дә, ничектер билет табып, тагы концертка киттем, бу юлы инде чәчкә гөлләмәсе тотып. Җырчымны якыннан күрәсе килә бит, ә чәчкә бирүчене берәү дә сәхнәдән куып төшерми. Чәчкәләр арасына шигыремне дә кыстырдым, дер-дер калтырап, менеп, ниһаять, үзен якыннан күреп, кулын кысып төштем. Шуннан китте! Миндә физика, математика, статистика кайгысы калмады. Башта бер генә төрле уй — Казан, Илһам, җыр, шигырь! Ике курсны бетергәч, ни булса, шул булыр дип, укуны ташлап, Аллага тапшырдым да, Чаллыга, КамАЗ төзелешенә эшкә киттем. Ни дисәң дә, Чаллыга Казан якынрак бит инде. Анда янә Илһам абый концертлары! Бу юлы мин билет эзләп йөрмим, ә «Энергетик» сараеның сәхнә артына, кулиса янына — артистларның юл өстенә үк кереп утырам, чөнки инде ярты ел чамасы үзем шул Сарайнын берьюлы ике сәнгать коллективында — татар хорында һәм урыс вокаль ансамблендә җырлап йөрим, хакым бар. Ике көн рәттән көненә икешәр концерт карап, Илһам абыйны сигез сәгать дәвамында якыннан күреп, хәтта бераз сөйләшеп тә алып, бәхеткә тиенәм. Ул чакны язган шигырьләр сакланмаган. Бер елдан соң, Казан дәүләт университетына кереп, өр-яңадан студент тормышына чумгач, Илһам абый концертларына йөреп тә карадым инде! Спорт сараен шыгрым тутырып та җырлады ул. Бүтән кечерәк залларны инде әйткән дә юк. Рим Хәсәновның әниләргә багышланган җырын (бер кайтмасам, әнкәй, бер кайтырмын, утынны сүндермичә мине көт...) ул елларда телдән төшерми кабатладылар. Шул ук композиторның «Кышкы романс»ы да, аны Өфедә Фидан Гафаров инде җырлап күрсәткән булса да, Илһам абый башкаргач, янача яңгыраш тапты. Вадим Усманов (урыны оҗмахта булсын!) җитәкләгән «Идел» ансамбле Илһам абыйның бик күп җырларына үзенчәлекле аһәң бирде. Ә Сара апаның Мостай Кәрим шигыренә язган «Өченче көн тоташ кар ява»сы! Илһам абый аны үзәк өзгеч сагыш белән дә, сугышка дәһшәтле нәфрәт хисе белән дә җырлады. Кайда хәзер андый җырлар?!

Күпме генә күрсәм дә, концертларына йөрсәм дә, миңа һаман да аз кебек тоела иде. Чөнки елның бер вакытында аның бригадасы Советлар союзының әллә кайсы почмакларына гастрольгә китеп югала. Ташкенты, Алма-Атасы, Төмәне, Әстерханы — барысы да Илһам җырын тансыклый. Бервакытны, гастрольдән кайтуына, мондыйрак шигырь әтмәлләп җибәрдем:

*Көз көне җылы якларга*
*Китә кошлар, диделәр.*
*Шакиров та шулар белән*
*Бергә кышлар, диделәр.*

*Сүзләре әллә рас килде —*
*Табалмадым эзләрең,*
*Кош кауырыйларыдай калды*
*Радио-язмаларың!*

*Яз килгәч, кошлар да кайтыр,*
*Көннәре матур торса.*
*Шакиров та шулар белән*
*Кайтыр, Алла боерса!*

Кайтты. Тагын нинди генә концертларда, нинди генә кичәләрдә жырламады! Берсендә хәтта аның белән бер концертта жырлау бәхете дә тиде үземә. Бу Хәсән Туфанның юбилеена багышланган кичә иде, ул чактагы — Камал, хәзерге Тинчурин театры бинасында. Без анда университетның «Каз канаты» исемле бию ансамбле белән чыгыш ясадык, «Зәңгәр шәл»дән өзек күрсәттек шикелле истә калган. Мин анда Мәйсәрә рәвешендәрәк, башлап жырлыйм. Ә Илһам абый ни жырлады икән? Мөгаен, Туфан шигыренә язылган «Ромашкалар»ныдыр, һәм бер жыр белән генә дә калмагандыр.

Илһамны аллалаштыруыма аның «күләгәсе» чик куйды: минем белән бер үк тулай торакта, Кызыл Позициядә яшәп-укып ятучы энесе, бертуган апасының улы артымнан йөри башлады. Ул да, абыйсына охшап, озын буйлы, матур тавышлы егет иде. Коридорның бер башында «Кара урман»ны сузып жибәрсә, күпләр тулай торакка Илһам килгәнме әллә, дип, ишектән башларын тыгып карыйлар иде. Әмма жырның бер-ике юлыннан ары китә алмый жырлаучы, тыны житенкерәми иде ахрысы...

Мин, күктән төшеп үк житмәсәм дә, жиргә бераз якыная башлаган студент, үземнең табыну объектына ничектер тынычрак карый башладым. Хәтта нинди эчке эгоизмым тойгысында, мондыйрак шигырь язып аттым:

*Мин генәме табынучы*
*Тик бирәүгә дөньяда:*
*Минем кебек янып-көеп*
*Йөрүчеләр күп алар.*

*Тик минем табыну үзгә,*
*Тик минем денем башка:*
*Сәждә кылмыйм, мәжүсиләр*
*Табынгандай кояшка.*

*Табынам үзем тапканның*
*Иң асыл жәүһәренә,*
*Баш идертә алган көчнең*
*Рухыма тәңгәленә!*

*Яшермим — табынам сиңа,*
*Илһам бирүче Аллам,*
*Тик онытма: Аллаларны*
*Мин үзем сайлап алам.*



*Бертуган апасының улы шагыйрь Хәйдәр Гайнетдинов һәм аның улы Марат янәшәсендә*

Тагы да соңрак, инде филармониядә, Дәүләт Жыр һәм бию ансамблендә эшләп чыгып, тагы бераз укып, газета редакциясендә эшли башлагач кына, Илһам абый белән якыннан танышып, дуслашып китәргә насыйп булды. Инде мин — Казанда унбиш еллап «тоз ашаган», дуслыкны да күргән, хыянәтне дә кичергән кеше, хисләр дә утыра башлаган, идеализм чиреннән дә арынганмын. Бервакыт, дуслар белән нindидер кичәдәнме, концерттанмы кайтып килгәндә, Бауман урамы чатында Илһам абыйны очраттык. Арада аны якыннан белүче

музыкантлар да бар иде. Шаулашып-гөрләшеп сөйләшә торгач, Илһам абый безне, берничә яшь кешене, өенә чакырды. Анда чәй эчеп, тагы нидер йоткалап утырдык та таралыштык. Алга таба ничектер тагын юллар кисеште, аралашып киттек. Бергәләшеп пылау пешерәбез, балык кыздырабыз. Сөйләшеп сүз бетми. Аның белән сөйләшүе дә рәхәт: жор телле, Тукайны яттан белә, ике сүзнең берендә аның шигырьләреннән, темага туры китереп, афоризмга әверелгән гыйбарәләр кыстыра. Әйтик, сүз, бер нәрсәдән икенчесенә сикереп, онытыла язганда, кире кайтып, туктале, сүз башым бит Шүрәле, дип куярга мөмкин. Берәр нәрсәгә артыграк сөенсәң, янә Тукайдан «фәгыйләтен, фәгыйләтен, фәгыйләт, вәт, Печән базары халкы көнле шат», дип төрттерә. Нинди моңлы кеше, ә үзендә никадәр юмор тойгысы дип уйлап куясың! Хәер, ул нәкъ халыкның үзе кебек ич инде — моңлы да, боекмас та!

Жырчыны өй шартларында, гадәти тормышта да, сәхнәнең алдында гына түгел, артында да күп күргәнгә, аның белән бергә төрле шәһәрләргә концертлар белән дә чыккалаганга күрә (Иваново, Саратов һ.б), холкын өйрәнәсең, төрле ягына күз төшерәсең. Ул синең өчен Аллаһы Тәгалә болытдан тукмый, ләкин аңа карап кына кумирына карата хөрмәтең, яратуың бер дә кимеми. Киресенчә, баштагы табынулы хисләр аны гап-гади кеше буларак та, шул ук вакытта кабатланмас, бөек җырчы буларак та аңлау, хәтта хәленә дә керү кебек тойгы белән алышынды. Менә абыкамның (дусты Хәмдүнә Тимергалиева аңа шулай, «абыкам», дип дәшә) чираттагы бер юбилее алдыннан язган шигырем:

*Сез карагыз аңа гаҗәпләнеп,*
*Иң беренче кабат күргән кебек.*
*Күз карашын, һәрбер хәрәкәтен*
*Хәтерегез алсын изге күреп!*

*Гади дә ул, кайчак хәтта ямьсез,*
*Нинди булса, шундый булып калсын.*
*Гадилеген тоя алмый торып,*
*Бөеклеген аның аңламассың.*

*Сез карагыз аңа сөеп-назлап,*
*Нәкъ иң соңгы кабат күргән кебек.*
*Сискәндерә бер сүз: «Ул да фани...»*
*Тик бер өмет җанда — җыр мәңгелек!*

Тагы ни өстим? Үзенә пот ясап, ундыңмы син, әллә тундыңмы, дип сорар кемдер. Уну ни дә, туну ни? Кемгәдер уну — шәхси бәхет, гаилә, бала-чага чыр-чуы, ә кемгәдер халкың белән бергә, аның моңын ишетеп, сөенечләрен, уңышларын, үсешен күреп, үзеңне шуңа багышлап яшәү. Үзем хакында алай зурдан кубып сөйли алмасам да, Илһам Шакировны әнә шулай яшәп китәр өчен җибәрелгән пәйгамбәр сыйфатында күрәм. Үземне исә шул пәйгамбәрнең канат очы булса да тиеп киткән кеше итеп сизүем белән бәхетле тоям. Миндәй хыялыйлар булмаса, пәйгамбәрләр дә булмас иде, мөгаен.

**Флюра НИЗАМОВА.**
*Башкортстан, Ярмәкәй районы*

# АЛПАР

...СССР дип аталган элекке илнең татар яшәгән нинди генә төбәкләрендә булмагандыр ул. Алтмышынчы-житмешенче елларда инде туган телен мәктәпләрдә укудан мәхрүм, димәк, Тукайның да исемен ишетмәгән кан кардәшләргә татарлыкны искә төшереп, концертта гына булса да татарча әрнеп, татарча сөенеп алырга мөмкинлек биргән бердәнбер Илһам Шакиров бар иде. Дөрес, ул ялгыз түгел, бирелә әлеге заманның бүтән затлы жырчыларын да искә төшерергә мөмкин. Тик нәкъ менә Илһам Шакиров кына «татар күңлениләр сизгәнен өзлеп-өзлеп кенә әйтеп бирүче» буларак халык күңеленә кереп калды, тарихка күчте.

Һәм бары тик ул гына «мискин булып торган өч йөз елда (күбрәк, һаман күбрәк шул!) тәкъдир безне ничек изгәнен» жыры белән, сүзе белән курыкмыйча әйтә алды. Зур сәхнәләрдә дә, ягылмаган авыл клубларында да. Чөнки ул үзе үк татар язмышының, чынга ашмаган милли хыялларның, реальләшмәгән мөмкинлекләрнең гәүдәләнеше иде.

Ходай тарафыннан ана, әлбәттә, олы талант бирелгән. Әмма Ходай Илһам Шакировка жырлау талантын гына түгел, ан-фәһем һәм ихтыяр көчен дә кызганмый биргән. Анардан ике курс алдан укыган Фасил Әхмәт дусты турында болай яза: «Шәп, көчле, табигый тавышы булуга карамастан, Илһам казганды, һәрчак кулында китап, һәрчак пианино янында иде».

Мин жырчылар, артистлар арасында Илһам Шакиров кебек эрудицияле башка берәүне күргәнем булмады. Татар әдәбиятын белү жәһәтеннән дә үз даирәсендә ана тиңнәр юк. Ул яшьтән үк татар тарихы белән кызыксына, Октябрь фетнәсенә кадәр басылып, совет чорында тыелган әдәбиятны үзләштерү өчен, үзлегеннән гарәп имлясын махсус өйрәнә хәтта. Нәкый Исәнбәтнең әллә кайчан, 1920 елда ук чыккан «Син сазыңны уйнадың» шигырен шул заманда иске бер журналдан таба да инде ул. Һәм шул сүзләргә искиткеч көй ижат итә. Күбебез аны хәзер халык көе буларак беләбез. Ә шул ук Исәнбәтнең «Туган ил» шигыренә язылган жыр?! Ул аның көен Финляндия татарларыннан алып кайттым дисә дә, жырдан Илһам аһәңе, Илһам өслүбе аңкып тора. Үзе ул беркайчан да композитор данына дәгъва итмәде. Дан анарда болай да житәрлек. Ә онытылган күпме халык жырын табып, эшкәртеп янадан халыкка кайтарды ул. Бу жырлар бүтән онытылмас, искермәс, дип ышанасы килә, чөнки алар, Илһам йөрәге аша үтеп, безнең көннәргә күчте.

Илһам Шакиров бөек жырларны сайлап ала беләме, әллә аларны ул үзе бөеклеккә күтәрәме? Икесе дә бардыр. Музыкаль һәм әдәби зәвыктан мәхрүм кеше олы жырчы була алмый. Көен Сара Садыйкова язган «Өченче көн тоташ кар ява» шигыренең авторы Мостай Кәрим менә ничек искә ала: «Минем тәнемне озак еллар сызлаткан мина ярчыгын Илһам Шакиров әйтерсең үз йөрәгенә суырып алды. Ул жырлый, ә ялы йөрәгеннән ап-ак кар өстенә тамчы-тамчы кызыл кан тама...»

Сирәк-мирәк очрашкан чакларда Илһам аганы мин читтән күзәтергә яратам. Ул салмак кына сөйли, башын кыңгыр салып, истәлекләргә бирелә, уң кулын беләзектән бөгеп, талгын хәрәкәт ясап ала – гүяки атып төшерелгән киек казның соңгы һәм уңышсыз талпынышы. Сүзе бер тында агыла, кайчакта озак кына туктап тора, фикерләрен тәртипкә китерәме, әллә үзе генә белергә тиешле хәлләрне хәтерләп аламы... Тик бүлдергәнне яратмый, паузадан файдаланып, сүз кыстырсам – ә ул шактый озын чыга! – тәкатьсез кулын селтәп: «Син кеше тыңлый белмисең!» Мөгаен, ана тыңлаучы да кирәкмидер, бу монолог аның үзенә генә мөһимдер. Тик бит ул публикага күнеккән! Менә сүз инеше тагын юл ала, инде күптән бакыйлыкка күчкән замандашлар, еллар, юллар... мәзәк хәлләрне искә төшерә, үз сүзеннән үзе көлеп ала һәм күп тә узмый, тавышы калтырап китә, күзе яшьләнә. Сәбәбен сорамыйбыз, бәлки аның Тукайны сагынган чагыдыр?

Колакның кыяфәтенә карап, кешенең акыл кимәлен, холкын белеп була, имеш. Илһам Шакировның башы гүя колактан гына тора. Мин белгәннәр арасында андый



*Академик Миркасыйм Госманов (уңнан сулга), җәмәгать эшлеклесе Сабирхан Мөхәрләмов, Илһам Шакиров*

зур колаклы тагын Миркасыйм Госманов кына бар иде. Дөнья шавын — ком шуышканнан алып ерактагы дингез гөрелтесенә кадәр — ике локатор кабул итеп утыра. Илһам Шакиров һәрнәрсәдән хәбәрдар, һәрнәрсә турында үз фикере бар.

Сиксән бишенче елның җәендә Комлев (хәзерге Мөштәри) урамыннан барганда, каршыма Илһам Шакиров очрады. Мин, билгеле, аны таныйм, үзен татар санаган кем генә аны танымый иде икән ул елларда? Башны сизелер-сизелмәс кенә иеп, исәнләшкән атлы булып, үтеп барганда, аз гына ишарә ясап, бөек җырчы туктап калды:

— Син Эркәил бит әле?

— Ыркаел! — дип аны төзәттем мин. Мине тануына нык гаҗәпләндем, билгеле. Шундый кеше! Шундый... Мәхмүт Хөсәенчә, «мине беляляр!» дип шәрран ярып кычкырырлык бит. Әле кем белә диген...

— «Казан утлары»нда поэманны укыдым, — диде ул. Тынып калды. Атылган киек каз, муенын боргалап, һавада түгәрәк ясап алды. — Син дөрес юлдан барасың шикелле. Поэмада эпиклык булырга тиеш. Вакыйгага корылган булырга тиеш ул. Югыйсә күпләр поэма дип озын шигырь яза... — Һәм китеп барды.

Мин исә шомырт агачы янәшәсендә әдәби даннын күләгәсен ябынып басып калдым. Аптырарлык та шул. Аңарчы да, аннан соң да мин татарча газета-журналларны даими укып баручы җырчыны күргәнем дә, ишеткәнем дә булмады. Сонынннан белүемчә, ул аларның барысын да өенә яздырып алган икән. Ул гына да түгел, кайбер журналларны Татарстаннан читтәге дус-танышларына да яздырган.

Ниндидер бер мәҗлестән Илһам ага, аның җияне Хәйдәр (2000 елда фаҗигале рәвештә һәлак булды шагыйрь) белән бергә чыктык. Андый чакта тиз генә таралып булмый бит ул. Акрын гына төнге Казан буйлап киттек. Әбиләр чуагы иде. Эрмитаж бакчасы. Сары яфраклар ерып, тып-тын барабыз. Һәм шәһәр дә тып-тын. Ул заманда машиналар аз һәм төнлә аларның да сирәге генә йөри иде.

— Төнге Казан урамнарында йөрергә яратам, — дип куйды Илһам Шакиров. — Уйланырга җайлы. Күңел белән әллә кайларга китәсең. Тарихка...

— Мин Казанга килүгә, бөтен урамнарны, тыкрыкларны йөреп чыктым, — диде Хәйдәр.

— Таптыңмы соң үз Казаныңны?

— Таптым! — дип, зур авызын җәеп көлде Хәйдәр. Аннары моңсу гына: — Яңа бистә зиратында, — диде. — Анда сөйләшеп йөрергә кеше күп.

— Безнең Казан монда ул! Монда... Без аяк баскан җирдә, — дип, Илһам Шакиров җиргә тибеп алды. — Өстә дә, аста да... — Җияненә әллә каршы төште, әллә килеште.

Хәзер уйлыйм: Илһам Шакиров аяк баскан җир, әлбәттә, татар җире генә була ала.

Аның сигезенче буын бабасы Алпар исемле булган. Алпар — алып ир, яугир мәгънәсендә. Ул Көнбатыштагы рыцарь сүзенә тиңгәл. Әлеге алпарлык, каннан канга күчеп, Илһам Шакировка да килеп җиткән.

Әнә ул — ак плащтан, яланбаш — сары яфракларга уранып китеп бара. Татар җырының алпары.

**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА,**
*Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты*

# МОҢ ТАҖЫ



*Чәчкәләр бүләк итүче тамашачылары арасында*

Алдан сөйләшеп куйганча, «Актёрлар йорты» фойесында мин аны көтәм. Әле монарчы сәхнә биеклегендә генә күреп ияләнгән Галиҗәнап моң иясенең Даһилыгын Гадилеге аша тояр өчен көтәм.

Юк, мин ана сораулар бирмәячәкмен. Тормышяшәеше, бүгенге җыр сәнгатенә мөнәсәбәте турында да сорамаячакмын. Бераз Тукайчарак әйтсәк, ул коеп куйган җырчы гына түгел, галим дә бит. Илһам ага татар җыры, татар моңы турындагы уй-фикерләрен кайсы гына чорда да кыйммәтен, дәрәҗәсен югалтмаслык итеп әйткән инде. Чөнки ул җырларны үз куллары белән җыйган, туплаган, үзенең йөрәге аша үткәреп, халкына тапшырган.

*«Җыр, музыка — кешенең аерылгысыз юлдашы ул. Кешелек дөньясы нинди катлаулы үсеш юлын үткән булса, аның культурасы да, аерым алганда, җырлары да шундый ук юл үткән. Халык үзенең музыкасын еллар аша, гасырлар аша үзе белән алып килә. Халыкнын тормышы үзгәргән саен, җырларнын эчтәлеге, янгырашы, тематикасы үзгәрә бара»*, — дип яза ул үзенең бер язмасында. *(«Халык моңнары». — «Азат хатын», 1961, февраль).*

Йә, бу бүгенге җыр сәнгате турында түгелмени? Юк, максатым һич кенә дә халкына бөтен гомере буе чын сәнгатьне, чын иҗатны, чын моңны бүләк иткән моңсарны сораулар белән ялыктыру түгел.

Менә ул салмак адымнар белән, төз гәүдәсен горур тотып, елмаюлы карашлар астында фойега үтә. Кемдер яратуын, якын итүен белдереп исәнләшеп китә, кемдер исә, мөмкинлектән файдаланып, хатирәләре белән уртаклашып алырга ашыга.

Ишетеп торам, сөйләшү күбесенең: «Илһам абый, сез безнең авылга концерт белән килгәч...», — дип башлана.

— Элек бит балаларны кич белән клубта булган концерт-театрга кертмиләр иде, — дип сүзен башлады Илһам ага ягына карап-карап алып, ниһаять, янына килергә батырчылык иткән, инде үзе дә өлкән яшьтәге ханым, — сәхнә артына кичке якта ук кереп, плакатлар, стендлар артына качып калдык, бөкшәеп утырып оеша башладыкмы, онытылып киттекме, берзаман бөтен стендлар җимерелеп, өстебезгә килеп төште, директор сизеп, икенче көнне берьюлы өч «2»ле куйды...

Илһам ага кинәнеп көлә. «Шул кирәк сезгә, йөрмәссез җыр тынлыйм дип дәрес калдырып», — ди.

Әнә, бер кырыйдарак, Илһам Шакиров чакыруы, киңәше белән ерак Кыргызстан якларыннан Казанга кайтып төпләнгән, татар телен һәм мәдәниятен саклауга үзеннән зур өлеш кертүче, һәм Илһам аганың якын дустына әйләнгән «Җыен» фонды директоры Фуат Рәфыйков елмаеп тора... Ул да булмый Түбән Кама Татар дәүләт драма театры режиссёры Рөстәм Галиев ике кулын сузып күрешергә килә. Ишетәм: алар да нәрсәдер искә төшереп көлешәләр. Уйларым исә мине дә Илһам ага белән бәйле булган балачак хатирәләренә алып китә.

...Ап-ак итеп акшарланган мичтән таралган җылы дулкынга уралып җыр агыла...

*Ай, әле бик ерακта идек без...*

Өйдә сихри тынлык. Һәммәсенең дә йөзендә моңсулык... Ә тәлинкә әйләнә дә әйләнә... Авыр сугыш елларының кыл уртасында дөньяга килеп, илгә төшкән фаҗигане әле ныгып та житмәгән иңнәрендә күтәрешкән, ерак Приморье краеның Находка шәһәрендә армия хезмәтен үтеп, шунда эшкә калган, инде ир уртасы булып килүче, үз ана телендә бер авыз сүз алышырга тилмереп, туган ягын, якыннарын, аның җырын-моңын сагынып кайткан уртанчы абыемның күзләрендәге сагышны күреп, уйнаткычның инәсен әлеге җырга янәдән көйләп куям.

*Ак калфакның табылган чагы,*
*Туганнарның сагынган чагы...*

Җыр арты җыр алышына. Әлеге җыр тәэсиреннән бераз арына төшкән туганнарның үзара сөйләшә башлавыннан файдаланып, җыр пластинкасын абыйның чемодан төбенә шудырам. Туган якның талчыккан тәнгә мең сихәт бирә торган бөрлегән-җиләкләре белән бергә татар җыры, Илһам моны да ерак Кытай, Япония чикләренә китеп бара.

Илһам агага бәйле булган бала чагымның хатирәсенә тиңдәш юлларны, аның хөрмәтенә чыгарылган истәлек-альбомдагы, Американың Висконсин университеты профессоры Юлай Шамилоглы истәлекләреннән дә укыйм:

*«Безнең әти туган илен һәм анда калган туган-тумачаларын бик сагына иде. Аны ватаны белән бәйләп торучылар татар җырлары, соңрак «Казан утлары» кебек милли журналлар булды. Ул чакта Советлар союзының «Мелодия» фирмасында язылган, минутка — 78, соңрак 33 тапкыр әйләнә торган пластинкалар Америкага да килеп житә иде»,* — дип искә ала ул.

Илһам ага үзе дә татар моңы, татар җыры белән якыннан танышуы, аны тирәннән аңларга тырышуы Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова, Рәшит Ваһапов, Фәхри Насретдиновларның җырлары яздырылган пластинкалар аша булды дип искә ала бер язмасында.

Балачакның җырга бәйле булган тагын бер хатирәсе булып, радиоларда тапшырыла торган концертлар истә калган. И көтеп тә ала идек соң без ул «Ял концертларын», чәршәмбе көнне була торган «Сораулар буенча», «Хатлар укыганда» дип аталганнарын. Ул концертларда иң еш тапшырыла торган җырлар, әлбәттә, Илһам Шакиров башкаруындагы «Кичер мине, әнкәй, гафу ит», «Әнкәй, синең куллар», «Әниемә хат» җырлары иде. Еракеракларда яшәгән, туган якларына кайтуларын тилмерепләр көткән балалары, үзләренең иң кадерле хисләрен хатлары аша гына түгел, Илһам аганың моңы аша да житкереп, газиз әниләрен юаталар, җаннарына тынычлык табарга телиләр сыман иде.

Юк, мин анардан бүген: «Иң яратып җырлый торган җырыгыз кайсы иде?» — дип тә сорамаячакмын. Кайсын гына атаса да, күпмедер дәрәҗәдә дөреслеккә хилафлык китерү булыр сыман.

Алты бала белән тол калып, олысын сугышта югалткан, калганнарын исән-сау үстерү өчен, ач-ялангач килеш авыр тормыш кичкән әнисе турында җырлаган, үз әнкәсенә генә түгел, миллионлаган аналарга һәйкәл булырлык әлеге җырлар ничек иң яратканы булмас икән?

Ачлыктан шешенеп, язгы кар сулары астыннан табылган өшегән бәрәңгене учларында кысып, әле җүнле-башлы «әти» дип әйтергә дә, аталарча каты кулын иңнәрендә тоярга да өлгермәгән, «халык дошманы» дип бер гаепсезгә кулга алынып, төрмәдә үлгән әтисен сагынып, бакчаның бер почмагында тын гына елаган чагы аз булгандырмы? «Син сазыңны уйнадың» җырына әнә шул әрнү-рәнҗешләр дә салынганга, шулай моңлы яңгырый бит ул.

Бәлки ул, бәхет эзләп киткән, ерак үзбәк кышлакларында, кыргыз далаларында, себер салкыннарында яшәгән милләттәшләренең авыр тормышын күреп, җанына тынгылык бирмәгәннән туган «Көзге ачы җилләрдә» җырыдыр? Ә бәлки, күңеле тулы яшь булса да, сөйгәненең хәтерендә елмаюлы карашы белән уелып калырга теләгән, ерак Финляндия чигендә озатып калган мәхәббәтенә багышлап җырлаган «Тик өметемне өзмә генә» җырыдыр ул?

Гаҗәп инде бу язмыш дигәнең. Падишаһ фәрманы белән, татар авылларына урман-

сулыкка якын жирләргә салыну тыелса да, авылга сыенып утырган Яна Бүләк авылының урман аланлыгы булачак халык артистына ин тәүге сәхнә була. Агачлар шаулавы, кошлар сайравы исә — тере оркестр. Тамашачы — урманга утынга, печәнгә килгән, агач артына качып, аның җырлавын тыңлаучы, кайберләре исә, Илһамның урманга таба киткәнен күреп, махсус килүче авылдашлары була. Хак Тәгалә табигый моң белән биргә табигать моның да кушып, Илаһи моң иясен тудырган, Илһамның әтисе Гыйльметдинне Таулыктан Яна Бүләккә — татар халкына яна бүләк бирер өчен әйтерсең лә юри күчереп куйган.

Илһам Шакиров — зур алкышлар белән, яратып каршы алынган җырчы, җырларына бернинди ясалма, өстәмә буяулар кушмыйча, Табигать-Анабыздан бөтен матурлыгы, тулылыгы белән кабул итеп, күңелендәге хис-тойгылары белән баетып, тамашачыга тапшыра белгән җырчы, «үзем өчен түгел, җырым өчен», — дип яшәгән, иҗат иткән җырчы. Ул яшәгән чор — гомумән, барлык иҗат кешеләре өчен дә сынау чоры, җәмгыять белән дә, аның кешеләре белән дә партия җитәкчелек иткән чор. Иҗатың да, килеш-кыяфәтең дә партия куйган таләпләрдән читкә тайпылмаска тиеш. Бу уңайдан халык арасында йөргән бер мәзәк искә төште. Җитмешенче елларда егетләр арасында озын чәч йөртү модасы булып ала. Илһам Шакиров труппасының Үзбәкстанда чыгыш ясаган вакыты икән. Үзбәкстан коммунистлар партиясе республика комитетына шикаять килә. Имеш, Илһам Шакировның музыкантлары сакал-мыеклы, озын чәчле...

Җырчыны республика комитетына чакырталар. Шикаять белән таныштыралар. «Ни өчен музыкантлар озын чәч, сакал-мыек йөртә?» — дип сорыйлар.

Җор телле Илһам ага югалып калмый, инструктор артында диварда эленеп торган Карл Маркс портретына ымлый да:

— Ана ярый, ә без кырынырга тиешме? — дип җавап бирә.

Төзегән репертуарында, чыгарган китабында партиягә дан булмаса, талантың «күмелеп» тә калырга мөмкин. Азмы халыкчанлыкның тамырына балта чабарга, моны аңламыйча, «милләтче» ярлыгы тагып куярга әзер торган түрәләр. Ул башкарган 300ләп җыр арасында заман рухын, аның яшәешен яктырткан җырлар да бар, билгеле. Әйтик, ул үзенең Юрий Гагаринның космоска очуын ишетеп тәэсирләнүен, бу олы вакыйганың җырда да чагылыш табарга кирәклеге турында уйлап, композитор Ә.Бакиров һәм шагыйрә Г.Зәйнашева белән ничек итеп «Галәм лачыны» дигән җыр иҗат итүләрен бер язмасында искә алып үтә. *«Дөрес, бу җырда тылсымлы шигъри образлар юк, ләкин, алда әйткәнемчә, җырда горурлык, совет кешесенә дан, бөек эшләргә чакыру яңгырый. Димәк, бу җырның дөньяга тууы бик табигый һәм кирәк. Тик бу һич тә оперативлыкка сылтап, халтурага урын бирергә кирәк дигән сүз түгел». («Социалистик Татарстан», 1964, 27 ноябрь).* «Иелгән башта таҗ тормас», ди бер акыл иясе. Чын иҗат кешесе, заман таләбеннән дә мәгънә таба белеп, Ходай тарафыннан кидерелгән Моң Таҗын да горур йөртә ала шул.

Илһам Шакиров иҗатының күп тармаклылыгы — берсе халкыбыз җәүһәрләре булса, икенчесе — эстрада җырлары, ана алып килгән яналыгы һәм композиторлык эшчәнлеген югары бәһаләп, сәнгать белгечләребез күп яздылар инде. Тыйнак шәхес буларак, Илһам ага үзенең композиторлыгын алга куярга яратмый. Ул иҗат иткән җырларның күбесе халыкныкына әйләнде инде. Хәер, халык өчен, мина калса, шигырь яки көй авторының кем булуы гомер-гомергә бик үк мөһим саналмаган. Иң мөһиме — җыр яшәсен!

...Юк, мин аннан бүген: «Кире кайта торган юл булса, яшьлегегезгә кайтыр идегезме?» — дип тә сорамадым. Яшьлек һәм Моң кабатлана алмый. Аны сагынып кына була...

**Гөлзадә БӘЙРӘМОВА,**
*Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре*

# МИЛЛӘТ ҖАНЛЫ АРТИСТ



«...Мине күрмәделәр, үстермәделәр, ярдәм итмәделәр, дип әйтә алмыйм. Миңа бөтен кеше ярдәм кулын сузды. Шуңа күрә үз көчемә ышандым да инде», — ди Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әзһәр Шакиров үзенең бер язмасында. — «Гомерем буе үз-үземә җан тынычлыгы таба алмыйча, үз-үземне кая куярга белмичә, яраланган кош кебек җәфаландым. Чөнки минем характерым шундый катлаулы, каршылыклы, эчемдә гел үз-үзем белән көрәш бара. Сәхнәдә — мине җәфалаган, гомеремне кыскарта торган уйлар, хыяллар берәзга онытылып торалар...»

«Әлбәттә, минем хыялларым тормышка ашмады, ә менә кайбер теләкләрем кабул булды», — ди ул шунда ук.

Әгәр шушы өзекләрне театрда Әзһәр Шакиров белән озак еллар бергә эшләгән хезмәттәшләренә бирепукытсаң, «Кем язган?» — дигән сорау куелса, һич икеләнмичә, Әзһәр икәнен әйтерләр иде. Һәр җөмләсендә каршылык, үз фикеренә үзе үк каршы килү сизелә.

— Әгәр бөтен кеше ярдәм кулы сузуы аркасында үз көченә ышангансың икән, нигә дип гомереӊ буе җан тынычлыгы таба алмыйча, үз-үзеңне кая куярга белмичә җәфаландың? — дип сорыйсы килә, әмма аның мондый сорауларга да җавабы әзер: «Мин татарның фаҗигасен аңладым, нишләп бу дәрәҗәдә түбән тәгәрәвенең асылына төшендем. Моңа йөрәгем бик әрни. Үз халкың белән горурлана белмә инде!.. Руска ялагайланып, түрә буласы килә. Татарлыктан оялып яшәдек».

«Татар акылы төштән соң», — диләр. Яһүдләр бердәм булып дәүләтләрен төзеделәр, ә без?.. Бөек татар халкы эчтән таркалып бара...»

«Татар үзенең фаҗигале язмышы турында уйламый, юк властьны бүлешеп иза чигә. Ялагайлык, аумакайлык көчле. Бәхәссез килешүчәнлек, дөреслекне әйтергә куркуыбыз каныбызга, җаныбызга сеңгән...» «Күпләребез аңлый: алда безне гаять зур сынаулар көтә... Заманнар үзгәрде. Очар кош ирекка омтыла... Читлектән ычкынып, аның очып китәсе килә...» «Мин хәзерге әдәбиятыбызда, шигърияттә, прозада, драмада кешенең дөньяны үзгәртүдәге ролен, халкы, милләте, азатлык өчен үзенең тормышын корбан итү дәрәҗәсенә күтәрелгән, күңелебездә яшәргә, көрәшергә өмет нуры уяткан чын татар улларын күрмәдем. Сүз йөзменнәрчә татар балаларының тиңдәшсез батырлыгы, үзләренең җанын, канын урыс дәүләтен саклап калу өчен бирүләре турында бармый. Сүз үз милләте, үз дәүләте хакына корбан булган, шәһит киткән татар балалары турында бара. Кая соң ул дәүләтебезнең, Казанның җимерелүе, меңләгән милләттәшләребезнең тере килеш яндырылуы турында җанны тетрәндергеч бөек драмалар? Яисә ханлыктагы югары катлам татарларының оятсызлыгы — балалы хатынны, дәүләтнең ханбикәсе Сөембикәне Явыз Иван карамагына коллыкка бирү турындагы? Ул үз иле, дәүләте, халкы хакына үзен-үзе корбан иткән дип әйтерләр. Чын ирләр хатын-кызны андый хәлгә

калдырмый, шундый дәрәҗәгә төшерми. Мондый гамәлнең фәкать бездә генә булуы мөмкин. Сөембикә турында бар дөньяны елатырлык искиткеч бөек трагедия язып булыр иде... Кая ул?

...Бөек тарихыбызга күз салсак, гаҗәеп язмышлар бар бит. Юк, юк талантлы драматурглар!»

...Әзһәр Шакировнның төрле елларда, төрле унай белән язган язмалары буенча төзелгән китабыннан алынган бу кайнар юллар аның эчке дөньясын «шыр» ачып күрсәтә, холкындагы пафос микъдарын да тулы чагылдыра, дулап китү гадәтенә дә ишарәли.

Артистның «хыялларым тормышка ашмады» дигәненә сәбәпне татар әдәбиятында, драматургиядә милләтнең фаҗигаләрен чагылдырган әсәрләр булмаудан күрсәк, ә менә кайбер теләкләре кабул булуы нәрсәдә күренә? Гомумән, артистның ният-теләкләре хыялларыннан, максаттан нәрсәсе белән һәм ничек аерыла?

Аның нинди теләкләр белән янып яшәвен дә без Әзһәрнең үз язмаларыннан укып беләбез: ул гомере буе идеяле, җаваплы зур рольләр кө тә, роль — аның иҗат кыры.

...Әйе, һәр артистның теләге — куелучы спектакльдә җаваплы роль алу. Ә рольне режиссёр бирә. Димәк, артистның язмышы —режиссёр кулында?! «Мина һәрвакыт начар геройларны уйнарга туры килде, бәхетсезләрне. Ә безнең тамашачы артистны роленә карап бәяли, образдан чыгып йә ярата, йә яратмый. Бәхетсезләрне уйнап, «елак артист» исемен алдым. Әмма моның икенче ягы да бар иде — «бәхетсез» булуым эмоциональ хатын-кызларга тәэсир итеп, мина тарта иде...»

Әлбәттә, моннан чыгып, мин, артист Шакировнның бар теләге — уены белән эмоциональ хатын-кызларны үзенә «тарттыру» гына булган икән, дигән фикергә килмим. Дискуссия, бәхәс яратучы кеше буларак, тамашачы күнелендә ул көткәнчә түгел, ә көтмәгәнчә гамәле, фикере, холкы белән тәэсирләрәк урын били.

Артист Әзһәр Шакиров катнашкан спектакльләр саны 100дән арта. Шуларда ул иҗат иткән сәхнә образлары уйнаган рольләреннән күбрәк булуы — аның иҗади потенциалын күрсәтүче факт. (Артистның рольне башкаручы гына булып калуы да гаеп була алмый). Яшерен-батырын түгел, профессиональ театрларда бер үк спектакльне озак еллар буе уйнау туйдыра да, арыта да. Әзһәр өчен «һәр спектакль яна, һәр роль — иң мөһим һәм бердәнбер», дип әйтсәк, «һәр» сүзен «күпчелек» сүзе белән алыштыру дөресрәктер. «Җанын бирер, сүзен бирмәс», диләр. Бу — нәкъ менә артист Әзһәр Шакировка карата әйтелгән кебек.

Аның белән эшләү җинел түгел. Авыр да түгел. Әмма азартлы, мавыктыргыч, нәтиҗәле. Режиссёр әйткәнне шунда ук эләктереп ала торган үткенлеге дә сизелми үзенең, житезлеге дә юк. Иң беренче реакциясе — ни әйтелсә дә, аны кабул итмәү, каршы у. Анализ, ревизияләрдән соң башланган бәхәснең нәтиҗәсе — «мин дә шуны сөйлим ич инде» дип тәмамлануда, пародоксаль финалда. Дөресен әйткәндә, мин һәр эшемдә, режиссёр буларак репетицияләр барышында, аны башка чакырмаска, дигән фикергә киләм дә, спектакль чыккач, фильм төшерелгәч, ана ихлас рәхмәт әйтәм. Нәтиҗәдә роль әсәр эчтәлеген дөрес ачкан булып чыга, режиссёр күргәнчә дә якын, Әзһәр Шакировча да. (Орлыктан үсемлек үстерелеп, ул үз орлыгын бирә, яна төр орлык барлыкка килә). Моннан соң куелачак әсәрдә дә, ул, режиссёрның төп актёры буларак, җаваплы роль алачак, цикл кабатланачак. (Талантлылыкка иң көчле дәлил).

...Билгеле булганча, һәр эштә артка борылып карау да, алга карап эш итү дә мөһим. Ә инде иҗади эштә исә оппонентың булуы — иң мөһиме. Һәр әйткәнгә ризалашып бару — сәнгатьтә иҗади пружинаны йомшартса, мактаулар исә оета, йокыга тарта.

...Бәхәсләр аша табылган хакыйкать кенә сәнгатьтә үз урынын таба.

Әзһәр Шакиров өчен бәхәсләшү, дискуссия оештыру үзмаксат түгел, ә бурыч.

Реалист иҗатчы буларак, ул бик аз гына микъдарда да фальшны кабул итеп, «түргә» уздыра алмый. Әзһәр өчен «Әйдә ярар, булган, житкән» дигән төшенчәләр юк. Аның үз-үзеннән канәгать булмавы да шулардан киләдер, мөгаен.

...Артист Әзһәр өчен татар кешесенең кыйммәте — милләте хакына, аның

хөр киләчәге өчен шушы бөек эшкә алынуында; милләтебезне саклап калуда, дәүләтебезне торгызу гамәлләрендә үзеннән лаеклы өлеш кертә алуында.

...Бу эшкә гомерләрен багышлаган шәхесләрне идеаллаштырып, шуларның сәхнә образларын тудыра алмау тынгылык бирми аңа. Чөнки артист иҗатына миссия дип карый ул, иҗатчыны миссионерга тиңли. Милләтебезнең тарих алдында һаман-һаман имтихан тотуына, дәүләт булып яшәвебезгә гарантия юклыкка борчыла; милли аңның түбән булуы, кол хәлендә яшәүгә күнеккәнлек аның җанын кимерә.

Әмма үзе, милләтнең йөзен аның әдәбияты, сәнгате билгеләвеннән чыгып, «театрыбыз дөрес юлдамы?» дигән сорауга туры җавап тапкан качып, идеаллар турында фәлсәфәгә күчә, гамәлне сүз белән алыштыра. Ихтимал, шунда — аның каршылыклар төенедер.

...Бүген театрларыбыз милләтебезнең кыйбласы, әйдәп баручысы, киңәшчесе, фикер юнәлешен күрсәтүчесе булырга тиеш, дибез. Бу — театрларның өлешенә чыккан язмышы, көмеше, миссиясе. «Шулаймы соң?» — дигән сорауга Әзһәр Шакиров кайчак: «Безне яраталар, мактыйлар, «афәрин, булдырдыгыз!» дип кул чабалар, рәхмәт әйтәләр, көтәләр, көләләр», — ди, сүз «кесәле» сиптерә. Шулай ул эзлеклелеген, миссионерлыгын киметә, миссионерның максаты иярту-әйдәү икәнне онытып, кайчак тамашачы зәвыгына иярә, хуҗасы булырга тиешлектән аның хезмәтчесенә (прислугасына) әверелә, үзен яраттырырга тырыша, яраклаша, бал биреп, шикәр көтә. Әмма ләкин театрның мәзәкчеләр урдасы түгеллеген белә торып, юнәлеш күрсәтү урынына күңел ачу уеннары оештыручыга әверелүе миссионер артистны эчтән кимерә, җанын бимазалый, борчылулар дингезенә сала. Артист бу хәлнең сизелүен сиздермәскә тырышып та ялгыша — сизелә шул.

...Театрның күңел ачу фабрикасына әверелүен кискен туктатып буламы? Юк — булмый. Бу шикәр диабетлы авыруны кинәт татлы әйбер ашаудан мәхрүм иткән кебек булыр иде. Димәк, шикәрне алыштырыр нәрсә табарга кирәк, табып булмаса — шикәрне оныттырырга кирәк.

Сәнгатьтә «шикәрне» оныттырыр нәрсәләр, әнә шул Әзһәр Шакиров тәкъдим иткән, аны борчыган милли проблемаларыбызны, милли каһарманнарыбызны сәхнәгә менгезеп, яңа сүз, проблемалы сүз әйтүдәдер, мөгаен.

...Мин үзем, мәсәлән, Әзһәр Шакировны, киләчәктә, Казан ханлыгын төзегән Олуг Мөхәммәд образын иҗат итүдә күрәм. Белеме белән дә, таланты, рухи көче белән дә ул моңа әзер.

...Сәхнәдә үзе теләгән олы шәхес образларын тудыруны көткән вакытны (аралыкны) бушка уздырмас өчен, бүген ул, кулына каләм алып, күргән-белгәннәре турында парчалар яза. Аларның һәркайсы дингез тирәнлегеннән табылган чын мәрҗән кебек затлы да, гади дә, ихлас та. Шулар белән дә ул милләткә хезмәтен дәвам итә. Шулар белән дә ул милләт хадиме дәрәҗәсенә лаек. Язмаларында — аның борчылулары, замандашларның матур киләчәккә өмете, ышанычы булмаудан. Максаты — сәхнәдә кеше язмышлары аша замананың шушы чирләренә диагноз кую, дәва табу, шифаландыру. Бирсен Ходай! Өметләнәбез!

...Егерме дүрт йортлы, бүген инде таралып беткән татар авылында үсеп, очраклы рәвештә генә театр дөньясына килеп кергән крестьян улының хыялына да китерә алмаган үрләр яулап, үз алдына шундый зур бурычлар куеп яшәве гаҗәпме? Гаҗәп түгел! Чөнки бу таләпләр безнең милләтебезнең җанында, хыялларында, канында.

Ата-анасыннан генетик юл белән күчкән бу васыятьне Әзһәр Шакиров миссия буларак кабул иткән икән, без — аның хезмәттәшләре — моңа һич тә гаҗәпсенмибез, шулай тиеш, шулай кирәк, дип аңа фатиха бирәбез. Үзе турында ул үзе нинди фикердә булуына игътибарыбызны кабат юнәлтик: «Үзең турында үзең чын дөресен язу — ифрат кыен гамәл... Мин яшәгән илдә артист кем соң ул? Тамашачыларны көлдерүче шамакаймы? Әллә фаҗигагә илтүче юлларны күрсәтеп кисәтүче инсанмы? Әллә милләтнең киләчәген юраган күрәзәчеме?

Һаман бер сүз: халкым — бар, дәүләтем — юк. Татар театрының урыс дәүләтендә урыны билгеләнмәгән. Ә бит татар халкы саны-исәбе белән Россиядә икенче урында. Академия театрыбыз югарылыгындагы һич югы ике-өч театрыбыз булганда да, тама-

шачыбызда спектакльләребезгә тансыклык бетмәс, калыр иде. Урыслашып беткән шәһәрләребездә татар үзен милләт итеп театрларда гына хис итә».

Әзһәр Шакировның истәлекләрендә, аның холыкфигылен ача торган мондый эпизодлар да бар: «...1970 елны Академия театрыбыз Мәскәүдә уңышлы гастрольләрен уздырды. Шул унай белән безне КПСС Үзәк комитетында кабул иттеләр. Бу хәл, хәзерге вакыт белән чагыштырганда, Рәсәй Президентының кабул итүенә тиң иде, артык булмаса.



*Р.Мөхәммәдиев. «Исәнлек өчен Гыйлемханга». Гыйлемхан ролендә — Ә.Шакиров. Мәсәй — Ш.Биктимеров.*

Очрашуны ачып: «Нинди теләк-сорауларыгыз бар, әйдәгез — уртага куеп, ачыктан-ачык сөйләшик», — диделәр. Иң элек сүзне директорыбыз Рәшидә апага бирделәр. Ул театрга яна бина кирәклеген дулкынланып сөйләде. Шуннан соң сүз баш режиссёрыбызга күчте. Ул, театрыбызның спектакльләрен чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезгә дә күрсәтү өчен, гастрольләргә чыгарга рөхсәт бирелүен сорады.

Габдулла абый Шамуков татарлар белән очрашуы турында белдереп, биш меңгә якын татар эшләгән заводның китапханәсендә бер татар китабы, газета-журнал булмавын, сәнгать-театр түгәрәкләре эшләмәвен сөйләде. Әгәр Мәскәүдә милләтләргә караш шундый икән, бүтән җирдә бу турыда әйтеп торасы да юклыкка басым ясап, игътибар ителү кирәклеген тәкрарлады. Мин шунда сүз бирелмәгән артистларыбызга, җитәкчеләребезгә карадым: барысы да ап-ак булып тын калганнар, Марсель Сәлимҗанов зәңгәрләнеп чыккан иде. Тынлык урнашты. Бер-беребезгә карарга куркабыз. Әгәр 15-20 ел элек булса, Габдулла абыйны атарлар иде, дигән уйда утырабыз. Шунда: «Менә хәзер яшь артистны тыңлап карыйк, бәлки, аның да сораулары, теләкләре бардыр, тартынып тормагыз!» — дип мина сүз бирделәр. Берәү булса, Партия Үзәк комитетына чакырып, яшьләргә шундый зур игътибар биргән өчен горурланып рәхмәт әйтер иде. Ә мин, торып бастым да, җанымны газаплап килгән, борчыган сорауларымның барысын тезә башладым.


Эш хакы, фатир, хезмәт һәм яшәү шартларының иҗат итү өчен яраксызлыгы турында чирек сәгать чамасы сөйләгәч, иптәшләремнең йөзенә карасам, бүртенеп, кызарып чыкканнар, берсе дә минем якка карамый. Минем сөйләгәннәремне ике секретарь язып барган икән. Кинәт сул күзем тартыша башлады, авызым кыйшая шикелле тоелды, күз алларым караңгыланып китте. Шунда: «Тынычланыгыз», — дип алдыма чәй, печенье куйдылар. Кая миндә чәй кайгысы! Очрашу беткәч нишләтерләр икән дип утырам. ...Барысы да чыгып, залда үзем генә калгач, Рәшидә апа: «Син сөйләгәннән үзгәрешләр булыр дисеңме?» — диде. Ә Марсель Хәкимович: «Моннан соң мин сине беркая да алып бармыйм!» — диде.

Алып барды! Кумадылар. Атмадылар. Эшләдек. Инде менә өлкәнәйдек. Финалга әзерләнәбез. Ул көчле булырга тиеш!

Кеше үзе турында ниятләре, хыялларыннан чыгып фикер йөртсә, иптәшләре, хезмәттәшләре аның турында эшләгән эшләреннән, поступокларыннан чыгып бәһа бирә.

Дөреслек — шуның уртасындагы уртаклыктыр, мөгаен»...

...Әзһәр Шакиров турында «Сер тотмас үрдәк» дип булмаса да, ул йомыкый, күңеле һәм теле бикле кеше түгел. Аның эчендәге — тышында булуы сыналган



*З. Хәким. «Күрәзәче». Хәнәви — Ә. Шакиров, Шәмсия — Р.Мотыйгуллина*

фактлар белән раслана. Ул фактларда танылган артист күп чак, үзе кыен хәлләрдә калып, анекдотлар туугa сәбәп була. Аның иң кыйммәтле һәм үзенчәлекле бер сыйфаты — ул, үзенә үзе читтән карап, көлә белә. Аның көлүендә нәрсәнедер, кемнедер хур итү, бетерү мотивы юк...

...Киләсе елга безнең аралаша башлавыбызга 60 ел була. Шушы озын-озак вакыт аралыгында Әзһәрнең «бу серемне сина гына әйтәм» дип кеше серен житкергәнен дә, кемнәндер сер алырга тырышуын да әйтүче булмас. Олыга да, кечегә дә яратып, үз итеп «үскәнем» дип дәшә ул. Миһербанлы булуы телендә дә, холкында да. Ул — гайбәткә катнашмаучы, теләсә кемнең бары тик яхшылык өчен генә яшәвенә инанган кин күнелле кеше.

...Аның турында гайбәтләр дә, төрле мәзәкләр дә күп, дидек. Шуларның икесен мисалга китермәсәм, язмам тулы булмаячак. Равил Шәрәфиевнең дусларча шаяруы:

*Щепкинчылар арасында*
*Иң яшебез син идең.*
*Иң акыллы, иң хәйләкәр,*
*Иң картыбыз син бүген.*

*Бу кушаматны кушадыр*
*Йә — мөкиббән, йә — куштан.*
*Әзһәр көтмәгән:*
*«Бөек» дип, үзенә үзе кушкан.*

Әлеге төртмәләрне капустникларда жырлауларны ишеткәндә, Әзһәрнең рәхәтләнеп көлүен күргән һәркем әйтә: «Бу кешенең күкрәге генә түгел, күнеле дә кин!» — ди.

Күкрәге кин, сулышы тирән, карашлары еракта, өметләре бары тик сәхнәдә генә аның! Ягъни яна спектакльләрдә хыялындагы рольләре белән яңа сүз әйтүдә. Ул әйткән сүзләрнең саллы булачагын без инде тәжрибәләрдән чыгып беләбез. Күрдек тә, ишеттек тә.

...Әгәр кирәк булса, шул ук югарылыктагы даирәләргә әйтер сүзләре һаман тынгы бирми аңа. Тик андый мөнбәрләргә бүген үтеп керә алу мөмкинлеге генә шикле. Соңгы сүз буларак, без шуны гына киңәш итә алабыз: Әзһәр! Синең сүз кайда һәм ничек әйтсәң дә ишетеләчәк. Әйт! Дәшми калма! Синең сүз — безнең сүз ул! Миллионнар сүзе. Синең сүзнең сәхнәдән янгыравын көтеп, имзам:

**Әхтәм ЗАРИПОВ** — *сабакташың, иҗатташың.*

# ӘТИ

Минә алты-җиде яшьләр чамасы булгандыр, мөгаен. Берзаманны малайлар белән кар атышып уйнаган чакта Фазыл:

— Әдһәр, Әдһәр, әнә бабаң килә, бабаң килә, — дип, мине үртәргә тотынды.

Мин әйтәм:

— Нишләп ул минем бабам булсын, минем әти бит ул! — дим.

— Бабаң инде, бабаң! Атаң булса, ул сугышта булыр иде. Безнең әтиләр, немецләрне кырып, чын герой булдылар! Ә бу синең бабаң.

— Юк, бу минем әтием! — дип, Фазылга ташландым.

Ә ул, «үтерәм» дип, минем өскә ташланды. Рушан белән Фаяз көчкә аердылар.

Чыннан да, мин дөньяга килгәндә, әтигә — 53, әнигә 43 яшь булган. Әтине ап-ак сакаллы, ап-ак чәчле, бер якка әз генә бөкрәеп торган кыяфәтле, жинел сәякле, зәңгәр күзле сурәттә күз алдына китерәм. Ә инде аның башка кешеләрдән аермасына килгәндә, шуны әйтә алам: күпме гомер сөрелгән дә, нинди генә кешеләр белән очрашып күрешелмәгән, ләкин аңа охшаш бүтән кешене күрмәдем; чөнки жәй көне эш эшләп тирләгәндә, аның уң ягы манма су, ә сул ягы коп-коры була торган иде. Әйтерсең лә кешене икегә бүлгәннәр.

— Әти, нишләп синең сул ягың коры, уң ягың манма су? — дип сораганым хәтердә калган.

— Әй, балакаем, безнең авылыбыз янганда, мин пожарник булып эшләдем. Шул вакытны салкын чишмәдән мичкәләргә тирләгән килеш су тутырганда, үпкәмә салкын тиде. Ике ай кан костым. Бер як үпкәм кан булып чыкты. Менә шуннан бирле шушындый чире калды инде, — диде ул.

Кышкы озын кичләрдә без тимер мич яга идек. Еш кына авыл яшьләре безгә җыелыша. Чөнки авылда клуб та, җыелып утырырлык нindидер бүтән урын да юк. Әти кызык-кызык хәлләр сөйләргә керешә. Гомумән, ул сүзгә оста кеше иде. Шуларның берничәсе хәтергә уелып калган. Авылда көзге эшләр беткәч, ир-ат егетләр бераз акча эшләү өмете белән Донбасска күмер чабарга чыгып китәләр икән. Әнә шул Донбасс турында сөйләгәне минем өчен иң кызыгы иде.

Әти әйтә:

— Мин шахтада сукыр атлар белән эшли идем, — ди.

— Әти, ул сукыр атлар җир астына ничек төшәләр соң? — дип сорыйм.

— Улым, алар башта сукыр булмыйлар, бер-ике ел җир астында эшләгәч кенә сукыраялар.

— Әти, сукырайгач та эшлиләрме?

— Без аларның арбаларына күмер төйибез дә әкрен генә алларыннан җитәкләп барабыз, алар безгә ияреп.

Мин исә әлеге сукыр атларны күз алдына китерәм дә, мөлдерәп күз яшьләре килә, еларга ук тотынам.

Әнкәй әткәйне:

— Төнгә каршы шундый әйберләр сөйләмәсәң, бүтән әйтер сүзең беткәнмени? — дип тирги.

Ә яшьләр:

— Шәфыйк абзый, урысларның акча алгач, ничек эчкәннәре турында да сөйлә инде, — дип аптырата.

— Аның нәрсәсен сөйлисең? Айга бер мәртәбә акча бирәләр. Менә шул көнне ата — улны, ана кызны белми. Җыелышып эчәләр дә сугышырга тотыналар иде. Кеше гомерен чебен урынына да күрмичә. Мин акча алган көнне ничек булса да читтә үткәрергә тырышам, чөнки араларында мин иң карты. Баракка кайтып кергәч күрәм: кайсысының кулы сынган, кайсысының күзе, иреннәре кара янган. Яман сүгенәләр, ыңгырашалар, хәтәр сугыштан чыккан бандитлар белән бер.

— Шәфыйк абзый, теге... балык тотканың турында да сөйлә инде, — дип, яшьләр әтинең теңкәсенә тияләр.

— Без Златоуст шәһәре тирәсендә урман кисәбез — Себер якларында. Шулай кисә торгач, бер күл буена килеп чыктык. Туктале, минәйтәм, шунда мурда салып карыйм әле, дим. Күл буендагы таллардан мурда үреп салдым. Эш беткәч, сак кына тартып чыгарган идем, кәрәкә балыгына шыплап тулган бу. Хәзер нишләргә инде? Иптәшләрем торакка кайтып киткән, янымда һичкем юк. Караңгы төшеп килә. Күлмәгемне салып, җиңнәрен төйнәп бәйләп куйдым. Әлеге йөгемне иңгә салып, кайтыр юлга төшү белән үк, бөтен тәнемне черки сырып алды бит. Нишләргә белмим, учым белән битемә шап-шоп сугам. Бара-бара күзем күрмәс булды. Ничек чыкканымны хәтерләмим. Бөтен тирәмдә корт күчедәй черки безелди. Үләм икән, мин әйтәм, кайталмыйм икән бит болай, дим. Яфраклы ботак белән черки өерен куам. Ә тегеләр аның саен котырына, бөтен тәнемне сырып ала. Хәзер инде мина балык комачаулый, аларны берәм-берәм ташлап калдырудан башка чарам юк. Мина күзгә төртсәң дә күренмәс караңгы сыман булды, һични күренми. Бер күземне ачып карыйм — юлымнан язган шикелле тоела. Шунда кылт итеп исемә төште: урманда кешеләрне җәзалап үтерү өчен йә кырмыска оясына, йә черкиләргә бәйләп ташлыйлар икән, кеше, түзә алмыйча, бер көндә һәлак була ди. Хәзер инде мин шуна тәмам ышандым. Инде нишләргә дә белмичә аптырап торганда, мина кычкырган тавышлар ишетелде сыман. Акылымнан шашкан кебек: «Ярдәм итегез, ярдәм итегез, үләм-үләм!» — дип, бөтен көчемә кычкыра башладым. Шуннан ни булганын хәтерләмим, ике көннән соң гына аңыма килдем дә үлемнән котылып калганымны аңладым.

— Әти, — мин әйтәм, — балыкларыңны кая куйдың соң?

— И, балакаем, ул вакытта миндә балык кайгысы идемени? Әти белән әни бәхетенә исән калганмын дип, Ходай Тәгаләгә мең-мең рәхмәтләр укыдым.

Театрдан ял акчаларын алып, иптәшләр белән җыелырга дип өйгә кайтсам, Җәннәт ападан хат килеп төшкән: «Балакаем, кайт, әтинең хәле авыр, сине күрәсе килә», — дигән. Бик кайтыр идем дә, акча яклары такыррак шул, ничек булса да бераз акча эшләп алырга кирәк иде. Берәр концерт бригадасы юк микән дип сораштырып карыйм, юк, барысы да җыелып, бергәләшеп беткәннәр, бер җүнле кеше дә калмаган. Шунда Миргалим Харисов:

— Әйдә, Искож клубы белән чыгабыз, — диде. — Көненә ун сум түлиләр, квартирный юк, ашау колхоздан.

— Мин үз исемем белән чыкмыйм, исем-фамилиямне алыштырам, — мин әйтәм.

Сәхнәгә Рәшит Гарифуллин исеме белән чыктым. Концертны алып баручы матур гына бер кыз: «Хөрмәтле тамашачылар, сезнең алдыгызда — Искож клубының танылган җырчысы Рәшит Гарифуллин, кул чабып каршы алыйк. Ул сезнең яраткан иң матур җырларыгызны башкарачак. Тарсынмагыз, бердәм кул чабыгыз, монда кулларыгызны җәлләп, бер-берегездән оялышып утырмагыз. Артистларны дәррәү килеп, кул чабып каршы алалар аны», — дигәч, сәхнәгә килеп чыктым. Кул чабып каршы алучы юк. Бу авылның театр-концерт күрмәгәненә 15-20 ел узгандыр, дип сөйләделәр. Без Алексеевский районындагы иң «караңгы» татар авыллары буенча йөрдек. Монда ни филармониянең, ни күчмә театрның булганы юк икән. Шунда сәхнә артына матур гына киенгән бер укытучы килеп керде дә миннән:

— Сезнең абыегыз артист Шакиров түгелме? Мин академия театрында сезгә охшаган бер артистны күргән идем. Сез шуны бик хәтерләтәсез, — дип сорады.

— Юк, — мин әйтәм, — академия театрында минем абыем эшләми, ләкин миңа охшаган бик талантлы бер артист бар дип сөйлиләр.

— Шул Шакировның туганы булсагыз, мин сезне үзебезгә кунакка чакырмакчы идем. Бик кызганыч болай булгач, хушыгыз инде, — диде дә китеп барды.

Соңыннан: «Нигә инде шунда мин аның бертуган энесе дип әйтмәскә? Хәзер менә кунак булып, җырлап утырыр идем», — дип үкенеп куйдым.

Егерме концертка 200 сум акча кулга алгач, егетләрне карта уйнап откан акчага җыелышып кунак булып, әти белән үги әни янына кайтып киттем (әни күптән вафат иде инде).

Минем каршымда чәче житеп үскән, ап-ак сакал-мыегы кырылмаган, йөзе саргая башлаган, бөкресе тагын да калкарак төшкән, артык нык ябыккан әтием басып тора иде. «Улым!» — дип күрешкәч, эчем жу итеп китте. Ничектер ул минем әтием кебек түгел иде: мин аның бөтен тәне генә түгел, ә бәлки жаны да үзгәрүен тоеп өлгердем.

Мин әйтәм:

— Нишләп чәченне алдырмадың? — дим.

— Сине көттем, — диде ул.

Тиз генә су жылытып, чәчен такыр итеп кырып алдым, сакал-мыегын пөхтәләп төзәттем, жылымса су белән муенын, аркасын юып төшердем. Әти хәл алып, рәхәтләнеп китте.

— Улым, — диде ул, — иртәгә мине Азнакай больнисына алып бар әле.

— Ярый, — мин әйтәм, — бензин ташый торган машинасында абый кайта, шуның белән иртүк барырбыз.

Икенче көнне Азнакайның баш табибы янына килеп кердем.

— Исәнмесез! Мин артист Шакиров булам. Минем әти бик нык чирли, ярдәм итегез, — дим.

Ул мина карап торды да:

— Мин жырчы Шакировны беләм. Ә син кем буласың? — дип сорады.

Мин әйтәм:

— Илһам Шакиров филармониядә эшли ул, ә мин — артист Шакиров, академия театрында эшлим. Филармония белән академия театрының дәрәжәсен дә белмәгәч, син ничек баш врач булып эшлисең монда? Бу турыда сөйләсәң, үзенне мыскыл итеп көләрләр бит. Бик кызганыч кебек булып чыктың әле, артист Шакировны белмим дисең!

— Ярый, ярый, бу турыда оныттык, — ди. — Әтиең кайда?

— Апаларда калып торды, кирәк икән, хәзер үк алып киләм.

— Әтиең ничә яшьтә?

— Сиксәннән өстә, кече йомышын үти алмыйча интегә.

— Ярый алайса, безне өегездә көтеп торыгыз, көндезге аш вакытында килербез.

— Бик зур рәхмәт мине хөрмәт итүегезгә, менә адрес, — дип чыгып киттем.

Кайтып, тиз генә аш куйдым, мунча ягып жибәрдем, жизни кабымлыклар әзерли башлады. Табибларны көтәбез. Шул арада әтине мунчада бик яхшылап юындырдым да, чиста күлмәк-ыштан киендергәч, диванга яткырдым.

Кичкә кырын гына табиблар килеп керде. Әтине карагач, үзләренчә киңәштеләр, ягъни консилиум оештырдылар.

— Бик өлкән яшьтә, операцияне күтәрә алмас, — диде хирург. Аның белән уролог та килеште: — Хәзер моның сидеге тәненә тарала башлаячак.

Ә терапевт әйтә:

— Дарулар белән ярдәм итеп булмас микән? — ди.

Янадан әти янына керделәр дә:

— Бабай, яшең бик өлкән, шуңа күрә сиңа операция ясамаска булдык. Менә, әкрен генә үләннәр, дарулар белән чәй эчәрсең. Хәлең авырайса, шалтырат, килеп алырбыз, — диделәр.

...Яхшы гына итеп сыйлангач, терапевтлары мина:

— Бездә дару бар инде ул, син главврачтан сорап кара әле, — дип куйды.

Мин исә бераздан баш табибтан:

— Сездә әтигә ярдәм итәрлек бернинди дә дару юкмыни соң? — дип сорадым.

— Бар инде ул, тик санаулы гына. Без аны райком секретарьларына, райисполком председателенә, прокурорга гына бирәбез, — диде ул.

— Болай булгач, первый секретарьның үзенә керергә туры килә инде. Ул мине белә, үзем сөйләшермен, — дидем мин.

Шуннан соң баш табиб, шофёрын жибәреп, әлеге даруны мина бүләк итеп бирде. Польшада эшләнгән дару икән. Башта чиреген генә, аннан соң яртысын, икенче көнне бер бөтенне кабасы икән.

Мин, зур рәхмәтләр әйткәч, тагын да сыйларга сүз биреп, табибларны озаттым. Мин кергәндә, әти теге дару төймәсен бөтен килеш капкан да куйган. Төн буена берөзлексез кысталып, жәфаланып чыкты.

— Үләм, балакаем, нигә эчтем икән? — дип, тәмам өзгәләнде.

— Нигә бер бөтенне эчтең, алай кушмадылар ич сиңа.

— Түзмәдем инде. Тизрәк ярдәм итмәсме, янәсе...

Ике-өч көн узгач, әти мине үз янына чакырып алды.

— Кил әле, балакаем, утыр әле яныма, — диде ул. — Сиңа әйтәсе сүзләрем бар иде... Мин үлгәч, әниең белән минем каберләрне карарга тырыш. Юкса Шәфигулланың балалары әти-әнисенең каберен дә карый белмиләр дип әйтерләр. Үзеңә бик уңайсыз булыр, кеше алдында абруең төшәр. Азнакайда күрдем сиңа ничек караганнарын, авторитетың бик зур икән. Аны сакла, бер югалтсаң, гомереңә буе үкенерсең... Бәйрәмнәрдә әниең белән мине искә алып, хәер бирергә онытма. Хәер бирсәң, җаның тынычланыр, әниең белән мине искә төшерерсең. Шул чагында кылган гөнаһларыңны ярлыкавын бер Ходайдан сора. Миңа әле исемә төште: үткән көз көне Буралыдан җомга намазыннан кайтканда, бурильщиклар казыган чокырга ялгыш аягым таеп төшеп киттем. Үзең беләсең, хәзер бит минем күзләр начар күрә, чокырны абайламаганмын. Ә чокыр бик тирән булып чыкты. Аяк астында нефтьле су иде. Мин чокырдан чыгарга тырышып карыйм. Күтәрелгән саен аяк тая да китә, тая да төшә. Кул белән тотынырлык бер әйбер юк. Бик озак азапландым. Бу юлда кеше йөрми инде, мин әйтәм, шушында көз көне үлеп калам икән дип уйладым. Бөтен гомерем, бөтен яшьлегем күз алдымнан узды. Ходай Тәгалә минем җанымны алырга шушы урынны табып әзерләгән икән, дип уйладым. Әх, мин әйтәм, балаларымны күрмичә, бәхилләшмичә, шушында үлеп калам икән дип, җан ачысы белән кычкырган сыман булдым. Белмим, мине нинди көч этәргәндер инде, үз-үземне белештермичә көчәнгәч, чокыр кырыена менеп ятканмын. Сөенечемнән мөлдерәп яшем ага. Әллә, мин әйтәм, Ходайның фәрештәләре күтәреп чыгарганмы? Бу бәладән нинди кодрәт белән котылдым дип, җылый-җылый Ходайга рәхмәтләр укыдым. Әҗәлең килеп җитмәсә, гомерең бетмәсә, Ходай Тәгалә яшәргә көч бирә икән. Хәзер инде, балакаем, менә мин үләм, озак яшисем калмады. Кулыңнан килгәнне эшләдең, рәхмәт сиңа...

Мин түбән караган килеш бер сүз эндәшмичә утырам, күземнән бертуктаусыз яшь ага. Мине укытыр өчен Чалпы мәктәбенә — 175 сум, фатирда тотар өчен аена 30 сум акча түләп, егерме чакрымга бер йөк утын китереп, ашатып, киендереп, бөтен рухымны, көчемне укырга бирсен дип, җан атып йөрде. Гомеремдә мине авыр сүзләр әйтеп тиргәмәде, сукмады, кулын күтәреп беребезне-бер рәнҗеткәне булмады. Үз гомерендә биш вакыт намазны калдырмады; яңгыр диме, кар диме, дүрт чакрымдагы Буралыга җомга намазына йөрде. Югыйсә аңа инде 87 яшь иде. «Аллаһы Тәгаләгә ышансаң, үлемне җинел кичерерсең, үлемнән курыкмассың», — дия торган иде ул. Чыннан да, Ходай Тәгаләнең барлыгына ышанган кеше үлемне җинел кичерә, диләр.

...Арча төбәгендә Хәй Вахитның «Мәхәббәтең чын булса» әсәре нигезендә куелган спектакльне уйнарга әзерләнәбез. Аны районның беренче секретаре карый, Хәй абый банкет ясый икән дип, барыбыз да күтәренке күнел белән кичке мәҗлескә әзерләнәбез. Ул вакытта банкетлар бик кадерле, чөнки аны киң күңелле авторлар гына эшли иде. Шунда театрыбызның директоры Рәшидә апа Жиһаншина телефоннан чылтыратты: «Әзһәр, әтиеңнең хәле авыр, кайтып җитсен, диделәр. Ничек уйлыйсың, бүгенге спектакльне отменять итәбезме, әллә инде иртәгә генә кайтырсың микән?»

Белмим, нишләптер спектакльдә катнашырга булдым. Бәлки билетлар сатылып бетүен, бүген «хуҗаларның» тамашага килүен, Хәй абыйның банкеты булуын искә алыпмы, шушындый матур көнне артистларның күңелләрен төшерергә көчем җитмәгәнгәме, спектакльне уйнадым, банкет та булды. Ә төнлә үземне кая куярга белмим: нишләп мин мондый начар эш кылдым дип, үземнең җанымны, йөрәгемне талыйм, җүнле кеше мондый эшне гомер эшләмәс дип, үз-үземне битәрлим, сүгәм.

Икенче көнне «Әтине җирләдек» дигән телеграмма килеп төште. Хәзер соң инде: шагыйрь әйтмешли, үкен, ул син, җыла! Барыбер мәңге төзәлмәслек хата.

**Әзһәр ШАКИРОВ,**
*2005 ел, апрель*

# ЯХШЫ ГАМӘЛ ЗАМАНЫ УЗДЫМЫ?

***Бу язмам Касыйм Гыйният улы Гафиятов рухына багышлана.***

Нәрсә язарга ниятләвемне белгән хәлдә һәм ошбу язмама исем сайлый-сайлый утырган чакта, Гамил Афзалның каһкаһәле бер шигыреннән ике юлы искә төшеп, көлеп җибәрдем. Нәрсә дигән әле?

*Бөтен халык Алла юк дип кычкыра.*
*Димәк, бер вакантный урын буш тора!..*

Инде менә Алланың барлыгына шиге калмаган, шактый иман утырткан халкыбыз еллар буе башка сүзләр кычкыра.

– Хәзерге түрәләрнең, байларның аналарын сатыйм! Шәфкать, мәрхәмәт, игелек дигән нәрсәләр калмады аларда. Безнең кебек гади халыкның хәле турында уйлый да белмиләр, яптырмалахайлар – миллиардлар өстенә миллиардлар туплыйлар. Үзләренә генә булсын!..

Сүгенә-сүгенә кычкырып сөйләүчеләрнең сүзләрен тынлаганда, бер күршем тыныч кына үз фикерен кыстыра:

– Кәкүй монда байлар, түрәләр генә! Үзебез дә бозылып беттек бу саташкан дөньяда. Әле үткән атнада бер пләмәшемнән ишегемә йозак куйдырдым. Эшен бетереп, кулын юганда әйтеп тә куйды: «Давай, әзи, яртынны чыгара тор. Бу йозакны юып алырбыз!» Мин әйтәм тегенә: «Мин бит бушлай куярсың дип уйлаган идем...» Сүземне әйтеп тә бетермәстән, шаркылдап көлде теге:

– Андый заманнар узды, әзи! Сыер да бушлай мышнамый хәзер. Капитализмда яшибез. Чыгар бер шешәңне!

Ул арада 85ен үткән, коммунизм төзим ди-ди эшләп, хезмәт ударнигы да булган, көчәнә торгач, аяклары да камытланган әби килә янәбызга.

– Йә, Банат апа, саулыгың ничек? – дип сорыйм, гадәтемчә.

– Үләр вакыт җитте. Тагын да яшәсәм, кабергә дә урын калмас сыман. Әнә бит, хәзерге алпавытлар хуҗа булып бетте җиргә.

Мондый сөйләшүләр вакытында хәлләренә кереп тә, сүзләрен хуплап яки сүзсез генә елмаеп та тынлыйм кешеләрне. Дөрес зарланалар чөнки... Шул ук вакытта, бер тәлинкә тары арасыннан энҗеләр дә тапкан тавык сыман, үз Минзәләмдә бөтенләй үк салып таптамаслык эшмәкәрләрне беләм, сирәк-мирәк булса да юньле, халык алдында адәмчәлек белән танылган җитәкчеләрне дә беләм. Кайберләрен үз яшьлегемдә күп күзәткән, игелекле булуы белән районга танылган бер шәхесне – Касыйм Гафиятов дигән колхоз башлыгын да бик еш искә төшерәм. Командировкага да ешрак барырга тырыша идем аның колхозына Минзәлә газетендә эшләгән яшьлек елларымда. Һәр баруымда ниндидер гыйбрәт ала идем шуның кылган гамәлләреннән. Рәхимсез, текә холыклы, күнел кайтаргыч түрәләрне күп күргән кеше буларак, күңелемдәге күгәрек-юшкыннардан чистарыну өчен бара идем аның янына...

### Куылган ирне кайтару

Шушы Гафиятовның кабинетына печән, салам кисәкләре дә ияргән иске телогрейкалы, бүрек колакчыннарының берсе өскә күтәрелгән, икенчесе җилкәсенә төшеп торган бер агай килеп керде. Баскан урынында таптангалап торды да, менә-менә елап җибәрердәй тавыш белән сүз башлады:

– Колхозың да, авылың да бик ошады... Үзең дә сагындырырсың инде... Әмма да ләкин китәргә туры килә бит инде, Касыйм энем. Шуны әйтергә кердем янына...

– Сәбәбен әйт, абзый. Сине бит монда бөтен авыл ярата, үз итә. Кая китмәкче буласың?

– Барыр җирем дә юк, беркайда да көтеп торучым да юк. Ләкин хатынның пәрмәпәр килүенә, син килмешәк белән тормыйм, бар, каян килгәнсең, шунда чыгып кит, дип көн саен тавыш чыгаруына, колак итен чәйнәвенә чыдашлы түгел. Шулай, энем, кирәгем калмады... Килгән җиремә – төрмәгә китәр идем дә бит, анда да кабул итмәсләр. Кабат утырырлык гаебем, гөнаһым юклыгын үзең дә беләсең...

Персидәтел монсу карашын агайның йөзенә төбәгән хәлдә тыңлады тегене. Шул мизгелләрдә икесенең дә күзеннән яшь чыкты сыман. Үземнең дә күз чыланды бу агайның мескен хәлдә калганлыгын аңлаудан.

– Аңладым, абзый, хатыныңа кирәгең калмавын... Ә син миңа кирәк, колхозга да кирәк! Мин сине беркая да җибәрмим. Тормышыңны яңартып, монда яшәячәксең.

– Кунар урыным да калмаган килешме?..

– Менә син, абзый, авылның иң читенә салынган яңа йортны күреп йөрисенме?

– Теге таш йортнымы?

– Әйе, шуны... Кем өчен салдырдым дип уйлыйсың аны?

– Колхозга килеп эшләячәк берәр нәчәнник өчендер инде... Бигрәк кәттә йорт бит...

– Юк, абзый, синең шушы хәлдә каласыңны белеп, синең өчен салдырдым мин аны. Менә шунда күчәрсең. Ачкычын Әрчәгә биргән идем, аның белән бергә барып ачарсыз. Дөрес, анда ятар нәрсә дә юк хәзергә. Бәләкәй генә сәке булса да ясап куй. Ә мендәрен-түшәген, матрасын дигәндәй, яңа хатының алып килер... Ике-өч урындыкны моннан да табарбыз.

Агай тәмам аптырашта калды. Карашында кырыкмаса-кырык сорау барлыгы сизелсә дә, шуларның берсен булса да әйтә алудан гаҗиз хәлдә иреннәрен мимылдаткалап торудан уза алмады. Ул арада Гафиятов баш хисапчыны чакырып кертте:

– Бу абзыйның биниһая кыен хәлдә калган чагы, Нәкыйп. Иң яхшы итне өченче сорт бәясе белән биргәләп торырсыз. Ул фермаларга күз-колак булып, андагы койма-киртәләрне дә төзәткәләп яшәр.

Аннары:

– Бар, абзый, яңа йортыңа хуҗа бул, берәр атнадан үзем дә хәлеңне белеп чыгармын, – диде.

Агай чыгып киткәч, рәхәтләнеп көлдем. Моңа кадәр Тукай шигырендә генә күренгән «биниһая» сүзенең колхоз башлыгының авызыннан бик матур булып чыгуыннан иде бу көлүем. Аннан соң теге агайның бу авылга ничек килеп эләгүен Касыйм абый үзе сөйләде. Шушы Кадрәк авылының бер кешесе Гафиятов эшли башлаганчы төрмәгә кергән булган һәм анда шушы Салихҗан (исеменең хәтердә дөрес сакланмаган булуы да ихтимал, чөнки бу хәлдән соң ярты гасыр үтеп киткән) белән танышып, бергә кайгырышып, уфтанышып сөйләшә торган булганнар. Салихҗанның әледән-әле зарланганы бар икән казна йортында: «Менә берничә айдан срогым тула. Чыгарырлар инде... Кая барып егыласымны да белгән юк...» Кадрәк кешесе ирләре сугышта кырылган чәчбикәләрдән берсенең адресын биргән. Менә шуның белән хат алыша тор, бәлки, кавышырсыз, дигән. Кадрәк белән төрмә арасында хатлар йөри башлаган. Чакырган тегене бу хатын. Ике-өч ел сөенешеп, тату булып яшәгәннәр. Ир дигәне балта остасы булгач, таралып яткан ихатаны сандыктай төгәллек белән коймалаган, йортын да курчак йортыдай итеп, нәкышләп, вак такталар белән «теккән». Ләкин, тора-бара, әллә эрәеп, әллә кадере артудан башы әйләнеп, куу турындагы кырын сүзләре белән тинтерәтә башлаган икән моны хатыны. Мин, район гәҗите хезмәткәре, шул гаугалар тәмам куерып житкән көннәрдә килгәнмен икән бу юлы. Әйткәнемчә, еш килә идем бу авылга. Чираттагы баруымда Салихҗан хакында Касыйм абыйдан кызыксынып сорадым...

– Бик ягымлы, чибәр дә, теге хатыныннан күпкә яшьрәк тә, бозаулар караучы хатын алып кайтып бирдем Тупачтан. Яшәреп китте абзый! Чөнки күргәләгән чакларында үзе дә сокланып йөргән булган ул хатынга. Көн саен кырынып, хушбуйлар да сөртеп йөри хәзер. Җефете дә Кадрәк фермасында... Тик менә теге куып йөдәткән хатыны йортларының тәрәзәсен таш атып чәлпәрәмә китергән көнләшүдән, шомлык. Әйттем ана, урамда очрагач. Апа, дидем, үзең куып чыгарган иргә зыян салма, тагын шулай кылансаң, монә кадәр милициягә бер чакта да йомышым төшмәсә дә, төшүе бик ихтимал, дидем. Хатын-кыз бит ул башта нидер кыла, шуннан соң гына ни кылганын уйлаучан була... Ирләр арасында да юк түгел кыска акыллылар...

## Шофёрлар «грозасы»ның улы белән танышу

Минзәләгә кайтып төшү белән, туп-туры гәҗит редакциясенә барып керү гадәтем бар. Бу кайтуымда да (октябрь ахырында) шул якка тәпиләдем. Килеп җиттем дигәндә генә бер кордашыма тап булдым. Куллар кысышып, хәл-әхвәл белешкәч, сорап куям:

– Бу кайтуымда игелекле кешеләрне барларга ниятлим... Бармы алар безнең Минзәләдә?

Капыл гына соравымнан кызык тапты кебек, көлемсерәп торды да:

– Очраштыралар... Әле менә мәчеттән кайтып барам. Бер егет үзенең эшчеләре белән шундый отделка... әйе-әйе... шундый бизәүләр башкарткан мәчетнең эчендә, карап, күреп, сокланып туймаслык! Чын сәнгать инде мәгәр!

– Соң, – мәйтәм, – акча эшләтә инде ул. Казанда да күп оста шабашниклар...

– Юк-юк, бушлай эшләгән икән ул аны. Корбан бәйрәмендә бүләк иткән шул гамәлен. Хәзрәтләр шулай диләр...

– Берәр әүлия нәселеннән микән әллә ул егет?

Кордашым тагын көлә:

– Хәтереңдә микән, Балакаев милиция начальнигы булып эшләгән заманда Сабиров дигән ГАИ башлыгы бар иде...

– Истә. Аны шофёрларның грозасы дип йөртәләр иде.

– Сүзең дөрес үк түгел... Лихачлар грозасы, диләр иде аны. Ул заманда мин үзем дә рульдә булдым. Тәртипле шофёрларга каты бәрелмәде ул, мәрхүм. Ну, шулай да, салмыш көе масаеп, тизлекнең чамасын белмәүчеләрне яшендәй көйдерә иде, мәгәр! Шул Сабировның Фаил исемле улы матурлаган мәчетебезне.

Редакция егетләре, кем әйтмешли, момент аңлап алдылар да, телефон аша чакырдылар да Фаилне, каршыма утыртып та куйдылар. Хәтта баш редактор Илдус Шәһиев үз кабинетын калдырып чыкты, иркенләп сөйләшегез, дип. Ләкин, ишек ябылуга ук, Фаил әйтеп куйды:

– Әйдә, абый, кыска тотыйк әле сүзне. Эшләр күтә. Әле мәчетне бизәгәндә, август аенда, мәктәпләрне тәртипкә китерү эшләренә дә өзелеп тордык. Уку елы башланганчы анысы мөһимрәк саналды. Шул ук вакытта мәчетне дә Корбан бәйрәменә өлгерттем.

Карап торышка гап-гади ир-егет икән бу Фаил Сабиров. Кайберәүләр арасында очрый торган геройлык күрсәтү яки мактану нияте дә юк. Базасында теләсә нинди төзелешләрне дә башкарып чыгарлык техникасы да барлыгын аңлагач:

– Әйе, игелекле егет икәнсең, энем. Ләкин синдәйләр юк санында шул... Сараннар күп...

Ризалашып бетмәде фикерем белән. Сәгатенә күз төшереп алды да:

– Алай ук димә, абый. Үзең дә беләсең, дөнья, нигездә, кара һәм ак төсләрдән тора. Кара күңелле кешеләр булган кебек, ак ниятле, ак һәм саф фикерле кешеләр дә бар. Караны күпме генә агартырга тырышсаң да, акка әйләнми ул. Алары бер чакта да ярдәмле булмаслар. Ләкин безнең Минзәләдә ак ниятле эшмәкәрләр күбрәк күренәчәк. Әле аларның шактые бизнесларын ныгыту чорын кичерә, – диде. – Алар да мәңгелек түгел икәннәрен, дөньялыкта чакта туган якларында, кешеләрендә яхшы истәлек калдырырга кирәклеген аңларлар.

Фәлсәфәсе ошады. Уйландырырлык булып та калды. Әнә бит, шул ук мәчетнең бер дәлиле үрнәк. Аны 1910 елда Миңнегәрәй Сәетбатталов дигән зур сәүдәгәребез салдырып, Минзәләсенә бүләк иткән. Йөз елдан артык вакыт үткән, ә исеме якташларымның теленнән төшми, җәннәтенә рәхмәт яугыры! Үз тамагыннны гына кайгырта-кайгырта, корсагына тәмледән-тәмлене тутырып, шуны көн саен ләззәт илә бушатып кына гомер кичерсәң, вә һәм дә ахыр житеп, аягыңны сузсаң, Минзәләнең ягымлылык белән танылган халкы да туп-турысын ычкындыра:

– Катты, ысбулыч! Күзенә туфрак төшкәч кенә бирәне тыгылды капсайотарнын!

Хәер, Фаилнең фикерләренә тирән кереп китеп, үзен онытып җибәрә язганмын түгелме соң? Ул бит әле каршымда утыра!

– Эшчеләрең күңел биреп эшлиләрдер. Мәчетне бик матурайган, диләр.

– Кайгыртсаң, хезмәтләренә канәгать калырлык акча бирә торсаң, барысы да әйбәт эшлиләр. Ә инде мәчетнең матурмы-түгелме икәнен белү өчен, үзең күрүгә житми.

Барлык сөйләшүебез ун минуттан да артмады сыман – урыныннан купты да:

– Әйдә, абый, сине мәчеткә кертеп калдырам да үз эшемдә булам, үпкәләп калма.

Ничава, үз кадерен дә белә икән бу Фаил – затлы машинасына утыруга ук кузгалып та киттек һәм ... минут та үтмәгәндер, мәчетнең капкасын ачтык. Аннары имамы һәм мөхтәсибе каршына килеп тә бастык.

Һәй-йе!.. Моңа кадәр кергән чакларымда да ямьле, матур булып тоела иде фамилиядәшем төзегән мәчет, хәзер килеп, илаһи нур иңгән сыман! Идәне, диварлары астан җылытыла икән хәзер. Баскычлары да яктырту җайланмалары белән бизәлгән. Ишекләренең һәркайсы үзенчәлекле сәнгать сыман игътибарыңны җәлеп итә. Фаил, саубуллашып, үз юлы белән китеп баргач, район мөхтәсибе Җәүдәт хәзрәт Харрас белән фикерләшеп алдык. Бераздан болай дип сорап куйдым:

– Кылынган игелекнең акча белән үлчәнмәскә тиешлеген беләм-белүен, ләкин саран эшмәкәрләр акчага табынган чорда минем соравымны гаеп итмәссеңдер... Әйт әле дөресен: бу кадәр затлы ремонтны шабашниклардан эшләткән булсагыз, күпмегә төшәр иде?

Мәчеттәге сокланргыч үзгәрешләренә карашын йөртә-йөртә һәм һәр сүзен үлчәп кенә җавап бирде Җәүдәт:

– Мөгаен, дүрт-биш миллионгадыр... Бәлки, әле күбрәккәдер дә...

Гыйбадәт йортыннан шактый ераклашкач, урам буйлап атлаганда, шушы Минзәләдән чыккан замана капиталисты искә төшеп көлдерде, каһәр...

Моннан унбиш ел элек архивчы-тарихчы галим дусларымнан нәселем шәҗәрәсен таптырган идем. Шул куанычымны дус-ишләр, якташлар арасында да уртаклашкан идем. Ике бай: «Миңа да эшләт әле нәсел агачымны», – дип йөдәтә башлагач, ризалашырга туры килде. Нәселләр тарихын Казан, Уфа, Ырынбур, Мәскәү һәм башка шәһәрләрдәге архивларга бара-бара, төрле архивлардан борынгы документларның копияләрен җыя-җыя, ерак юлларны үтә-үтә, расхутланып яшәүче тарихчылар үз эшләренә 1000 доллар яки 30 мең сум сорыйлар иде ул чакта. Бер сүз белән әйткәндә, байларның икесенә дә әзерләттем шәҗәрәләрен. Шуларның берсе, милләтебезнең керәшен өммәтеннән булганы, утыз меңне рәхмәт укый-укый чыгарып салды да: «Менә монысы мәшәкатьләнеп килгәнең һәм юл хакың өчен булыр», – дип, өеп куйган акчасының өстенә тагын өч меңне салды. Аннары, алдан шалтыратып, Минзәләбездән чыккан капиталистка бардым. Анысы өстәлгә арасында тимер акчалар да күренгән акчалар салды. Санагач, гаҗәпкә калдым: егерме сигез мең дә сигез йөз унике сум кырык тугыз тиен икән биргәне!.. (Мин бу санны, кызык өчен «Хәтер дәфтәре» дип исемләгән амбар кенәгәсенә теркәп куйган идем.)

Күтәрелеп йөзенә багуга ук әйтте теге: «Аптырама. Кичә-бүген доллар бераз арзанайды. Калькулятор белән төгәл исәпләдем. Син сораган мең доллар, сумнарда исәпләгәч, биргәнем кадәр булды». Елмайдым да: «Кайбер нәселләр үзләренең бәяләрен төгәл беләләр шул! Маладис!» дип мактадым үзен. Инде менә мәчеттән

кайтканда үз-үземә сорау бирәм: бу бәндәнең берәр мәчеткә яки мохтаж адәмгә бер тиенлек булса дә ярдәме тиде микән? Юктыр! Чөнки бирсә, акча чыгу кайгысыннан сулышы буылачак аның...

## Бу дөньяның кемнәре юк...

Әйе, Фаил сүзен кыска тотты. Аннан соң мин тәфсилләп сөйләргә һәвәс һәм вакытын да чикләми торган бер шәхескә тап булдым шул ук көндә. Әйтерсең лә татар теленнән дәрес бирүче мөгаллимне тыңлап утырам... Түзмәдем, сөйләвен өзеп, сорау бирергә мәҗбүр булдым:

– Син педагогмы әллә, Мисхәт энем?

– Юк, минем кооператив белемем генә бар. Ләкин шунысын беләм: муллалар нәселеннән мин. Патша армиясендә бер бабам полк мулласы буларак та хезмәт иткән.

Ә сүзе коррекцион мәктәптән ике ятим малайны тәрбиягә алуы, төрле эшләргә өйрәтеп үстерүе, аларның чын егетләргә әверелүе турында бара. «Коррекцион мәктәп» дигәне сәламәтлекләре чикле булган, ягъни кайсы да булса җәһәттән зәгыйфь балалар мәктәбе инде...

– Чаллыдагы «Весенний» совхозының башлыгына Минзәләдә төрле яшелчәләр сату өчен кибет булдыру тәкъдиме белән бардым, – дип сүзен дәвам итә Мисхәт. – Бездә шәһәр халкының күп йөри торган үзәгендә ташландык иске бина бар, шуны төзекләндереп, кибет итү мөмкинлеге бар, дидем. Ул, Минзәләгә килеп, район башлыгы белән сөйләшеп, шул бинаны сатып алу җаен тапты. Ләкин тыштан шыксыз күренгән бу борынгы бинаның эче һәм подваллары да бик пычрак булып чыкты. Совет чорында «Горторг» кантуры иде бит... Андагы черек салам, черек бәрәңге сазлыкка әйләнгән. Әлеге коррекцион мәктәптән берничә бала алып кайтып, чистарттыру мөмкинлеге туды. Унөч, ундүрт, унбиш яшьлек балалар инде... Эшлиләр, яннарында үзем дә кайнашам, төрле тәм-том белән сыйлаштырам, ашатам-эчертәм мескеннәрне. Икесе аеруча игътибарны җәлеп итте: файдалы, сәләтле булуларын күрсәтергә тырышып, житез эшлиләр. Шул икесе эш беткәч тә, укыган җирләреннән минем янга килә торган булдылар: тартмаларга яшелчәләр тутыралар, көчләре житкәннәрен төйиләр, «әткәй» дип кенә торалар. Бервакыт боларны әнкәй янына алып кайттым. Әнкәй белән сөйләшкәндә, җөмлә саен «әнкәй» дип дәшәм бит инде... Көтмәгәндә шушы малайлар әнкәмә «әнкәй» дип мөрәҗәгать итә башладылар. Шуны ишеткән әнкәм «аһ!» итте дә, гаҗәпкә калып, миңа әйтә: «Карале, улым, урыс булсалар да, «әнкәй» дип эндәшәләр бит! Сөбханаллаһ!» Тора-бара татарчага да өйрәнделәр болар, берсе хәтта әнкәм белән намаз да укый башлады.

Шул балаларның хокукларын яклау, яшәү рәвешләрен кайгырту җәһәтеннән хөкүмәтнең нинди генә инстанцияләрен үтмәгән, нинди генә катлаулы проблемаларны хәл итмәгән шушы Мисхәт Афзалов! Сабырлыгын да, таләпләрен дә җигеп, күпме генә җәфалар, матавыклар күрмәгән ул. Мәсәлән, шушы балаларны торaклы итү өчен, сәләмәгә калган бер барак биргәннәр боларга. Шуны изалана-изалана ремонтлап бетергәч, прописка гамәлләрен кайгырту нияте кергән... Баксаң, бу бинаның... адресы да юклыгы ачыкланган. Ягъни исәпкә-санга да кермәгән икән ул шәһәрдә... Көлкеме, укучыларым? Сәгатьтән артык сөйләвен тыңлаган чакта минем зиһендә бер генә уй булды: «Чыдаса да чыдый икән адәм баласы!»

Кыскасы, һәр эшкә сәләтле булып үскән бу малайлар. Эшләп акча таба башлагач, олырагы атасына – Мисхәткә – «Калина» машинасы да алып биргән. Шулчак кечесе: «Әткәй, минем дә машиналы буласым килә», – дип уфтанган.

– Анысына болай дидем: «Улым, машиналы буласың килсә, син миңа бүләк бирергә тиешсең». «Нинди бүләк өмет итәсең?» – ди. «Күл!» – дидем. Аптырап калды бу, нинди күл, ди. «Туган авылым Иске Иркәнәштә ихатама күл казып, күрер күзгә үк сокланырлык бизәп, шуны миңа бүләк итәсең», – дип җавап бирдем.

Шул хакта да сөйләп алгач, Мисхәт, әллә каян гына зур планшет тартып чыгарып, алдыма куйды:

– Менә ул ясап биргән күл!

Төрле паркларда, санаторийларда, күп шәһәрләрдә йөргәнем булды, дөнья гизгәндә бихисап ясалма күлләр күрдем, ләкин бу кадәр соклангыч һәм әкияти күлне хыялыма да сыйдыра алмый идем. Кем дә кем ышанып бетми икән язганыма, Минзәләнең әнә шул авылына барып күрегез. Бигрәк тә җәй көне барсагыз, шаклар катачаксыз.

– Шулай да, ни өчен татар балаларын алып кайтмадың син «коррекцион» дигән шул мәктәптән? – дидем. Җавапны кыска тотты:

– Анда татар балалары бөтенләй юк иде бит!

Бу җөмләсе 25-30 еллар чамасы элек булган хәлләрне искә төшерде. Татарстан радиосында эшләгән елларымда, командировка алып, Минзәләдән тапшырулар әзерләү өчен кайткан идем ул чакта. Милиция бәйрәме якынлашып бара икән. Милиция начальнигы очрап, үтенеч белдерде:

– Шул көндә Минзәлә милициясе турында берәр тапшыру оештыра алмассыңмикән? Менә, мәсәлән, зур һәм катлаулы җинаятьләрне тиз ача торган Зөлфәт исемле тикшерүче егетебез бар. Хет шуның хакында сөйләсәң иде радиодан.

Ризалаштым. Шул егетне таптылар да каршыма утырттылар. Яшь егет, күрер күзгә үк мәхәббәтле. Микрофонымны алдына бастырып куюга ук сүз башлады. Үтерешләр күбәйгән икән туган ягымда. Кемдер бер яртылык акча бирмәгән атасын суйган, кемнәрдер йөз грамм аракылык тиеннәр тапмаган әнисен бәреп үтергән, бабасын яки әбисен кыйнап гомерләрен өзгән... Кардәш-ыруларының йортларына ут төртеп, яндырып үтерүчеләр дә бар икән... Кем әйтмешли, кашшмарр!.. Ул сөйли тора, мин кара янып, хурланып утырам: нұжәли элек ун елга бер генә үтереш булган Минзәләм шул хәлгә төшкән? Туктаттым да шул Зөлфәтне, сорадым:

– Әйт әле, энем, шул җинаятьчеләр арасында татарлар күпме?

Күземә сәерләнеп киткән карашын төбәп текәлде дә, учы белән һаваны ярып, урыс сүзе дә кыстырып, кистереп җавап бирде:

– Анысы – исключено, абый! Чөнки татарда иман бар әле!

Аңлагач, үз милләтем, Минзәләм өчен сөендем.

Шул ук көнне мине, райком машинасына утыртып, күптән түгел генә төзелеп беткән, сиксән-туксан тирәсе кеше урнаштырылган картлар йортына алып киттеләр. Райкомның шул йортны радиодан мактатасы килгән. Бардым, тел-теш тидермәслек чисталыгын, яткан-торган урыннарының да уңайлы булуын, ашаган ризыкларының шәплеген күреп, хәтта кайберләрен авыз итеп тә тикшереп, сумкамнан магнитофонымны чыгарып, бүлмәләр буенча йөри башладым. Чиста-пөхтә мохиткә килеп эләккән булсалар да, зарлары күп бахыркайларның... Боларны монда уллары, кызлары, оныклары, киленнәре китереп тапшырган икән. Берсенең язмышы аеруча истә калды: улы өйләнгән, чибәр кыз алган, әмма киленгә бизәнеп-ясанып утыру өчен трильяж, урындык куярга урын житми икән фатирларында... Ул бизәнергә теләгән урында каенанасының караваты комачаулый икән. Киңәшкәннәр дә улы белән килен, бу карчыкны шушы йортка китереп «сдавать» иткәннәр. Айлар буе хәлен белергә дә килмиләр икән. Ул елаганда ник килүем искә төште. Татарча тапшыру әзерләргә килеп, бер генә татар да күрмәдем бит әле хәзергә... Сорадым шушы йортның директорыннан, кайсы бүлмәләрдә ята татар карчыклары, картлары, дип. Шым булды. Баксаң, китереп тапшырылган һәм монда ятучы карт-корылар арасында да бер генә татар да юк икән! Әйе, китереп ташламаганнар татарлар үз ата-аналарын, әби-бабаларын. Ярый әле чатнатып татарча сөйләшә торган марҗа әбиен таптым. Башкалар язмышы турында тезеп-тезеп сөйли, рәхмәт төшкере! Сиптерә генә!

Ә тапшыру болайрак чыкты эфирга: автор буларак сөйлим-сөйлим дә теге әбинең сөйләүләрен магнитофоннан ялгап-ялгап куям. Кыскасы, шул әбиегез белән бергә алып бардык кырык минутлык тапшыруны.

...Шулай, Мисхәт якташымның игелекле зат икәнен, аның зәгыйфь балалардан да чын кешеләр «ясый» алганлыгын тыңлаганда, Касыйм Гафиятовның да чираттагы вакыйгасы истән чыкмады...

## Зәгыйфьләргә дә дәрт бирде

Шул Кадрәккә тагын баргач, колхоз хәлләре турында сөйләшә башлаган иде Касыйм абый, алыптай бәдәнле бер егет кереп басты каршыбызга. Кергәндә, ишекнең өске борысына маңгаен бәрүдән сакланып, башын да иде хәтта.

– Чакыргансың икән, Касыйм абый, менә килдем мин, – дип мөгрәве әле хәзер дә колагымда яңаргандай була. Күз карашына, сүз сөрешенә игътибар итүгә үк чамалап алдым: гәүдәсе сазга баткан тракторны сөйрәп чыгарырдай көчле күренсә дә, акылы зәгыйфьрәк моның.

– Килдем, Касыйм, абый...

– Касыйм абыеңны санга сугып килүең өчен рәхмәт, энем. Менә бик тә җаваплы эш тугач, уйланып йөрдем-йөрдем дә, ул эшне бары тик син генә башкарып чыга алырыңны аңлап чакырдым сине.

– Әйт кенә, Касыйм абый, эшлим!

– Тыңлап бетер әле, энем. Катлаулы, төгәллек һәм синекедәй көч тә сорый торган эш ул. Менә шуны башкарып чыксаң, мин бик сөенер идем...

Ә теге, эш дәрте белән кабынып, кат-кат мөгри:

– Әйт кенә, Касыйм абый, хәзер үк башлыйм ул эшне!..

...Баксаң, бу «җаваплы да, төгәллек тә» сорый торган эш моннан гыйбарәт икән: менә шушы Калинин исемендәге колхоз үзәгеннән чакрым ярым чамасы арада Җәмәк авылына телефон кертү ниятендә баганалар утыртып чыгу өчен тирән чокырлар казырга кирәк булган персидәтелгә. Хәер, әйтүенә караганда, үзе яши торган шул Җәмәктә яшәүче Касыймга өендә дә телефон булдыру кирәклеге хакында район башлыклары да сүз кузгатканнар икән.

– Кайбер мәсьәләләрне хәл иткәндә, Касыйм Гыйниятович, төн уртасында да фикерләшәсе килә кайчак. Телефон куйдыр әле син, куйдыр! – дигәннәр.

Тәмле телдән таш та эри, диләрме әле? Шундый шәхес иде Гафиятов, колхозындагы һәр кешегә нурлы да, якты да карашы, тәмле теле белән эш йөкләсә, аның өметен, максатын тормышка ашыру өчен атлыгып тормаган беркем дә юк иде. Шунысы да искә төште: әлеге егетнең көнлек эшенә баш агрономның айлык хезмәт хакы кадәр акча түләгән ул!

...Әйе, үз кадерен дә, башкаларның бәясен дә белде Касыйм ага. Шуңадыр, 35 ел буе шушы колхозны һәр җәһәттән алдынгы тотып, СССРның дүрт орденына лаек булды. Ләкин ул аларны берчакта да такмады, түш киереп йөрмәде. Гомере буе һәр колхозчының гап-гади кардәше, дусты, якын кешесе кебек ягымлы карашын тәбәп, һәркайсы белән тигез кимәлдә сөйләшеп яши белде. Әле бу арада шундый хәбәр житкерделәр: авылның бер урамына Гафиятов исеме бирү ниятенә кергәннәр колхозлашлары.

* * *

...Моннан өч ел элек берәү шалтырата миңа. Сәламләшүгә үк сорау бирә:

– Фәнзаман абый, син Кадрәкнең Әрчәсен хәтерлисеңме әле? Мин бәләкәй чакта бездә кунак булып, рюмкалар да күтәргәләп, гармун уйнап, җырлап утырган идегез. Мин менә шул Әрчәнең улы Юрий Гарнышев булам... Гафиятов рухы тәэсирендә авылдашларыбыз чыгарган йөзләп йөремсәк мәзәк тупладым. Шуларны, әдәби яктан эшкәртеп, берәр газиттә яки журналда бастырып булмас микән?

Үтенечен тыңлап бетергәч, рәхәтләнеп көлдем башта. Ничекләр онытмак кирәк ул Әрчәне?! «Төшергәләп», җырлашып утырганда, шул Әрчә, безнең кети-метиле мәзәкләребезне ишетмәсен дип, яныбызда уралган жиде-сигез яшьләрдәге малаена:

– Бар әле, Җүри улым, урамда уйнап җөр дә, бакчадан укроп, кыяр, фамидур кебек нәрсәләр җый. Алар кирәк булгач, үзем чыгып чакырырмын сине.

Колхозчыларга шаян сүзләр дә әйткәләп, елмая-елмая эш биреп йөри иде авыл буйлап шул Әрчә, ягъни Арсентий Гарнышев. Гафиятовның иң ышанычлы бригадиры, таянычы иде ул...

Баксаң, әлеге шалтыратучы теге чакта безгә яшелчәләр җыйган Юрий икән бит. Гомер диген! – ул да 54 яшенә житкән.

Ризалаштым, әлбәттә! Мәзәкләрен әдәбиләштереп, «Чаян»ның баш редакторы Рафаэль Хәлиуллов өстәленә салдым:

– Тулаем бастырсаң гына калдырам, Рафаэль энем, булдыра алмасаң, икенче бер басмага тапшырам, – дип. Яратты аларны редактор һәм Юраның бармак битедәй сурәтен дә куя-куя, бите-бите белән елдан артык журналында бастыра барды. Менә шуларның берничәсе...

## Табеевка юл ачу

Берчакны колхоз башлыгы Гафиятовка Кадрәк аша Минзәләдән Сарманга обкомның беренче секретаре Табеев үтәргә тиешлеген хәбәр итәләр. Әлбәттә инде, Гафиятов ул үтәчәк юлны карап кайтырга, чүп-чар күренсә, чистарттырырга тиеш була. Бераз баруга ук, ни күрсен, юлга аркылы йөзтүбән яткан «Озын» кушаматлы Микулайга тап була. Кадрәклеләр әйтмешли, чебенләп ята колхозның иң хөрмәтле техника остасы – исергән... Көлкегә калып булмый бит инде республиканың иң зур түрәсе алдында!.. Күтәреп кенә торгызыр иден, Озын Микулайның гәүдәсе дә мулдан, әкият әзмәвере кебек – домкратсыз яки крансыз булмый. Гафиятов күп уйлап тормый, юл читеннән кычыткан өзеп алып вә һәм дә Микулайның тере утыргычы ачылырлык итеп чалбарын төшерә дә, ялангач җиренә кычытканны тидереп-тидереп алгалый. Ә теге гигант кычыткан тигән саен өтәләнеп, ыңгырашкалап юл читенә таба шуыша, аннары, куаклар белән капланган канауга тәгәрәп, күренмәс була... Ул арада Табеев машинасы да, озак көттермичә, килеп туктый.

– Маладис, иптәш Гафиятов! Колхозың алдынгы булган кебек, юлларың да төзек, чиста икән!

– Тырышабыз инде, Фикрәт Әхмәтҗанович, – ди персидәтел, аннары, кулындагы ташлап өлгерелмәгән кычытканга күзе төшкәч, өстәп тә куя: – Юл читендә ял итеп алырга теләсәгез дип, кайбер урыннарда кычытканнарны да йолкыдык.

– Синдә ял иткән чаклар булмады түгел. Күрешербез әле, пленумга ашыгам, – дип, кузгалып китә Табеев.

...Кешеләрне сүгеп яки җикеренеп түгел, бәлки акыллы юморы белән туры юлга бастыра белүче Гафиятов икенче көнне тыныч кына болай ди Озын Микулайга:

– Йокың килгән чакларда, Николай Степаныч, юлга аркылы ятма инде, җайлап кына буйга ятырга тырыш, яме, – ди.

Шушы урында гарәпләрнең хатын-кызлар турындагы «Ля хәйре фиһөннә вә ля беддә минһөннә» дигән гыйбарәсе искә төште. Мәгънәсе болай: «Аларда һичбер яхшылык юк, әмма алардан башка яшәү мөмкин түгел». Әйе, еш кына сүксәк һәм хурласак та, без – сау-сәламәт ирләр – алардан башка атна буе да яши алмыйбыз. Язуымның сәбәбе хәзер үк күренәчәк.

## Тату булуга ни җитә!..

Авылыбызның бер «донжуан»ы Казакъстаннан самавырдан чак кына калку кыз алып кайтты да, үзе армиягә китеп барды. Казакъ кызының да марҗаныкы кебек үк «җаны» бар бит инде. Иренә сагыну хатлары яза-яза, бик еш кына аулак өй оештыра башлады. Берничә йөремчәк егет, казакъ кызын күрәсе, сөеләсе килеп (экзотика бит!), тегенең янына берән-сәрән баргалап йөриләр икән. Ә бер кичне, расписаниеләре буталгандыр, күбрәк жыелганнар. Андый чакта сугыш-талаш булмый калмый бит инде. Көрәшче егетебез барысын да «чәчеп» аткан. Ныграк «чәчкән», ахрысы, бу хәбәр Гафиятовка да барып җиткән:

– Әх, эне-кәш-ләр! – дигән Гафиятов, сыкранган тавыш чыгарып. – Шул бияләй хәтле кыз өчен сугышып, авылның абруен төшергәнсез бит. Тату булсагыз, барыгызга да җиткән булыр иде ләбаса! Моннан соң арагызда татулык булсын, яме?..»

## Катырак әйткән

Хатын-кызлар да, ирләр кебек үк, бер-берсе белән ызгышкалап яшиләр бит инде. Кайбер чакта бик оятсыз сүзләр белән дә ныгытыла мондый талашлар. Бездә дә ике хатын талашкан. Берсе ярпач тавышы белән әшәке сүзләр кычкыра икән, ә икенчесе, ыштанын төшереп, артын күрсәткән килеш туңкаеп, бер сүзсез тынып

калган. Теге каты кычкырганы гарьләнгән һәм, гадел казый янына барган кебек, Гафиятовка барган. Икенчесен дә чакырып, Гафиятов, сүзне тирәнгә кертмичә генә, «стриптиз» күрсәткән хатынга:

– Ай-һай, бигрәк каты әйткәнсең икән шул! – дигән, башын чайкап. Аннары, шәрран яра кычкырып талашканына борылып: – Син дә тавышсыз-тынсыз гына шулай каты әйткән булсаң, авылга таралмаган булыр иде җәнҗалыгыз.

Ахырдан икесенә дә мондый киңәш биргән:

– Моннан соң ышыкка кереп кенә, тып-тын талашыгыз, ямме? Бу киңәшемне башка ахирәтләрегезгә дә әйтегез.

Шуннан соң, дистә-дистә еллар үтеп тә, авылыбызда хатын-кызларның кычкырып талашканы ишетелми. Мөгаен, Гафиятов киңәшен тотып яшиләрдер...

* * *

...Күрдек, укыдык: «ыштансыз », «некультурный» мәзәкләр булды болары. Ләкин, нихәл итмәк кирәк, тормышта гомер-бакый кабатланып тора торган хәлләр... Бүтән пердсидәтелләр булсамы аның урынында: милициягә дә, судларга да, партия, профсоюз оешмаларына да «эш» арткан булыр иде.

Ыштан дигәннән, Гафиятов заманында икенче бер колхозда булган хәл дә еш искә төшә... Апрель ахырында персидәтелнең уҗымнарның көр булып күтәрелүен күрсәтәсе килде миңа, шул ук Татарстан радиосыннан Минзәләгә кайткач. Машинасына утырып, авыл читенә чыгуыбыз булды, персидәтел, ыштанына ут капкан кебек, шыр-шыр акыра, сүгенә башламасынмы!..

– Бәреп үтерәм сволочьны! Карале, уҗымнарны таптый берәү! – Күреп алдым, юл читендәге канау астында бер малай мотоциклы белән мәш килә... Аңлап алдым, язгы пычрак юлдан таеп төшкән бу. Тирләп, җәфаланып беткән үндүрт-унбиш яшьлек балакай, ачы күз яшьләрен түгә-түгә, елый-елый, матаен юлга менгерү өчен әрле-бирле килеп, ике-өч квадрат метр уҗымны таптап, «пеләшләндереп» бетергән. Персидәтел һаман оран сала:

– Милициягә озатам, судка бирәм, төрмәгә тыгам!

Ул арада теге малай янына төштем дә:

– Җәле, улым, руленне тот, юлга менәбез, ямме, – дип, багажнигын тотып, күтәреп, юлга менгердем. Аннары: – Бар, кайтып кит, улым, сиңа милиция дә, суд та тимәячәк, – дидем.

– Рәхмәт, абый! – диде дә, рәхмәтен кабатлап, Минзәләгә китеп барды. Уҗымнар карарлык та кәефем калмаган иде инде. Авылга кире кайтуыбыз булды, тагын акыра башлады бу очраган һәр кешегә:

– Нәрсә, алкаш, әллә бүген дә эчтеңме, уйнаштан туган нәрсә? Милиция көт, хәзер шалтыратам!

– Арбаңда нәрсә ул? Фураж урлап кайтасыңмы?

Соңрак, тынычланган сыман, әйтеп куйды:

– Халыкны шулай коры тотмасаң, иген дә үсми, терлекләр дә симерми, сөт тә артмый, социалистик ярышта да җиңеп булмый. Халык бит ул көтүчесез хайваннар төркеме кебек, чыбыркы шартлап тормаса, ялкаулана, таркала.

Аның белән сөйләшерлек хәлем калмаса да, болай дидем:

– Пажалый озак эшли алмассың син персидәтел булып...

Аннары, якынлашып килүче машинаны туктатып, Минзәләгә китеп бардым. Мондый кешене мактап эфирга чыксам, Аллаһның каһәре сугар кебек тоелды. Ә ярты еллап вакыттан соң ишеттем – куганнар тегене....

...Бу кайтуымда мин шахтада эшләгән, ташкүмер убылуына да тап булган, шулчак колагын да өздергән танышымның хәлен белергә дә кердем. Сүз иярә сүз чыгып, 80 яшьлек карт малай чагындагы бер гыйбрәтне сөйләде.

– Менә, Фәнзаман, кешене кадерсезләгән җитәкчеләр дә күп булды... Шулай, бала чагымда район башлыгы Абдрахмановны Иске Байлардан кошовкалы атта озатып куярга куштылар. Барабыз... Салкын. Буран. Юл читендә бер агай күшегеп тора. «Утыртыйкмы, абый?» – дидем. Утыруы булды тегенең, Абдрахманов сорап куйды агайдан: «Колхозда кем булып эшлисең?» Агайның: «Әле калхузга кереп

житкән юк...» – диюе булды, Абдрахманов, кавындай йодрыгы белән селтәнеп, бар көченә сукты тегенең йөзенә, колхозга кермәгәч, дошман син, контра син, дип. Төртеп тә төшерде авызыннан-борыныннан гөжләп кан киткән агайны. Соңыннан ишеттем: мәетен шуннан тапканнар...

...Ярый, житте! Шул кансыз бәндәләр турында язганда, тәнем дә суынып киткәндәй тоелды. Күчик әле күңелле хәлләргә, җәмәгать! Әйтик, язмамның башында ук искә алынган Гамил Афзал:

*Кош баласы, һәр агачы, һәр бөҗәге, һәр үлән*
*Мөлдерәп күзгә карыйлар моң белән, рәхмәт белән,*

дип сурәтләгән табигатькә! Әйтегез әле, шундый көннәрдә авыл сабантуйларына кунакка кайтырга яратасызмы? Картаюым галәмәтеме, сагынуым көчәя барадырмы, соңгы елларда сабантуй саен туган ягыма кайта башладым. Кайбер кайтуларымда дүртәр-бишәр авылда карыйм якташларымның сабантуйларын һәм күпчелек очракта төрле көрәшләрдә җиңгәннәргә күп дистәләрчә бүләкләр өләшеп торучы бер үк затларны, дөресрәге, замана эшмәкәрләрен күргәчә күнегеп барам. Мәсәлән, әлеге дә баягы Кадрәк Юрие яки Дәвекнең Язкәре...

Юрийнең кемлеге хакында шактый сөйләдем инде. Ә хәләл җефете – Гафиятов кызы икән! Мөнирә (мәгънәсе: нурлы, яктылык сирпүче) исемле... Узган елны Корбан бәйрәме көнне шул нурлы да, чибәр дә хатын улы Марат белән килеп керде, котладылар, ләкин, түргә узыгыз, диюемә бары тик:

– Улыбыз туды, Фәнзаман абый, әле генә мулладан исем куштырдык. Данияр исемен сайладык. Әйбәтме? – дигән җавап ишеттем.

– Бабасы кебек данлы булып үссен Даниярыгыз, котлыйм! – дидем. Ә инде шуннан соң очрашкач, Юраны шаярттым: «Карале, егет, мәхәббәт, диннәр мәсьәләсендә демократ икәнсең бит син! Сизәсеңдер, нәселең исламга күчеп бара». Ә ул кеткелдәп көлде дә болай диде:

– Үз нәселемнең дә, ягъни ерак бабаларымның нинди диндә булганлыкларын да белмим бит әле. Мәсәлән, Гарнышев фамилиясенең безгә ничек бирелгәнен дә белми яшим, эш артыннан куа-куа... Анысын Фәннәр академиясендә докторлык диссертациясе якларга әзерләнүче, архивларда да казынучы кодам Нәкыйп эзли... (Тагын бер сере ачылды Гафиятовның: бер улына теге чактагы «башбух»ының исемен кушкан.) Ә инде Юраның улы Маратка килсәк, анысы фәннәр кандидаты, югары уку йортында дәресләр бирә...

– Шулай, Фәнзаман абый, миңа бар диннәр дә якын. Авылымдагы керәшеннәр дә, мөселманнар да минем өчен тигез. Белгәнеңчә, Чаллыда яшим. Әле мине андагы «Иман» фондына житәкче итеп тә сайлаганнар иде...

Шулай да, Кадрәкнең быелгы сабан туенда кызгандым мин Юраны... Күктә бер болыт әсәре дә күренмәгән көндә, кояшның рәхимсез кыздыруы астында яна-яна, биш-алты сәгать буена теге яки бу ярышларда җиңгән авылдашларына, концерт куярга килгән төркемнәргә бихисап бүләкләрен өләшеп йөрде. Ә халык, ягъни башкалар, зонтиклар белән килгән... Аларга рәхәт: төрле сулар эчеп, туңдырмалар суырып утыралар.

Тәмам караңгы төшкәч кенә кайттык авылындагы өенә. Хәлдән тайганын белсәм да, мин юләр, гадәтемчә көләм:

– Ну, акчанны күп туздыргансың, малай! Җәл түгелме хәләл көчең белән тапкан капиталың?

– Анысы үземне тудырган, үстергән авылыма бүләк кенә... Тик менә шундагы күлем буенда урман булсын дип утырткан агачларымны жәлләдем. Шактые тапталды. Кем уйлаган меннәрчә кунак кайтыр дип...

Ә эшмәкәрлеге бик гади аның: Чаллысындагы ашханә, кафе, рестораннарны, ягъни «общепит»ны ит, балык белән тәэмин итә. Балыклары – үз күлендәге карплар, ә инде ит үз хуҗалыгыннан гына түгел, башка авыллардан да маллар сатып ала. Һәркөн юлда-сәфәрдә. Үзе шофёр да, төячүе дә...

Инде туган авылы Дәвеккә, шундый ук юмарт, игелекле Язкәр Бижановка килик

һәм жыйнак кына бәдәнле, терекөмештәй хәрәкәтле шушы егет белән сөйләшеп алыйк.

– Бай һәм зур масштаблы кеше икәненне ишетеп тә, күреп тә беләм. Әйт әле, Язкәр, ничекләр менден мондый югарылыкка?

– Иң башта илле гектар жир алдым. Алуын-алдым, ләкин кулда сәнәк тә көрәк кенә... Үкенеп тә куйдым. Ләкин мине Ходай шулай яралткан: кешеләр алдында булдыксызлык күрсәтүдән гарьләнәм. Әнә шул бәләкәй генә жирне тергезеп жибәрү әмәлләренә ирештем. Шулчак күрәм, колхоз вакытында төзелгән, тузган фермаларны жимерә башладылар... Сутмәгез, егетләр, аларга ремотны үзем ясатырмын, терлекләр симертү белән шөгыльләнәсем бар, дип аркылы төштем. Беренче уныштардан сон түләдем алар өчен дә... Ашлык әйбәт унды, сыер маллары да яхшы симерә башлады. Ләкин беләм, ашлыкны сатсаң, бәясе бик арзан. Шуңа күрә тегермән булдырдым. Он да арзан, табыш керту кыен... Пекарьня ачтым. Файдасы керә башлады. Тора-бара ашханәләр, кафелар ачтым, күп шәһәрләрдә азык-төлек һәм көнкүреш товарлары сата торган кибетләрем дә бар «Эльдорадо» дигән кибетләр челтәрендә. Сөйләү ансат ул, мәгәр ул еллардагы жәфалануларны үзем генә беләм...

– Шулай... Әле бит эшен кинәя барган саен, үзенә хезмәт итүчеләргә дә әйбәт түләргә кирәк. Күпме хезмәт хакы түлисен аларга?

– Унбиш-егерме мен. Урып-жыю вакытында комбайнчыларга йөзәр мен, аннан да артыграк бирәм. Чөнки инде жирем дә мен гектар хәзер.

– Көнләшүчеләр сизелмиме?

– Сизелә... «Бижаннын Язкәренә ни житми микән инде?!» дигән сүзләр йөри. Үзем, гаиләм турында гына кайгыртсам, мина бар да житә! «Күршең бай булса, көнләшмә, сиңа бирмәсә дә, үзенә кереп сорамас» дигән мәкалебез дә бар бит әле.

– Авылыгызда мохтажлыкка дучар булган картлар, әби-сәбиләр бармы? Әз-мәз акча сорап, ярдәм итүенне өмет итмиләрме?

– Мох-тажж-ларр.... Юк, андый көнгә калучылар юк бездә... Азмы-күпме пенсияләре, үзләренә ризык эстәрлек бакчалары, терлекләре бар. Минем авылга ярдәмем – су килүче жиһазларга төзеклек булдыру, бозылган юлларга һичьюгы ком, чуерташлар жәеп яңарту... Ә инде үзәк урамга асфальт салдыручылар, культура йортын, мәчетне заманча итеп яңартучылар – абыйларым акчасына башкарылды.

– Быел да сабантуйда бик юмарт кыландың. Кыйммәтле бүләкләр өләшә-өләшә кулларың да арыгандыр. Сабантуйның жиһазлары да, бизәлешләре дә сокландыргыч булды...

– Минем юмартлык зур булмады анда, әйткәнемчә, читтә яшәүче миннән дә зуррак эшмәкәр абыйларымның өлешләре күп керә ул бәйрәмне ел саен чын бәйрәм итү өчен. Мәсәлән...

– Чү, иң баеның исемен әйтә күрмә! Әйтсән дә язмыйм. Чөнки мин ана: «Синен дөньякүләм эшмәкәрлеккә ничек ирешүен турында язасым – гади генә авыл малаеның зур капиталистка әйләнүен халыкка күрсәтәсем килә», – дигән идем берничә ел элек... Ул: «Тыйнак буласым, үз исемемне илгә дә, дөньяга да таратасым килми», – диде.

– Бу хакта белмәдем... Инде дә үземнең туган авылыма өлешем турында әйтсәк, жавабым кыска. Минем туган авылым бер генә – шушы бердәнбер Дәвек кенә бит! Ана да хәл кадәри нур өстәмәсәм, нинди ир булам инде. Шунысына иманым камил: әткәй-әнкәемнең нигезеннән берчакта да китми торган төпчек малайлары бит мин! Авылдашларымның күз алдында гомерем буе яшәячәк кеше!

* * *

Тагын бер эшмәкәр белән таныштырырга булдылар якташларым. Фамилиясе Юдин икәнен белүгә үк, бала чагымдагы бер вакыйга яңарды хәтеремдә...

Әткәйнең беренче хатыныннан туган Мулланур абый мине – шыр ятим калган ун яшьлек баланы – үзе яши башлаган Казанга алып китте. Юдино станциясе янында рельслары белән тимер юл челтәре читенә чыгарып куелган вагонда яшәдек 1950 елда. Ул чакта абыйга 27 яшь булган, димәк. Фронтларны үткән, Германия

концлагерена да эләккән һәм качып котылган кеше иде ул. Казанның үзәгенә мине дә ияртқәләп китә иде. Бер баруда сорап куйдым тегеннән, концлагерьдан ничек качтың, дип. Ул, бер сүз дә әйтмичә, кирпеч коймага кәлтә еландай менеп тә китте һәм төшкәч кенә, кулларындагы тузанын сөртә-сөртә, соравыма җавап бирде:

– Менә шулай качтым, энекәш...

Җиңел гәүдәле шул абыемның инде алтмышына җиткәндә дә аякларын өскә күтәреп, кулларында биюен еш күрә идем әле. Казан үзәгенә бер баруыбызда танышлары очрады. Исәнләшкәч, тегеләрнең сүз сөреше аңлашылды: без килгәнче керәшеннәрне хурлап торган чаклары булган икән. Сүзләрен дәвам итә башлаулары булды, ачуы бик килгән чакларда кызып китүчән абыем, зәһәр генә «майтлап» алгач:

– Керәшеннәрнең фәләнен чәйнәмәгез, анагызны сатканнар. Сездә ничектер, безнең Минзәлә керәшеннәре барыгыздан да әйбәтрәк: бергә эчәбез, бергә ашыйбыз, бергә эшлибез, тату яшибез! – диюгә үк куллары белән якаларыннан эләктерергә теләгәндәй хәрәкәт ясап алгач һәм тегеләр артка авышып беткәч, минем кулны җәһәт кенә эләктереп җитәкләде дә:

– Киттек, энекәш, юньле кешеләр түгел болар! – дип, җил-җил атлап та китте.

...Инде менә әлеге Алексей Георгиевич Юдин белән әңгәмә корып утырабыз. Бу да керәшен икән. Татарчасы әйле-шәйле генә булганлыктан, урысчага күчәбез.. Элекке глава моңа Воровский посёлогыннан җир алырга тәкъдим иткән. Шул җирдә эшләре уңышлы гына башлангач, андагы чиркәүне төзекләндерү чарасын күргне дә йөкләгән.

– Башта чиркәүне тышкы яктан гына төзекләндерү нияте белән башлаган идек эшне... Ләкин, эченә керсәк, ни күрик, дистә еллар буе җыелып яткан чүп-чар, алам-салам, иске-москы белән тулган икән. Короче, полный хлам! Стеналары да ямьсезләнеп беткән – карарлык җире калмаган. Текемләп яңарта башлагач, бизи торгач, рухи йолаларны үткәрү өчен бөтен шартларны булдырдык, җылы керттек, электрлаштырдык, койма койдык... Хәзер инде яңа туган балаларны шунда коендыралар, исем кушалар, бөтен йоласын китереп чукындыралар. Әйе, зур эш башкардык чиркәүдә. Берочтан су торбаларын да, водокачкаларны да төзекләндердек посёлокта. Бигрәк тә йортларның өске катларын да сулы итүгә ирештек. Элек аларга су менеп җитмәгән икән. Сез бая сабантуйларга күпмелек өлеш кертүебез белән кызыксынган идегез. Анысына кыскача гына җавап бирсәм, елына карап 50 меңнән 100 меңгә кадәр. Ә инде бәйрәмнең мәйданын җиһазлауны посёлок советы персидәтеле белән киңәшеп, өстәмә акча да табарга тиеш булабыз...

Ярый, Алексей Юдин да үз диненә зур игелек кылган. Олы яшьтә булса да, тәвәккәллек белән зур эшкә тотынган һәм башкарып чыккан. Молодец! – диярге генә кала. Әңгәмәбез беткәч тә нәкъ шул сүзне әйттем аңа.

* * *

...Укучыларым белән әдәби очрашуларга йөргән чакта кайбер районнардагы керәшеннәр яшәгән авылларда да булырга туры килгәләде. Шуларның һәркайсында диярлек бер үк сорауны бирәләр. Ягъни: керәшеннәргә, аларның башка диндә булуларына мөнәсәбәтем нинди? Җавабым һәрвакыт бер булды:

– Һәркемнең үзе якын иткән динне тотарга хакы, үз ата-бабаларының диненә тугры калырга хокукы бар. Ул кадәресе сезнең ихтыярда! Ләкин... мин үзем чукындырылган нәселдә туган булсам һәм мәҗбүриләп чукындырылган бабамнарның кемлеген архивлардан тапсам, шундук ерак бабамнарның фамилиясен кабул итеп, исемемне исламчага үзгәртеп, муллага барып, алыштыртыр идем. Монысы инде минем ихтыярда!

Дөньяда, Кояш астында бер Аллаһ яраткан һәркемгә яшәрлек урын бар. Бигрәк тә халкы елдан-ел кими баручы Рәсәйдә урын киңәя бара. Шулай булгач, барчабызга да тигез, тату, тынычлыкта һәм иминлектә яшәргә насыйп булсын!

* * *

Язмамны түгәрәкләр вакыт житкәндә, үземне авылдан-авылга, шәһәрнең төрле якларына үз машинасында йөрткән, һәр очракта кинәшчем дә булган Минзәлә журналисты Дилфас әфәндегә зур рәхмәтемне әйтергә ашыгам. Чираттагы авылга да – Югары Тәкермәнгә дә бергә жилдерттек. Анда шактый мәктәпләрнең ашханәләренә уку елына житәрлек яшелчәләр биргән, игелекләре белән танылган аталы-уллы Нәсим һәм Шамил Дәүләтовлар бар икән. Шулар белән танышырга, эшмәкәрлекләре ни дәрәжәдә, ни хәлдә булуы белән кызыксынырга барам бу юлы...

Бәй, житез машинада утыз чакрымны үткәнебез сизелми дә калды. Безне яшь Дәүләтов каршылады. Дилфас алдан ук шылтыратып куйган икән, килеп житүгә үк бинаһая зур биләмәдәге ашханәгә алып китте Шамил. Әтисе Нәсим шушы хужалыкның эшләре буенча Казанга китеп барган икән. Улы да уртак проблемаларның һәркайсыннан хәбәрдар булганлыктан, сөйләшүләребез мәгънәле барды. Әйе, мәктәпләрне бәрәңге, кишер, чөгендер, суган, кәбестә кебек яшелчәләр белән тәэмин итүләре хак. Төшке ашны тәмләп ашаганнан соң, безне әнә шул яшелчәләр базасына алып китте. Түшәмнәре бик югары булган базаны күргәч, гажәпләнүдән телсез калгандай булдым: бая санап киткән яшелчәләрнең һәркайсы тау-тау монда! Шуларны саклау хәстәрен күреп кайнашучы кешеләрне эчемнән генә бик дәү кырмыска оясының эшче кырмыскаларына да тиңләдем. Үзебез дә кырмыскалардай вак булып күренгәнбездер, мөгаен, күтәрелеп күрүче дә булмады сыман. Эшләре тыгыз аларның – жәй-көз буе тырышып үстергән нигъмәтләрне кышкы саклауга әзерлиләр. Инде моннан чыккач, Дилфас белән Шамил дә ишетерлек итеп: «Бик зур, бик бай икән шул Дәүләтовлар дәүләте!» – димичә түзмәдем. Юл хәрефләре белән генә язган «дәүләте»м бу очракта мал-мөлкәт мәгънәсендәге тәржемәдә булды.

Саубуллашу алдыннан тагын бер сорау бирдем Шамилгә:

– Ихластан әйт әле, сезнең яшелчәләрегез чыннан да бушлай барып життеме мәктәпләргә?

– Әйе, – диде. Аннары өстәп куюны кирәк тапты. – Әз-әзләп түләүчеләр дә табылды башкалар арасыннан. Ләкин ул каләресе, кем әйтмешли, секрет фирмы инде.

Мин бит ревизор яки кешеләрнең күзенә текәлеп караучы, сорау алучы тикшерүче түгел. Ләкин шунысын беләм: игелекле, ярдәмле кешеләр алдый белми, иманлы була.

...Минзәләм төбәгендә өч-дүрт көн буе ниләр кылып йөрүем хакында әйтү өчен, район башлыгы янына да кереп чыгуны кирәк таптым. Ни өчен дигәндә, күп дистә еллар буе гел генә чит яклардан килеп торган «Беренчеләр» дән, «главалардан» гарык булган якташларым: «Ниһаять, Башлыгыбызның монысы үзебезнеке, Минзәләбезнеке!» – дип сөенә-сөенә кабатлап торалар районда. Монда икән, ник әле мин кермәскә, бераз булса да кинәшмәскә тиеш?

Сөйләшеп утыруыбыздан соң мондый нәтижә ясады Айдар Фәслах улы Сәлахов:

– Кылынган игелекнең кире кайтачагын син санап чыккан кешеләребез үзләре дә бик яхшы белә, минемчә. Дан булып та, Ходай өстәп торачак сәләт-талант буларак та, эшмәкәрлекләренә куәт, киң юл биреп торачак савап буларак та кайтачак! Шөкер, андый игелекле затларга бай безнең туган ягыбыз. Насыйп булса, алары хакында да фикерләшербез әле...

**Фәнзаман БАТТАЛ**

# СЕЗНЕҢ ЯЗМЫШ СУГЫШ УТЫ БЕЛӘН ҮРЕЛГӘН

**Госман Бакиров**

*(1896–1982)*

Татар балалар әдәбиятында озак еллар эшләгән Госман Фәтхулла улы Бакиров 1896 елның 12 мартында Татарстан Республикасының хәзерге Арча районы Югары Курса авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. 1912 елдан күрше авылда башлангыч мәктәптә балалар укыта. 1915 елда аны солдатка алып, Беренче империалистик сугышка озаталар. Ул Украинада Австрия-Венгрия гаскәрләренә каршы барган сугышларда, аерым алганда, Тернополь шәһәрен азат итүдә катнаша, ләкин 1916 елда, үзе хезмәт иткән часте белән чолганышта калып, дошман кулына эләгә һәм 1918 елга кадәр Австрия-Венгриядәге Дебрецен шәһәрендә әсирлектә була.

Ватанына кире әйләнеп кайткач, балалар укытуын дәвам иттерә. 1922 елда Казанга килә. Монда ул Г.Тукай исемендәге балалар йортына укытучы-тәрбияче булып эшкә урнаша, анда гражданнар сугышыннан кайткан курсант, яшь язучы Афзал Шамов клуб мөдире булып эшли. Алар дуслаша һәм шул елларда ныклап торып әдәби иҗат эше белән шөгыльләнә башлый: балалар өчен хикәяләр, пьесалар язалар, аларны шунда сәхнәләштерәләр. Балалар белән стена газеталары һәм кулъязма журнал чыгара башлыйлар. Казанда пионерлар оешмасы төзү эшендә актив катнашалар.

Афзал Шамов — балалар газетасы – «Яшь ленинчы»ның беренче санын әзерләүдә катнашкан язучы. Алар Госман Бакиров белән шул газета битләрендә мәкаләләрен бастыралар.

Госман Бакиров Җир төзү техникумының кичке бүлеген тәмамлаганнан соң, 1929-1937 елларда «Мәгариф» журналының җаваплы сәркатибе булып эшли, аннары Көнчыгыш педагогия институтын тәмамлагач, 1940-1942 елларда Татгосиздатта (хәзер Татарстан дәүләт китап нәшрияты) дәреслекләр һәм методик кулланмалар редакцияли.

Афзал Шамов Казан дәүләт университетының рабфагын, аннары Беренче Мәскәү университетының әдәбият һәм сәнгать факультетын тәмамлап, 1931 елның мартыннан Татарстан дәүләт нәшриятының матур әдәбият секторында җаваплы редактор һәм өлкән редактор булып эшли.

1942 елның 18 ноябрендә Госман Бакиров фронтка китә.

Г.Бакиров истәлекләреннән: «Якын дустым Афзал Шамов та озата килгән. Ул, минем кулымны кысып:

— Тиздән мин дә китәм. Канәчкеч дошман һаман түргә үрмәләгәндә, монда ничек түзеп ятарга. Китәм мин дә, сау бул, дускай, исәнлектә күрешик! – дип калды.

Безне Ижевск шәһәренә алып килделәр, сугыш эшенә өйрәтергә тиешләр икән. Частьларга бүлделәр... Мине миномётчылар частена билгеләделәр.

Көне буе урманда өйрәнүдә булабыз. Баракка кайткач, миномётларны сүтеп җыябыз, шулай итеп аның бөтен «серләрен» өйрәнәбез. Мине политрук ярдәмчесе

*Дәвамы. Башы 2014 елның 10 нчы санында*

итеп куйдылар. Кичке занятиеләрне мин үткәрәм, стена газеталары чыгарам. Эш житәрлек...

Сталинград тирәсендә дошманга каршы каты һөҗүмнәр башланган. Эшләр ашыгыч. Безгә дә чират килеп житте. Эшелонга төялеп юлга чыктык...

Сталинградка якынлашып киләбез...

Безнең юл Сталинград аркылы үтмәде. Сталинградта чолганышта калган немец гаскәрләре тар-мар ителгән иде инде...

1943 елның 1 маеннан башлап 120 миллиметрлы миномётта – полк миномётында орудие командиры булып эшли башлыйм. Ватаным тапшырган бу бурычны намус белән үтәргә тырышам.

Оборонада ятканда, партия миңа яңа бурыч тапшыра: батареядә мин партия оештыручысы булып эшли башлыйм. Без хәзер – Беренче Украина фронты сугышчылары.

А.Шамов та миннән соң күп тормаган, үзе теләп фронтка китеп барган икән. «Фронт газетасында эшлим, алдынгы сызыкка кадәр барып, батыр сугышчылар белән бик еш очрашам», дип яза ул...

1944 елның 20 марты. Дошманнан чистартылган Тарнопольгә барабыз. Фронт хәзер Тарнопольне үтеп, алга китте».

1944 елның 21 маеннан Госман Бакиров — Беренче Украина фронтында «Ватан намусы өчен» газетасы редакциясендә хәрби корреспондент.

Госман Бакиров үз башыннан ике сугышны кичерә һәм икесендә дә кулына корал тотып Ватаныбызны немец илбасарларыннан саклауда катнаша. Беренче империалистик сугышта ул патша армиясенең гади бер солдаты гына булса, Бөек Ватан сугышында инде ул подразделение парторгы, аннары фронт газетасы корреспонденты, Иделдән Одерга кадәр данлы җиңү юлын үтә ул. Кызыл Йолдыз, Икенче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, «Берлинны яулаган өчен», «Праганы азат иткән өчен» һәм «Германияне җиңгән өчен» медальләре белән бүләкләнә.

Сугыштан соң ул Казанга кайта, янадан нәшриятта эшли башлый. 1945 елдан 1956 елга хәтле дәреслекләр редакциясе мөдире. Госман Бакиров 1982 елның 12 мартында Казанда вафат була.

Афзал Шамов 1943 елның 9 февралендә үзе теләп фронтка китә һәм татар телендә чыга торган «Алга, дошман өстенә» газетасында хәрби корреспондент булып хезмәт итә. Бу газета башта Калинин фронтында чыга, аннары Беренче Балтыйк буе фронты карамагына күчә. Капитан Шамов авыр һәм данлы тарихи юл уза. Духовщина (Смоленск өлкәсе), Невель (Великие Луки өлкәсе), Витебск, Полоцк, Паневежис, Шауляй, Мемель (хәзерге Клайпеда), Кёнигсберг (хәзерге Калининград), Пиллау (хәзерге Балтийск) шәһәрләре аша үтә.

1945 елның 5 июнендә «Алга, дошман өстенә» газетасының татар редакциясе тулысынча Байкал арты фронтына күчерелә. Япон империалистларына каршы сугыш хәрәкәтләре башланыр алдыннан, бу фронтта «Суворовча кысрыклау» исемле татар газетасы оештырыла. Бу газетаның хәрби хәбәрчеләре Читадан башлап, Монголия далалары, соңыннан каты сугышлар белән Зур Хинган тауларын һәм Маньчжурия кырларын үтеп, Сунгари елгасын кичеп, Маньчжуриянең башкаласы Чаньчуньга, аннары Хабаровск шәһәренә кадәр барып житә. 1946 елның 27 апрелендә А.Шамов армиядән Казанга кайта. Бөек Ватан сугышы чорындагы шәхси батырлыклары һәм әдәби иҗат өлкәсендәге хезмәтләре өчен Кызыл Йолдыз (1944), Хезмәт Кызыл Байрагы (1957), Октябрь Революциясе (1971), Икенче дәрәҗә Ватан сугышы (1985) орденнары һәм бик күп медальләр белән бүләкләнә.

1949-1950 елларда А.Шамов «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналының редакторы, 1958-1962 елларда Татарстан Язучылар союзы идарәсе рәисе булып эшли.

Әти Госман абый белән соңгы сулышына кадәр бик дус булды. Сугыш елларында дуслар бер-берсенә бик еш хат язганнар. Әтинең архивында Г.Бакировның 21 хаты саклана. Минемчә, хатлар саны күбрәк булырга тиеш, чөнки берничә хат, әти әйткәнчә, «плен төште» ахры. Мин бу хатларны үз искәрмәләрем белән укучылар игътибарына тәкъдим итәм.



Госман Бакиров (икенче рәттә, сулдан икенче), фронтовик дуслары белән.

*Афзал дус!*

*Кичә генә миңа синең җаваплыгыңда чыккан ике нөсхә «Алга, дошман өстенә» исемле татарча газета китереп бирделәр. Газетаны кем җибәргәндер, белә алмадым. Синнән хат ала алганым юк. Бер хат җибәргән идем, ул хатыма Гимадиев[1] җавап бирде. Синнән хат булмаганга аптыраганмын, хат язарга да вакыт таба алмыйсыңмы, әллә шулай туры киләме, шулай да бу хатны тагын язарга булдым. Бәлки ничек тә бер кош теледәй генә хат язарга булдыра алырсың. Газетаны җибәрүегезгә зур рәхмәт. Татарча газета уку миңа монда зур удовольствие. Чөнки монда татарлар юк, татарча газеталар да килми. Ә болай газеталар нормаль килеп тора, үзәк газеталар да килә. Укып барам. Алдынгы линиядә булсам да, газеталар укырга вакыт табам. Иптәшләрдән, туганнардан һәм өйдән бик еш хат алып торам. Гомәр[2] әле Казанда хезмәт итә, аның язуына караганда, Сәйдәш[3] фронтта үлгән. Ә Бичурин[4] больницада ятып, туберкулёздан үлгән. Фатымадан[5] да бер хат алдым, рәхмәт аңа. Фронтта хат алуның бәясен ул белгән, җавап яздым. Газетадагы подпись буенча, Гимадиев белән бергә булырга кирәксез. Газета төрелгән кәгазь эчендә А.Ахмәт[6] иптәшнең котлау сүзләрен укыдым, димәк, ул да сезнең белән булырга кирәк. Минем аңа язган хатымны син тапшырырсың инде.*

*Үзем хәзергә исән-сау, искечә дошманны кууда дәвам итәбез. Урыны-урыны белән дошман кискен каршылык күрсәтә, ләкин безнең данлы Кызыл Армия, бөтен каршылыкларын җиңеп, алга баруын дәвам итә. Җәй буе немец бандаларын куып килдек. Сталино[7], Чистяковоны[8] азат итүдә катнаштым, хәзер Киевны да үтеп киттек. Тау башыннан безнең иске чикләр дә «күренә» инде. Тиздән Берлин морҗалары күренә башлар кебек. Бер ел эчендә үтелгән юллар, күргән картиналар, гомумән, баштан кичкәннәрдән миндә күп кенә материал җыйналды. Фәрештәләр канаты астында исән калсам, бәлки файдаланырга ярар. Хәзерге шартларда язарга бер мөмкинлек юк. Нарат урманы эчендә землянкаларда яшибез. Бик еш күчеп йөрергә туры килә. Хәзергә шунда нокта куеп, кыйтмир бәдүк[9] итик.*

*Гимади иптәшкә сәлам әйтерсең.*

*Хат көтеп калам.*

*Бакир*
*15.12.1943.*

[1] Гимадиев – Минһаҗ Гыймадиев (1903-1970), журналист, «Алга, дошман өстенә» исемле Беренче Балтыйк буе фронт газетасының редакторы.
[2] Гомәр – Абдулла Гомәр (1906-1974), Таттосиздатның матур әдәбият бүлеге мөдире.
[3] Сәйдәш – Сәйдәш Ибраһимов, Таттосиздатның матур әдәбият бүлеге хезмәткәре.
[4] Бичурин – Гали Бичурин, Таттосиздатның матур әдәбият бүлеге хезмәткәре.
[5] Фатыма – Фатыйма Шамова (1907-1980), укытучы, язучы Афзал Шамовның бертуган сеңлесе.
[6] А.Ахмәт –Абдулла Әхмәт (1905-1976), язучы, «Алга, дошман өстенә» исемле Беренче Балтыйк буе фронт газетасының хәрби хәбәрчесе.
[7] Сталино – хәзер Донецк шәһәре.
[8] Чистяково – хәзер Донецк өлкәсендәге Торез шәһәре.
[9] кыйтмир бәдүк итик – саубуллашыйк.

* * *

*Афзал дус!*

*Карангы төн уртасында нарат урманы эчендә немец кабахәтләрне куып барганда, мина почтальон бер хат китереп бирде; хатның кемнән икәнен белергә мөмкин түгел иде. Яктыргач, миномётны сугыш хәленә куйгач, каты обстрел вакытында хатны ачып укыдым. Бу хат синнән беренче хат иде, ләкин каршысына җавап язарга мөмкин булмады – без алга киттек. Ике-өч көннән соң мин тагы бер хатыңны алдым. Шул көнне үк җавап язарга тагы мөмкинлек булмады. Менә бүген генә бераз иркенләп хат язарга мөмкинлек туды. Якын дус күреп, җылы язылган бу хатларың өчен сиңа зур рәхмәт. Хатларың укып мин бик шатландым. Сезнең нинди шартларда хезмәт итүегез белән таныштым. Ике мәртәбә сез җибәргән газеталар да тапшырылды, бусы өчен дә зур рәхмәт. Монда татарча газеталар күрү бик күңелле. Чөнки монда татарлар юк диярлек, аз. Татарча газеталар да килми.*

*Афзал дус, мин бөтенләй башка шартларда хезмәт итәм. Хезмәтем җинел түгел, нишлисең инде, сугыш шартлары шуны таләп итә, Ватаныбыз шундый киеренке минутлар кичерә, тик шуңа шатмын: һәр көн алга барабыз, көн саен яна уңышлар казанабыз, авылларыбызны, шәһәрләребезне немец кабахәтләрдән азат итә барабыз. Бу азатлык өчен канлы көрәштә мина орудие командиры булып катнашырга туры килде. Җәйге һөҗүм башланганнан бирле, өзлексез рәвештә диярлек немецларны куабыз. Яңа елны Житомирда каршы алдык, безнең дивизия Житомирский дивизия исемен алды.*

*Афзал дус, бу хатым инде сиңа өченчесе булырга кирәк. Фатыма да мина бер хат язган иде, җавап яздым. Шуннан бирле аннан хат алганым юк.*

*Гимадиев иптәштән дә бер хат алган идем; җавап яздым. Ләкин Ибрайдан[10] хат ала алганым юк. Бер хат язган идем, җавабы булмады, хатым ирешмәдеме. Редакция исеменә язган хатым да җавапсыз калды. Үзем Армия һәм дивизия газеталарында катнашам, ләкин русча язарга туры килә. Башка газеталарда катнашканым юк, вакытым да сыйдырмый. Язарга уйлаган нәрсәләр һәммәсе дә план хәлендә. Материал күп. Әгәр сугыш кырларында ятып калмасам, миномётчиклар тормышына бер пьеса кебек нәрсә оештырырга теләк бар, ләкин киләчәк күрсәтер. Хәзергә бөтен омтылыш, бөтен көч немец кабахәтләрне тизрәк тар-мар китереп, җиңеп чыгуга юнәлдерелгән. Дошманны җиңәчәгебезгә нык ышанам, сугышчыларның моңа ышанычы зур, рух күтәренке. Алга таба атлаган һәр адым бездә чиксез зур шатлык, җиңүгә өмет тудыра.*

*Афзал дус, син анда ялгыз түгел икәнсең, каләм иптәшләрен үз янында, бу зур бәхет. Мин татар дөньясыннан хәзергә ераклашыбрак торам, язучылар хәленнән бернәрсә дә ишетә алмыйм. Татгосиздаттан күптәннән бирле хат алганым юк. Кемнәр, нәрсәләр эшләп яталардыр, белмим. Әгәр сиңа билгеле булса, мина язар идең.*

*Гимадиев иптәшкә, Ш.Маннур[11] һәм А.Әхмәт иптәшләргә сәлам әйтерсең. Бу хатны алгач, җавап хаты көтеп калам. Газеталар җибәрүдә дәвам итсәгез, бик шат булыр идем, сонаеп килсә дә, бу газеталар миндә җылы тәэсирләр калдыра, алар еракта килсәләр дә, миңа бик якыннар.*

*Өйдән, Гомәрдән хатлар еш алып торам. Сәйдәш һәм Бичурин үлүләре турында язалар.*

*Хәзергә шунда туктап, сәлам белән,*

*Госман.*

*Афзал дус, партиягә керүеңә мин бик шатмын, уңышлар телим, мин рекомендация калдырган идем шикелле. Бүләкләнү шатлыгын уртаклашуына рәхмәт.*

*Г.*

*3.01.1944.*

[10] Ибрай – Ибраһим Гази (1907-1971), язучы.
[11] Ш.Маннур – Маннур (1905-1980), язучы.

* * *

*Афзал дус!*

*Синең 12/XII дә язган хатың тапшырылды. Иптәшләрнең минем турыда кайгыртулары, үз яннарына хезмәткә күчерү чаралары күрүләре мине дулкынландырды. Минем күзләремнән яшьләр килде. Ләкин күп вакыт үтте инде, синең хатың да айдан артык вакыт юлда булган. Мәсьәлә минем файдага хәл кылынмаган булырга кирәк, хәерле булсын. Ни эшләмәк кирәк, фронт тормышының авырлыкларын күтәреп, хәзергә бер көйгә бара бирәм. Хәзерге көндә түн җирне чукып чокырларда ятабыз. Хат язарга да мөмкинлек юк. Синең хатың җавапсыз калмасын дип, карандаш белән генә булса да, бу хатны язарга булдым. Әгәр берәр авылга туктап, язарга мөмкинлек туса, иркенләбрәк бер хат язармын.*

*Гимадиев, А.Әхмәт һәм Ш.Маннур иптәшләргә миннән сәлам әйтерсең. Хәзергә сау-сәламәт, кабахәт немецларны кууда дәвам итәбез.*

*Авыр шартларда булса да партия эшләре алып барам. Полкта партбюро члены булып эшлим. Үзең ни хәлдә? Партиягә член булып үткәнсеңдер инде. Ибрайдан да бер хат алдым. Аның миңа язган хаты кире үзенә кайткач, шуның белән ул миңа хат язудан туктаган булган. Ике мәртәбә синнән газета алдым, рәхмәт, тагы җибәреп торыгыз.*

*Сәлам белән,*
*Усман.*
*23.01.1944.*

* * *

*Афзал дус!*

*Синең 4 мартта (нәкъ безнең дошман оборонасын җимереп, һөҗүм башлаган көнне) язган хатың 10 апрельдә кулга иреште. Минем өчен кайгыртып язуыңа бик рәхмәт. Синең белән очрашу миңа мөмкин булмады күрәсең. Хәзергә шул иске хезмәттә. Дошманны бик каты куабыз. Дөрес, бик зур кыенлыкларга да очрыйбыз. 8 март көнендә булган сугышта исән калуыма гаҗәпләнәм, кем бәхетенәдер, азгадырмы, күпкәдерме, кыл өстендә калдым. Гомумән, бу соңгы ике ай бик киеренкелек белән үтте. Тарнопольны[12] чолгап алып барылган сугышның авырлыгын, анда кичерелгән минутларны, исән калсам, сөйләргә генә булсын инде.*

*Афзал, хәзер безнең һөҗүм, нәкъ моннан 29-30 еллар элек минем немецларга каршы сугышкан урыннарда бара, көндәлек дәфтәрем кабатлана. Кем уйлаган 30 елдан соң бу урыннарга килеп, тагы немец кабахәтләр белән очрашырга туры килер дип!*

*Афзал, бу хатны карандаш белән генә сызгалаганга гаҗәпләнмә, чемоданым артта обоз белән калды, алар авылда ята, ә без кырда!*

*Без кыш буе авылда бик сирәк кунак булдык. Ә менә бүген кырда булсак та, көн матурланып тора. Чокыр читенә чыгып, сиңа хат язарга да мөмкин...*

*Афзал, синең хатың белән Р.Ишмурат[13] редакциясе астында чыга торган газетаны китереп бирделәр, бу инде икенче мәртәбә. Мин аны сез җибәрәсез дип уйлаган идем, һәм, шуңа күрә, Ишмурат сезнең белән бергә күрәсең дип санаган идем. Бу соңгы хатың буенча, Риза безнең 1 нче Украина фронтында булырга тиеш булып чыга, безгә татарча газеталар килми, шуңа күрә ул турыда хәбәрем дә юк иде. Безнең армейская газета, син уйлаганча, «За честь Родины» – татарчасы Риза чыгара торган газета була алайса!*

*Ләкин газетаны адреслап миңа кем җибәрә, газета бер ай чамасы килгән. Мин бу хат белән бер үк вакытта Ризага да язарга булам.*

*Их, Афзал, бар иде Порфировкада[14] гамьсез үткәргән көннәр! Шәһәр*

[12] Тарнополь – хәзер Тернополь шәһәре.
[13] Р.Ишмурат – Риза Ишморат (1903-1996), язучы, «Ватан намусы өчен» исемле Беренче Украина фронт газетасының редакторы.
[14] Порфировка – Татарстанның хәзерге Спас районындагы авыл, Болгар шәһәреннән көньяк-көнчыгышка таба 20 километрда.

*тормышыннан аерылып, авылда эшләү безнең өчен кыен күрелгән иде, ләкин без анда кунакта яткан икәнбез. Мин ул көннәрне бик сагынам, иске иптәшләр юк; язарга оныткәнмын — монда безнең дивизиядә Рахимов (Татгосиздат) очрады. Ул да парторг булып эшли икән, дивизионный партактивта очраштык. Капитан чинында. Соңгы көндә исәнлеген белмим.*

*Хуш, дускай, тагын язармын.*
*Госман.*
*11/IV-1944.*

* * *

*Әфзал дус!*

*16 мартта язылган хатыңны 15/V да алып укыдым, рәхмәт искә алуыңа. Бик күптәннән бирле синең хатың килми торды, аптырагач, моннан 1-2 көн элек кечкенә генә бер хат кисәге язып җибәргән идем. Алырсың. Хатлар гаҗәп озак йөри, болай булса, җавап көтеп торырга туры килмәс, искә алган саен, вакыт сыйдырган саен, кечкенә булса да хат язып торырга туры килер.*

*Афзал дус, якын дус күреп, җылы язылган хатларың миңа яңа көч, яңа дәрт кертә. Дус-ишләрдән бик аерым яшим мин, татарлар бөтенләй юк диярлек (бер татар егете бар, ләкин ул — әдәби хезмәттән ерак кеше), шуңа күрә фикер алышып, әдәби эшләр өстендә эшләү турында гәпләшеп утырырлык кешеләр гомумән бирелә юк. Кайчакта иске иптәшләрне күрү өчен, әллә кайларга барасы килә. Ишмуратов килеп чыгармын дип, адресны сорап хат язган иде, ул да килеп чыга алмый, күрәсең, хатларның озак йөрүе аны тотадыр.*

*Афзал дус, мин хәзер редакциягә күчеп эшләүдән өметне өздем инде. Синең һәм башка иптәшләрнең минем турыда кайгыртуларына бик рәхмәт. Өлешемә тигән йөкне күтәреп барудан башка чара юк. Бәлки, исән калсам, очрашырбыз. Әгәр мин сугыш кырларында ятып калсам, минем үтенеч: басылган һәм басылмаган әйберләрне карап чыгып (билгеле, төзәтү кертү кирәк булыр), балалар өчен бер җыентык кебек нәрсә оештыруда инициатива күрсәтсәң иде. Бу — кечкенә генә булса да, мин яратып эшләгән балалар, яшь буын өчен бер истәлек булыр иде...*

*Их, Афзал дус, белсәң иде, яшисе килә! Менә без торган хуторның исән калган чия агачлары хәзер ап-ак чәчәк җибәрә, һәр якта яшеллек, табигать үзенекен итә, гамьсез кошлар сайрый, тирә-юньгә ямь кертә. Ләкин бу күренешнең ямен кинәт туп тавышлары, баш очыннан очып киткән пуля сызгырулары гына боза. Дошманга каршы нәфрәт уяна, аны изеп ташлыйсы килә. Афзал дус, син минем табигатемне беләсең, элек тә мин кеше үтерү түгел, тычкан үтерүгә дә кулым бармый иде. Ә хәзер немец кабахәтләрне өере белән кырып ташлыйбыз, моны, тенкәгә тигән озынборын-черкине сытып ташлагандагы булган бер ләззәт белән эшлибез. Аларның үле гәүдәләре аркылы атлап алга барганда төкереп үтәбез.*

*Болар турында язмасам да, син аңлыйсың инде, яза башлагач, тыйнаксыз каләм барын да яза бирде.*

*Афзал дус, нигәдер сез миңа газетаны туктаттыгыз, Ризадан да килми тора, тик минем хатым басылган номеры килмәде, мин аны басылмады ахры дип уйладым.*


*Гыймадиев, Ш.Маннур һәм А.Әхмәт иптәшләргә сәлам ирештер. Сез тагын кемнәр белән очрашасыз. 4-5 көн генә элек Рахимовны очраттым, сезгә һәммәгезгә сәлам күндерде. Җитәр, землянканы караңгылык басты, күзләр начар күрә. Җыентыгыгыз[15] басылып чыктымы, их, күрәсе иде аны!*

*Афзал дус, кулыңны кысып, сәлам белән калам.*

*Госман.*
*16.05.1944 ел*

[15] Сүз «Нәфрәт көче» җыентыгы турында бара. Анда Калинин фронтындагы батыр татар сугышчылары һәм офицерлары турында очерклар җыелып басылган.

* * *



*Афзал дус!*

*Мин көтмәгәндә газета эшчесе булып киттем әле. 18 майда бик ашыгыч телеграмма белән Р.Ишмуратов чакыртып алды. Алар миңа ике айдан бирле берничә мәртәбә хәбәр җибәргәннәр, миңа нигәдер ул чакырулар ирешмәде. Соңгы телеграмманы алу белән, җыенып юлга чыктым, 2-3 көн эчендә бөтен кирәкле дистанцияләрне үтеп, автомашина белән килеп җиттем. Иптәшләр бик җылы каршы алдылар. Кочаклашып, үбешеп күрештек. Иптәшләрнең болай үз күреп, игътибар белән каршы алулары мине дулкынландырды. Минем турыда чын күңелдән кайгыртуыңа синә да рәхмәт. Мин хәзер бөтенләй икенче дөньяда кебек. Яратып эшли торган язу эшендә. Бу хезмәт белән илебез алдында үземне акларга тырышачакмын. Хәзер эшләр белән танышып барам. Материаллар хәзерләшәм. Хәзер без хәбәрчеләр киңәшмәсенә бик нык хәзерләнеп ятабыз. Риза доклад хәзерләде. Мин корреспондент-хәбәрче булып эшләячәкмен. Эшли алырмын дип уйлыйм. Монда килгәч, татар әдәбияты дөньясы белән очраштык. Күп кенә минем өчен яңа булган хәбәрләр ишеттем, китаплар күрдем. Кайбер яңа үсеп килә торган язучылар турында ишеттем. Монда килгәч, минем дә язасым килеп китте. Тик каләм дә тупаслана төшкән, инде бераз язгаларга мөмкин булыр дип уйлыйм.*

*Тормыш монда ярыйсы гына, культурный гына оештырылган, аерым столоваябыз бар. Үзебез, татар газетачылары, аерым бер йортта торабыз, шунда ук эшлибез. Аның күп кенә уңай яклары бар. Г.Хужи[16] һәм М.Садри[17] иптәшләр мине эшләр белән таныштыралар, булышалар. Алар шактый үскәннәр. Газета өстендә эшләү аркасында күп кенә опытлары бар. Иптәшләр һәммәсе дә офицерлар. Мин хәзергә өлкән сержант булып офицерлар хезмәтен үтим. Киләчәктә офицерлык дәрәҗәсе бирү турында Риза иптәш кайгыртып йөри. Аның уңай яклары бар инде. Риза, Хужи һәм Садри иптәшләр кайнар сәлам җибәреп калдылар. Гимади һәм А.Әхмәт иптәшләргә сәлам ирештерерсең инде.*

*Хәзергә исәнлек теләп, хатымны очлыйм. Хат язып тор. Үземнең кайдалыгымны тизрәк белдерү өчен бу хатны язарга ашыктым.*

*Хуш, Афзал дус!*

*Г.Бакир*
*23.05.1944 ел*

* * *

*Афзал дус!*

*Типография урнашкан йорт янындагы чия бакчасында өстәл куеп, газета материалларын эшләп ятканда, почта бер төркем хат һәм газеталар белән син җибәргән «Нәфрәт көче» исемле җыентыкны китереп тапшырды. Рәхмәт. Китап белән әле танышырга өлгерә алмадым, әчтәлеген генә карап чыктым, күп кенә материал тупланган. Әйбәт иткәнсез. Ләкин ни өчендер китапның техникасы*

[16] Г.Хужи – Гали Хужи (1912-1966), шагыйрь, «Ватан намусы өчен» исемле Беренче Украина фронты газетасының җаваплы секретаре.

[17] М.Садри – Мөхәммәт Садри (1913-1999), шагыйрь, шул ук газетаның корреспондент-оештыручысы.

*мина ошамады. Шундый әйберне бераз игътибар белән эшләгән булсалар, ни булган соң инде. Бу инде Татгосиздатның эшкә салкын каравыннан килеп чыккандыр.*

*Үзем газета эшләре белән танышып килəм, һәр санда катнашам, ләкин зуррак нәрсә эшли алганым юк әле. Газета эшенә күчкәч, сиңа хат язып салган идем, әле үзеңнән җавап ала алганым юк.*

*Газета эшен бик яратып эшлим. Минем үзем яраткан хезмәткә күчүемдә, синең тырышлык булды инде. Мин аны бервакытта да онытмам.*

*Гыймадига, А.Әхмәткә миннән сәлам. Садри, Г.Хужи һәм Ишмуратов иптәшләрдән сәлам.*

*Сәлам белән, Г.Бакир.*
*6.07.1944.*

* * *

*Афзал дус!*

*Җибәргән китабыңны алгач, бер кош теледәй генә хат язып салган идем. Бүген бер кочак хат китереп бирделәр. Ул хатлар иске адрес белән частька килгән булган, шуннан җыеп җибәргәннәр аларны. Менә шулар арасында синнән дә хат бар иде. Әле син минем Риза янына күчеп эшли башлавымны белмәгәнсең. Яңа хезмәткә күчкәч, мин инде дүртенче хатымны язам булырга кирәк. Синең тырышлык бушка китмәде, мин дә үз урынымны таптым. Газета эшләре белән танышып килəм, кызыксынып эшлим. Иптәшләр дә күнеллеләр. Ләкин мин синең белән булсам, тагын да күңеллерәк булыр иде. Афзал, фронтта уңышларыбыз искиткеч зур, безнең данлы гаскәрләребез шулкадәр тиз хәрәкәт итәләр, без стенадагы картаны буяп барырга да өлгермибез.*

*Афзал дус, сугыш дүртенче елга китте, исеңдәме, без сугышның беренче елында Порфировкада ашлык суктырып яткан идек, ишегалдында саламнан салган «сарай»ны хәтерлисеңдер. Күршеләрнең бәдбәхәт сыеры килеп, төнлә ишеп ташламаганда, без анда бик тыныч йоклый торган идек...*

*Кайда калды син өйгән салам кибәннәре!*

*Полтава өлкәсе кырларын үткәндә, кырларда куелган шундый кибәннәрне күргәч, мин синең шул хезмәтләреңне искә төшердем. Алар да бик ерак калды инде, үткән юллар шундый озыннар, күз алдына китерү дә читен! Син, Венгриягә житәбез, дип минем онытылган истәлекләрне кузгатып куйгансың, әйе, Афзал дус, бәлки таныш мадьяр кызлары белән очрашырбыз...*

*Ләкин, мин карт кебек, алар да инде икмәкне, бәлки, суга манчып, җебетеп ашыйлар булыр. Их, гомерләр!!! Инде синең белән беренче очрашкан вакытларга күп заманнар үтте, хәтереңдәме, мин сине беренче мәртәбә Яңа бистә белән ике арада, «алтын» бушата торган урында очраткан идем, син ул вакыт шәһәребезнең ышанычлы «алтынчылар»ыннан санала идең, чөнки озын саплы чүмечләр белән тутырылган мичкәләрне һич түкми-чәчми урынына илтеп, хыянәтсез рәвештә бушатуың белән йорт хозяйкалары арасында мактанып сөйләнә идең. Билгеле, минем квалификациям әз иде әле, син миңа башта озын саплы чүмечне ничек тотарга, аны чокыр эченә ничек батырырга һәм чүмечне тулы итеп чумырып алырга өйрәтә идең. Хәтерендәдер, бервакыт мин чокыр эченә төшеп киткән идем, шулвакыт мине коткару өчен син аякларыңны суздың, ләкин, мин тәҗрибәсезлегемнән, синең аякларыңнан тотасы урынга, чалбар балагыңа ябышканмын, шуннан соң мин чалбарыңны тартып төшереп, сине йорт хозяйкасы алдында оятка калдырган идем. Ярый инде, алар бары да үтте.*

*Сәлам белән, Госман.*

*Гыймадига, А.Әхмәткә сәлам. Садрыйдан, Ризадан, Г.Хужидан һәммәгезгә сәлам.*

*Нигә газетагыз безгә килми, җибәрсәгез лә!*

*12.07.1944.*

* * *

*Афзал дус!*

*Яңа авылга күчеп, урам уртасында квартира көтеп торганда, Риза синең хатынны китереп бирде. Ләкин ул хат миңа бик «кыйбат»ка төште. Риза биетмичә бирмәде, каһәр!*

*Фронтта уңышлар искиткеч зур. Сез дә алга шәп барасыз, әмма без тагын да шәбрәк шикелле. Сезнең белән ярышырга мөмкин. Син бер өер[18] фрицны пленга алдым дип язасың. Безнең егетләр — алар сынатмыйлар, молодец! — дип куйдым эчемнән. Каләме очлы булган егетләребезнең сөнгеләре дә үткен шул аның. Әйдә, иш янына куш булыр. Бездә алар хәзер соңгы көннәрдә генә дә күпме инде! Шуларны күргәч, бу кабахәтләрнең дә кулга эләгер көннәре булыр икән, дим.*

*Афзал дус, син безнең иптәшләрнең бүләкләре турында сорыйсың. Белмим, кайдан чыккан икән ул хәбәр? Бездә хәзергә бары да искечә. Риза белән миндә — чит орденнар, башкаларда юк әле. Мин үзем өлкән сержант булып эшли бирәм шунда, начальник кешеләр кайгыртмый, үзем бу мәсьәләне күтәрергә кыймыйм. Әйдә, үтәр әле, дип йөри бирәм. Газетаның партия бүлеген алып барам.*

*Нигә безгә газетагыз килми икән?*

*Гыймадига һәм А.Әхмәт иптәшләргә сәлам әйт. Риза белән Галидән сәлам. Бу хатны чия бакчасында яздым. Иртәгә чыгачак газетаның материалларын хәзерләп утырабыз.*

*Сәлам белән, Бакир.*
*27.07.1944.*

* * *

*Әфзал дус!*

*Бик күптәннән бирле синнән хат юк. Әллә вакыт тапмыйсың, әллә болай оныттың инде. Соңгы хатымны, әгәр ялгышмасам, июньдә үк язып салган идем, ул хатны бик иркенләп, Порфировкада яткан вакытларны искә төшереп язган идем, әллә андагы шаяру сүзләремә кәефең киттеме, ләкин без синең белән андый гына шаяруларны күтәрә торган идек бит. Сездән хат булмауга ул сәбәп булгандыр дип уйлый алмыйм мин. Бу хатны алгач, бер хат яз әле, мин шуннан үзем аңлармын...*

*Әле без Садри белән бүген частьта дежур торабыз. Ял көне. Хәзер кино бара. Без редакциябездә утырабыз.*

*Газетагыз ике айга бер генә номер килде, ә үзебез һәр чыккан номерын җибәрә барабыз, сезгә барып чыгамы, юкмыдыр. Эшләр бер көйгә тәгәри, менә көз житте, ахры кышларга туры килер. Өйдән хат еш кына алып торам. Бер көе генә торалар шунда. Гомәрдән дә хат килә. Ул әле һаман Казанда ята.*

*Без монда 1 нче Украина фронты татар сугышчыларының татар халкына җавап хатын оештырып җибәргән идек, Татарстанда аны бик яхшы каршылаганнар. Безнең хатлар русча-татарча аерым китапчык булып басылып чыккан, аннан тыш плакат итеп тә бастырганнар. Редакциягә һәркөн өем-өем хат килә (Татарстан районнарыннан).*

*Партиягә үткәнсең инде. Эшләреңдә уңышлар телим.*

*Гыймадиевка, А.Әхмәт иптәшләргә сәлам тапшыр.*

*Шулай, Әфзал дус, менә карт солдатның хезмәт итә башлавына тиздән ике ел тула инде. Мин болай озак хезмәттә булырмын дип һич уйламаган идем. Казан сагындыра, семьялар, дуслар сагындыра.*

*Ярый, хәзергә хуш булып торыйк.*

*Сәлам белән,*
*Госман.*
*25.09.1944.*

---

[18] Эти 1944 елның 30 июнендә Белоруссиядә 7 немецны пленга ала.

* * *

*Афзал дус!*

*Ашъяулык кадәр кәгазь алып, сиңа хат язарга утырам. Ләкин белмим, ниләр язып тутырырмын икән!*

*22/XI дә язган хатың 22/XII дә тапшырылды. Нәкъ бер ай килгән! Синнән хат булмауга аптырап тора идем. Әллә, мин әйтәм, болар эш бетереп кайтып киттеләрме, каһәре! Чөнки газетагыз килми. Үзебез һәр номерын җибәреп торабыз. Гомумән, хәзер фронт газеталары сирәк килә. Хәзер бездә, Газиз Иделле[19] белән «Кызыл Татарстан» эшчесе Фатыйма Галиева. Алар февраль башларына кадәр бездә торачаклар. Без Татарстанның 25 еллыгына бер җыентык бирмәкче идек. Риза шул мәсьәлә буенча Казанга кайтып килгән иде, ул үзе белән шул иптәшләрне алып килгән. Хәзер бөтен коллектив шул эш өстендә эшли. Мин дә кайбер нәрсәләр бирергә уйлыйм. Хәзергә Польшаның бер авылында ятабыз. Фронт «тыныч» тора. Соңгы кышның яртысына җитәбез, май бәйрәмен Казанда каршыларбыз инде.*

*Казаннан, өйдән хатлар еш алып торам. София[20] хәзер мединститутка кереп укый башлаган, авиаинститутта бер ел укыгач, яратмады, чыкты. Хәзер ул үскән инде, рәсемен җибәргән. Аның үсүе картаеп баруымны күрсәтә. Синең Миләүшә[21] үсеп җиткәндер инде, хат яза торгандыр, ә Гадилә[22] эштән бушамыйдыр, ул болай да хат язарга яратмый иде шикелле. Була бит шундый табигатьле кешеләр. Мин үзем хатны еш алам, дус-ишләр дә язып тора, София да, Гөлсем[23] дә (рәхмәт төшсен үзләренә) еш кына хат язалар. Шулай итеп, 2-3 көндә кемнән булса да берәр хат килеп тора.*

*Үзең нихәл, син майор булгансың инде. Ә мин шул өлкән сержант булып йөри бирәм, старшина итәбез дип язып алган булдылар, әле очы-башы күренми, ә офицер булу өчен сынауга хәзерләнергә кирәк. Без өйләнгәч, төн кыска булды, дигәндәй, хәзер аның шундый мәшәкатьләре бар икән, хәзерләнергә вакыт юк, картайгач, көчәнәсе дә килми, тизрәк сугыш бетеп, семьялар янына кайтасы гына килеп тора. Казаннан килгән иптәшләр сөйләвенә караганда, анда тормыш бераз яхшыра төшкән, базарда азык-төлек нәрсәләре дә арзанайган.*

*Таттосиздатка тагын Тинчурин[24] кайтып эшли башлаган. Х.Хәйри[25] «Совет әдәбияты»нда эшли икән. Газизнең килүе яхшы булды, ул күп хәбәрләр алып килгән иде.*

*Тиздән яңа елны каршыларга җыенабыз. Бу инде армиядә 3 нче мәртәбә каршылау була. Гомерләр шулай уза. Үткән юлларны исәпләсәң, акыл җитми. Кем уйлаган бу сугыш шулай озакка сузылыр дип. Инде сугыш башланган көннәр бик еракта артта калдылар. Синең белән колхозда ашлык суктырып яткан вакытлар әллә кайчан булып үткән көннәр шикелле хәтердә калганнар. Ул көннәрдән бирле күп сулар акты, сугыш барышында зур үзгәрешләр булды, безнең гаскәрләр үз илебездән дошманны куып кына калмадылар, Будапештка барып җиттеләр. Инде сугышның бетүен дә күрсәк иде. Зур тарихи эштә катнашучы булып кайтыр идек. Үзең әйтмешли, бергә чүкешеп бокал күтәрер идек (бу эштә без икебез дә ташка үлчим инде!).*

*Гыймадиев һәм А.Әхмәт иптәшләргә сәлам ирештер, алар ни эшләп яталар, картлар әйтмешли; Риза, Гали Хуҗиев һәм М.Садри, Газиз Иделле иптәшләр һәммәгезгә сәлам язарга куштылар. Газиз бу арада бераз чирләп тора, Польша һавасы килешмәде ахры Казан кешесенә. Ул бер атна чамасы вакыт алдынгы сызыкларга барып, туп төшкән урыннарны карап килде. Үзем монда килгәннән бирле чыгып*

---

[19] Газиз Иделле (1905-1985) – язучы, 1944 елның ноябреннән 1945 елның мартына кадәр «Ватан намусы өчен» исемле Беренче Украина фронты газетасы редакциясенә иҗат командировкасына килә.

[20] София – язучы Госман Бакировның кызы.

[21] Миләүшә – язучы Афзал Шамовның кызы.

[22] Гадилә – язучы Афзал Шамовның тормыш иптәше.

[23] Гөлсем – язучы Госман Бакировның тормыш иптәше.

[24] Тинчурин – Таттосиздат белән идарә итүче.

[25] Х.Хәйри – Хәсән Хәйри (1910-1994), әдәбият галиме, тәнкыйтьче.

*йөргәнем юк әле, аллә ничек туры килми, яшьләр генә барып киләләр. Күбрәк газета материаллары өстендә утырам. Күп сәлам белән,*

*Госман.*

*Хат язып тор, дус!*

*23.12.1944.*

* * *

*Афзал дус!*

*Яңа ел белән котлап язган хатың чүт кенә өстенә төшмәде. 4 кенә көн соңарып килде. Шулай да искә төшереп язуыңа зур рәхмәт. Киләсе елны, үзең әйтмешли, бергә каршыласак иде инде, дус!*

*Үзем искечә кыбырдап ятам, көн дә бертөсле эш белән вакыт үтеп тора. Алдынгы линиягә чыкканым юк. Яшьләр чыгып-чыгып керәләр. Әле күптән түгел Риза да барып килде. Ул яңа елны шунда каршылады. Газиз Иделле әле безнең белән. Аның нинди максатлар белән килүе турында алдагы хатта язган идем шикелле.*

*Яңа елны иптәшләр белән күңелле генә каршыладык. Монда поляклар яңа елны кызык каршылыйлар икән. Көндезен костёлга барып, гыйбадәт кылып кайттылар. Ә кичен яшьләр, өй саен кереп, төрле тамашалар күрсәтеп йөрделәр, акча җыйдылар.*

*Казаннан еш кына хат алып торам. Казан үз урынында икән әле. Кайчан Казанны күрәбез инде, сагындырды ул хөрмәтле шәһәребез!*

*Гыймадига, А.Әхмәткә сәлам ирештер. Бөтен коллективтан барыгызга сәлам.*

*Кайнар сәлам белән,*

*Госман.*

*5.01.1945.*

* * *

*Афзал дус!*

*Бик озын итеп язылган хат тапшырылды. Рәхмәт искә алып язуыңа. Хатың килгән көнне нинди дер могҗиза белән бер номер газетагыз да килде. Синең «Көзге чәчәкләр»еңне укырга вакыт таба алмыйм әле, бу арада эш күбәеп китте. Садри командировкада, Хуҗи Иделләр белән Казанга китте. Эш үзебездә генә калды.*

*Афзал дус, без Германия эченә керә барабыз. Яңадан-яңа шәһәрләр, авыллар үтелә. Ләкин немец халкы качып беткән. Йортларда беркем дә юк. Үзебез хуҗа булып йөрибез. Йорт җиһазының, чүпрәк-чапракның чиге юк. Бөтен илне талап, бай яшәгәннәр икән кабахәтләр.*

*Афзал дус, син минем положение белән кызыксынып, офицерлар хокукы белән файдаланасыңмы, дип сорыйсың. Мин һәм башка минем кебек иптәшләр (без бишәү шундыйлар) килгәннән бирле, офицерлар хокукы белән файдаланабыз. 2 350 сум хезмәт хакы алам. Шуннан 1 000 гә якыны өйгә җибәрелә. Безгә, Германиягә килгәннән бирле, марка белән түлиләр. Ул 4 700 марка чамасы.*

*Безгә дә имтихан бирергә кушалар. Ләкин иптәшләрнең берсе дә аның белән кызыксынмый. Алар кузгалмагач, мин карт башым белән йокы калдырасым килми. Тизрәк сугыш бетүен генә көтәбез.*

*Хуш, дустым, ашыгычрак булды.*

*Госман.*

*18.03.1945.*

* * *

*Афзал дус!*

*Апрельнең 3 ендә язган хатың тапшырылды. Истән чыгармавыңа бик рәхмәт. Хат язмыйсың, дисең син; мин ара-тирә булса да язып торам шикелле. Минем сиңа ирешмәгән соңгы ике хатым булырга кирәк әле. Ул хатларны синнән хәбәр булмауга аптырап язган идем. Әллә безнең еракка китүнең зыяны инде, хатлар*

*озак йөри башлады. Кичә генә Гали Хужи Казаннан килде. Ул Казан хәбәрләрен китергән. Сиңа күчереп тапшырырлык нәрсә юк, жыентыгына договор төзегән. Кашшаф[26] Москвада авырып ята икән, Татарстанның 25 еллыгына хәзерлек салмак кына хәзерләнеп ята, ди.*

*Афзал, без бу арада бик шәп киттек, безнең фронт инде Берлинда. Риза әле Берлинда, мин бармакчы идем, ул үзе китте. Мин ул кайткач барырга уйлыйм.*

*Торып-торып тагын сезнең газеталарыгыз килә башлады. Мин жибәргән газеталар сезгә барадырмы? Үземнең хәлем искечә, офицер булып кайта алмам, ахры, хәзерләнеп йөри алмыйм, вакыт та юк. Күңел сугыш бетүен генә көтеп тора. Иптәшләр арасында кызыксынган кешеләр юк. Алар да, сугыш бетеп, тизрәк тыныч хезмәтне генә көтеп торучылар. Бу арала Садрины «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләделәр. Риза белән мин II дәрәжә «Ватан сугышы» ордены белән бүләкләндем.*

*Афзал, синең дә орденнарың бардыр инде, нигә язмыйсың, Гимадиның да шулай ук.*

*Иптәшләр һәммәсе дә сиңа сәлам әйтергә тапшыралар.*

*Сәлам белән, карт солдат —*
*Г.Бакир.*

*Афзал, «Совет әдәбияты»ң (№10) ничектер синең исемгә безгә килеп төште, мин аны, төзәтеп, сиңа жибәргән идем, нишләр инде, барырмы. Минем анда бер хикәям кебек нәрсәм дә басылган икән.*

*28.04.1945.*

* * *

*Афзал дус!*

*Минем хатым килмәүгә пошынып язган ачык хатың тапшырылды. Хатым тапшырылмауга мин дә гажәпләнәм. Ышанасыңмы, ничә хат яздым! Күпме хатлар йөри? Өйдән регуляр рәвештә алып торам. Хат язмый калган көнем юк. Сез ни эшләп ятасыз? Газета эшенә чумып, башка ижат эшләрен тукталып торамы? Газеталарыгыз бик сирәк кенә килеп тора, аның буенча гына эшегез турында хөкем итүе читен.*

*Афзал дус, ниһаять, сугыш та бетте бит, малай! Ләкин кайчан кайтабыз инде, без картларның күңеле шунда гына инде. Тормышыбыз — Германиянең зур шәһәрләреннең берсендә. Шәһәр матур гына. Яшеллек күп. Торган йортыбыз тормышның бөтен шартларына жайланган. Ләкин, шуңа карамастан, күңел утырмый. Казан сагындырды, семья сагындырды.*

*Үзебездә артык яңалыклар юк шикелле. Моннан алдагы хатларымда язган булсам да, алар тапшырылмаган булуы мөмкин. Берлин урамнарында сугышлар барганда, Риза, яраланып, инде госпитальда ятып, савыгып чыкты. Хәзер әйбәт кенә йөри. Садрины капитан иттек. Ә мин старшина булып йөрим әле. Шулай кайтырмын, ахры. Риза белән икебез II дәрәжә «Ватан сугышы» ордены белән, Садри «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләндек. Мин синең бүләкләрең белән кызыксынам. Син нигә язмыйсың? Буш йөрми торгансыңдыр ич!*

*Ярый, дус, үзең дә хат язып тор.*

*Сәлам белән,*
*Госман.*
*Германия.*
*31.05.1945.*

*Хатларны һәм искәрмәләрне* **Әлфия ШАМОВА** *әзерләде.*

[26] *Кашшаф – Гази Кашшаф (1907-1975), тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме.*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Илдар ЮЗЕЕВ**

## Син бердәнбер!

Атаклы гармунчы Фәйзи Биккинин белән Илһам Шакиров гастрольгә чыга. «Татар көйләрен җиренә җиткереп, моңлы итеп башкаручы синең белән мин генә!» — ди икән Фәйзи ага Илһам Шакировка.

Илһам, Фәйзи Биккининның мактаганга эреп китә торган гадәтен белеп алгач, бер авыл егете белән алдан ук сөйләшеп куя. Егет, Илһам Шакировның кушуы буенча, концерт беткәч, сәхнә артына кереп, Фәйзи Биккининның кулын кысып: «Фәйзи ага, татар көйләрен синнән башка берәү дә болай ук моңлы итеп уйный алмый! Фәйзи ага, син бердәнбер сәхнә йолдызы!» — дип әйтергә тиеш була.

Концерт тәмамлана. Егет, сәхнәгә менеп, Фәйзи Биккининга Илһам өйрәтеп куйган сүзләрне әйтә, кулын кыса, рәхмәтләр укый. Музыкант алдында баш ия. Фәйзи ага, егетнең кулын ычкындырмыйча, Илһам Шакиров янына алып килә дә:

— Илһам, Илһам! Тыңлале! Кабатла, егетем, Илһам да ишетсен! Менә мине халык ничек олылый! — дип сөенә карт музыкант.

Фәйзи ага Биккинин шушы вакыйганы жае чыккан саен һәркемгә сөйли торган була.

**Рабит БАТУЛЛА**

## Уйнап кына

Үзбәкстандагы гастрольләр вакытында бер концерт барышында мондый вакыйга була. Гадәттәгечә, Илһам Шакировка залдан бик күп язулар килә. Ул аларны ачып укый да шунда ук җавабын да бирә. Чираттагы кәгазьне сүтеп карагач, көлә башлый:

— Тагын җыр сораганнар. Мин инде кәгазьгә акча төрелгән дип торам!

Шуннан соң залдан бер сумлыклар, өч, биш, ун сумлыклар төрелгән кәгазьләр ява башлый. Җыелган акча мең сумнар тирәсенә житә.

— Агай-энеләр, дусларым! — ди Илһам Шакиров. — Мин бит бая уйнап кына әйткән идем. Зинһар, акча җибәрмәгез!

Залдан кычкыралар:

— Без дә шаярып кына... Чынлап тотынсак, илле, йөз меңнәр салыр идек! — диләр.

Җыелган акчаны Илһам Шакиров оркестр егетләренә бирә, тегеләр икенче көнне шәп кенә бәйрәм ясыйлар.

Гәрәй РӘХИМ

## Бүре һәм гөмбә

Азнакайда әдәбият-сәнгать көннәре үткәрдек тә Бөгелмә—Казан самолётында кайтып киләбез. Илһам Шакиров белән урыннарыбыз янәшә. Гадәттәгечә, кызык сүзләр, мәзәк хәлләр турында сөйләшеп барабыз. Артыбызда утырган Әхәт Гаффар да сүзгә катыша:

— Илһам абый, мин бит һәвәскәр гөмбәче! Шундый шәп тозлыйм, м-мм, теленне йотасың...

— Булмагае, мин гөмбә ашамыйм! — дип кырт кисә Илһам Шакиров.

— И-ии, Илһам абый, — дип дәртләнеп китә Әхәт, — гөмбә бит ул бик файдалы ризык, туклыклылыгы ягыннан иттән дә өстенрәк!

Илһам, кашын җыерып берара сүзсез торды да, артка таба борылып, Әхәткә:

— Ахмак син! — дип әйтеп ташламасынмы. — Гөмбә итне алыштырса, аны бүре ашар иде. Гомерен куркыныч астына куеп, Хөппенисаттәйләрнең сарык абзарларын басмас, ә урманда тыныч кына гөмбә чүпләп йөрер иде!

Әхәт үзе дә, әңгәмәгә колак салып барган язучы һәм артист халкы да дәррәү көлеп җибәрделәр.

Әхмәт РӘШИТ

## Тырышлык кирәк

1967 елда Ташкентта гастрольдә вакытта бер-берсенә бик тә охшашкан өч кыз, сәхнәгә менеп, Илһам Шакировка чәчәк бәйләмнәре бүләк итәләр.

— И-и, матуркайларым, — ди атаклы җырчыбыз. — Әллә сон сез бертуганнармы?

— Ие, — ди арадан иң олысы, ун яшьләр чамасындагы кызыкай.

— Бигрәк үрчемле нәсел икәнсез! — ди Илһам. — Рәхмәт! Чәчәгегез өчен дә, үрчемле булганыгыз өчен дә рәхмәт!

Еллар узгач, Илһам Шакиров тагын Ташкентка килә. Бу юлы бер-берсенә охшаш җиде кыз сәхнәгә менә.

— Әстәгъфирулла! — ди җырчыбыз. — Сезне каядыр күргәнем дә бар шикелле...

Буй житкән олы кыз сүз башлый:

— Без, Илһам абый, Айдаш Мортазин балалары!

Илһам Шакиров кызларны аркаларыннан сөеп, берәм-берәм үбеп чыга да микрофонга әйтә:

— Хөрмәтле Айдаш иптәш Мортаза! Рәхмәт сезгә! Ә сез, кадерле тамашачылар, Айдаштан үрнәк алыгыз! Барыгыз да Айдаш кебек тырыш булсагыз, мин әле йөз яшькә чаклы җырлаячакмын!

Сәхнә — чәчәкләргә, зал алкышларга күмелә.

Марсель ГАЛИЕВ

## Чыбыркы тәме

Ул дәвердә әле телевизор дигән йорт шайтаны юк дәрәҗәсендә. Илһам Шакировның радио аша гына халыкка танылып килгән чагы. Ринат Таҗетдин аны Чүпрәле ягына, үзенең туган авылы Кече Чынлыга кунакка алып кайта. Икесенең дә яшь, егет чаклары.

Менә алар табигать хозурына чыгалар. Яр буйлап барганда, иненә чыбыркы салган көтүче янында тукталалар. Сүз иярә сүз китә.

— Цүпрәлегә Илһам Шакиров кайткан диләр, хак сүз микән? — ди мишәр абзаң.

— Кемгә хаҗәте бар аның! — ди Илһам Шакиров исе китмичә генә. Көтүче абзый аңа сәерсенеп карап ала.

— Илһамның ни моңы, ни комы! — дип өсти Илһам Шакиров.

— Нәк сүгәсең аны! Кем булдың шыл чаклы?! Выт син аны, ә! — дип, кайнарланган мишәр абзаң, чыбыркысын селтәп, Илһам Шакировның балтырын «яндырып» та ала. — Илһамга тел тидерергә синең ни хакың бар! — дип отыры кыза барган чүкеч кебек абзыйны ничек суындырырга хәзер?

— Ул үзе Илһам Шакиров, шаяртты гына, — димәкче була Ринат Таҗетдинов, әмма соң, хәзер инде моны исбатлый да, кызган агайны тиз генә туктата да алмыйсың, бөтен ышаныч — аякларда.

Көтүче абзый, чыбыркысын колак төбендә чыжылдата-чыжылдата, ике артистны авыл башына кадәр бастырып килә. Шулай итеп, Илһамга тел тидергәне өчен Илһамга чыбыркы тәмен татырга тура килә.

* * *

— Чүпрәле ягында тап-такыр дала, бер агач та үсми, башыңнан эшләпә төшсә, Ульяновскига кадәр җил тәгәрәтеп бара, диләр, шул дөресме? — дип сорыйм Илһам агадан.

— Таҗига кунакка барган чакта мин анда үсеп утырган бер агач күрдем, ул да зиратта иде, ул да сынган иде...

Минем җәелеп көлүемне Илһам ага бүлдереп, сүзен «төзәтеп» куйды:

— Чүпрәлеләр — тырыш халык. Хәзер инде яшеллек тә күп, шаулы урманнар да үсә, — диде.

## Гайбәт әйбәткә йога

— Үз гомерегездә гайбәтләр күп ишеттегезме? — дип сорыйм бөек җырчыбыздан.

— Һи-и, аларның исәбе-хисабы юк. Студент чорыннан ук башланды, — ди Илһам ага. — Бервакыт Сарманнан Кыям абый телефонга чакыртты. Тавышы бик хәвефле: «Син авырмыйсыңмы?» — дип сораган була. Соңыннан белдем: «Рәшит Ваһапов, көнләшеп, Илһам Шакировны атып үтергән икән», дигән хәбәр таралган булган. Киресе дә булды: имеш, Рәшит Ваһаповны мин агулап үтергәнмен... Бер елны Себердә гастрольләрдә йөрибез, кунакханәгә Казаннан берәү шылтырата бит: «Син исәнмени?» — ди. «Соң, исән булмасам, синең белән сөйләшә алыр идеммени?!» — дим. «Юк, ышанмыйм, син исән түгел!» — ди бу. Күпмедер вакыттан соң кайтып төштек... «Илһам Шакиров үлгән икән» дигән хәбәр бөтен Казанга таралган. Җәсәдемне үз куллары белән кабергә төшерүчеләр дә байтак икән. Бу гайбәтне туктату өчен телевизордан концерт бирдем. Юк, барыбер ышанмыйлар, иске язма ул, ялган, диләр икән. Шуннан соң Казанның мәдәният сарайларында ун көн буена концертлар бирдем. Халык өстендә халык, бер-берсен таптап керәләр. «Сезнең нигә килгәнегезне беләм мин...» — дим сәхнәдән. Зал көлә. Шулай итеп, мең мәртәбә үтереп, мең терелттеләр мине ул елларда.

## Хельсинкида

1968 елның көзендә Илһам Шакиров бер төркем артистлар белән Финляндия татарларына концертлар бирә. Хельсинкида аларны президент Урхо Кекконен үзе кабул итә. Югары кимәлдә очрашудан соң татар миллионеры боларны үзенең супермаркетына чакыра: «Миннән бүләк — җаныгыз ни тели, шуны сайлап

алыгыз», — ди. Артистлар ябырылалар. Үз илендәге кибетләрдә кара сатин трусиктан, «Спартак»ның каты ботинкасыннан гайрене күрмәгән кеше шушы кадәр әкияти байлык уртасында торып калсын әле... Бер читтәрәк кыенсынып басып торган Илһам Шакировны хуҗалар, култыклап алып, бусы ошамыймы, тегесен алмыйсызмы, дип кибет буйлап йөртәләр. Илһам Шакиров, күңелләре булсын дигәндәй, әйберләрне тотып карый да кире урынына куя бара.

Бераздан, кызышкан, тирләп-пешкән, пар чыгып торган артистлар кап-кап әйбер күтәреп, кибеттән чыгалар. Илһам Шакиров кулында — чеметеп кенә тоткан бер пар носки... Артистларга, бер-берсенә төртешеп, ым кагып көләргә азык була бу.

Һотельгә кайтсалар... ни күрәләр... Илһам Шакиров кибеттә нинди әйбер турында тукталган, шуларның барысы да, матурлап төрелеп, бүлмәсенә китереп куелган.

Бөек җырчыбыз ул әйберләрне Казанга кайтып җитүгә, үзен каршыларга килгән музыкантларга, дус-ишләренә вокзалда ук таратып бетерә. Үзенә бик матур бер пар носки кала...

## Кырык биш ел элек...

«...Илһам Шакировның бу юлы ап-ак чалбар һәм кара озын камзулдан булуы, сәхнәдә туктаусыз сикеренгәләп йөрүе, бер җыр башкарган саен, тамашачыларны ялындырырга теләп, сәхнә артына кереп китүе табигый булып бетмәде. Сәхнәдә йөгереп йөрү Әлфия Авзалованы да ардырды булса кирәк, соңгы җырлары залга бик начар ишетелде.

Билет бәяләре турында да әйтми булмый. Концерт әллә ни зур расходлар тотып оештырылмаган. Димәк, билет бәяләренең 2 сум, 2 сум 50 тиен булуы бераз сәеррәк. Биредә филармония җитәкчеләре финанс ягына артык басым ясаганнар. Югыйсә тамашачы өчен күп унайлыклар тудырылмаган иде. Тамаша залы салкын, күпләр өс киеменнән утырырга мәҗбүр булды».

*Миргалим Харисов, Рәшит Гарипов.*
*«Зур концертка зур таләп».*
*Социалистик Татарстан, 1970, 19 декабрь.*

**Илһам ШАКИРОВ**

## Ямаулы янчыктан

*Күпләр ни өчен «ямаулы янчык» дип сорыйлар. Асылы бик гади. Зиһенле һәммә кешенең хәтер янчыгы була. Тулышкан хикмәтле фикерләр, янчыкны тишеп, дөньяга чыгарга гел кыҗрап тора. Шуңа күрә, «тишек хәтерле» булмас өчен, янчыкны гел ямап торырга кирәк.*

Редакциядән.

• Патшалар арасында да гайбәт йөри, теге дөньяда да юк дип уйлама.

• Сина рәхәт... Син — җүләр...

• Ваемсызлардан көлеп әйткәнмендер инде. Бу илдә акыллы булып яшәү читен бит.

• Мине җырлый гына, диләр. Ә мин бии дә беләм. Бигрәк тә чарльстонны...

• Кайчакта мин җырлаганда, тамашачының гына түгел, үземнең дә чәчләрем үрә тора.

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

# С

**САЙГАНОВ** Абдулла Җамалетдин улы (18.5.1913, Әстерхан ш. — 19.4.1974, Казан), әдәбият галиме, филол. фәннәре д-ры (1972). Әстерхан пед. ин-тын тәмамлый (1940). 1943 елдан Казанда, ТАССРның Мәгариф наркоматы инспекторы булып эшли. 1946 елдан Казан. пед. ин-тында, 1953 елдан татар әдәбияты кафедрасын житәкли, бер үк вакытта, 1948-54 елларда тарих-филология ф-ты деканы. Эзләнүләре реализм эстетикасына, татар реалистик әдәбиятында типиклык мәсьәләсенә, татар һәм рус әдәбиятлары бәйләнешларына, шигырь төзелешенә карый. Хезмәтләре Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Ш.Камал, Һ.Такташ, Г.Кутуй иҗатларына багышланган. Урта мәктәп өчен татар әдәбияты буенча дәреслекләр һәм хрестоматияләр авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша.

Әсәр.: Проблема типического в татарской реалистической литературе. К., 1972; У истоков эстетики реализма: Эстетика Фатиха Амирхана и её место в развитии татарской реалистической литературы. К., 1982.

**САЛИХОВ** Данил Хәбибрахман улы (7.10.1958, Актаныш р-ны Киров. исем. совхоз пос. туа), драматург, актёр, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2000). Казан т-р уч-шесын тәмамлагач (1983), Татар академ. һәм Татар драма һәм комедия т-рлары актёры (1985-93). 1993-98 дә ТРсы Язучылар берлеге рәисе урынбасары, 2003-06 да Татарстан интеллектуаль милек агентлыгы (ТАИС) директоры. 2006-10—ТР Язучылар берлегенең Әлмәт бүлегендә җаваплы сәркатип. Татар академ. т-ры сәхнәсендә уйнаган Алмазбулат (Ю.Сафиуллинның «Алмазбулат» пьесасы, 1983), Тимур (Р.Мингалимнең «Кайда сез, ирләр!» пьесасы, 1983); Татар драма һәм комедия т-ры сәхнәсендә — Басарый (Т.Гыйззәтнең «Ташкыннар», 1987) рольләре ин унышлыларыннан. «Туй күлмәгем — соңгы бүләгем» (Татар драма һәм комедия т-ры, 1988), «Яшьлек хатам — йөрәк ярам» (шунда ук, 1989), «Бәйрәмгалинең сыер тышавы» (шунда ук, 1990), «Алла каргаган йорт» (Әлмәт татар драма т-ры, 1991), «Никүләй дәдәйнең бөер ташы» (Минзәлә татар драма т-ры, 1992), «Хатын түгел — аждаһа» (Әлмәт татар драма т-ры, 1992), «Сәер кеше» (шунда ук, 2008) пьесалары авторы. Әсәрләре «Яшьлек хатам — йөрәк ярам» (1998), «Гыйлаж тәрәзәләре» (2004), «Пьесы» (2008, рус телендә), «Таш сандык» (2008), «Ак күгәрсен» (Өфө, 2012, башкорт телендә) җыентыкларына тупланган. ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. пр. лауреаты (2005).

Әд.: Илялова И. Мысли по поводу... // Идель. 1998. №8; Саттарова А.М. Современная татарская драматургия: 1985-2000 гг. Концепция эпохи и героя. К., 2003.

**САЛИХОВ** Хибатулла Сәетбаттал улы (псевд. Хибатулла Салихбаттал, Хибатулла Каргалый, Хибатулла Ишан) (1794, Оренбург губернасы Түбән Чебенле а. — 1867, Оренбург губернасы Каргалы бистәсе), шагыйрь, дин эшлеклесе. Мулла гаиләсеннән. Бабалары бирегә Казан губернасы Чистай өязеннән күчеп киләләр. Каргалы мәдрәсәсендә белем ала; 1842 елдан шунда ук мөдәррис, бистә мәчетенең имам-хатибы була. Үзе исән чакта ике шигъри җыентыгы дөнья күрә: «Төхвәтел-әуляд» («Киләчәк буынга бүләк»), «Мәҗмәгыльәдәб» («Үз-үзенне тотыш кагыйдәләре», 1956). Беренче китапта гарәп теле фонетикасы бирелә. Икенчесе дини-этик нәсыйхәтләрдән гыйбарәт: автор ялгыш адымнар ясаудан тыелырга, гадел булырга чакыра, дини-әхлакый кануннар буенча яшәүгә өнди; үгет-нәсихәтле сүзләрен тиешле хикәяләр б-н ныгыта (мәсәлән, берсендә автор ахмак кешене үзенә юлчы итеп алырга ярамаганлыгын күрсәтә; икенчесендә, «Гаса кеби булып» дигән сүзләргә башланганында, сүзсез, сер саклаучы таяк кебек, ялгызга юл-

Дәвамы. 2005 елның 4нче санынннан басылып килә.

даш, алашканга маяк, сукырга ярдәмче булырга, ягъни кешегә һәрвакыт ярдәм итәргә өнди). Автор күптөрле жанрларда иҗат итә: мәдхия, мәрсия, газәл, мәсәл, шигъри хикәят һ.б.; аларның бер өлеше Р.Фәхретдиннен «Асар» (Оренбург, 1908) китабында урын алган. «Тәндә жаным» («Диване Ризаи», 1860, җыентыгына кергән) лирик шигырендә С. суфичылыкны тарату йөзеннән дөньяның фанилыгы, кылган гамәлләрнең файдасызлыгы турында яза (1906 елда Тукай бу шигырьгә «Мөритдәр каберстаныннан бер аваз» исемле пародия яза). Кайбер мәгълүматлар буенча, С. — «Дөррел-кәлям» (1856) китабы авторы. С. шигырьләре лирик-фәлсәфи афористик стиль, оригиналь чагыштырулар һәм метафораларның күплеге б-н аерылып торалар. Аның әсәрләрендә чит тел сүзләре, гарәп яки фарсы телендә язылган шигъри юллар очрый; бер үк вакытта авторның сөйләм телен куллануга омтылышы да сизелә.

Әдәб.: Гайнуллин М.Х. Татарская литература XIX в. К., 1975; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. Т.2.

*Х.Й.Миннегулов*

**САРАИ-ГӨЛЕСТАНИ** Мәхмүд (тулы исеме Мәхмүд ибне Абдаллаһ әс-Сараи әл-Каһирәви) (? — 1398, Каһирә, Мисыр), шагыйрь, дәүләт эшлеклесе. Яшьлек елларында Алтын Урданың Гөлстан, Сарай-әл-Җәдид шәһәрләрендә яши, 1370-80 елларда Мәмлүкләр Мисырында, анда ул Баркук солтанның (1382-99) дәүләт канцеляриясе б-н җитәкчелек итә. Язма чыганакларда төрле жанрларда язылган күпсанлы әсәрләр авторы буларак искә алына. Бүгенге көннәргә аның робагый жанрында, Мисырга Әхмәт Гийсса (1382-1410 елларда хакимлек итә) солтан килүе унае б-н язылган бер шигыре килеп җиткән («Китабе Гөлстан бит-төрки» җыентыгына кергән).

Әдәб.: Миннегулов Х. Татарская литература и Восточная классика. К., 1993; аныкы ук. Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты. К., 1976.

*Х.Й.Миннегулов*

**САТТАР** (Саттаров) Ил Рәхим улы (10.2.1933, Башкорт АССРы Үчәле р-ны Үчәле а. — 21.4.2001, Казанда вафат, Биектау р-ны Биектау а. җирләнә), публицист, философ, фәлсәфә фәннәре канд. (1986). Казан ун-тын тәмамлый (1960). 1961 елдан Халык иҗаты йортында репертуар буенча методист. 1965 елдан Казан архитектура-төзелеш ин-тында укыта. Вакытлы матбугатта төрле елларда басылган публицистик мәкаләләр авторы. Сонынннан алар «Прозрение» («Төшенү», 2003), «Милләт алга барамы әллә чигенәме?» (2007), «Поиск истины» («Хакыйкатьне эзләү», 2009) исемле җыентыкларга керде. Аларда авторның халыкның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турындагы уйланулары, аның язмышы өчен хафаланулары урын алды. Философик хезмәтләре эстетика һәм сәнгатьлелекнең табигатенә, кеше табигате һәм сәнгать мәсьәләләренә багышланган.

Әсәр.: Эстетика. К., 2002; Фәлсәфә: 2 китапта. К., 2000-03; Философские записки. К., 2009; Объективные основы эстетического сознания. К., 2009.

**САТТАР** (Габделсаттаров) Рәхим (Габделрәхим) Сөләйман улы (15.8.1912, хәзерге Башкортстан Республикасы Чишмә р-ны Түбән Хаҗәт а. — 1943), шагыйрь. 1939 елдан соң Казанда, «Яшь сталинчы» г-тасы редакциясендә эшли. 1941 елның көзендә сугышка алына, 1942 елның июнендә әсирлеккә төшә. Вустрау фашистлар лагеренда «Җәлилчеләр төркеме» әгъзасы була. 1943 елның июнендә лагерьдан кача. Алдагы язмышы билгесез. 12 яшьтән яза, вакытлы матбугатта басыла башлый. Мәхәббәткә, Ватанга тугрылыкка багышланган, сугыш елларында язылган «Ант», «Әнкәмә хат», «Әсирләр», «Халкым өчен», «Бүленгән җыр» шигырьләре «Җыр дәвам итә» (1966), «Три поэта-воина» («Өч көрәшче шагыйрь», 1979) исемле коллектив җыентыкларга кергәннәр.

Әсәр.: Безнең буын. К., 2006.

Әдәб.: Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т.2.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

*Сәхифәне* **Рәйсә МУСАБӘКОВА** *әзерләде.*

## Килмә якын

Чибәр кызый, гашыйк булма миңа,
Гашыйк булма, янма утларда.
Яр кырына якын килә күрмә,
Вакытында кирәк туктарга.

Якын килмә миңа, якынлашма,
Минем йөрәк — утлы шарлавык.
Ә син — җиләк, пешкән кызыл җиләк,
Өзеп кенә алып кабарлык.

Мин — шарлавык, миңа якынлашма.
Эләксәң син минем кочакка,
Ут ташкыны сине алып китәр,
Чыгалмассың кайнар учактан.

Якынлашма миңа, килмә якын,
Утлы кочагыма ашкынма.
Син кагылсаң, көчәерләр кебек
Йөрәктәге утлы ташкыннар.

Зинһар өчен, зинһар өчен, борыл,
Күзләремә алай карама.
Утлы күмерләргә кагылма син,
Кагылма син канлы ярама.

## Татар буласым килә!

*Әлеге шигырьне бер ак яулык япкан татар апасының оныгы белән тырыша-тырыша, вата-җимерә русча сөйләшүен ишеткәннән соң тетрәнеп яздым.*

Ирина буласым килми –
Иркә буласым килә.
Галина буласым килми –
Гөлкәй буласым килә.

Маруся буласым килми –
Мәрьям буласым килә.
«Бабуся» буласым килми –
Оныгым үсеп килә.

Балаларга, оныкларга
Русча гына өйрәтсән,
Күрше-күлән, дуслар белән
Русча гына сөйләшсән,

«Мамаша» да булырсын,
«Папаша» да булырсын.
«Эй, бабуся!» — дип дәшкәндә,
Артка да борылырсың.

«Әбием», — дип дәшсен өчен
Оныгыма: «Балам! — дим. —
Әйдә әле минем белән,
Мин намазга барам», — дим.

Татар телем — туган телем
Шулкадәр хуш күнелгә!
...Урыс буласым килми шул,
Татар буласым килә!

**Раил ГАТАУЛЛИН**

---

# ХИКӘЯ ЯЗА АЛАСЫЗМЫ?

***Хикәячекләр журналда бирелгән башламнарны (былтыргы 12нче яки быелгы 1нче сан) дәвам итеп язылა. Күләм бер журнал битеннән артмау фарыз.***

## Интернет

**«Күрәчәгең булса, күркә талап үтерер», ди. Интернет аша танышуларны өнәп бетермәгән Алия үзе дә әлеге ысулның корбаны булырмын дип һич тә уйламаган иде.** Иптәш кызы Сәлия ниндидер сайтта утыра иде. Алиягә борылып:

— Кара әле, ахирәткәй, менә монда нинди игълан язганнар. Укып күрсәтимме? — диде дә, иптәшенең җавабын да көтеп тормыйча укып китте.

Алия, үзе дә сизмәстән:

— Кайсы сайтта? — дип сорады.

Сәлия барысын да сөйләп бирде. Үзе яңадан компьютерена капланып, дөньясын онытты. Тәкъдим — ымсындыргыч. Һичбер чыгымсыз акча эшләргә мөмкин, диелгән. Тик яңа класс компьютер кирәк икән. Кыз күптән ноутбугын алыштырырга йөри иде инде...

Ноутбукка кушып төрле җиһазлар да бирделәр. Тик җайланмалары бик сәер. Башлыгы бар, аны киеп компьютерга тоташасың. Аннан бөҗраларын аяк-кулга эләктерәсең. Эш эффекты нык арта икән.

Алия шул кичне үк, барлык таләпләрне төгәл үтәргә тырышып, башлыкны

киде, аяк-кулына беләзекләрне электереп, ноутбугын кабызды. Сайтка керде. Анда ничек язганнар бит әле. «Сезне борчыган проблема-мәсьәләләрне без үз өстебезгә алабыз. Эш хакы атна саен саклык кенәгәсенә күчәчәк. Сезгә бары тик без кушкан эш-йөкләмәне генә тырышып үтәргә кирәк».

Башланды. Кыз эшкә тотынды. Эш бик кызыклы булып, бер мавыктыргыч уен кебек кенә иде. Һәм Алия бар дөньясын онытты...

Менә экраннан Алиягә исем шәрифләре белән эндәшеп, рәхмәт әйттеләр. «Шушы кодлар белән барып, башкарган эшегез өчен шул-шул банкның икенче бүлегеннән акча алыгыз, — диелгән иде тагын. — Сезнең пенсия фондына да шул кадәр акча күчерелгән. Карточкагыз белән билгеләнгән пенсиягезне дә ала аласыз. Рәхмәт! Ә инде үзегезгә алмашка тагы берәр кыз йә егет тапсагыз, шул микрорайоннан фатир да булыр!»

Алия, кодны учына кысып, урамга чыкты. Исәбе тизрәк банкка барып, кирәкле карта алу иде. Тик... урам ул яшәгән урам түгел! Барсы да үзгәргән, тирә-якны танырмын димә. Икенче шәһәргә барып эләктем бугай дип уйлады ул. Шулай да ишеге зур көзгедән эшләнгән банкны тиз тапты. Көзгедән аңа таныш та, таныш түгел дә бер карчык карап тора иде. Кыз моны чираттагы бер реклама-шаярту эффекты дип уйлады. Ишек ачылып китте. Аның кулына исеме язылган карта тоттырып, нәрсәдер сөйләделәр. Шунда аның күзе стенадагы сәгатькә төште. Анда: бүген 2045 елның 20 мае. Валюта курсы, дигән дә төрле саннар тезелеп киткән. Ул тәүдә бернәрсә дә аңламады. Шуннан өстәл артындагылардан, стенадагы сәгатькә күрсәтеп:

— Бу... бу дөрес күрсәтәме? — дип сорады.

Алия шунда гына бик нык алданганын аңлап алды. Кичә генә ноутбук артына утырган кебек иде. Сизелмичә 30 ел үтеп тә киткән. Ни баласы, ни гаиләсе юк. Үзенең 50 яшьлек карчык икәнен аңлап, Алия елап җибәрде. Ә банк хезмәткәрләре карчык шатлыгыннан елый дип уйладылар.

## Урман юлында

**«Там, там, там, тамуыңны яратам», — яңгыр астында шулай дип җырлап барганда, ул ... уянып китте. Кайдадыр чалкан ята икән бит, ә аның өстенә ниндидер кыз иелгән. Теге җылы тамчылар шуның күзеннән тама икән ул!**

Бәй, бу Сәбилә түгелме соң? Шул бит. Егет күзен бер ачып карады да тагы йомды. Бу бәхетле минутларны озаккарак сузарга теләде. Барсы да исенә төште.

Ул картәтисенең хан заманындагы иске генә велосипедына утырып урман юлларын бер йөреп кайтырга дип чыккан иде. Исәбе урман һавасы сулап, җиләкле акланда җиләк пешкәнме, юкмы, шуны белергә теләде. Менә бит нәрсә килеп чыкты! Кем уйлаган урман юлында да машина очрар дип. Борылышта кинәт каршысына килеп чыккан машинаны шәйләми калды. Машина да шәп килә иде шул. Менә шуның нәтиҗәсе инде. Аның өстенә иелеп, нәрсә эшләргә белми елап утырган кыз, әйе, Сәбилә. Ә Сәбилә мединститутта 3 нче курста укый. Шамил исә кыз яшәгән күп катлы йортта бер әбидә фатирда тора. Ул техникум бетереп, заводта эшли. Егет Сәбиләне бер күрүдә үк яратты. Тик моны кызга белдерергә генә җай тапмый йөри иде. Аннан Сәбилә ул — шәһәр кызы. Машинасы да бар. Егет шуннан кыенсына. Каккан казыгы да булмаган авыл егетенә кем карасын да кем аңа кияүгә чыксын ди? Һәм менә бүген шушы чибәр аның әле йөрәген тыңлый, әле пульсын саный. Ясалма сулыш алдырып та карады. Егеткә рәхәт. Шушы оҗмахны тагы да озаккарак сузарга дип, егет дәшми генә күзен йомып ята бирә. Ә кыз тәмам аптырап, нәрсә эшләргә дә белмичә һаман яшен түгә. Шунда егетнең башына бер уй килеп, ул Сәбиләгә ишетелер-ишетелмәс кенә иреннәрен тибрәтте:

— Мәңгелеккә йокыга талган принцесса батыр егет аның иреннәреннән үбеп алгач кына күзен ачкан. Син дә үп. Мөгаен, мин дә уянырмын.

Ишеттеме, юкмы, анысы билгесез. Тик кыз аның иреннәреннән, яңакларыннан үбеп елый да елый әнә:

— Тор, жаныем, тор инде. Ач күзеңне! Һушыңа кил, — диеп, аны, җирдән күтәреп алып, машинасына утыртырга ук чамалый башлады. Тик көче генә җитми шул. Егет исә кызның кайнар сулышыннан бөтенләй башын җуяр хәлгә җитте. Тагы да үҗәтләнеп һәм барча батырлыгын җыеп:

— Сәбилә, мин сине күптән яратып йөрим. Миңа кияүгә чыгарга риза булсаң, хәзер үк күземне ачып аягыма торып басам, — дип пышылдады.

Кыз аны-моны аңлап та бетермәде шикелле, аптыраган-каушаган хәлдә:

— Мин риза, риза! Тик син генә, һушыңа килеп, күзеңне ач! — диде. Егет шундук күзен ачып, кызга елмайды. Кулларын сузып кыз битендәге яшь бөртекләрен сыпырып алды. Салынып төшкән чәчен кулына салып һәм башын калкытып, битеннән үпте.

— Елама, кадерлем! Елама! Мин терелдем!

Бераздан алар, алгы тәгәрмәче бөтенләй яраксызга әйләнгән велосипедны машина багажнигына салып, кайтыр юлга кузгалдылар. Урманны чыккач, кыз машинасын үзе кунакка кайткан авылга таба борырга чамалаган иде дә, егет:

— Юк, иң тәүдә безгә кайтып, ватык велосипедны калдырыйк. Аннан сезгә барырбыз, — диде.

Шулай килештеләр.

Машинаны капка төбендә калдырып, ватык велосипедны күтәреп кергәндә, картәнисе йортта чебешләр ашатып йөри иде. Оныгының ватык велосипед күтәреп һәм таныш булмаган кызны җитәкләп кергәнен күргәч, ни әйтергә дә белмичә аптырап калды.

— Менә, картәни, таныш бул, бу — киленең булыр. Көзгә туй ясыйбыз. Әзерләнә башлагыз, — диюгә кыз егет кулыннан үзенең бармакларын ычкындырырга чамалаган иде дә, булмады. Егет Сәбиләнең учын ныклап тоткан. Егет, кызның күзенә тутырып карап:

— Шулаймы, Сәбилә җаным? — диде.

Кыз, тәмам кызарып:

— Әллә инде? Әти-әниләрдән сорарга кирәк. Алар нәрсә дияр бит әле, — дип пышылдады.

— Ансы өчен кайгырма! Әйдә, кереп, безнекеләр белән ныклап танышып, чәйләп алыйк. Аннан инде мине үзегезнекеләр белән таныштырырсың.

Берничә сәгатьтән егет белән кыз машинада Сәбиләнең туганнары белән танышырга күрше авылга китеп баралар иде. Шамилнең машинага килеп бәрелүе дә файдага булды, ахры. Егетнең кыюсызлыгын кыз гүяки күз яше белән юып төшергән иде. Бу бәрелешүдән егет белән бер яшьтәрәк булган велосипедтан башка беркем һәм берни зыян күрмәде.

## Геном

**SMSны укыгач, кыз бетте генә инде... Анда өч кенә сүз язылган иде.**

Әлфия тәүдә аптырады. Авылда кесә телефоны тотмый. Ә SMS ничек килгән? Кыз, өенә кайтып та тормыйча, туры лабораториягә барды. Анда эшләгән дусты Зәйтүнәне тиз тапты. Ахирәт, үзе үк сүз башлап:

— Кара әле, Әлфия, сиңа бәйләнешкә чыгып булмады, — диде. Кайда югалдың? Аптырагач SMS җибәрдем. Каннарыгызны тикшердем. Сезнең геннарыгыз йөз процент туры килә. Тәк што котлыйм! Һич шикләнмә, абыең үзеңнеке...

Сүзен әйтеп тә бетермәде, аны чакырып алдылар. Дусты:

— Ярар, хуш! Кичкә очрашырбыз әле, — диде дә ишектән кереп югалды.

Әлфия, нәрсә уйларга да белмичә, өйләренә кайтып китте. Аның башында

тик бер генә сорау. Ничек була соң әле бу? Мөгаен, бутаганнардыр. Алай дисәң, чит кан белән аның каны шулкадәр төгәл туры килүе һич мөмкин түгел.

Әлфия озак уйланып йөрде. Әнисенең фотокарточкалары белән үзен чагыштырып карады. Ул әнисенең яшь чагына, теге кем әйтмешли, суйган да каплаган. Фотолар арасында әтисе белән әнисенең яшь чакта бергә төшкән фотосы килеп чыкты. Бу сурәтне күргәч, ул дертләп китте. Чөнки анда әйтерсең лә Әлфия белән Илшат икәү бергә. Шулкадәр охшашлык була аламы?!

Илшат белән бер ай элек тансыда таныштылар. Илшат чит өлкәдән килгән. Әлфияне биергә чакырды. Сөйләшеп киттеләр. Аларның бик күп уртак яклары бар икән бит. Һәм егет аңа беренче көнне үк үлеп гашыйк булды.

Ә бүген Әлфия әнисеннән тегеләй-болай боргалап тормыйча, турыдан ярып:

— Әни, сезнең миннән алда балагыз бар идеме? — дип сорады.

Әнисе сораудан югалып калды. Кызына сәер генә карап алды да:

— Нинди юньсез сораулар белән башымны катырасың? Әллә берәр алама гайбәт сөйләп кайтардыларммы? — диде.

Кыз җавап бирмәде. Әмма бүлмәсенә кереп китәр алдыннан тутырыплар карады. Ананың йөрәге чәнчеп алды. Күңеленә шик кереп утырды. Кызына кемдер сөйләгән. Кайдан белергә мөмкин ул моны? Ерак туган апасы Тәнзилә күптән мәрхүм инде. Ә кем сөйләргә мөмкин? Кызы нәрсәдер белә. Һәм ул тәвәккәлләп, Әлфиягә барысын да ачып салырга булды. Кызы күптән буй җиткергән. Булачак медик. Аңлар дип уйлады. Сак кына кызы янына үтте. Кызы фотоальбом карап утыра иде. Әнисе, сүз башлап:

— Кызым, вакыты шундый иде, — диде. — Әтиең армиягә алынгач кына үземнең авырлы икәнемне белдем. Элек егетләр икешәр ел хезмәт итте. Нишләргә? Бала тапсам, миңа ничек карарлар? Әтиең хезмәт итеп кайткач миңа өйләнәме әле, юкмы? Менә шул. Ташкентта балам туды. Нишлисең бит, абыеңны калдырып кайттым. Әтиең армиядән кайткач, өйләнештек...

Әни кеше тагы бик озак кызы алдында нәрсәләрдер сөйләп акланып утырды. Тик Әлфия генә бөтенләй икенче нәрсә уйлап баш ватты. Моны ничек итеп аңа әйтергә икән соң? Аңлармы?! Кыз менә хәзер генә егетнең чынлап торып үз абыйсы икәненә ышанды. Ә бит генетик тикшерүгә каннарын шаярып кына биргәннәр иде. Имеш, бер-берсенә күпмегә туры киләләр? Ялгыштан Ходай үзе саклады.

Әни кеше хискә бирелеп елап та алды. Кызыннан бу турыда кайдан, кемнән һәм ничек белүе турында күпме генә сорашса да, кызы дәшмәде.

Икенче көнне Әлфия бернәрсә дә белмәгән Илшатны үзләренә алып кайтты. Әнисе барысын да абыйсына үзе аңлатыр дип уйлады. Әнисе яңа гына эштән кайткан, күрәсең. Чәй табыны әзерләп йөри. Керүчеләрне күреп, ана бөтенләй югалып калды. Әлфия артындагы егетне күреп, аның кулы калтырый башлады, күзендә яшь күренде. Кызы, әнисенә туры карамыйча гына:

— Сез сөйләшә торыгыз. Мин хәзер кайтам, — диеп, өйдән чыгып китте.

Кыз соң кайтты. Әтисе дә эштән кайткан. Кунак белән өчәүләшеп фоторәсемнәр карап утыралар. Тик әнисе генә бөтенләй картаеп, мескенләнеп калган. Кыз, әнисен кызганып, килеп кочаклап алды да колагына гына:

— Әнекәем, мин сине бик тә яратам, барыгызны да яратам, — дип пышылдады.

**Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ,**
*Башкортстанның Эстәрлебаш районы*
*Турмай авылы*

## Укытучы кыз бәхете

**«Кил, кил, кил...» — җырның бу куплетын җитмешенче кат җырлады бугай инде ул. Ә иркәсе һаман юк әле. Тагын бер кат сузып җибәрүе булды, кинәт...**

Көтмәгәндә ишектән килеп кергән Женя апасының калын тавышын ишетеп куркып ук китте Фәридә, кулындагы энәсеннән бәйләп утырган шәл читенең күзәнәкләре берәм-берәм «сикерешеп» чыктылар... Кыз, күзен ишектән алып, тиз-тиз генә күзәнәкләрне җыярга кереште.

— Нинди бетмәгән «кил, кил» инде ул сәгатьләр буе? — дип ачуланды квартирант кызын Женя апа. — Килер әле, кая барыр, килмичә? Төн уртасы җиткәнен беләсеңме син, балам?

Шулай «балам» дип, яратып эндәшә ул Фәридәгә, ачулануы да аны яратып, үзенчә кызганудан гына.

Сөйгәнен сагынып, юксынып, җырлар җырлап, берүзе кич утырды шул төн кошы Фәридә. Төн уртасы җиткәнен сизмәгән дә икән.

Ул, ашыкмыйча гына әзерләнеп, йомшак урын-җир эченә чумды.

Ә иртән...

Һәрвакыттагыча, иртәнге җидедә Фәридәнең кесә телефонының будильнигы җырлап җибәрде. Күзен ачар-ачмас, ул SMS күреп алды, SMSны укыгач, кыз бетте генә инде. Анда өч кенә сүз язылган иде: «Без кичә яндык».

Ике күзен шушы утлы сүзләрдән аерып ала алмыйча, соң дәрәҗәдә борчылып, кат-кат укыды Фәридә Фәритенең сүзләрен, әмма «Нишләп?», «Нигә?», «Ничек?», «Ә билгеләнгән туебыз?» дигән сорауларына ни телефон, ни Женя апасы җүнләп җавап бирә алмадылар. Телефондагы өзек-өзек гудоклар Фәридәне тагын да көчлерәк борчуга салдылар.

— Ник телефоныңны алмыйсың, бәгърем? — дип иләнде ул, тик нигәдер еректагы Фәрите, никахланган яры , дәшмәде генә...

Фәридәгә мәктәбенә керергә вакыт җиткән иде.

Кыңгырау чыңы белән бергә дәрескә керде. Исәбе бирәүгә дә, берни дә сиздерергә түгел иде, билгеле.

Нихәтле сынаулы күз аңа төбәлгән. Ягымлы, сөйкемле, нурлы күзләр...

— Фәридә Гаязовна, Сезгә ни булды? Нигә еладыгыз?

— Апа, нигә борчылдыгыз? Безгә әйтегез!..

Фәридәнең ике күзенә ихтыярсыздан кайнар яшьләре бөялде, керфекләре юешләнде, ул сыйныф бүлмәсеннән чабып чыгып китте.

Тәнәфес вакытында укытучылар бүлмәсендә директорлары Мансур Наилевич Фәридәне генә түгел, барлык коллегаларын тиз «тынычландырды» — иртәгә Мәгариф бүлегеннән саллы гына тикшерү киләсе, итәкләрне җыеп, әзерләнеп торасы икән...

Фәридә тынычланды. Юк, тикшерүдән курыкмый ул, чөнки үз-үзенә ышана. Аны иң яхшы аңлаучылар, тыңлаучылар, хәленә керүчеләр шушы укучылары икән ләбаса! Аны хөрмәт итәләр, яраталар икән бит!

Фәридә, беренче елын чит шәһәрдә торып, чит кешеләрдә яшәп, урта мәктәптә быел беренче елын балалар укытырга алынган Фәридә Гаязовна, күзенә генә карап утыручы укучыларын сагынып, яратып, тәмам тынычланып, ныклы, ышанычлы адымнары белән 11 А сыйныфының ишеген ачты.

## Көндәлегем битләреннән...

**— Утыр, Рәзинә, «бишле!» — диде укытучы. Әмма 11 «А» кызлары яшь педагогның бу сүзләрен гел бүтәнчә ишеттеләр.**

Бүлмәдә чебен очканы да ишетелерлек тынлык урнашты. Авыр тынлык иде бу. Сыйныф ниндидер шартлау көткән кебек тоелды миңа бу минутларда...

Кара инде, Айгөл белән Мәдинә торып ук бастылар. Мин, йөзләрен күрмәсәм дә, ниндирәк сүзләр әйтәселәрен белгәнгә, партама сеңдем.

Менә тынлыкны Айгөлнең чәрелдек тавышы ярды:

— Кызлар, ишеттегезме, аңладыгызмы инде, миңа ышанмаган идегез...

Аның сүзләрен Мәдинә элеп алып китте:

— Рәзинәне ярата бит ул, шуңа аңа гел «бишле» тезә... Дөрес бит, кызлар?

Ни кызлар, ни малайлар актан-карадан Мәдинә белән Айгөлгә бер сүз дә әйтмәделәр. Сүзне хәзер укытучы абыебыз әйтергә тиештер инде. Нәрсә диярсең икән инде, Ленар абый?

Мин, кызарынып, партама сеңеп утыра бирәм. Тынлык озакка сузылды түгелме? Киеренкелектән башым чатнарга, колакларым чыңларга тотынды. Бары тик бераздан гына гадәти тыныч гөжләүне ишетә башладым. Сыйныфташларым, күзләре ялтырап-ялтырап алса да, тирләп-пешеп мәсьәлә чишүләрен беләләр. Әйтерсең, Айгөл белән Мәдинәне бөтенләй дә ишетмәгәннәр.

Рәхмәт сезгә дәшмәвегез өчен, дип, күңелемнән аларга рәхмәт укыйм. Ә мин үзем нигә болай кызарынып утырам соң әле? Минем саф хисләремә кагылырга Айгөл белән Мәдинәнең ни хаклары бар? Укытучыга каршы әйтергә ни хаклары бар? Миннән көләргә ни хаклары бар?

— Сабыр, сабыр, — дидем мин үз-үземә. — Сабыр, Рәзинә... Кулыма ручка алсам да, башкалар кебек мәсьәлә чишәрлек хәлем дә, теләгем дә юк икәнен беләм бит инде югыйсә.

— Әйдә, Айгөл. Чык тактага! — диде Ленар Илсурович.

Айгөл такта янына чыгарга уйламады да, ахры, бер минут эчендә китап-дәфтәрләрен җыештырып, сыйныф бүлмәсеннән чыгып ук китте. Айгөл артыннан, аның күләгәсе кебек, сүзсез генә тек-тек басып, «бишле» алгандай, башын югары тотып Мәдинә теркелдәде...

Шул чыгып китүләреннән Айгөл белән Мәдинәне без бүтән күрмәдек. Аларның башка мәктәпкә китүләрен генә белдек. Нәрсә диим? Айгөл белән Мәдинә үз мәхәббәтләре өчен көрәшмәделәр шул, миннән чын көндәш ясап, мәхәббәт сынауларын уза алмадылар кебек. Алар Ленар абыйның минем элекке күршем булуын да, безнең икебезнең арадагы дуслыкның самимилеген, эчкерсезлеген дә күрмәделәр, минем нигә шулкадәр үлеп бетеп математиканы яратуымны, бу фәнне су урынына эчүемне аңларга да теләмәделәр ... Ни өченме? Чөнки алар үзләре дә минем кебек чын күңелләреннән Ленар абыйга гашыйк иделәр.


Алай да, рәхмәт сезгә, сыйныфташларым, рәхмәт сезгә, Айгөл белән Мәдинә!

Рәхмәт сиңа, укытучым, Ленарым! Сиңа күземне тутырып карарга курыккан яшьлек мәхәббәтем, мәктәп елларым мәхәббәте!

**Надия ВӘЛИЕВА,**
*Казан*

# «ТАНЫМЫШ» ДӘРЕСЕ

*Зөлфәт Хәйруллин ясаган шаржларда тасвирланган затларны тану сорала. Бишесен дә танучыга «бишле» куячакбыз. «Бишле» алучылар, ай-һай, булыр микән? Бу дәрестә «икеле» алу да ярап торыр кебек. Ә менә шаржлар астына куярлык биш шигъри эпиграмма яза алучы «Казан утлары» чыгарган, «Яңа базар» дигән сатирик китап белән бүләкләнәчәк.*




---

## ЯХШЫ ДУС — ҖАН ЗИННӘТЕ

*Дуслык турында халкыбыз мәкальләре*

- Күңелсез кеше дус тапмас.
- Дус дустының этен дә дус күрер.
- Дустың дус булып калсын дисәң, аңа баш булма, иш бул.
- Корымнан корым йогар, начар дустан сөрем йогар.
- Кеше кеше белән дус булса да, кесә кесә белән дус түгел.
- Дус көлгәндә беленми, бөлгәндә беленә.
- Атаң-анаң — чын дустың, дус-ишләрең — юлдашың.
- Ялган дус — мәче: алдан ялый, арттан тырный.
- Яхшы кием — тән зиннәте, яхшы дус — җан зиннәте.

# МӘКАЛЬ ӨМӘСЕ

• Дөньяны тышкы матурлык түгел, эчке матурлык коткара.
• Хокуклар кечерәйгәндә, йодрыклар зурая.
• Арканнан котылган ат тышаулы ирекка дә риза.
• Илемнән колак кагыйм дисәң, килмешәкне түрә ит.
• Утлы күмерне көл саклый.
• Яман исем хужасын котырган эттәй талый.
• Хәрәмнән килгән байлык – жан суыручы сазлык.
• Орлык чәчелмәгән жирдә ачлык үсә.
• Алганда бурыч ярыкка да сыяр, кайтарганда өй түбәңне алып ташлап чыгар.
• Жинел акылны иң нык аяклар да күтәрә алмый.
• Зур авызлы хатынга зур кашыклы ир кирәк.
• Ялгызлык – кысыр болыт: юк янгыры, юк кояшы...
• Ялганчының күзен күр, мактанчыкның – өен.
• Явыз белән бал эчкәнче, яхшы белән таш күтәр.
• Шәрәне дә талыйлар.
• Судтан дөреслек тә курка.
• Жәйне жырлап ашаган көз кышны елап каршылый.
• Саран ярлыдан да ярлырак яши.
• Алкашның кояшы шешәдән чыгар.

Юныс САФИУЛЛИН

• Ура-патриотның баласы чит илдә яшәр, үзе лимузинда жилдерер.
• Адвокат жинаятьчедән фәрештә ясый, ләкин кеше ясый алмый.
• Жинүчеләр тарих яза, жинелүчеләр бәет чыгара.
• Корольне яраннары шәрә калдыра.
• Аллага «син», бәндәгә «сез», дип эндәшкән кавемнең жаны серледер.
• Иң хәтәр кеше – хәтерле кеше.

Газинур МОРАТ

• Китап – уй карабы.
• Яхшы атка ия кеше яманатка юл калдырмый.
• Комсызлык белән бәхетнең очрашуы икеле.
• Тигез түгел бәхет бизмәне.

Әлфия СИТДЫЙКОВА

• Буш башны югары йөртү авыр түгел.
• Дөньяның яме – хезмәтең тәме.
• Яхшы борын йодрыкны бер атна алдан сизә.
• Сертотмас үрдәккә балык үрнәк.
• Ир бала бишектән төшсә, күзе ишектә булыр.
• Чүлмәкчедән күрмәкче – балчыктан бау үрмәкче.

Әнәс ХӘСӘНОВ

*Сәхифәне* Рәфикъ ЮНЫС *әзерләде.*

# Яңа китаплар




**ТУФАН МИҢНУЛЛИН.**
*Казан: Татар.кит.нәшр., 2014. – 239 б. Тиражы – 3000 данә.*

Олуг язучыбыз, күренекле җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллинга багышланган затлы бизәлешле, зур күләмле китап-альбом дөнья күрде. Анда язучы-әдипнең үз әсәрләре, гомер юлыннан сәхифәләр бирелә. Мәшһүр шәхесебезнең замандашлары — дәүләт эшлеклеләре, сәясәтчеләр, язучы-шагыйрьләр, журналистлар һәм танылган артистларның кызыклы истәлек-хатирәләре бу китапның кабатланмас мәгънәсен замана биеклегенә күтәрә.

Әлеге альбом-китапның редколлегия төркеменә Разил Вәлиев (җаваплы мөхәррир), Рабит Батулла, Әзһәр Шакиров, Фәндәс Сафиуллин, Нәбирә Гыйматдинова, Дамир Шакиров кергән. Китапның төзүчесе — Марсель Галиев.




**«АЛТЫН СИНҖАП» («АЛТЫН ТИЕН»).**
*Әнкара: «Бәнгү» кит.нәшр., 2014. – 294 б.*

28 татар язучысының мәктәп яшендәге балаларга адресланган әсәрләре Төркиядә төрек телендә дөнья күрде. «Алтын тиен» («Алтын синҗап») дип аталган җыентыкны Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, тәрҗемәче Фатих Кутлу тәрҗемә иткән. Әлеге проект Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов тәкъдиме белән эшләнгән. Фатих Кутлу тәрҗемәсендә мәрхүм татар язучыларының балалар өчен иҗат иткән хикәяләре узган ел «Филдиши чакы» («Сөяк саплы пәке») исемле китапта дөнья күргән иде. «Алтын тиен» («Алтын синҗап») китабында исән язучыларыбызның әсәрләре урын алган. Җыентыкка өч әкият, егерме биш хикәя кергән. Әсәрләр рәсемнәр белән бирелгән. Авторларның тормыш юлы турында белешмә, электрон почта адреслары һәм фоторәсемнәре дә урнаштырылган. Китапка исемне хикәя атамалары арасыннан Фатих Кутлуның тугыз яшьлек кызы Равза сайлаган. Җыентыкка кереш сүзне күренекле төрек язучысы, прозаик, Мәхмүт Кашгарый исемендәге халыкара хикәяләр конкурсының жюри әгъзасы Осман Чәвиксой язган.

### МӘДӘНИЯТ ЕЛЫНА ЙОМГАК

Качалов исемендәге Зур рус драма театрында, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы коллегиясендә Мәдәният елына йомгак ясалды. Былтыр Казан төрки дөньяның мәдәни башкаласы буларак, халыкара форумнар, конференцияләр, бәйрәмнәр, бәйгеләр үзәгенә әверелде. Төрки илләрнең рухи кыйммәтләрен, бай мирасын саклау, пропагандалау максатында зур эш башкарылды. Болгар тарихи-археологик комплексының ЮНЕСКО карамагындагы объектлар исемлегенә кертелүе елның мөһим вакыйгасы, республикабызның зур җиңүе булды. ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллинның чыгышындагы саннарга караганда, 2014 елда республикабызда 51 бина төзелгән, 47 авыл клубы сафка бастырылган, федераль статуска ия булган һәм архитектура һәйкәлләре исемлегенә кертелгән 25 объект төзекләндерелгән. Җыелышта Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннеханов катнашты һәм чыгыш ясады. Ул мәдәният учреждениеләре җитәкчеләренә 44 җинел автомобильнең ачкычларын тапшырды. Мәдәниятне үстерү максатында районнар арасында барган бәйгедә беренче урынга һәм 500 мең сумлык сертификатка Тәтеш районы лаек булды. Икенче урында — Саба, өченче урында — Лаеш районнары. Әлеге чарада РФ мәдәният министры урынбасары Григорий Ивлиев та катнашты һәм чыгыш ясады.

ТР Мәдәният министрлыгының конференцияләр залында иң алдынгы коллективлар һәм хезмәткәрләр министр кулыннан грантлар алу бәхетенә иреште.

Мәдәният елының дәвамы булып 2015 — Әдәбият елы башланды.

### ТИНЧУРИН ТЕАТРЫНДА — «КАРА ПУЛАТ»

К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында «Кара пулат» опера-риваятенең премьерасы булды.

Тарихтан билгеле булганча, Кара пулат — Болгарда XIV гасыр урталарында төзелгән бина. Ул бүгенгә кадәр сакланган. Риваятьләргә караганда, Кара пулат Болгар ханлыгының хөкем итү урыны булган. Композитор Эльмир Низамов белән Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис әлеге әсәрне 12 кыз турындагы риваятькә нигезләнеп язган. Аксак Тимер гаскәрләре шәһри Болгарны яулаганда, 12 кызны кулга төшерә. Араларында хан кызы да була. Сугышчылар кызларны төрлечә кыерсыта, ләкин алар хан кызын сатмый. Аларны хөкем сараена ябып, ут төртәләр, әмма хан кызы янмый...

Әсәр туган илгә мәхәббәт, тугрылык турында. Авторлар әлеге операны Минтимер Шәймиев тәкъдимен күздә тотып язган. Аның режиссёры — РФнең атказанган сәнгать эшлеклесе, ТРның халык артисты Георгий Ковтун. Киемнәр рәссам Әсәл Исмәгыйлева эскизы буенча тегелгән.

### ТУКАЙГА ҺӘЙКӘЛ

Алабугада халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайга һәйкәл ачылды. Аны ачу тантанасында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, ТРның бала хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиле Гүзәл Удачина, Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Зөлфия Сөнгатуллина, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире Вахит Имамов һәм башкалар катнашты.

### ЮБИЛЕЙ

Татарстанда Әдәбият елы күренекле язучы Шәйхи Маннурның тууына 110 ел тулуга багышланган чаралар белән башланып китте. Юбилейны әдипнең туган ягы Мамадыш районында зурлап билгеләп үттеләр. Бәйрәм шәһәр үзәгендәге Ш.Маннур һәйкәленә чәчәкләр салу белән ачылды. Аннары язучының туган авылы Тулбайда дәвам итте. Анда Мәскәү, Казан, Чаллы, Түбән Камадан килгән кунаклар да катнашты. Алар әдипнең каберен зиярәт кылды, аның рухына дога багышлады. Кунаклар әдип турындагы истәлекләре белән уртаклашты.

Район мәдәният йортында үткәрелгән кичәгә бөтен районнан укытучылар, укучылар, китапханәчеләр, әдәбият сөючеләр җыелган иде. Кичә Шәйхи Маннурның тормыш юлын һәм иҗатын яктырткан, татар әдәбиятының киләчәге өчен борчылып,

1957 елны Хрущёвка язган хатына багышланган әдәби-музыкаль композиция белән башланды. Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Илнар Хафизов Ш.Маннур исемендәге премиянең яңа лауреатларын игълан итте. Быел ана Шәйхи Маннурның «Кояш, чык, чык!» китабын, А.С.Пушкинның татар теленә тәрҗемә ителгән әкиятләрен бастырып чыгарган өчен Татарстан китап нәшрияты (директоры — Дамир Шакиров), «Яшьлегем авазы» шигырьләр җыентыгы һәм Шәйхи аганың якташлары белән очрашулары вакытында төшергән фоторәсемнәре өчен җирле шагыйрь Рафаил Фәләхов, «Дастан «Чура Батыр» в творчестве тюркских народов», «Татарский эпос. Книжные дастаны» дигән китаплары өчен галимә Лилия Мөхәммәтҗанова (Ибраһимова), «Алай түгел, болай ул», «Ерып чыгарбыз» дип исемләнгән юмористик хикәяләр җыентыклары (икесе дә Татарстан китап нәшриятында басылды) өчен Илдар Хәйруллин, фронтовик-әдипнең иҗатын пропагандалавы өчен район үзәкләштерелгән китапханәләр системасы (директоры — Лилия Шәрифуллина) лаек булды.

Мамадыш районында үткәрелгән чараларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов, Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир Шакиров, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Илфак Ибраһимов, «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире Вахит Имамов, язучылар Зиннур Мансуров, Марсель Галиев, Шаһинур Мостафин (әдипнең мирас комиссиясе рәисе), Ринат Мөхәммәдиев, Рифат Җамал, Рашат Низами, Госман Гомәр, Хәсәен Вәлиәхмәтов, Рафаэль Газизов, Вәрис Гали, Амур Фәлах, Вахит Галиев һәм башкалар катнашты.

Шәйхи Маннурның тууына 110 ел тулуга багышланган кичә (сценарий авторы — Рәмис Аймәт) Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында да үткәрелде. Анда Берлек рәисе Рафис Корбанов, язучы Вакыйф Нуруллин, күренекле артистлар, нәфис сүз осталары чыгыш ясады. Кичәне Луара Шакирҗанова алып барды.

### ИСКӘ АЛУ КИЧӘСЕ

Мәскәүнең Журналистлар йортында күренекле шагыйрь, прозаик, драматург, тәрҗемәче Равил Бохараевны искә алу кичәсе үткәрелде. Анда Р.Бохараевның Санкт-Петербургтагы «Антрей» нәшриятында басылып чыккан яңа хезмәтләре — «Совецкие рассказы», «Письма в другую комнату», «История российского мусульманства. Беседы о северном исламе» китаплары тәкъдим ителде.

Кичәдә катнашу өчен, Лондоннан әдипнең хатыны, шагыйрә һәм фоторәссам Лидия Григорьева да кайткан иде. Аның укучыларга «Поэзия сновидений — стихи, которые приснились» китабы тәкъдим ителде. Лев Аннинский, Сергей Чуприлин, Борис Львович, Юрий Казаков шагыйрь турында истәлекләрен сөйләде.

24 гыйнварда Равил Бохараевның бакыйлыкка күчүенә 3 ел тулды. Ул Казанның Яңа Татар бистәсе зиратында әтисе белән янәшә җирләнде. Бу чорда Р.Бохараевны искә алу кичәләре күп кенә илләрдә һәм шәһәрләрдә, шул исәптән Лондонда, Парижда, халыкара поэзия фестивале кысаларында Грузиядә, ике тапкыр Казанда үткәрелде.

### «ТАТМЕДИА»ДА ЯҢА ҖИТӘКЧЕ

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннеханов Указы белән «Татмедиа» матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгының яңа җитәкчесе итеп Айрат Зарипов билгеләнде.

Агентлыкның элеккеге җитәкчесе Ирек Миңнәхмәтов «Татспиртпром» ААҖ генераль директоры итеп куелды.

### УТЫРЫШ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Анда ике утырыш арасында башкарылган эшкә хисап ясалды, Әдәбият елында каләм ияләренең хезмәтен стимуллаштыру максатында тәкъдимнәр каралды. Утырышта «Уен», «Сакау күке», «Ком сәгате» (Татарстан китап нәшрияты, 2010, 2005, 2000 еллар), «Игезәкләр йолдызлыгы» («Казан утлары», 9, 10нчы саннар, 2010 ел) романнары өчен Камил Кәримов, балалар өчен язылган «Рафис Корбанов шигырьләре» китабы (Татарстан китап нәшрияты, 2013 ел) өчен Рафис Корбанов Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә тәкъдим ителде.

2015 елның 20 гыйнварында Башкортстан Республикасының халык язучысы, пьесалары республикабыз театрларында да даими куелган драматург **Бүләков Флорид Миннемулла улы** 67нче яшендә Уфада вафат булды.

2015 елның 24 гыйнварында «Казан компрессор машиналары төзү» предприятиесенең элеккеге генераль директоры, техник фәннәр докторы, ТРның атказанган машина төзүчесе, СССР Министрлар Советы премиясе лауреаты, иҗат әһелләре, шул исәптән язучылар белән хезмәттәшлек иткән шәхес, журналыбызның якын дусты **Галиев Әхмәт Мөхетдин улы** 84нче яшендә вафат булды.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: роман-элегия К.КАРИМОВА «Жаворонки в облаках»; документальная повесть Р.САГДИ «Я один из твоих сыновей»; рассказ А.ХАЛИМА «И прозвучал гудок паровоза»; стихи Р.ИДИЯТУЛЛИНА, Р.ШАРИПОВА.
«В литературных объединениях»: стихи И.БИЕКТАУЛЫ, Г.САФИНА, Р.БАТТАЛА, А.НИЗАМОВОЙ, Г.ИСХАКОВОЙ с предисловием Р.БАТТАЛОВА.
«Искусство»: статьи Г.РАХИМА, Ф.НИЗАМОВОЙ, Р.ЗАЙДУЛЛЫ, Г.БАЙРАМОВОЙ, посвящённые 80-летию Ильгама ШАКИРОВА; статья А.ЗАРИПОВА, посвящённая 75-летию А.ШАКИРОВА; А.ШАКИРОВ. «Отец».
«100-я страница»: Х.БАДИГИ. «Нужна «Энциклопедия Джалиля».
«Доброе дело»: воспоминания Ф.БАТТАЛА.
«Память»: А.ШАМОВА. «Ваши судьбы связаны с огнём войны».
«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Белый парус»: стихи Р.ГАТАУЛЛИНА; рассказы Х.ИСМАГИЛОВА, Н.ВАЛИЕВОЙ; «Узнавайка».
«Пословицы XXI века».
Из фотоархива журнала. Рубрику ведёт Р.ФАЙЗУЛЛИН.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Ильгам». Работа художника Р.Вахитова; Сад-эрмитаж Казани. Фото Г.Хафизова.

## IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: novel-elegy by K.KARIMOV «Larks in the clouds»; documentary story by R.SAGDI «I am one of your sons»; story by A.HALIM «And the horn of the locomotive sounded»; poems by R.IDIYATULLIN, R.SHARIPOV.
«In literary associations»: poems by I.BIEKTAULY, G.SAFIN, R.BATTAL, A.NIZAMOVA, G.ISKHAKOVA with the foreword by R.BATTALOV.
«Art»: articles by G.RAHIM, F.NIZAMOVA, R.ZAYDULLA, G.BAYRAMOVA dedicated to the 80th anniversary of Ilgham SHAKIROV; article by A.ZARIPOV dedicated to the 75th anniversary of A.SHAKIROV; A.SHAKIROV. «Father».
«100th page»: H.BADIGI. «We need «Encyclopedia of Djalil».
«Good deed»: memories by F.BATTAL.
«Memory»: A.SHAMOVA. «Your fates are linked with the fire of war».
«Pages of humor»: section is led by M.GALIEV.
Pages from «Tatar encyclopedia».
«White Sail»: poems by R.GATAULLIN; stories by H.ISMAGILOV, N.VALIEVA; «Find-it-out».
«Proverbs of the XXI century».
From the photo archives of the magazine. Section is led by R.FAYZULLIN.
Diary of the social-cultural life.
On our covers: «Ilgham». Work by artist R.Vahitov; Garden-Hermitage of Kazan. Photo by G.Hafizov.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Илһам». *Рәссам* ***Рифкат Вахитов*** *эше.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Казанның Эрмитаж бакчасы. ***Газинур Хафизов*** *фотосы.*




*Икенче бөтендөнья сугышы тәмамлануга 40 ел тулу уңаеннан сугышта катнашкан бер төркем язучылар Тукай клубында җыелган.*
*Беренче рәт (сулдан уңга): Нури Арслан, Газиз Иделле, Мөхәммәт Садри, Риза Ишморат, Әхмәт Исхак, Гариф Галиев, Хатыйп Госман, Салих Баттал;*
*икенче рәт: Шамил Шаһгали, Әмирхан Еники, Мөнир Мазунов, Мәхмүт Хөсәен, Ибраһим Нуруллин, Атилла Расих, Сафа Сабиров, Әбрар Кәримуллин,*
*Баян Гыйззәт; өченче рәт: Нәби Дәүли, Сәет Шәкүров, Әдип Маликов, Кави Латыйп, Мәгъсүм Насыйбуллин. 1985 ел.*

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

2015
Парклар һәм
Скверлар елы



Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)